ISSN 0206–4189
Индекс 73210
12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.2015



№12 (1118) 2015

# «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ – БӨТЕНРОССИЯ КОНКУРСЫНДА ҖИҢҮЧЕ




«Казан утлары» журналы Татарстан Республикасы «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Журналистлар берлеге тарафыннан үткәрелгән «Многоликая Россия – 2015» Бөтенроссия ачык журналистика конкурсының «Матбугат басмаларында патриотизм һәм туган якка мәхәббәт хисләре тәрбияләү турында язмалар сериясе» номинациясендә I урынны алды.

# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Илаһилык вә даһилык. *Шигъри дастан* ....... 3
Вахит ИМАМОВ. Сөләйман солтан. *Тарихи роман* ....... 15
Рүзәл МӨХӘММӘТША. Җанга төшә авыр күләгән. *Шигырьләр* ....... 61
Зөлфәт ХӘКИМ. Газап. *Бәян* ....... 64
Гөлнур АЙЗАТ. Тормыш бит ул — мизгел генә. *Шигырьләр* ....... 127
*100 нче бит:* Газинур МОРАТ. Балалар әдәбияты ник үги? ....... 100

ЮБИЛЕЙЛАР

Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ. Ике даһи дуслыгы. *(Хәсән Туфанның тууына 115 ел)* ....... 132
Мостай КӘРИМ. *Шигырьләр* ....... 139
Хәсән ТУФАН. *Шигырьләр* ....... 140
Нурмөхәммәт ХИСАМОВ. Милләт гаме белән янып ....... 143

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Рашат НИЗАМИ. Поэма белән очрашу ....... 145

ФӘН

Зәрия ХӘБИПОВА. Бер легенда эзеннән ....... 150

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. Чын Тукай өчен көрәшеп... ....... 157

ЯҢА ИСЕМНӘР

Самия ТИМЕРБАЕВА. Күңелемне сагыш биләде. *Шигырьләр* ....... 160
Рәмзия ӘХМӘТОВА. Җаным — шигырь, күңел — моң... *Шигырьләр* ....... 162

ХӘТЕР

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Җыр дәвам итә. *Очерк* ....... 164
Рәфикъ ЮНЫС. Сез һаман бергә икән?! ....... 172

2016 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. *Абдулла ДУБИН әзерләде* ....... 175

АК ҖИЛКӘН

Нәҗибә САФИНА. Кем казый? Сәнәгати сәнгать. Балачак хатирәләре ....... 176
Хикәя яза аласызмы? ....... 179
«Танымыш» дәресе ....... 181

ШАЯН СӘХИФӘ

Уены-чыны бергә. Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде ....... 182

2015 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге ....... 184
«Казан утлары» архивыннан ....... 130
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ....... 190

ТМ татмедиа

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (өст. 1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст. 1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст. 1268).*
**Факс** — (843) *222-09-83 (өст. 1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 26.11.2015, график буенча 26.11.2015.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-3399. Тираж 4010.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2015 ел



Флёра Гыйззәтуллина

# ИЛАҺИЛЫК ВӘ ДАҺИЛЫК

ШИГЪРИ ДАСТАН

*Күренекле татар галиме һәм әдибе*
*Гали Рәхимгә багышлана*

## 1. Гыйлем елы — кояш елы быел...

*Ватаныбыз елъязмасында һичкайчан даны тоныкланмый торган, киләчәк буыннар хәтерендә мәңгегә сакланачак тарихи вакыйгалар байтак. Җиңү көне ата-бабаларыбыз шөһрәтен тагын да арттырды, милли горурлык һәм чиксез рәхмәт хисләре, йөрәк әрнүе һәм мәңгелек хәтер символына әйләнде. Татарстанның ул һәм кызлары — туган илебезне фашизмнан азат итү өчен гомерен корбан итүчеләрнең тиңдәшсез батырлыкларын бәйрәм көнендә олы хөрмәт белән искә алабыз. Фронтта һәм тылда каһарманнарча, фидакарьлек һәм ныклык белән, үзегезне аямыйча көрәшүегез беркайчан да онытылмаячак!*

*Ихтирам белән, Р.Н.Миңнеханов*
(Ватандашларны Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгы белән котлау хатларыннан.)

**Рәхмәтлегә мең рәхмәтем төшсен!**

...Аяз күкле ай тарагы белән
Үзем тарих ялын тарап торам,
Ихтирамлы ихлас Миннеханга:
— Рәхмәт, Илбашыбыз! — дияр өчен,
Аркасыннан бәплән сөяр өчен,
Кояш чыгышына карап торам.
Безнең өчен Кояшка тиң бит ул
Падишаһлар язган котлы хатлар.
Ихлас сүздән тоныклана хәтта
Кояштагы күләгәле таплар.
Күләгәсез, бер кайгысыз гына
Узмый берәүнең дә гомер юлы.
Сугыш чыккан көннәрдә мин
сабый идем,
Хәзер инде кояшланган сугыш толы.

Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА – *шагыйрә; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. «Йөрәгемдә шаулый карурман», «Күз нурларым», «Башкаемда дөнья исәпләре» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Сугышның мин ач-ялангач ятимәсе,
Туган илдән тибелгәне, сөрелгәне...
Газиз әткәм яулап алган җиңүләргә
Ап-ак чәчле кылган булып сибелгәне.
Аяк сөртеп, таптап изеп үтсәләр дә,
Кылган аһын берәүгә дә мин ачмадым.
Адашканда, кешеләрдән юл сораштым,
Бер тапкыр да ләкин хәер сорашмадым.
Соранмаган, теләнмәгәнгәме, —
Миңа бушлай берни бирмәделәр:
«Тумышыңа яраклаша белмәс
Үксез бозау — Син!!!» — дип тиргәделәр.
Ә үзләре, туган көннәр ясап,
Һәр ел саен шатлык бүлештеләр:
Мин җөйләгән күлмәкләрен котлап
Кочаклашып кат-кат үбештеләр.

***

...Әйе ...Бозау!!! Болын бозавы мин!
Утлыйм җирдән яшел чирәм кыркып.
Өемә дә кайтмый йөрим менә,
Ирем белән үбешүдән куркып.
Куркып йөрим һәрбер эчүчедән:
Шигыремне мактап акча сорар
Әйләнәмнән янә бер урар да
Сөйгәнемне бәхетләгә юрар:
— Бер булса да, бир, кулыңны үбим,
— Син бик мәрхәмәтле хатын... — дияр...
Мәрхәмәтлелегем чын булса да,
Оялудан дөнья башынияр.
Һәм чәрелтәр заман фахишәсе:
— Төкерегез шуның дөньясына!!!
Дөнья тулып ятим үрчегәндә,
Бу төкерек җитмәс кем башына.
Кемнән күреп, кем азынмас тагын
Әзер яз шатлыгы даулап бездән?
Мин ятимнәр токымыннан, әйе...
Һәм төшенәм моны һәрбер сүздән.
Һәрнәрсәгә мин куркынып карыйм,
Сөеп карау миңа ярамаган.
Шагыйрьләрне язмыш тумыштан ук
Ярамаулар белән яралаган.

## 2. Җир йөзенә кояш көн дә чыга

*Язгы көнгә карап булмый туры:*
*Күзне чагылдыра кояш нуры.*
*Ирек җырын йота металл җыры:*
*Илдә гигант төзелешләр чоры!*

Гыйлем елы, быел җиңү елы:
Ачыш көткән омтылышлар олы!..
Зурлык, олылыкка өнди чорны
Таңда томшык кайрар фән былбылы.

Фән былбылы — илнен гали улы
Яла афәтенә эзли дәва,
Ничә гасыр шул дәвага сусап,
Күзләренә анын гавам бага.
Бага ана изге Кол Шәрифләр
Канда бакыйлашкан утлар аша.
Шушы утлар кылкаләмдә тибрәп,
Гыйльми чиксезлеккә юллар ача.
Күз күреме жетеләнсен өчен,
Галим гыйлем белән тәрәкләнә.
Гыйлемленен һәрбер хәрәкәте
Кояш калфагында сурәтләнә.
Шуна күрә тоткарланып калмый,
Жир йөзенә кояш көн дә чыга:
— Бер-берегезгә терәк булыгыз!.. — дип, —
Хозурланып икмәк урыгыз!.. — дип,
Халыкка ул ай урагын суза.
Кояш төсле сабый бала суза,
Мәхәббәтен сина чиксезлектән...
Сыкрый галим: сабый чагыннан ук
Без кочәсе дөнья ник өзлеккән?!
Мәрхәмәтле, унган жир хужасын
Яла ягып ник чор кыерлаган?
Илнен бураznaга түккән тирен
Жир шарымы әллә сыйдырмаган?
Гыйльми гавам юлыкканмы әллә
Үрә каткан ташлык гасырына? —
Чал гасырлар хәерхаһлык даулап
Муеннарга безнен асылына.
Асылына көнләп кан-дошманын
Бер гөнаһсыз сөю назларыннан.
Бу назларны тәрбияләр өчен,
Тел фәнендә азмы казганылган?!
Бу әрнешле, үкенечле хисләр —
Безнен бакыйлашкан сөргендәшләр! —
Алар инде безнен тел нужасын
Каурый-канатларга индермәсләр.
Тармак-тармак тарих сабаклары
Ирек бирмәс илгә тынычларга...
Без хәзер дә япан-кырга чыксак,
Абынабыз тутык кылычларга.
Чагылабыз кәлтә, еланнардан,
Хөсетледән,
Сатлык,
Ялагайдан.
«Сукыр тәкә» кочып гөрли, әнә,
Ялагайлар ачкан яна мәйдан!
Шагыйрьләргә гыйлем мөнбәреннән
Күкрәк кагып сөйли «укымышлы»:
— Хәзер илдә ин почётлы уен —
«Сукыр тәкә» белән «Күз йомышлы!»
Сукыр суфи кояшка күз салмый,
Дөнья йөген илгә йөкләп алмый.

Гасырларга йомгак ясаганда,
Ул бары тик «суфлёр» гына яллый.
Сугыш чорларында бу уенны
Без дә бик яратып уйный идек,
«Хәрам уен» качкыннарын тотсак,
Сугыш туктар диеп уйлый идек.
Без кичергән сугыш туктады ул —
Үргә сузып кояш ызаннарын.
Тик мин хәтерләмим берәүнең дә:
«Һай, ятим!» — дип мине кызганганын.
Үги әнием дә — сугыш толы!
«Балам...» — дип, ул безгә эндәшмәде.
Кояш елы белән саный калсак,
Димәк, ятимә мин мең яшьтәге.
Сугыш турындагы шигырьләрнең
Берәүгә дә, димәк, кирәге юк.
Әткәм печән чапкан аланнарның
чия,
        бөрлегәне,
                        җиләге юк!
Йөгерә-йөгерә илдә җиләк җыйган
Мусалар да, димәк, онытылган?!
Гыльми нур чәчүче шигърияткә
Буйдан-буйга «юклык» моңы тулган.
Ләкин әле минем әткәм җиккән
Тимеркүкләр, Көрәнкүкләр исән!
Алар мине таныр, бер Илаһка
Шөкер укып үрдән башым исәм.
...Елъязмалар, әйе, тоныкланмый,
Ачсаң исәннәрнең хәтер күзен...
Хистә-кыякланды, тоякланды
Хәтерсезгә минем әйтер сүзем.
Әле дә минем канда кайнап әрни
Дәвамнары Ватан сугышының...
Шигърияткә йөрәк каным түгеп,
Кынын эзлим мин җыр кылычымның.
Шул тиклем дә ардым, йончыдым мин
Язып үз-үземне җәзалаудан,
Тирән картлыгымнан файдаланып,
Уттан-утка салган казалардан.
Казаланып, гел сызланып яшәү
Оят та кебек... Инде куркыныч та...
Тынычланыр идем,
                        шигъриятттә
Лаек хужа тапсам шул «кылычка».

**Халкыбызның гали улы**

*Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында татар филологиясе, тарихы, сәнгатендә бай мирас калдырган мәшһүр галим Гали Рәхимне, иҗатын һәм фәнни эшчәнлеген югары бәяләп, искә алу мәрәсиме булды. Бу чара галимнең рәссам Айдар Хисамов эшләгән яңа портретын тәкъдим итүгә бәйле рәвештә узды. Бертуган рәссамнар Айдар һәм Нияз Хисамовларның иҗаты институт галимнәренә яхшы таныш. Алар татар халкының мәшһүр шәхесләрен үз иҗатларында әледән-әле җанландырып тора. Гали Рәхим портреты да шушы галерееяне тагын бер шәхескә баетты.*

Илсөяр Закирова,
филология фәннәре докторы

## 3. Татар — гали халык, галим халык

**Сугарылу**

...Кылычлардан үткен, кылдан нечкә
Меңәрләгән гамь сираты сузып,
Меңьеллыклар чиксезлеген узып,
Гыйльми гавам галәми мон гизә.
Милли сабырлыкта моң сугарып,
Күк йөзендә яралы ай йөзә.
Көне-төне бер ялгыз эт шыңшый
Кисеп аударылган манарада...
Ялгызлык ул шыңшып, үксеп үрчи,
Эт кыяфәтендә ярала да,
Ә замана көн дә бәйрәм итә,
«Эт сөяккә барган» көйне көйләп.
...Шушы көйме, сугыш батырына
Җиңү көнне теләнәчәк теләк?!
Шушы көйме, илне сөрген сөргән
Зинданчының «сөйкем сөятмәге?!»
...Эт котырса, колны чәйнәп ата
Идел ярларында аунап ята
Эттән калган адәм сөякләре.
Шул ук ярдан кайта җиңү язы,
Тукай язы белән култыклашып...
Назлы яз шатлыгы беркайчан да
Йөрми инбашына мылтык асып.
Әмма татар халкын бу йола да
Коткаралмый яла бәласеннән... —
Шул хаклыкка бәя отты Гали
Рәсеменә баккан мәрәсимнән.
Айдар ижат иткән ай сукмагы
Күтәрелде өскә, югарыга!
Шушы югарылык исәп салды
Бүген минем хәтер диварыма.
Элдем шунда аның портретын,
Ак чалмалы алтын кадак кагып,
Ирек вәгъдә иткән хакыйкатьнең
Иң тотрыклы умырткасын табып.

***

...Сөяк сәясәтен алга сөреп,
Тапкан урталыгың читләп йөреп,

Тәре үбеп хыянәткә керсәң,
Көтәр көнең караңгылык баса.
Кайберәүләр көн күрүдән өркеп,
Коточыргыч ят йолага беркеп,
Шул караңгылыкка кереп кача.
Сукырая, чукраклана шундук,
Онытa нәсел-затын, Илаһ хакын —
Сыендырып назлы кочагына
Кан-дошманын, илнең җиде ятын.
Ә җиде ят егып көчли сине,
Басынкыга салып бар тапканың.
Көткән дөньяң эчтән шәмдәй сыза,
Бармак белән басканга да сына,
Умырткасы зәгыйфь, тар арканың.
Иң элгәре шулай эчкә үтеп,
Гыйльмияткә, хискә һөҗүм итеп,
Үч кайтара тарих хыянәте.
...Динле, тәһарәтле ак өммәткә
Каян килгән соң ул...
Каян килгән
Мондый хыянәтләр кыямәте?
Эт өстереп үзен талаттырган,
Теле белән канын ялаттырган,
Бар иреген көчләп тарайттырган
Басымчакны татар яратканмы?
Ятамы ул әллә умырткасын
Һаман бер якка да боралмыйча,
Хурлык ятагыннан торалмыйча?..
Ник соң үрсәләнә минем халкым,
Рухи тарлавыктан чыгалмыйча?!
Нигә илнең мәшһүр галименә
Олау-олау яла өйгәннәр?..
Галим генәме соң?.. Ул иң затлы
Рәхим атлы гали пәйгамбәр!
Ул зәвыклы, сабыр, мәртәбәле,
Мал-мөлкәтле тырыш токымнан.
Гомере зинданнарда йотылганда,
Хәләл мөлкәт утка тотылган.
Пәйгамбәрлек дәрәҗәсен исә
Көн дә җиргә салып таптаганнар:
... Ярый әле үзен атмаганнар,
Кыйнап сынау өчен саклаганнар...

## 4. Җан ачысы

*...Таң сызыла...*
*Сызылып аткан таңдай*
*Талгын гына яктырыла хәтер.*
*Казан урамнарын урап үтсәң,*
*Гасырларга гавам гамен түксәң,*
*Гасыр сакчылары ни дип әйтер?*

***

...Телсез, өнсез, денсез ул сакчылар
Берни әйтә алмый ачыктан...

Чөнки залим ата алардан да
Гасыр буе мәет ташыткан.
Илнең гомер гөле, гыйлем гөле
Шытып чыккан шәйгә йолкынган.
Өр-яңадан кан хәвефе аңкый
Коллык ачкан шәхес культыннан.
Жанга курку салган һәр очкыннан
Күтәрелә тарих сөреме.
...Инри галимнәрнең жан ачысы:
— Тереме син, Вөждан,
үлеме?!
— Кая китте безнең гыйльми шөһрәт?..
— Мәртәбәле, данлы исемнәр?..
Сугыш ача Рухка
исемнәрен
Фәннән сызып аткан жисемнәр.
Сугыш ача тәкать жуйган сөю:
Сүзнең нахагыннан, хагыннан...
Мәхәббәт тә, шигърият тә, әнә,
Кара пәрәнжәсен ябынган...

***

Гыйльми нурга төбәлгән күз күрә:
Кяфер айга хәтәр тозак үрә.
Кем язса да, шул тозакка каба
Фәнгә ялганасы шигъри сүрә.
Бүгенгәчә күренми дә кебек
Бу афәттән илнең чыгар юлы...
Тәреленең барлык гөнаһ-шомлыкларын
Каплап тора базар чыбылдыгы.
...Вөждан ярасында базар басып,
Рухи кыйммәт белән сатулашып,
Тулган айга туры юл откannar
сугыш,
сөрген,
яла сәясәтен
Онытканнар инде... онытканнар.
Шагыйрьләрнең хаерчелеге дә
Алыпсатар өчен хурлык, көлке!..
..............................................................
...Шигърият ул — гыйльмиятнең күрке,
Түгел хакын жуйган базар милке.
Алда торган күрәчәккә күкрәк терәп,
Чор офыгын галим һәрчак түрдән ача.
Уйлы башын уйландырып, сызландырып,
Язларга ул чәчәк ташый үрләр аша.
Яз жырыннан гөл ясый ул,
тел ясый ул,
Каурый-канат ясый очар лачыннарга.
Кирәк булса, пар атларын жигеп бирә
Яз аенда кыз ярәшкән асыл ярга.
Тукай моңын чор моңына тиңләштерә
Пар атларга көмеш йөгән кидертүче.
Шигъри тояк таушы белән сугарылып,
Ил өстендә тибри ГЭСлар гөрелтесе.

Янгырап тора боерыкларның иләмсезе:
— Олауларга!!!
— Олауларга!!!
— Олауларга!!!
Галимнәрне көрәштәш һәм үрдәш күреп,
Тел озайткан шагыйрьләрне богауларга!!!

***

...Ул чордагы богау зынҗырыннан
хәтта
Кубарылган, диләр, кара гүрдәгеләр!
Зиндан кичеп дәррәү гүргә кергәннәрне
Сугыш беткәч гаепләде түрдәгеләр.
Сугыш чоры, зиндан чоры ил түренә
Шагыйрен дә, галимен дә сыйдырмады.
Иман шартын, вөждан шартын төгәл үтәп,
Берәүнең дә җеназасын җыйдырмады.
Сабырлыгын исбат итәр өчен, татар
Идел өсләренә күпер булып ятты.
Кыйбла уйган ирегенә дәвам көтеп,
Шигърияте галәм күзләренә бакты.

## 5. Вәхшилек

*Ә гасырлар төптән набат суга һаман:*
*— Камышландык кара кайгыдан! — дип, —*
*Илдә коллык ачкан явыз Иван*
*Әҗәл хастасыннан айныган! — дип...*
*...Бу кайгыны инкарь итеп булмый:*
*Тарих сүзе — тере күзәнәк!..*
*Чынбарлыктан беребез тайпылса да,*
*Тарихчыга ява йөз әләк...*

Бу камышлар, бу сагышлар Илнең
Һәр күзәнәгендә чайкаладыр.
Чайпалышлы дәрьялардан хисап алсаң,
Шәһри Казан күз-яшьләргә бай каладыр.
Бай каладыр шагыйрьләргә, галимнәргә,
Таш диварлы биек гыйлем йортларына.

..........................................................................

...Кем җаваплы бүген шул йортларның,
Ничә еллар буе эчтән тынып,
Тере тәмуг уты йотканына?!

***

...Бу тәмугка кяфер иҗат иткән
Вәхшилекнең бөтен төре сыйган.
Ирек даулап бәргәләнә шунда
Көчләп чукындырган вәгъдә — иман.
Яный шуннан яла сәясәте,
Галәм түбәсеннән дарлар асып:
«Татар — кара,
надан,
яман,
ялкау,
Игелексез...» — дигән гайбәт ташып.

Дүрт-биш гасыр буе бинахактан
Бәгырьләргә төшкән шушы гайбәт
Туксан тәмуг гизгән татар халкын
Һәлакәткә таба бара әйдәп.
Һәм Гали дә, шул тарафка карап,
Чоңгылына чумган уйларының,
Күзләренә сагышлары тулган
Уздыралмый калган туйларының.

## 6. Моңсулык

*Шигырь — минем язмыш җырым,*
*Буразналы маңгай сырым!*
*Таш атмагыз, маңгаема —*
*Язмышыма карап кырын!*
*...Сөрген сөргән юл читенә*
*Кылган чәчеп кыл урганда,*
*Минем дә бит ак өметем*
*Беркетелгән турбиннарга...*

...Коллык, толлык фаҗигасе илнең
Инде йөзгә, меңгә түнтәрелгән.
Коллыгыма хисап бирер өчен,
Толлык төпкеленнән күтәреләм.
Күтәреләм Тукай бакчасына
Чәчәк түтәлләре арасыннан.
Иделләрдәй сагыш түгелер сыман
Таш Тукайның моңсу карашыннан.

***

...Шушы моңсулыкмы, телгә килеп:
«Су сибәргә онытканнар...» — диде...
Балкып торган җәйге эсселектән
Чәчәкләр дә сулыкканнар иде.
Шешә җыйган ир затыннан битәр
Чалынучы да булмады күзгә...
Мин үзем дә һич көтмәгән идем
«Сәрхуш» белән килермен дип сүзгә.
«Ачу — алдан, акыл арттан», — диеп
Әйтмәгән шул халык тикмәгә.
Утлы фонтан кебек күкрәгемнән
Бәреп чыкты үч тә, үпкә дә.
Һәм ташландым ана зәһәр чәчеп:
— Ерак йөр! — дип, — сәрхуш, Тукайдан!!!
Ул ялварды:
— Бик сусадым, апа!
Табыйм икән эчәр су кайдан?..
Иреннәре аның чатнап кипкән,
Кул чуклары канап ярылган.
Шешә җене кагылганга микән,
Күзләренә томан сарылган.

***

...Шул томанга кереп чикләндемме —
Сорамадым атын, исемен...

Исемнәре, хәер, булмыйдыр да
Шешә җыеп йөргән кешенең.
Ихтимал, ул эчә-яна торгач,
Күптән оныткандыр кемлеген...
Йотса-йота... Әмма хисап тотмый
Шешә эчендәге җен бүген.
Яз килсә дә, якын киләчәкнең
Яктылыгы никтер күренми.
Күз яшьләре юкка түгелми ул,
Килмәс борын, язлар сүрелми...
Котып җилләре дә котырынмый,
Югалтулар кыйммәт тормаса.
...Үз-үземне эзләп менә мин дә
Томан гизәм ничә чор аша!..
Сабый чактан
Мин әнкәйне эзлим,
Газиз әткәемне эзлим мин...
Йөрәгемдә упкын хасил иткән
Ике ут арасын күзлим мин.
Мин сугышам котып җиле белән:
— Талама! — дип, — илне,
талама!!
Дөрләп янган ут азыгы ич ул —
Таланудан калган алама.
Ятимлек тә — Утка сипкән бензин:
Януларга чама гына юк.
...Ятимнәр күп...
Әмма башларыннан
Сыйпап куяр Ана гына юк.
Ятимнәрнең шагыйрьләре дә бар,
Җырчылары, көйчеләре дә.
Рухи, милли көчне астан кимереп
Симерүче күселәре дә...
Андыйлар да «яну» ярышында
Үзен тиң дип саный Тукайга.
Язмыш безне төрле яклап сыный
Бөек Тукай туган бу айда.
Эшләнмәгән эшләр, ятим хисләр
Куа безне утлы упкынга —
Җанга әрнеш салган убыр-утның
Нindиләре генә юк монда!

## 7. Безнең хәерчелек

...Елдан-елга тирәнәя, әйе,
Аракыдан алган яралар...
Яра ялап, кан косканың өчен
Кем түләсен сиңа гонорар!
Түләнмәде! Исәп-хисапсызга
Бай да, хәерче дә — бер аңа!
Гөлбакчалы юл өстендә, әнә:
Хәер өстәп тора бер Ана!..
Шешә җыючының әнкәсе ул! —
Куа һаман бала нужасын.
Үзең ана кеше була торып
Ничек аны читләп узасың!

Без бит сугыш чоры балалары:
Йөкләп алдык барын йөрәккә.
Безне күрсә, шешә эчендәге
Жен дә әверелә өрәккә.
Гөлчәчәкле бакча юллары да
Тоташтыра кайчак ГУЛАГка...
Минем жанда утызынчы елның
Өрәкләрен ГУЛАГ улата.

***

...Күкрәк читлегеннән чыгып качмый —
Мин бит шагыйрь!.. — Минем жан чыдам...
Үксеп елаганда, нибарысы
Кан саркыла каеш камчыдан.
Палач балтасыннан нибарысы
Башым гына минем чабылган!..
Башсыз гәүдәм баш калкыта, әнә,
Жир шарының төрле ягыннан.
Баш калкыта шуннан Мөжәй, Муса,
Фатих Кәрим, Гали Рәхимнәр...
Башсыз, ихтыярсыз калган өчен
Алар бәлки безне бәхилләр!
Бәлки без бергәләп арынырбыз
Ошбу хәерчелек кереннән...

...............................................................

...Сөйли Ана:
— Гөлдәй бу Жиһан, — дип, —
Инде ничә үлеп терелгән!
Ана телен, шигъри телебезне
Инде ничә тапкыр кискәннәр...
Язмыш ярын кочкан шигырьләр дә,
Гомерләр дә жилдәй искәннәр.

***

Әйе... әле күптән түгел генә
Ул шагыйрә иде ләбаса!
Хәзер исә шешә жыючының
Бакыр тиеннәрен санаша.
Түбәнсенә, мескенләнә бәгырь:
Алла хакы өчен бир, жаным?!.
Йөз-меңнәрен биреп көйләсәң дә,
Көен тапмас ла ул дөньяның.
Эт өстереп кусалар да китмәс:
Янар шушы жилле тәмугта...
Чөнки ул да котып жилләренә
Улын: «Тукаев!» — дип таныта.
— Иң талантлы шагыйрь, — ди ул аны, —
Бар, — ди, — калын-калын томнары.
Әмма торак-йортсыз калгач кына
Сыгылып төште зифа сыннары...
Ю-у-ук, — ди, — эчми тиен акчасын да,
Бик намуслы аек бала ул...
Шешә саткан акчасына бары
Кәгазь-каләм генә ала ул...

***

Димәк, шөкер! Шагыйранә алма
Агачыннан ерак төшмәгән?
Халкы аракыдан көчләнгәндә,
Дөнья гына әллә нишләгән.
Милли рухлы азатлыгын гына
Ватан саклап кала алмаган.
Шуңа күрә каләм ияләрен
Котып салкыннары ялмаган.
Мәхәббәт тә җуйган
Шигърияттән
Отып алган сөю аһәңен.
Күнелләр дә, Иделләр дә корый,
Йолкып атсаң илһам чәчәген.
Шигърияте Илнең таркатылса,
Даны, иманы да сүсәрә.
Сүсәрү ул — үзәк тамырынны
Өзелүгә иткән ишарә.

***

Миндәй ятим-җилпе, өзгәләнеп,
Өзлегүен кемгә сөйләсен!
...Юк, сөйләмим, халкым: «Сабырлыгы
Сынган икән моның...» — димәсен.
Бүтәннәр дә түзсен гыйбрәт алып
Шушы шешә җыйган егеттән...
Шешә сатып китап чыгарса да,
Ул бит өзелмәгән өметтән.
Әнкәсе дә кулын сузган килеш
Баскан урыныннан купмаган.
Шигърияткә охшаш чал Ананың
Тик йөрәге генә туктаган.
Һәм Тукайга илткән юллар гына
Әверелгән җитмеш чатлыга...
Сайлап алган көрәш максатына
Һәркем үз юлыннан атлыга.
Үз язмышын һәркем үзе яза,
Үз кояшын үзе тудыра.
Күпме тапталса да
тапланмаган
Борынгыдан килгән бу йола.
Имин чорда җиңү көнен көтеп
Ләкин күпме генә котайма —
Шигъриятне корткан хәерчелек
Ягылып кала бөек Тукайга.
Зиндан аһына тиң бу афәттән
Отмый кем дә вөждан хөрлеге.
Хәрам көчкә нәфрәт атып дөрли
Шигъриятнең сынык өрлеге...

*(Дәвамы бар)*

Вахит
Имамов

# СӨЛӘЙМАН СОЛТАН

ТАРИХИ РОМАН

23

— Баш вәзир галиҗәнапләре вафат булган, — дигән хәбәрне Сөләйман көтте дә, көтмәде дә сыман. Солтан аның әллә ничә сырхау белән газап чигүен күптән белә иде. Хәтта Хүррәмнең кайчакларда, төртеп уяткан шикелле: «Баш вәзиреннең мыштыр-мыштыр атлап йөрүеннән тавыклар да көлә», — дип чәнечкәләп алуларына да гадәтләнгән иде. Ә бүген, менә, ул да уйга калган, сагышланган сыман. Күнеленнән солтанның уй-ниятләрен бүлешәдер, бәлки.

— Баш вәзир урынына Ибраһимнан да кулайрак кеше табылмастыр инде, — дип нәкъ менә Хүррәм, үзе башлап, аның уен бүлде. — Мин сиңа Ибраһимнан да ныграк ирелгән башка бер кешене дә белмим. Ибраһим — киявең бит, һичкем гаепләмәс.

Сөләйман күләгә шикелле аваз бирми торгач, сак кына кыйланып, янә пышылдады.

— Ибраһим — әүлия шикелле, синең тәхетеңә дә, данына да тыкшыначак түгел. Иң авыр йомышларга аны җибәрерсең. Син солтан бит, тәхеттә утырган килеш кенә фәрман бирүең дә бик-бик җиткән.

Сөләйманның җавабы катгыйрак һәм усал яңгырады.

— Шәйхелислам белән Мөхәммәдияр казый искә төшерделәр. Чыңгызханга да берзаманны шундый чамадагы тәкъдимнәрне ясаганнар икән. Ә ул кырт кистереп кенә җавап биргән. «Атка менеп йөзәрләгән илләр яулап алу мөмкин, әмма бер ил белән дә ияр өстендә утырган килеш кенә идарә итеп булмый». Юк, һәрбер җиргә үзең өлгермичә, үз эзеңне калдырмыйча булмый, җаныкаем.

Шулай да, атна буе үлчәп йөргәннән соң Сөләйман Ибраһимны хозурына дәште. Әллә куркып калды, ул Сөләйманның тәкъдименә шундук каршы төште.

— Син мине биек баскычларга үрләттермә, зинһар. Биектән мәтәлеп төшкән бәндәнең гәүдәсе бик нык ватыла ул. Әле күп вакытта үзенең исән калуы да бик икеле. Кирәк булсам, янында йомышчы итеп куллан. Мохтаҗ туса, сәрдәрең дә, җансакчың да булам. Тик, зинһар, мине дәүләт эшләренә җигеп, сарай корты ясап газаплама. Синең белән дистә еллар буе янәшә яшәсәм дә, мин чит-ят кавем улы, төрекләрнең җанын-бәгырен дә, хәйлә-мәкерен дә тоз-борычлар ялап кына аңлаячак түгел.

— Тик барыбер мин сине баш вәзирем итеп куячакмын, — дип Сөләйман бер адым да артка чигенмәде. — Үземнең дә синнән якынрак аркадашларым юк, Хүррәм дә сине генә куюны таләп итә.

Солтан-ханымның исеме яңгырагач, Ибраһим да башкача эндәшмәде. Язмыштан узмыш юк, дигәннәре чынында да хактыр.

*Дәвамы. Башы узган санда.*

## 24

Сөләйман солтан мең биш йөз дә утыз икенче елның ахырында Сәхибгәрәй тарафына карап күзен ачты бугай. Казанны ташлап качкан тәж иясен ул тәлинкәсен яларга өйрәткән сукыр песи баласыдай кулына ияләштерде дә, башлы-күзле булып алган улын нигез-йорт җиткереп башка чыгаручы юмарт атай кыяфәте белән, Бакчасарай тәхетенә утыртып та куйды. Шул хактагы сөенечне ишетеп алуга ук Сафагәрәй, канатланып, гамуҗа агасы хозурына очты. Сигез ел буена берсен-берсе белешмәгән ике туган, билгеле ки, кочаклашып күрештеләр. Сафагәрәй — кичәге агасы шикелле үк, тәхетеннән сөрелеп чит-ят йорт капкасы алдында хуҗалар ташлаган сөяк сыныкларын ялап яткан сукбай. Анын рәнҗү хисләре усал төйнәлгән йодрыгына сыеп бетә алмый, күзләреннән ачы тамчы булып сытылды да чыкты.

— Мине тәхетемнән куып җибәрделәр. Тамырыннан йолкынып, ялан кырда тәгәрәп йөрүче дүңгәләк хәлендәмен. Казан халкына мыскал гына да зәүрәт китермәдем. Ил өстенә лаеклы хан идем. Мине өр-яңадан Казаныма кайтар.

Сәхибгәрәй үзе дә ау этеннән бер дә кайтыш түгел, аны өсләтеп торулар да артык. Ул икенче җәйдә үк Мәскәү җирләренә сикерде дә керде. Кырым гаскәре Рязань каласына тикле барча кирмәннәрне, котырган үгез чүмәлә-кибәннәрне сөзеп чәчрәткәндәй, сытып-изеп кенә барган иде. Шымчы-үткер күзләр Мәскәү тарафыннан хәбәр юлладылар.

— Василий кенәз, өне алынып, Мәскәү кирмәненнән чыгып качкан. Ул хәзер Коломна каласы янында гаскәр җыеп ята.

— Һе, элек тә булды, булды бит мондый хәлләр, — дип Сәхибгәрәй энекәше Сафагәрәй алдында күкрәкләрен киереп кукрайды. — Моннан унбер сәнә элек тә без Мөхәммәд агам белән Василийны пайтәхетен ташлап качарга мәҗбүр иткән идек. Бүген дә мондый галәбәгә ирешкәнмен икән, димәк ки, мин теге чактагы Мөхәммәд агам белән бер дәрәҗәдәге җиһангир хәлендәмен. Болай булгач, сине кабат Казанга кайтарып утырту да кыен түгел. Тагын бер талпынып, Мәскәү кенәзенең умырткасын сындырырга кирәк.

Василий кенәз бирешергә һич тә теләмәде, кырымныкыларга каршы гаскәр куды. Татар сәрдәрләре тегеләрнең аннан-моннан, бик ашыгып кына җыелган көч икәнен кыяфәтләреннән үк ансат ачыклады. Ярты гаскәр — көбә киемнәрдән, калганының өстендә, җиһанда җәй чилләсе торуга карамастан, — мамык белән сырган бишмәт-кафтан. Башларына да корыч очлым урынына озын колаклы бүрек каплаганнар. Күбесенең кулларында — чалгы, билләрендә — балта.

— Артка чигенегез! Без китәбез! — дип оран салган булды Сәхибгәрәй.

Төмәнбашлар өннәре алынган кыяфәткә кереп, җайдакларның сафын кире борды. Бүре тешенә эләгүдән курыккан сарык көтүедәй, берсен-берсе куалый-куалый һәм өшәнүдәп яман чиный-чиный, килгән юлларына таба чигенделәр. Мәскәү боярлары, җим күргән балыктай, татарларның кармагына эләкте, камчыларын мамык бишмәтләләр сыртында уйната-уйната, алайларын төрекләр эзеннән куа башладылар. Таба шикелле түм-түгәрәк үзәнлек эченә килеп кергәч кенә Сәхибгәрәй үзенен җайдакларын капылт кире борды. Үзәнлекне чорнап алган усак-каен арасына да меңәрләгән яугир яшерелгән булган, урысларны камалышка алып, төрле яктан камыш сабагы урынына урырга һәм кырырга тотындылар.

— Без тозакка эләктек! Капкын, капкын! — дип сәрдәр-боярлар ис-акылларына килеп кычкырганда инде соңарганнар, урыс ирләренең күпчелеге үзәнлек уртасында утын әрдәнәсе урынына өелеп ята иде.

— Мин Мөхәммәтгәрәй агамнан бер дә ким кыйланмадым, анын шикелле үк тоташ галәбәгә ирештем бит, — дип шапырынды Сәхибгәрәй, үзәнлектән соңгы

бояр чыгып качуга ук. — Безнең икебезгә дә, аның төсле, татар ханлыкларын бер йодрыкка төйнәү, Чыңгыз каһанлыгын өр-яңадан аякка бастыру турында ният корыр вакыт җитмәдеме икән?

«Әһә, ошбу агамда да Чыңгыз-җиһангирлык чире калкып чыкты, — дип күңеленнән генә йөзен чытты Сафагәрәй сукбай. — Мине Казан тәхетенә кайтарып утыртса да, муеныма — элмәк, кул-аякларыма тышау салып, гомер буе бәйдә тотуны өмет итәчәк бу».

Исән калган урыс боярлары «солых, солых», дип кычкырып ярлыкау сорауга ук, эчендәге рәнҗешләрен тыеп кала алмыйча, Сафагәрәй чәчрәп алга чыкты.

— Василий кенәзегез колагына энәсеннән җебенә тикле илтеп тапшырыгыз. Казанда хан булып торган чагымда мин бер генә мәртәбә дә урыс җиренә талау сәфәрләре ясамадым, зәүрәт китермәдем. Киресенчә, гел Василий кенәз генә минем өстемә гаскәр җибәреп, золым ясап, җәберсетеп торды. Ул мине хәтта ханлыкны ташлап китәргә мәҗбүр итте. Менә, Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәте илә мин үчемне алдым. Ул ятласын, Казан тәхетенә мин кабаттан кайтып утыргач та, һичбер вакыт гафил булмам вә җавапсыз калмам!..

Тик Сафагәрәй дә рәнҗеш һәм үч сүзләрен дошманының колагына илтеп җиткерергә нык сонарган, Василий кенәз хурлыклы җиңелү кайгысын күтәрә алмыйча, актык сулышларын йотып ята иде...

## 25

— Миңа тагын яңа сәфәргә кузгалмыйча булмый, Хүррәм җаныкаем, — дип сүз башлаганда ук Сөләйманның йөзе кара янган иде.

Хүррәм күз ташлады: Сөләйманга утыз биш яшь тулып кына килә, ләкин чигә чәчләренә чал да иңгән икән. Атасы Сәлим солтан кырык икесен тутыруга ук җанын тәслим кылган, Сөләйманга да шул яшь якынлаша. Сәлим солтан аның җаныкаен да үз янына чакырып ала күрмәсен, ялгыз калса, Хүррәм үзе, балалары нишләр?..

— Әле ике ел элек кенә мин мадьяр белән валахлар бәйлегән аерым пашалык һәм үз мәмләкәтемнең уналтынчы вилаяте, дип игълан итеп кайтып киткән идем. Мәгәр миннән качып котылган Фердинанд әүвәл чех бәкләре хозурына барып үзенә яклау тапты, ә аннары инде Вена каласында җебегән Янош ташлап качкан таҗны үзенә кидерттергән. Фердинанд мин көлгә калдырып киткән Буданы да хәзер өр-яңадан аякка бастыра, ди. Анысы гына чүп хәл. Ул мин төзегән вилаятьне үзенә буйсындырмакчы. Абыйсы Карл өсләп торганга күрә, ул мине бөтен Аурупа корольләре алдында мыскылларга чамалый. Моның ише хурлыкларга түзеп тора алмыйм. Без үзенә бөек король дәрәҗәсен алган Карл белән бер басмага кергән ике тәкә сыман. Йә ул мине упкынга төртеп төшерә, йә мин аны, орышка чакырып, эт бугыдай изәм...

Сөләйманның пәһлеваннар һәм җайдаклар бәйгесенә йөри башлавын да белеп алгач, Хүррәм аеруча зур хафага төште. Солтан элек тә пәһлеваннар көрәше, җайдаклар узышы белән хозурланып утыруны бик ярата иде. Ир-ат өчен монысы гадәти хәл, теге аргамак йә бу көрәшче өчен җан атып утыру солтанлыктан, сыбайлыктан яки синең һөнәрчеме, игенчеме булуыңнан гына тормый. Бәйге — җан тартуы, аңдый чир эләктерү — фәкать савап кына. Ләкин Сөләйман хәзер бәйгеләргә шәхсән үзе, киемнәрен алыштырып, йөзенә битлек киеп чыга башлады бит. Аллаһы Тәгаләнең фатихасы буенча тәхеткә утыртылган солтан хәтле солтан кара чура, кара коллар белән бил алышып йөри. Үзенең чиксез түбәнлеккә төшүен дә аңлый белми торган нинди тискәре бу?

Шушы хакта тузынып сүз кузгатса, Сөләйман һәрвакыт кулын гына селти.

— Бәйгеләргә солтаннар да, корольләр дә йөргән. Әнә, Чыңгызхан турындагы кобайырларны гына тыңлап кара. Хан тәхетенә менүгә ирешкәнче, ул кан

дошманы булган Торгытай нойонны да, Җәмуга бәкне дә үз куллары белән чәнчелдергән. Әле каһан булып алгач та, Мөхәммәд шаһның малае Җәләлетдин солтан белән дә, гәрәйләр хуҗасы Тогрул, найманнар хакиме Даян, мәркетләр башлыгы Бавырчак кебек ханнар белән дә орышларга чыккан. Бүген мөселман дөньясында көферләрнең төп короле булган Карл белән йөзгә-йөз басып орышырга җөрьәт итәрдәй башка хакимдар юк. Аллаһ Тәгалә бу тәкъдирне мин колына бүләк итә икән, аның фәрманын тик шатланып кабул итү фарыз.

Әй беркөнне Сөләйман кулында «Зөлкарнәйн» китабын күреп алды да Хүррәм, бөтенләй, камыш урынына шартлап сынгандай булды.

— «Җиһангирлык чире эләккән икән, Сөләйман да үлемен чит җирләрдә, яу кырында тапмыйча, тына белмәс инде».

Дөрес чамалаган, Сөләйман әүвәл Ибраһимны Балкан аша Карпат тауларына төбәп куган иде, майның унысында үзе дә иярөнә менде. Болгарлар белән валахлар укмашып яшәгән София, Бухарест тирәләре, Казанлык, Фракия, Добруджа үзәнлекләре — күптән үз җире бит, Дунайга кадәр араны шактый тиз үттеләр. Белград аръягындагы серблар, хорватлар, словеннар төрек пашалыкларына буйсынудан чыккан, андагы кала-кирмәннәрнең барчасын да тагын бер кат сытып узарга туры килде. Сөләйман гаскәрләре Дунайның ике яры буйлап югарыга күтәрелә башлагач та, күрше каһанлыкның солтанына бүләк тә юлламыйча король булырга чамалаган Фердинанд Будадан Венага чыгып качкан. Сөләйман Буда каласына кереп кенә килә иде әле, ә ермак алайдагы бер меңбашы сәерләрдән-сәер хәбәр белән каршылады.

— Солтан галиҗәнапләре турында ишеткәч тә, куян йөрәк Фердинанд тәһарәтен югалткандыр инде, ул үзенең король таҗын ташлап калдырган бит!..

Ләһләр куышына качкан икенче куян йөрәк «король» Янош та Сөләйманның яңа яу сәфәре турында ишетеп өлгергән бит, «үтә сагындырган» кодагый шикелле, Буда капкасы янына ул да килеп житте.

— Мин сиңа янә таҗ кидерәм, — дип усалланып, тешләр кысып дәште аңа Сөләйман элеккеге мадьяр короле Стефани төзеп калдырган иске зур сарайда. — Ләкин бу юлы син инде үзеңне төрек солтанының вассалы, дип игълан итәчәксең. Риза түгелсең икән, башыңа капчык кидереп, Дунай төбенә генә озаттырам.

Тантана вакытында Янош, тезгә чүгеп, Сөләйман чапанының җиң һәм итәк очларын үбеп алудан да, солтанны үзенең хуҗасы һәм атасы, дип танудан да тартынмады. Йөзәрләгән мадьяр, валах, серб вә чех кенәзләре каршында солтанга утыз мең алтын дукатлык ясак юллап торырга да ант сулары эчте. Сөләйманга хәзер Венага юнәлеп, Фердинандны тезгә чүктерүдән башка хәсрәт калмаган да иде. Будадан кузгалган чакта Вена тарафына һавалы һәм шомлы кисәтү озаттырудан да онытмады хәтта.

— Таҗсыз корольләрне сыендыра торган яна пайтәхетегезнең капкаларын бикләп интекмәгез. Өч көн дигәндә мин барыбер аны яулап алам! Солтан галиҗәнапләренең тәгаме бик нәзберек, мәҗлес өстәлләрен мулрак әзерләгез!..

Ләкин ата-бабаларның «бәхетсезнең чалкан егылса да борыны каный», дигән гыйбарәсе солтан галиҗәнапләрен дә урап үтми икән. Будадан соң юлда бер атна да бара алмадылар, ярты гаскәр эч китүдән ауды. Биш төмәнбаш ерак сәфәргә авыр туплар алып маташмаган, Сөләйманның аларны дарга мендерүдән кала чарасы юк иде. Аптырагач, Вена диварлары астына яшерен юллар казый башладылар. Анда хасил булган базларга капчык-капчык, мичкә-мичкә дары тутырдылар, нәкъ алар шартларга тиешле минутларда меңәрләгән кыр туплары бердәм телгә килде. Әмма күк йөзеннән янә каһәр суккан яңгыр коя иде, базларга ташылган дары мичкәләре дә шартламады, кыр тупларының ядрәләре дә диварга житә алмыйча җиргә коелдылар. Солтанның мәсхәрәгә калуын абайлагач, кирмән өстендәге

алман, бавар, мадьяр сәрдәрләре ихахайлап көлде. Шул минутта дивар өстеннән солтан чатыры ягына нәни капчык элгән сәрпи ук очырдылар. Капчыктагы «сәлам хаты»ның эчтәлеген Будадан ук ияртеп килгән әсир тылмачлады.

— Синең өчен әзерләгән мәҗлес өстәлләрендәге ризыкларыбыз суынып беттеләр бит. Җылытып ашарга синең тарафына ялкын элдерәбез.

Сөләйманның чатырдан чыгуын гына көтеп торганнардыр, Вена диварлары өстеннән шул минутта ук йөзәрләгән ядрә очырдылар. Ядрә кыерчыкларының берсе солтан әләмен нәкъ урталай телеп узган иде, моны шәйләп алган меңәрбашлар төрекләргә катгый әмер бирде:

— Яуга, яуга! Агач баскычларны, тараннарны алга чыгарыгыз! Диварларны кем беренче уза, таланган ганимәтләрнең бөтенесе тик шуларга гына! Солтан галиҗәнапләре үзенә тиешле ганимәтне таләп итмәячәк!..

Төрек яугирләре һөҗүмгә бөркет өередәй ябырылды, алар очырган ук болыты күкне каплап китте, ләкин диварлар өстенә үрмәли алмадылар. Австриялеләр кайнап торган сумала-су койды, очкын элгән бүрәнәләр, сөңге, кайнар ташлар диварлардан ташкын булып акты. Кирмән буендагы ерымнарны мәет тавы каплый башлагач кына, Сөләйман һөҗүмне туктатырга мәҗбүр булды.

Алдагы көннәрдә дә Вена өстенә сәгатьләр буена ук яңгыры яуды, сәрпи уклар колагына алтын дукат, асылташлар, хәтта ефәк тукымалар да бәйләп маташтылар, биш дөягә капчык-капчык алтын тәңкә төяп озаттылар — капка ачучылар барыбер күренмәде.

Уникенче октябрь кичендә солтан үзенең чатырында диван җыйды. Иң беренче, баш вәзир генә түгел, яу сәфәре вакытында сәргаскәр дә булып исәпләнгән Ибраһим сүз алды.

— Нәүкәрләргә җаны кыелган һәрбер бавар, чех, саксон, мадьяр сугышчысы өчен алтын тәңкәләр вәгъдә иткән булдык. Тик меңбашлар һәм сыбайлар нәүкәрләрне һөҗүмнәргә фәкать чыбыркылап кына күтәрәләр. Ярты гаскәр чатырларыннан да чыга алмыйча, хаста булып ята. Читтән ярдәмгә көтәрдәй башка көч калмады. Мин камалыш һәм яуны кичектереп торырга тәкъдим итәм. Белград ка кайтып, без кышны шунда да бер кайгысыз гына уздыра, ә иртә язда Венага һөҗүмне өр-яңадан башлый алабыз бит.

Сөләйман яу тәхетендә утырган көенә бер генә аваз да чыгармагач, моны аның ярсуы һәм килешмәве, дип кабул иттеләр, күрәсең, чатыр эчен түгәрәкләп тезелгән түмәнбашларның дүрте-бише берьюлы сүз ташлады.

— Тагын бер мәртәбә талпынып карамыйча, кире чигенмибез!

— Яуга керми генә ташлап китсәк, безнең гаскәр куркып качкан кебек була.

— Тагын бер яу, соңгы һөҗүмне булса да үткәрергә кирәк!

Соңгы һөҗүмне ике көннән соң, ундүртендә ясарга килештеләр. Һәрбер дошман мәете өчен бишәр дукат, ә әсирләр өчен унар дукат алтын тәңкә вәгъдә иткәч, төрек нәүкәрләре арыслан һәм юлбарыс гаярьлеге белән орышты. Бер урында дары шартлатып, алтмыш аршын чамасы диварны юк иткәч, кала урамнары эченә үтеп тә сугыштылар хәтта. Ләкин сакчы гаскәр өстән бүрәнәләр ташлап дивардагы ярыкны томалагач, артка юл бикләнде, сиксәнгә якын төрек нәүкәре дошман кулына әсир булып төште. Австриялеләр бер бичараны, ике кулын беләк турысыннан чабып, кире чыгарганнар. Мондый кансызлыкны күргәч, төрек нәүкәрләре чокырларга чүкте. Камчы-сөңге белән куалауга, ярсып үкерүгә колак салмадылар. Ахыр чиктә Сөләйман үзләре төзегән хәрби ыстанга ут төртергә генә боерды да, иң беренче булып, яу кырын ташлап китте.

— Яу кампаниягез бик уңышлы чыкты, чын күңелдән котлыйм! — дигән юха сүзләр белән Буда каласында курчак король Янош каршы алган иде, Сөләйман, аннан зәхмәттән курыккан шикелле читләшеп, Истанбулга очты.

Кулында Хүррәмнән бер атна элегрәк килеп ирешкән соңгы хат битләре, аларда сагыну, мәхәббәт, чакыру шикелле иң-иң кайнар хисләр.

Мең ирне дә алыштырмас хуҗам, якты кояшкаем,
Намазга баскандай иелеп үбәм кайнар эзләреңне.
Искә алсаң мин колыңны, нык белеп кайт, солтанкаем,
Олы бүләк каршы алыр сагынулы, җылы күзләреңне...

Кайтып керсә, асылда да бүләк — Хүррәм аңа тагын бер угыл табып куйган икән. Бәп-бәләкәй үзе, песи баласыдай йомарланып ята. Хүррәмнең күнелендә генә ниндидер хафа бар, ахрысы, яңаклары буйлап аккан күз яшьләрен һич яшерә алмый. Хәер, бу озак вакыт күрешми торганнан, сагынудан гына булуы да мөмкин ләбаса.

— Мин инде әллә кайчан уйлап куйган идем. Бу угылыма фәкать Җиһангир дигән ат тиешле. Мин өлгерә алмаганны ул үтәп бетерер, мин хыялда тоткан бар җиһанны яулар...

Сабый шулай Җиһангир атлы өмет булып китте, зәгыйфьлеге ике-өч айдан соң гына тәмам ачыкланды. Бичаракай җир йөзенә бөкре булып туган, ул исеменә тиң гамәлләр кылудан мәхрүм бала иде...

Ә Сөләйманның үз кырыгы — кырык. Ике кышны уздырып җибәрүгә, янә ияр өстенә сикерде дә менде.

— Карл дошманым белән йөзгә-йөз орышка ирешмичә торып, мин яу сәфәреннән тукталачак түгел!..

Янә йөз егерме мең кешелек гаскәрнең үз тарафына юнәлүен белгәч, Фердинанд Сөләйман каршына зур илчелек юлларга мәҗбүр булды. Төрек гаскәре Дунайга җитәрәк ялан кырда Сөләйманны мөһерле кәгазьләрен баш өстенә чөйгән кенәз-бәкләр тезгә чүккән хәлдә көтә иде.

— Сине Фердинанд Трансильваниядәге мадьярларның короле дип таный. Буда каласы да моннан ары синең вилаятең булып саналачак. Фердинанд сиңа ел саен утыз мең дукат пансион түләргә дә риза. Яңа яуны туктат, әйдә, солых төзик.

— Трансильвания белән Буда — инде болай да минем вилаятем, — дип Сөләйман шаркылдый-шаркылдый көлеп җавап бирде. — Фердинанд вәгъдә иткән утыз меңне дә миңа күптән Янош түләп тора. Яуны туктатудан бер отыш та күрмим. Мин Фердинанд энекәшен үз куенына алган һәм аны гел миңа каршы өстереп яткан испан короле Карлны йөзгә-йөз килеп орышуга дәшәм. Йөрәге җитә икән, кыр өстенә чыксын. Күләгә төшүгә дә кача торган чебен шикелле куркак җанлы икән, үзен минем вассалым дип танысын да ясак түли башласын. Башка таләбем юк, солых булмаячак...

Сөләйман Карпат өркәчләре янына барып житкәч, дошман яктан хәбәр ишетелде.

— Бөек Карл Сөләйман солтан белән орышка чыгарга җыенмый, аның каравы Фердинандның кул астына бик зур гаскәр юллый. Венага ул туплаган испан, юнан, алман, саксон алпарлары килеп җиткән. «Чокырга егылып төшкән кәҗә бүрегә дә «җизни», дип ялвара икән», — дип сөйлиләр бит. Өстәмә гаскәр җыйнау хакына Карл да хәзер алман илендә католикларның җене сөймәгән лютеран динендә булучылар белән үгет алып бара. Тегеләре чиркәү эченә иконалар элүне һич танымый, алар каршында тезләнеп чукынудан «мәҗүсилек йоласы», дип баш тарталар икән.

— Әһә, менә бу яктан лютераннар мөселманнар белән кардәш булып чыга, — дип төрек имамнары куллар уа-уа сөенгәннәр иде, яңа хәбәр килде.

— Нюрнберг атлы бер калага туплангач, тискәре лютераннар барыбер дә

Бөек Карл ягына авышканнар. «Католиклар белән лютераннар — күлмәк сайлаганда үзара бозылышкан бертуганнар гына, ә мөселманнар — безнең кан дошманнар», янәмәсе. Хәзер шул лютераннар да Карл гаскәренә алпар көбәләре җыя башлаганнар...

Котыру-ярсудан, Сөләйман юл өстендәге авыл-бистәләрнең барысын да тоташы белән кырып кына барды, әсирләрне, меңәр-меңәр итеп, Истанбул ягына куа башладылар. Дошман көчләр Венадан алтмыш чакрымдагы Гюнс атлы кирмән янында очрашты. Фердинанд биредә гарнизон башлыгы итеп хорватлардан Николай Юрисич атлы бер кенәзне калдырган, ә үзе Вена диварлары эченә бикләнгән, ди.

Гюнс — кыя шикелле текә, биек диварлардан хасил. Сөләйман әүвәл аның өстенә бер төмән нәүкәрен генә ташлаттырган иде, ярга бәрелгән диңгез дулкыннары шикелле кире чигенделәр. Ук яңгыры койган чакта меңәрләгән ирнең яралардан ачыргаланып кычкырган тавышы ишетелде, тик диварлар сакчылардан һич тә бушамады. Тора-бара гына ачыкланды: кирмән белән якындагы бер кыя арасында җир асты юллары бар, камалыштагы сакчы гаскәр шуның аша гел яңара икән. Яшерен юлны дары мичкәләре куеп шартлаткач та, сакчыларда каршылык кимемәде. Түмәнбашлар меңәрләгән кыр тупларын эшкә җигәргә тотынды, кирмән эченә болыт-болыт булып ядрә яуды.

Сөләйманның вакытны заяга үткәреп ятасы килмәде, Вена тарафына чапкын артыннан чапкыннарны куып кына торды.

— Мин җибәргән Карлның Вена янына якын килергә дә куркып, Ратисбон атлы калада бикләнеп ятуын беләм. Безнең ара — ике йөз генә чакрым. Карл атлы ул бушкуыкны минем ат тизәге өстенә сузып салып, типкәлисем, яңаклыйсым, күсе урынына куып йөртә-йөртә юк итәсем килә. Алманнар гына җитмәгәч, ул испаннарны басып алган булды, Карл урынына үзенә «Карлос» кушаматын тагып куйды. Ярты Аурупага тешләрен батыргач, үзенең вилаятьләрен «Изге Рим каһанлыгы», дип игълан итүдән дә, «мин бар җиһанда католиклар каһанлыгы төзеп куям», дип шар яруларыннан да тайчынмады. Мине дә тез астына салырга хыялланучы бөек король икән, йөз чакрымдагы Секеш дигән елга ярында бергә-бер орышуга чыксын!..

Атна буе көтте, ун көн көтте, король Карл һичбер төрле җавап кайтармады. Гайрәте чиккән Сөләйман, ак әләмнәр күтәртеп, Гюнс капкалары янына илчеләр юллады.

— Юрисичка тапшырыгыз анда. Кенәзегез бик кыю сугышты. Ул солтанны зурлау, ә гади нәүкәрләрнең күзләренә тотен җибәрү өчен генә кирмән ачкычларын чыгарып бирсә, Сөләйман хәтта сыңар ук та очырып тормыйча, бар гаскәрен ияртә дә китә.

Ай буена юлбарыстай сугышкан Юрисич шушы гади генә хәйләгә алданды да куйды. Ул кала ачкычларын тапшырырга дип кирмән капкаларын ачкан гына иде, төрек нәүкәрләре, чүплек тапкан карга өере шикелле, диварларга кычкырып ташландылар. Төрекләрнең Гюнс гарнизонын соңгы сакчыга кадәр кырып чыгуларын көткәннәр диярсең, Фердинандтан янә бер мәртәбә илчелек килеп җитте.

— Буда каласы да, Трансильвания, мадьяр иленең үзәге дә — һәммәсе синеке. Яноштан тыш без үзебез дә сиңа ел саен утыз мең алтын дукат озатып торачакбыз. Яуны гына туктат.

Сөләйман, Вена ягына төкеренә-төкеренә, кайтыр юлга чыкты...

Истанбулда биш тәүлек буена туплардан аттылар, меңәрләгән утлы шарны күккә очырдылар. Солтан фәрманы буенча, биш тәүлек буе базарлар төнлә дә эшләде, сугым малы ауды, яудан кайткан нәүкәрләргә бушлай өләшенгән

кымыз, шәраб, сөже чишмә булып акты. Сөләйман үзе төнлә, гади нәүкәр киеменә төренеп, битлек киеп, базарлар буенча йөреп караган иде дә, дарга озатырдай нахак сүз таратучы гайбәтчеләр бер дә очрамады.

## 26

— Син яуда усал тәкә шикелле сөзешеп йөргән чакта мин монда Халык ермагы аша асылмалы күпер, Аксарай бистәсендә яңа мәчет төзетә башладым бит әле, — дип, Сөләйманның йонлы күкрәкләрен кытыклый-кытыклый, җай белән генә мактаныргa тотынды Хүррәм, әле йокы түшәгеннән сикереп купканчы ук.

Сөләйманның күзләре маңгаена менгән кебек булды, шаклар катты.

— Әттәгенәсе! Менә сиңа җиде дәрья аръягыннан килеп төшкән әҗнәби солтанбикә! Син кылганнар монда туып үскән төрек хатыннарының, хәтта вәзирләрнең дә кулыннан килмәс иде. Афәрин, афәрин, солтанбикәм, җаным!

Әнисе Гайшә фани дөньяга күченгәннән бирле Сөләйман Хүррәмне «солтанбикә» дип кенә үсендереп йөртә. Шуны ишеткән саен Хүррәмнең май кояшы сыман елмаюын шәйләгәч, адым саен кабатлап, гел күнелен күрә. «Авызыңа мал да май», — дип Хүррәм аңа күңеленнән генә рәхмәт сүзләре укымыйча калмый, канатланып китә.

— Мин болгарларның София каласында да яңа сарай төзү нияте белән янып йөрим әле, — дип Хүррәм янә сер капчыгын ачкач, Сөләйман моңа гел мөкиббән булды. — Гарәп байчурасы борынгы заманнарда ук яшәгән Семирамида атлы шаһбикәләре турында әкиятләр сөйләп шапырынган була. Имеш, шул Семирамида Вавилонда җир өстендә түгел, ә бауларга, җепләргә үрелеп үсә торган агачлар һәм чәчәкләр үрчетеп, асылмалы гөлбакчалар нигезләп шөһрәт казанган, ә исеме бөтен җиһан буйлап таралган, ди. Ә мин солтанбикә кадәр солтанбикә була торып, нишләп әле үземнең исемемне калдырмаска тиеш? Җитмәсә, минем артымда Сөләйман җиһангир атлы алтын калканым да бар лабаса. Шулаймы, җаныкаем?

Сөләйман гел хуплап кына торгач, Хүррәм Аксарайдагы мәчет төзелешен тизләттерде, София тарафына меңәрләгән мигъмарларны куды. Халык ерымы аша тартылган асылмалы күпер аның гына түгел, бар Истанбул күңеленә хуш килеп калка иде, аның янында кайтып керүне дә белми бәргәләнде. Арып-талып Топкапега кайтса, анда куккә очынырдай яңа шатлык. Ул аны Сөләйманы белән бүлешмичә һич кенә дә түзеп тора алмый.

— Францисконың хатыны Агнеттадан хат алдым бит бүген. Королева ире белән икесенең җилкәнле карабларда Сена елгасы буенча Марсель бугазына чаклы сәяхәт кылулары турында мактанып һәм хозурланып яза. Франциско үзенең королевасына якасына фирүзә ташлар тезелгән һәм күкрәк турысы кендегенә кадәр ачык күлмәк тектергән дә Агнетта шуның белән бар Парижны шаккатырган икән. Якут, энже, фирүзә ташлар тезгән күлмәкләр үземдә дә биш-алты дистәләгән, мәгәр миңа, күкрәк ачып, һич югы солтаным каршында масаеп йөрүләр дә тәтемәстер инде.

— Тектер, тектер, — дип кул селти хыялдагы ләззәтләрне күз алдына китерүдән мәлҗерәп төшкән солтан. — Мин үзем дә бер генә күлмәк яки җиләнемне дә ике тапкыр кимим.

— Һе, сине иртән киендерүче ялчынны да бер як кесәндә биш йөз дукат, икенчесендә хәтта мең тәңкә алтын да күтәеп тора ласа.

— Дөнья дилбегәсе безнең кулда түгелмени, солтанбикәм, җаным? Шулай булгач, бу җиһанның кадерен белеп калыйк. Гомәр Хәйям әйтмешли, безне

фани дөньяда алтын касә тулы шәраб белән күтәп торалармы әле, аллә юкмы — анысын шайтан гына белә дә, фәрештәләр белә. Ә хәзергә бердәнбер фәрештәм — ул син генә! Мине сөеп, шатландырып, очындырып яшә.

Хүррәм шушы сүзләрне генә көтеп торган кебек, икенче көнне үк Вена, Париж, Венеция тарафларына махсус хат юллады. Аллан хәтта киная ташлап та кисәтмәгән иде, күршедәге мәмләкәт пайтәхетләреннән арфачылар, рәссамнар, күчмә циркташы тамаша осталары килеп төшкәч, Сөләйман кабат-кабат хәйран гына калды. Хүррәм рәссамнардан әүвәл Сөләйманны әллә ничә төрле итеп ясаттырган иде, бер тукыманы буйый башлаганда солтан янәшәсенә үзе дә килеп басты.

— Без — синең белән бер үк жан һәм бер үк тәхет ияләре, кояшым, бәгырькәем. Һич югы бер рәсемдә булса да мәңгелеккә яшәп калыйк әле.

Сөләйман элеккечә гел елмаеп торгач, колагына иелеп пышылдады.

— Их, синең белән Парижларга, Венецияләргә сәяхәт кылсаң, алардагы сарай тамашаларын, күңел ачу мәжлесләрен барып күрсәң иде!

Бу юлы инде Сөләйман бөтенләй елмаймады, йөзе битлек киеп алган сыман капылт кырысланды.

— Мин — бүтән сәяхәтләр өчен яратылган әрвах. Безнең икебездә ике төрле кыйбла.

## 27

Жангалине хан тәхетенә чакырып утырткач, ни галәмәт, Казан көчле яңгырдан соң тулыланган күл өстедәй тынып калган иде. Әмма мондый иминлек сәхрәдәге рәшә төсле алдавыч бер ара гына булган, дәрьядагы басма такталары өстенә килеп кергән аңгыра тәкәләр кебек сөзешүдән һәм бер-берсен жәһәннәмгә сугып төшерүдән туктый белмәде бит бу Казан халкы.

Жангали Василий кенәзгә садыйк-тугрылык турында ант китергән булгач, үзенә ияртеп озатылган илче-шымчы Морозов сүзеннән чыгарга маташмады да сыман. Шул шымчы кубызына биеп торгангамы, Жангалинең бер генә адымын да аңлый алмый тәмам чиләнделәр. Гажәп түгелмени: Мәскәү Нугай морзалары белән сәүдә эшләрен ныгытуны таләп итә башлый, Жангали һичбер яраны белән дә киңәшләшеп тормыйча, сәүдәгәрләр тарафына шундук фәрман сырлый.

— Мәскәү табынына биш мең куй каләре олы көтү куып китерегез!

Мәскәү үзенең сугышчыларына итек тектерү өчен йомшак итеп иләнгән тире даулый, Жангали бугазга сөяк булып кадалырдай фәрман ыргыта:

— Биш мең сарык суеп, тиреләрен иләп, Нижгардагы Мәкәржә базарына илтеп житкерегез!

Жангалинең мондый чиле-пешле фәрманнарыннан тиз арада туя башладылар, ризасызлык һәм рәнжешләр артты. Шушы кулай жайны көтеп кенә йөрүчеләр дә байтак булган икән, бөке сыман, шулар калкып чыкты.

Яңа ханның балигъ түгеллеген сылтау итеп, әүвәл Гәүһәршад бикә бар диванның дилбегәсен үз кулына сосып алган иде. Аның тирәсендә бөтерелеп йөргән Сәед углан су төбенә киткән балтадай эзсез югалды да, Гәүһәршадның янәшәсенә Булат Ширин белән Кечек Гали атлы морза менеп басты. Булат үзе — Кырымдагы иң-иң эре аксөяк нәселеннән, аннан тыш Казанда Мөхәммәтгәрәй хан куып жибәргән Аппак углан, Сафагәрәйгә ияреп килгән Жәүдәт-бахши[1], байтак кына сәрдәрләр дә бар әле. Шулар бөтенесе, тәбикмәк пешерәчәк табаны кыздыргандай, Казандагы морза-имамнарны иплән-жайлап кына үз тарафларына күндерә башладылар.

— Бу Жангали, абыйсы шикелле үк, бер боламык булды. Һаман-һаман

[1] Бахши — бу очракта канцелярия башлыгы.

Мәскәү жырын тугылый да тора. Аның кыйбласы Мәскәүдә, ул шәрык ягына авышмастыр инде.

— Мөхәммәдәмин дә, Габделатыйфы да Мәскәү китереп утырткан ханнар иде, юкса. Мәгәр Казан эченә кереп чирканчык алуга ук, безнең мәнфәгатьне кайгырттылар ласа. Мөхәммәдәмине, хәтта, үзен үстергән, үзен күтәргән кенәз өстенә ничәмә-ничә тапкыр яу артыннан яңа яуга чапты. Май чүлмәге тышыннан билгеле бит, бу Җангали асыл иманга кайтмастыр да инде.

Хәтта, Касыйм каласыннан Җангалигә ияреп килгән Котлыкай морза да җиргә лачкылдатып төкерергә мәҗбүр булган икән.

— Кырымнан Аргын илә Ширин бәкләр юллаган өч йөз олаулы кәрванны кире борган бит бу. Ә алар Сөләйман солтаннан сатып алган дары, туплар, шәм вә затлы бәрхет белән шыплап тулган булган. Шул байлыклар Казан-йортның эчен тишәмени? Ашка таш атып җавап саплый торган нинди нәгаләт бу?!

Шушыннан соң диван карар чыгарды да Җангалинең алдына кертеп салды.

— Моннан ары диван рөхсәтеннән башка бертөрле дә фәрман чыгармыйсың! Морозов сине эт котырткан кебек өсләтүдән туктый белми икән, ул шымчыны сасы себерке белән Мәскәвенә куып җибәрәбез!

Илче-шымчы Казандагы хөкүмәт фетнәсе турында көне-сәгате белән Мәскәүгә житкергәндер, тегендә Иван Дүртенче дигән олуг кенәзләре итәктә генә утыра торган сабый булганга, аның Мария исемле анасыннан фәрман килеп төште:

— Җангалигә унҗиде тулып килә, тулы канлы ханга әверелсен өчен, аны башлыкүзле итәргә дә вакыт. Нугайлылар Мәскәү белән бик тә теләп, атлыгып сәүдә итә, яшь кияүгә кәләшне дә нугай морзаларының тирмәләреннән эзләү хәерлерәк.

— Һе, нугайлылар әйбәт, аларның киленнәре дә шәбрәк икән боларга, — дип бүрәнә аша бүре куа-куа дәгъвалашты Казан. — Хаҗитархан тәхетен Касыйм хан эләктерде, Мәскәүгә барып тезләнгән Хөсәенгә кире кайту өчен юл бикләнде. Касыйм хан Мәскәү белән элемтәне өзде, менә шуңа күрә андагы кенәзләр Хаҗитархан белән кодалашуны өнәми дә инде. Кырым ханлыгын телгә алып торулар да артык, Мәскәү алардан Казан-йортка килен төшертүне хуплаячак түгел. Шул, нугайларны үз арбаларына утыртып жырлаттыру өчен, Мәскәүнекеләргә безне нугай морзалары белән кавыштырып кую отышлырак. Киленнәре Казан-йортка төшсә, нугайлар да Мәскәү хозурында биеп йөриячәк.

Байтак кына әреп-талаштан соң нугай бәге Йосыф җәйләвенә яучы җибәрделәр. Җангали каршына китереп бастырган Сөембикә унбиш яшендә генә булса да, җәйрәннәр шикелле гайрәтле һәм елгыр, өстәвенә, пешкән җиләк кебек ымсындыргыч һәм сылу да икән. Егетләрдән һич тә кайтыш булмаган озын һәм зифа буй, арыш кылчыгыдай тылсымлы, төз керфекләр, сандугач канаты шикелле сыгылмалы кашлар һәм, иң сәере, бер елмаеп төбәлсә, аяк табаннарыңа чаклы көйдереп ала торган жете-коңгырт күзләр.

Җангали әле унҗидедә генә, кияүнең үз тиңе булуына Сөембикә сөенде дә сыман. Картаеп беткән ханга вәлидә хатын булып төшү түгел бит бу, беренче атналарда Җангали белән аның Казансу буенда, Нургали манарасыннан кул сузымында аккан чишмә яннарында су чәчрәтеп йә дивар эчендәге агачлар арасында куышып уйнаган чакларын күрүчеләр дә булды. «Икесе дә читтән килгәннәр бит, Казан эчендә бер-берсенә терәк булганнардыр», дип сөенделәр хәтта. Ләкин сөю-сәгадәт көннәре, ком бураны каплаган чишмә төсле, күз ачып йомган арада коргаксыды бугай.

Мәскәүгә олы-олы кәрван белән киткән ике нугай сәүдәгәре эзсез югалганнар. Имеш-мимешле хәбәрләр, даладагы учак ялкыны шикелле, төрле якка авып уйнаклады.

— Сафьян күн төягән ул кәрваннар Костырма[2] каласыннан исән-имин чыккан, мәгәр Лыскабага[3] барып җитмәгәннәр. Костырмада чакта кенәзләре нугайлардан бер итеклек күнне сигез алтынга бирүне сораган, ди. «Без Мәскәүдә аны унбишкә озатабыз», дип нугайлылар моны кире каккан. Лыскаба белән ике арадагы бер түгәрәк күл буенда төн кунарга туктаган булганнардыр, таң атткач, болар корган ыстан урынында башлары чабып төшерелгән ике әрвах җәсәде генә аунап калган икән. Аларны сакчылары суеп качкан, дип гоманлап та булмый, арбакашларын Костырма зинданында күреп кайтканнар бит.

— Бу — Костырмадагы кенәзнең генә эше, — дип сүз кыстырды Сөембикә әле тәүге тапкыр диван утырышында пәйда булуга ук. — Мәскәүгә хат юллап, ул әшәке җанның башын чаптыруны дәгъваларга кирәк.

Диван түрендә урын алган Гәүһәршад бикә, Булат Ширин, илче Аппак, Тагай морза — һәммәсе шаккатты. «Әттәгенәсе, йомшак иренле бозау кебек мыштым гына йөрсә дә, бармагыңны каптырсаң, тешләп өзәчәк бу!» — дип берәгәйле нәтиҗә чыгардылар.

Тәхеттән кул сузымында утырган илче-шымчы Морозов күзләрен акайтып ым ташлаган иде, Җангали, аяк табанына кызган энә калагандай, сикереп үк торды.

— Ә син хан тәгәрмәченә таяк тыгып утырырга ул чаклы кем әле? Ике мәмләкәт арасындагы низагъны хәл итү — нугай җәйләүләрендәге сарык көтүен куып йөрү түгел бит ул!..

Сөембикә елан чаккандай сикереп кузгалды да диван утырышын ташлап китте. Шуннан ары аның елмайган көннәрен бер дә күрмәделәр. Әйтерсең лә, әкәм-төкәм яисә шыгый хатыннары сыман, яулык-шәлләр эченә төренде ул. Җаен тапкач һәм көенә генә торгач, Гәүһәршад бикә белән Булат морза гына аның янына кереп йөри алды. Халыкта: «Сөембикәне атасы Йосыф морза килеп алмакчы да Хаҗитархандагы Касыйм ханның улы Дәрвиш-Галигә кияүгә бирмәкче, ди. Ул Җангалинең «талак» кычкырганын гына көтеп яши икән», — дигән имеш-мимешләр дә купкан иде инде.

Ләкин көннәрдән бер көнне барча Казан-йортны яшен кебек хәбәр телеп узды:

— Булат Ширин морза Җангалине ауга чакырган да, ханны Казансу ярында атып үтергәннәр. Җангали кабан дуңгызын чукмар белән сугып алырга маташкан бер мизгелдә аталы-уллы Исмәгыйль белән Камай морзалар, саксызланып, ук очырган, имеш.

— Ай-һай, ялгыш кына, саксыз гына микән? Кара мунча эчендәге кебек төтенле бу сарай, — дип нык шикләнде халык.

Нигезсез дә түгел, бер атна үтүгә Казан тәхетенә янә Сафагәрәй кайтып утырды бит. Корыны бушка аударып йөрмәгәндер, Җангалидән калган Сөембикәне үзенә хатынлыкка алып куйган, әнә. Үзеннән унбиш яшькә кечерәк төнге сандугач моңсыз-назсыз гына сайрамыйдыр, Сафагәрәй Мәскәү өстенә олы яу белән барырга гаскәр туплый инде.

## 28

Баязит бакчасы — үзенә бер дөнья. Анда солтан белән солтанбикәләр юк, аңа вәзир белән пашалар да үтә сирәк кенә аяк баса. Баязит солтан төзеп калдырган иске бу кирмәндә сакал-мыеклары чаларып чыккан баш хадим Якуб хакимлеге дә, баш бирүне белмәс Мостафа патшалыгы.

Гөлбаһар юкка гына улы өчен, әле тегенең сабый чагыннан ук, ут йоткандай янып-көеп, әрсез кодагый урынына теләсә кем белән җадалашеп йөрде. Ә Мостафа

[2] Костырма — Кострома.
[3] Лыскаба — Лысково.

бишек көе тына башлауга ук бәйдән ычкынган эт шикелле урамга томырылды, борын асты да кибеп өлгермәде — тайлар иярләде. Кирмән сакчылары эшермәләргә йозак элә-элә һәр капканы иртә-кичен бикләп куйган була, әмма орчык кадәрле малай актыгы, эт тә сыймастай тишек-ярык табып, йә таш диварлар астыннан чыгып кача, йә бакчадагы зәйтүн, тирәк, анар[4] ботаклары буенча еландай шуышып, урам уртасына сикереп төшә. «Улың йөгәнсез, ташбаш, наян», — дип, курыкмыйча, солтан каршына зарланып баручы юк, ә шаһзадә малай шул йомшак якны чамалап өлгергәч, тагын да әрсезләнә. Җиде-сигез яшендә үк Мостафаны Мисыр базарындагы көрәш бәйгеләреннән, аннан ары йә тимерчеләр алачыгыннан, йә юртаклар чабышыннан табып кайтара башладылар.

— Син — шаһзадә, Аллаһ боерса, киләчәктә солтан булачаксың. Бераз гына булса да ипкә кер дә, үз дәрәҗәңне белеп, сарайлардан чыга күрмә инде, улыкаем? — дип әнисе Гөлбаһарның ялваруларын да колакка элмәде ул.

Тагын югалдымы, кичен кирмәнгә авыз-борынын канатып кайтып керә. Колак салсаң, йә «абынып егылган» инде ул, йә «ат өстеннән мәтәлгән дә төшкән». Бер-ике көннән соң янә суга төшкән балта кебек була. Бусагага кайтса, кесәсендә пәке. «Базардагы көрәштә бер зәнҗи малаен егып алдым», — дип тәкрарлап тик тора. Чокына башласаң, дөрес булып чыга. Шуннан инде Гөлбаһарның да куллары, сынган каз канатлары шикелле, ике якка салына да төшә. Әрепләргәме моны, мактаргамы — һични аңламассың.

Иң-иң әкәмәте: сигез яшен тутыруга Мостафа, беркемгә әйтмичә-кисәтмичә, янычарлар мәктәбенә укырга барып керде.

— Синең итәктән тәхеткә күченеп кенә солтан булып булмый, — ди бит Гөлбаһарга. — Миңа Мәхмүт Фатыйх, Баязит Елдырым, Явыз Сәлим бабаларым кебек сәрдәр булырга әзерләнергә кирәк. Әнә, Сөләйман атам да яу сәфәрләреннән кайтып керми, ә мин Балкан белән Кырым атауларының яисә Дунай белән Җифрат дәрьяларының кайсы якта икәнен дә белмим.

Янычарлар мәктәбенә сөннәткә утыртылган нәсара малайларын кайсы мәмләкәтләрдән генә китереп япмаганнар! Серб, хохол, чех, ләһ, юнан, урыс, гөрҗи, әрмән, болгар, мадьяр, баск-испан, гот-француз, алман-бавар... Төпченә башласаң, һәр малайның икешәр исеме бар. Кичә Никола, Ян, Григорий, Вазген, Антонио, Пьер, Лье, Робану, Ганс, Франц, Арон, Иосиф дигән ат күтәреп йөргәннәр, бүген алар — Нәҗип, Мөбарәк, Габдулла, Раббани, Йосыф, Хәйретдиннәр. Чит-ят җир һәм кыргый мохитләргә, яңа исем белән башка дингә ияләшеп китү бик читендер, ахры, шәкертләрнең һәрберсе үз эченә бикләнгән, мәкерле һәм үчле. Хәлфә-мөдәррисләр никадәрле генә уяу кыйланмасын, Мостафаны өч-дүрт мәртәбә, юрганнарга томалап, кыйнап ташладылар. Мөгаен, алга таба да дәвам итәр иде, шаһзадә аларны үзенең тешләклеге белән яулады да куйды.

Хәлфәләр шәкертләр яшәгән бүлмәләрдә әледән-әле тентү үткәрергә яраталар икән. Мондый хыйлаф гамәлне күбесенчә шәкертләр көрәш бәйгесенә, ат чабышларына киткән чакта гына башкарганнар. Беркөн өйлә намазы үтеп китүгә үк: «Иртәгә сезне кыялардан үрмәләп менәргә өйрәтү өчен Пәри тавына алып барачакбыз», — дигән хәбәр таралуга, ике грек-юнан малае чыш-пыш килергә тотындылар.

— Син теге бакыр әйберенне ныклап яшердеңме?

— Кәвеш табанына йә билбау эченә тегәрмен, дип торам.

— Кара аны, юлда барган, тауда йөргән чакта югалтасы булма. Монысын да сиңа базардагы кылый Әбүбәкер аша гына, көчкә табып бирдем...

[4] Анар — груша.

Иртәгәсен Пәри тавына барып житкәннән соң да, шәкертләргә барча киемнәрен биштәрләргә салырга боердылар. Мостафа күзләренең яны белән генә шәйләп торды: юнан малайларының берсе билбавыннан алып учына нилер кысты, үзе тиргә батты, карашы уттай яна, алга таба нинди хәйлә табарга да белми. Житмәсә, аны тоттырырга жыенган шикелле, учының бер читеннән ефәк бау кисәге асылынып тора, хәлфә якынайса, күрми калмаячак. Мостафа «ә» дигәнче теге ефәк бауның очыннан эләктерде дә бар куәтенә үз ягына тартты. Юнан малае мәче сыман сикереп кулына ябышуга, гыжлый-гыжлый тегенә пышылдады.

— Мин синең бу малыңны беркемгә дә бирмим. Хәлфәләрнең шәйләп калуы бар, юкка сикеренмә.

Ялгыз калганнан соң ефәк бауны алса, анда бакыр тәре. Мона чаклы да күпне күргән, ахры, урыны-урыны белән сыдырылып йә яньчелеп беткән. Әмма үзе барыбер дә шома, комлап чистарткандай ялтырап ук тора. Юнан малае моны оныткандa бер мәртәбә генә кулларына алмый, элеккечә табына ул, димәк.

Мәктәпкә әйләнеп кайтуга, Мостафа тәрене кабат хуҗасының кулларына состы.

— Дар агачына эләгердәй мал түгелдер, мөгаен, тик барыбер дә яшер. Икенче мәртәбә капсаң, коткара алуым бик икеле.

Шушы хәлләрдән соң Мостафа кичәге нәсаралар өчен тәмам үз кешегә әверелеп бетте. Ә инде шәкертләр арасында уздырылган ат чабышларында, мәргән бәйгеләрендә дә өстен калгач, шаһзадәне әйдәманнары итеп саный башладылар. Урамнардан «пайтәхеттә оста җайдакларның бәйгесе уздырыла», дигән хәбәр бәреп кергәч, янычарлар мәктәбеннән үзләре үк Мостафаны сайлап озаттылар.

Бәйге шартсыз гына түгел булып чыкты.

— Солтан галиҗәнапләренең килүе дә мөмкин. Җайдаклар йөзләренә бакыр битлек киеп узышачак. Сызыкка пашалар йә сыбайлар чыкса, казыйлар яклашмас, хәрәмләшмәс өчен шулай отышлырак.

Ярар соң, битлек икән, битлек. Мостафа да аны һич карышмый киде. Бәйге сызыгына йөзгә якын чаптар чыгып басты. Дүрт чакрымлы ара узасы бар, арадан бер җайдак та бүре куган сыман алга ташланмады. «Бәйге уртасында «Мөбарәк хадим» атлы ерымны үтәсе бар», дип алдан ук кисәткәннәр иде. Имеш, шундый хадим анда үзен-үзе пычак белән суеп үтергән, ди. Шул ерымны узган чакта кайнар табадан читкә сикерешкән борчак урынына бердәм коелдылар. Ерымның ике яры да тоташ кызыл балчык. Иртән яңгыр коеп үткәнгәдер инде, атлар анда аяклана да алмый. Әүвәл бер яктан шуышып төшеп, кибән сыман өелгәннәр иде, каршы ярга үрмәли башлагач та, берсен-берсе сытып бетерделәр. Арадан кайсы да булса елгыррак рәвештә үрмәли башладымы, арттагылар чаптарларны койрыгыннан йә ияреннән сөйрәп төшерәләр. Мондый мәхшәрне күрүгә, Мостафа озын-озак итеп баш ватмады. Ул ерым чокырына ишелеп төшүгә үк үз чаптарын ташлап калдырды да, икенче як ярга җәяүле көенчә үрмәләп кенә менде. Җайдагын ташлап калдырган беренче аргамак текә яр өстендә пәйда булуга ук, шуның ияренә сикереп атланды. Кайсы җайдакның нинди атны иярләп чабуын дәфтәрләргә төшереп торучы казыйлар бармыни? Мостафа мәйданга иң беренче әйләнеп кайткач та, бераз гына аптырашып-чәпчеп алдылар да егетнең ияренә олы төргәк ефәкне китереп ташладылар. Менә шул чагында гына солтан җайдакны үз янына дәште.

— Җиңүчегә шәхси бүләгем бар.

Мостафа чаптарын йөгәненнән җитәкләп солтан хозурына атлый башлагач та, пыш-пыш килеп янда теркелдәгән казыйлар ым ташлады.

— Солтан каршына җиткәч битлегеңне салырга онытма. Бүләген алган чакта җиргә тезлән.

Ә Мостафа каккан казык кебек селкенми дә торды. Битлеген дә салмый, тезенә дә чүкми. Арттан казыйлар касыгына төрткәли, тез артына тибә. Инде Сөләйманның да йөзе кара янып чыкты. Саф алтыннан койган тәпсине[5] баш очына күтәреп сузган чакта гына, үзе дә түзмичә, усал ысылдады.

— Тезенә чүк, мәхлук, битлегең сал!

— Ә ул мәхлук — синең улың булыр, — диде дә, менә шул чагында гына Мостафа битлеген кулларына алды.

— Шаһзадә, шаһзадә! — диешеп, бар мәйдан «аһ» итте.

Сөләйман улына текәлде дә гаҗәпләнеп торды.

— Менә нинди пәһлевандай булып үсеп җиткәнсең син, йә машалла!

Ул Мостафаны берничә мизгелгә генә кочагына алды, аннары каударланып янә читкә этте.

— Йөземә кызыллык китермәдең, монысы өчен рәхмәт...

Баязит бакчасына кайтып кергәч, сарай идәннәрен дөбердәтә-дөбердәтә, Мостафа иләсләнеп-ярсып биеп алды. Абзыйларының йөгәнсез икәнен күрше бүлмәләрдә тупырдашып үскән Мәһруй сеңлесе дә, Сәлим, Баязит, Җиһангир энекәшләре, хәтта ничәмә-ничә еллар буена кырнак[6] кыз булып йөрүче Сания да белә. Шулар бөтенесе, аю биеткәндәй, Мостафа янына ашыгып җыелдылар. Абзый кешенең авызы — колагында, алтын тәпсиен болгый-болгый бии.

— Абзыегыз бүген җайдаклар бәйгесендә иң беренче килде! Солтан-атабыз иң зур бүләкне мин фәкыйрьгә бирде!

Хүррәм балалары булсалар да, Сәлим белән Баязит Мостафаның мондый кыланмышларына күптән күнеккәннәр. Янычарлар мәктәбеннән кайтып кергән саен Мостафа бар белгәнен энеләре алдына чыгарды да түкте. Агач ботагын хәнҗәр ыргытып кыярга өйрәнгәннәр икән, шуны кабатлата. Родос утравының кайдалыгын чамалый башлауга ук, чәчәкләр түтәлендәге туфрак өстенә таяк белән сызгалый-сызгалый, белемен уртаклаша. Ахыр чиктә Баязитны үз артыннан янычарлар мәктәбенә дә илтеп кертте. Сәлим — ялкау, арада иң өлкәне булуга карамастан, ишек ярыгыннан шәрә җарияләрне күзәтүдән башка шөгыль белми. Аның каравы, бөкре булса да, төпчек Җиһангир Мостафаның җилкәсенә менеп атлану өчен җанын фида кылырга да әзер. Асрау хатыннарның, хадимнәрнең ай-ваена карап тормыйча, Мостафа бер Баязитны гына түгел, орчык чаклы Җиһангирны да иярргә күнектерә. Баязит белән Җиһангирның кеп-кечкенә җәяләре дә, аткыч уклары да «яуга китү өчен» күптән әзер.

Гөлбаһар улын мондый беркатлы гадәтеннән биздерү өчен әллә ниләр кылып караган иде дә, Мостафа ыжламады.

— Без бит бер ата балалары, дошманлашып үсмик. Кайсыбызга солтан булырга язган, кайсыбызга зиндан — анысы Аллаһ эше. Ә бүген үк башны ташка орып яшәү — зур чатаклык...

Юк, ана күңеле сизгеррәк шул, дөрес чамалаган. Бәйгедән соң ярты ел чамасы гына узган иде, Сөләйман Мостафаны үз янына дәште.

— Сиңа унсигез яшь тулып килә инде, санап барасыңмы? Мине әткәй синең яшьтә Каффа каласына вәли итеп озаттырган иде. Аннары дүрт ел чамасы Манисcада вәли булып тордым. Инде сиңа да камыт кияргә, жигелергә вакыт. Бик еракка кумыйм. Син дә, әйдә, илгә хезмәтеңне шул ук, мин утырган Манисcадан башлап кара әле. Фәрман әзер, тоткарланмый кузгал.

Әнисенә әйткәч, әлбәттә, Гөлбаһар тоташ күз яшенә чумды гына инде.

— Тагын Хүррәм эше генә бу, шул юха елан эше. Сине пайтәхеттән читкә олактырып, үзенең балаларына тәхеткә юл арчый.

[5] Тәпси — поднос.
[6] Кырнак — сарайдагы хезмәтче кыз бала.

— Синен өзгәләнүләреннән бер файда юк. Фәрман алып кайттым, мин Манисcага юл алырга тиеш, — дип Мостафа ятаган-калканнарын барлый башлагач, Гөлбаһар да, янгын купкан сыман, кием-салымнарына барып ябырылды.

— Хүррәм-аждаһанын катыйллар яллап та синен җаныңны кыюы бик мөмкин. Алтынга сатылган сораннарның ашына агу яисә зәхмәт салуы бар. Бер адым да калмыйм, синең белән барам, балакаем!..

## 29

Сөләйман әле нәсара Карлны гына үзенең бердәнбер дошманы дип санап яши иде, шәрык якта яна елан угын күрсәтте шул.

— Атаң Сәлим солтан үзе исән чакта Баһдад каласын яулап алган иде, андагы Исмәгыйль шаһ ясагын да түләп торды, бүләкләр юлларга да берчак онытмады. Ә малае Такмасып шаһ Каф тау янындагы Тәбриз каласына кереп бикләнде, җиде шыгый кабиләсен үз янына җыйды, алар гаскәре өчен «кызылбашлар» дигән исем уйлап тапкан. Шыгый кызылбашлар Әл-Хатыйб, Мосул, Диярбакыр, Халеб бәйлекләренләге меңәрләгән сөнниләрне суеп үтергәннәр, сөнни мәзһәбендә изге саналучы Әбү-Кадыйр белән Әбү-Хәниф атлы шәехләрнең төрбәләрен җимереп юк иткәннәр. Син килеп өлгермәсән, фарсы мәмләкәтендәге барча сөнниләргә җан бирергә кала.

Әлеге хәбәрне исән көе качкан чапкын кайтып әйтте. Ә Такмасып шаһ Сәлим солтан Баһдадта калдырып киткән илчеләрне дарга аскан икән. Сөләйман колагына кайтып ишетелсен өчен, кара, нинди коткы сүзләр дә сөйләгән бит әле:

— Сөләйман мадьяр җирен тез чүктерергә дип әтәчләнеп баргач, Бөек Карл белән Фердинанд корольләр аның койрыгына ут төртеп кайтарды бит. Мина килә икән, сакал-мыекларына тикле көйдереп җибәрермен!..

Ал-лай! Үзен төрек солтанының колы дип санамый, буйсынудан, баш июдән туктамакчы, димәк. Сөләйманның яуларыннан кычкырып та көлгәч, аны кимсетмәкче, үзен дөньяның кендеге итеп күрсәтмәкче булып масаядыр инде. «Кыйналасы килгән ишәк үзе таякка килеп ышкына», ди, ярар алай булгач.

Бер кышны гына тыныч-имин үткәргән һәм иге-чиге булмаган каһанлыкның һәрбер почмагына тагын яна фәрман тоткан мөнадилар[7] очты.

— Һәр вилаятьтән бишәр мең нәүкәр җыеп, Басра каласы янына озатырга! Янычарларга Ван күле ярлары буйлап кичекмәстән юлга! Фарсы култыгында тупланып бетү өчен бер ай гына вакыт!

Сөләйман үз янына иң беренче итеп, билгеле ки, Ибраһимны дәште.

— Юлга җыен. Бушбугаз Такмасып Тәбриз каласы диварлары артына кереп качкан. Тәбризгә җиткәнче, Арарат, Әл-барс тауларын, Төрбән каласы янындагы Тимер Капканы[8] да үтеп чыгасы бар. Ермак алай булып алдан син барырсын. Янычарлар белән мин синең эзеңнән үк килеп җитәчәкмен. Елан үлгәч кенә тураям шул, бу Такмасыптан нәселен корытып котылырга кирәк.

Ибраһим солтан сараеннан да чыгып өлгермәде, Сөләйман янына арт бүлмәдән генә Хүррәм үтеп керде.

— Син Ибраһимны койрык сымак үзенә тагып йөреп, ирәйтәсен бугай, солтанкаем. Бер тәртә арасына ике ат җикмиләр, ә син үзеңә тиеш данны һаман-һаман Ибраһим белән урталай бүлешәсең. Юлда алай-болай булып куйса, аның юрганны үз ягына тарта башлавы бар. Ана күз-колак булып, һәр адымы турында сиңа хәбәр юллый торган ышанычлы кешеләрне тагып җибәрү зыян итмәс иде, минемчә.

[7] Мөнади — мәйданнарда фәрманнарны кычкырып укучы, глашатай.
[8] Әл-барс — Эльбрус. Төрбән — Дербент. Төрбән үзе — төрки халыклар элек кия торган биек баш киеме. Тимер Капка — Дербент каласы янындагы ерып чыккысыз тауларны элек шулай атаганнар.

— Ярый, таянырдай кеше тап алайса, — дип Сөләйман ияк каккан иде, Хүррәм шундук баш казначы янына чыгып очты.

— Без инде биш-алты ел буе барча серне уртак бүлешәбез, — дип сайрады Хүррәм казна сакчысы Искәндәр колагына. — Софиядәге сарайны төзетүгә киткән чутсыз алтын көшелләре турында син солтанга бер кәлимә сүз дә җиткермәдең, мин дә синең кулләгәнә таш атмадым. Тишек юрганны хәерчеләр генә тарткалап өзгәлиләр, ә безнең казна төпсез, берүк күз тимәсен.

Искәндәрнең күзләре төнге ябалакныкыдай акайса да һични анламый утыруын күргәч, Хүррәм юха тавыш белән һаман пышылдады.

— Яуга түгелгән алтыннарны берчакта да санап интекмиләр. Яу кыры — ул капкачы ябылган караңгы баз төсле, аның төбен сынар эт тә күрми. Мин әле генә солтанны үгетләдем, ул сине Ибраһим пашаның казначысы итеп җибәрәчәк. Мин пайтәхеттән аккан алтыннарны күздән ычкындырмыйм, син тегендә һәр тарафка күз-колак бул. Исәп-хисап кәгазьләре синең кулда, без элек тә аларны бергә-бергә бик аз шомартмадык. Бу юлы да шома эш итәрсең. Иң мөһиме — һәр чыгымны Ибраһимга аудар, аны майла. Иллә мәгәр берчакта да йоклап йөри торган булма, кирәк икән, якалашып алулардан да һич тайчынма. Чәчең агармасын, монда мин яклармын...

Өч көннән соң Ибраһим белән Искәндәр пайтәхеттән ерак юлга чыкты. Казнасыннан бигрәк михнәтләре күп тапкырлар авыррак иде шул, Каф тавын үткәндә өч ай чиләнделәр. Каф тау татарларының Тәукил атлы бәйлегенә кергәч, ярый әле кабилә башлыклары әмир Голәм үзе каршылады.

— Солтан галиҗәнапләренә караганда Такмасып бездән салымнарны ун мәртәбә күбрәк итеп сава. Кулыннан килсә, ул таштан да йон кыркыр иде. Тау татарларындагы бер генә кабилә дә Такмасып олтаны астында михнәт чигү белән разый түгел. Һәммәбез дә солтан галиҗәнапләрен капкаларны ачып каршыларга әзер.

Әмир Голәмнең төрек гаскәрен таулардагы иң яшерен юллар аша ияртеп килүен белеп алуга ук Такмасып шаһ Тәбриздән үзбәк далаларына, кичә генә кан дошманы саналган Шәйбани хан куләгәсенә чыгып качты. Аның җансакчылары үзе белән качкан, ә калага көчли-көчли куып китерелгән яллы алайларның кан коярга исәбе юк иде. Тәбризлеләр кирмән капкаларын шәрран итеп ачып каршылады. Ә мәйдандагы күтәртмә өстенә менеп алгач, әмир Голәм Ибраһим пашаны гайреләрдән-гайре тәкъдимнәре белән гүя өтеп алды.

— Каф тау мөселманнарының барча кабиләсе синең алда баш иярга әзер. Син — ерак Мисырга да, мадьяр җиренә дә яулар чаба-чаба шөһрәт казанган ир. Сиңа Каф тау татарлары солтан дәрәҗәсен бүләк итә. Шуны кабул кылып алсаң иде, Ибраһим сәргаскәр галиҗәнапләре.

Ибраһим мәйдан уртасында, меңнәрләгән күз каршында тораташтай калды, тел тибрәтеп җавап кайтарырдай кодрәт таба алмады. Ул арада инде үзләре дә иләсләнгән татар яугирләре дә, төрек нәүкәрләре дә күзләре томаланган мал шикелле мөгрәп кычкырдылар.

— Сөләйман диңгез юлбасары Хәйретдингә дә Алжир солтаны дигән ат бирде бит әле. Ә син яуларда чыныккан зур сәргаскәр. Яулаган җиңүләрең санап бетергесез, сиңа да «татарлар вә фарсылар солтаны» дигән зур дәрәҗә тиеш. Син моңа лаек, лаек, Ибраһим паша, ризалык бир!

— Безнең Сөләйман солтаныбыз бар, ул «Шәүкәтле» һәм «Кануни» дигән дәрәҗәләр йөртә. Күк йөзендә ике кояш булмый, миңа «солтан» дәрәҗәсен алу олы гөнаһ. Моның өчен Сөләйман да гафу итмәячәк, — дип, үзенә калса, хәтәр каты кычкырып каршы төште Ибраһим, әмма мәйдан янартаудай шаулый, андагы халык ялгыз тавышны ишетерлек хәлдә түгел иде.

— Син — солтан, безнең солтаныбыз! Үзенә илтотмыш олугбәкләребез булган Насретдиннәр нәселеннән калган тажны кидерергә рөхсәтен бир!

«Ярамый, ярамый, Сөләйман моның өчен сине гафу итмәячәк, — дип пышылдады Ибраһимның күкрәгендә жанының бер яртысы, ә икенчесе үзенчә иттереп, мәкерле агулады. — Ә чынында син дә солтан дигән дәрәжәгә лаек. Сөләйман бер генә яуга да берьялгызы көе чыкмады бит. Янында, калкан шикелле, гел син басып йөрдең. Ермак алайда — син, яуга ташланырга дисә, тагын син — иң беренче. Асылына баксаң, ул һәрчак син аскан казан янында гына жылынган бит, шөһрәт шулпасын да берьялгызы эчкән. Һаман-һаман нишләп шулай тиеш? Халык дөрес сукалый, ул Хәйретдингә солтан дәрәжәсен өләште бит әле. Нигә мине үги итә һаман? Мин — аның кияве. Солтан дәрәжәсенә мин дә лаек лабаса!»

Ургылып аккан яшь бөртекләрен ерып күзен ачкан иде, ана таба кулларына асылташлары белән жем-жем уйнаклаган тажны тотып, әмир Голәм якынлашып килә. Ә мәйданда урман шаулагандай, күк күкрәгәндәй бертуктаусыз тавыш.

— Син — Каф тау татарларының солтаны, безнең солтан!

Ибраһим әмир Голәмнең кулларын читкә этәрергә кодрәт таба алмады. Аның баш түбәсенә инде таж эленгән, халык жиргә тезен чүккән иде...

Тәбриздәге шаһ сараенда ялгыз калгач, аны Искәндәр генә болытлар өстеннән сөйрәп төшерергә жөрьәт итте.

— Ә син хаталандың, Ибраһим паша, аһ, ялгыштың! Мин синең бу жинаятең хакында Сөләйман солтан галижәнапләренә хәбәр юлламыйча кала алмыйм.

Менә шушы мизгелдә Ибраһим үзенең чыгырдан чыгуын да, бизмән жуюын да аңларга өлгермәде. Кинәт кенә карчыгадай сикереп кузгалды да Искәндәрнең өстенә ябырылды.

— Хөррәм солтанбикә белән икәүләшеп казна коесында нинди этлек кылып ятуыгызны белми дисезмени? Мин жинаятьче түгел, мин солтан дәрәжәсен яу кырында каннар коя-коя яулап алдым. Ә син, аның белән бергәләшеп, харам юллар аша ил казнасын саудың. Мин иртәгә, юк-юк, бүгеннән үк син әрәм-шәрәм итеп бетергән казнаны тикшерттерәм. Сынар гына дукат югалса да, дар агачы сиңа, дар агачы!

Сәргаскәр кеше шәхсән үзе әмер биргәч, иртәгәсен тикшерүчеләр казна дәфтәрләрендәге хыйлаф адымнарны тиз таптылар. Ибраһим Искәндәрне сарай бакчасына көйләнгән дарга чыгарып асарга, дигән фәрманны тамгалады. Бичараны жанкыярлар инде ишек төбенә таба сөйри башлаганнар иде, Искәндәр кыяр-кыймас кына аваз бирде.

— Мин үлемнән курыкмыйм, әмма дарга менгәнче бер гозерем бар. Миңа бер бит кәгазь белән каләм кисәге бир. Бу — дарга менүченең соңгы үтенече. Шәригать кануннары буенча, син минем соңгы үтенечемне үтәргә бурычлысың. Моны сиңа Коръәни Кәрим дә шулай куша.

— Ярар, бирегез шуңа берәр ертык кәгазь аламасы! — дип теш арасыннан гына сытып әмер ташлады Ибраһим, ә Искәндәр күз алдыннан чыгып югалуга, янә онытылды.

## 30

Сөләйман Тәбриз каласына көз кергәндә генә килеп житте. Фарсылар башкаласын корбаннарсыз гына кулга төшерүдән бик канәгать иде, килеш-килбәтендә ярсу чагылмады. Шулай да, солтан булгач, ул һәр яңалык белән хәбәрдар шул. Шымчылары хәбәрләрне суга салган борчак кебек бүртеребрәк бәян иткәннәрдер, Ибраһимга хәтәр дорфа дәште.

— Баш казначы Искәндәрне тиктомалдан дарга астыргансың, аның белән ниләр бүлешмәдең?

— Ул ярты казнаны каядыр олактырган. Тикшерүчеләр төзегән дәфтәрләр шул көе. Үзләре дә исән. Миңа ышанмасаң, чакырттыр да сораш. Ә казнаны талап яткан карактан кулын чабып кына ил кадәр ил казнасына байлыкларны кире кайтарып булмый. Черек тешне суырып алып кына котылалар. Син үзең игълан иткән кануннар да нәкъ шушыны раслый.

Ибраһимның судан бик тә коры чыгуы үтенә тиде, ахры, Сөләйман, теше сызлагандай, казналарын уйнаткалап кына дәвам итте.

— Дарга менәр алдыннан Искәндәр бәй хат сырлаган, диләр, анысын юк иттенме?

Ибраһим бу юлы эчтә нинди мәчеләр тырнаганын тышка сиздермәде.

— Нишләп юк итим, ди? Ул бит хатын сиңа атап язган. Ничек итеп мөһерләгән булса, аны шул көенчә саклап йөрдем. Менә, үз кулларың белән ачып укы.

Мөһер ватып, хатның юлларына күз йөгертә башлагач, Сөләйманның йөзен зур пәрәвез каплагандай булды. «Ибраһим синең белән янәшәгә, күк йөзенә менеп, үз-үзенә солтан атын алды. Тагын форсат туса, аның сине тәхетеннән чәнчелдереп куюы да мөмкин. Ул астыртын җинаятьче, берүк сак бул...»

«Әһә, — дип уйланды Сөләйман, хатны тоткан килеш күзен йомып. — Ибраһимның җинаяте тулысынча исбатланып тора, аны Искәндәр эзеннән үк дарга озатсаң да, гаеп ташлаучылар булмаячак. Искәндәр алда тагын Ибраһимның этлекләрен бәйнә-бәйнә итеп язып калдырырга өлгермәдеме икән?»

«... Ибраһимның казнаны туздыруда минем өскә гаеп ташлавы да гел урынсыз. Гөнаһым юк. Тәбризгә килеп җитмәгән сәрмая турында солтанбикә сөйләп бирә ала...»

«Әттәгенәсе! — дип сүгенде Сөләйман, хатны ерткалап ташлаудан чак тыелып. — Аһ, кабих җан, мәкер тулы соран! Казна туздырудагы гаебен солтанбикә тарафына аудармакчы була. Ләкин, һич тә көтмәгәндә, дөрес булып чыкса? Хүррәм гаебен таныса, Ибраһим Искәндәрнең җанын кыйган кебек, мин дә солтанбикәм муенына дар элмәге астырырга тиеш. Ул чагында... ул чагында бүген минем Ибраһимны дарга озатырга хокукым юк. Әлегә бернинди дә хәвеф килмәгәндәй кыйланмыйча булмый. Тавык урынына чалып ташлау беркая да качмас, хәзергә канатларын җилпеп очынган булсын, әйдә».

— Гаскәргә әмер бир, Баһдадка төбәләбез! — диде солтан, карашына бернинди дә тойгы чыгармыйча. — Атай тапкан — мал түгел, дип Сәлим солтан яулап биргән калҗадан баш тарту муафыйк эш булмас. Җим өстенә менеп тибенгән тавык кебек сөмсез кыйланулар һич ярамый безгә. Кикеренә башласаң, бер байлыгың калмас. Шигыйларны да тулысынча тезгә чүктерергә вакыт.

Ибраһимның эченә дә, ниһаять, җылы өмет йөгергәндәй булды. Сөләйман җанкыярлар чакыртып вакланмады, хәвеф болыт сыман үтеп китте бугай...

Баһдад каласына кыш кергәндә генә барып өлгерделәр. Утлы табага эләгүдән шүрләп, башкисәр шигыйлар чыгып качкан, шәһәрдә сөнниләр генә торып калган, ахры, кала Сөләйман гаскәрен капкаларны ачып каршылады. Дар агачлары тезүнең хаҗәте юк, Сөләйман төп эшне, барча фарсы имамнарын-ахуннарын җәмигъ мәчетенә җыеп, вәгазь сөйләүдән башламакчы булды.

— Сезнең мәмләкәттәге ярты диндар — сөнни, ә калганы шигый. Алар тайгак юлда. Коръән Кәримнең астын-өскә китереп, анда саналган унике пәйгамбәребезне дә дегет белән буяп бетерделәр. Алар бер Галине генә изге пәйгамбәргә санап саташалар. Хаталанган ул кавемне дә Хак Тәгалә юлына күндерергә кирәк. Мөселман дөньясы шушы ике агымны бер үк эзгә бастыра алмый икән, ул дилбегәләре өзелгән олауга утырган әрвах шикелле, берчакта да туры юлны таба һәм үзара дошманлыктан арына алмаячак. Мөхәммәд

галәйһиссәлам дә хаталанучыларны сөннилә юлына кайтару өчен бар гомерен биргән. Үзеннән соң шушы ук изге гамәл өчен анын мөридләре шәһид киткән. Сөнни пәйгамбәрләребезне, аларның мөридләрен байрак итеп күтәрергә кирәк. Шул чагында хаталанган кавем дә без янарткан сукмакларга күнәр. Мин әле юлда чагында ук кат-кат исәпләп һәм хәйран калып киләдем. Мөхәммәд галәйһиссәламнең шәхси әләмчесе булган Әюб моннан тугыз гасыр чамасы элек үк Истанбулны Рум баскыннары кулыннан тартып алып, аны мөселманнар кулына кайтару хакына шәһид булган икән. Анын җәсәден мөридләре Баһдад зиратына кайтарып җирләгәннәр, шуны безгә эзләп табу һәм янарту фарыз. Шыгыйлар төрбәләрен җимереп бетергән Әбү-Кадыйр илә Әбү-Хәниф каберләрен дә ачыкламый һәм янартмый булмас.

Сөләйман коры вәгазь белән генә канәгать кала алмады, дистәләгән имамнарны Баһдад читендәге зират ташларын актарырга куды. Ходайга мең шөкер, мөдәррисләр, дамеллалар, язуларга карап, кайсы ташнын кайсы чорда куелуын гына аерала әле. «Алты йөз дә кырык, алты йөз дә житмеш саннары[9] чокылган кабер ташларына юлыктык без», — дигән хәбәр алуга ук, Сөләйман солтан кош тоткан сабый шикелле очына-очына үзе килеп житте.

— Каберләрен актармыйча, җәсәдләрен кузгатмыйча гына булмастыр шәт.

— Әрвахларнын җәсәдләрен кузгату — зур гөнаһ ла! Монын өчен зәхмәт сугу гына түгел, Ходай Тәгаләнен дә үч алуы мөмкин, — дип мөдәррис-муллалар кыймый торгач, Сөләйманнын ярсудан уртлары уйнаклады.

— Нәсаралар ничәмә-ничә попларынын, кенәз-бәкләренен җәсәд калдыкларына, иконага, шәмгә, ачуым килмәгәе, тизәгенә чаклы потларга табынганнан уздырып табыналар. Ә без ин-ин олы пәйгамбәрләребезне дә изгеләрдән санарга хаклы түгелмени? Нәсараларда гомер буе аракы чөмергән, зина кылган йөзләгән поп — изге, ә без пәйгамбәргә тин шәехләребезнен дә каберен оныттыйкмы?

Юк, Сөләйманны ниятеннән биздерү дә, кире чигерү дә мөмкин түгел, анын күзләре үк учак сыман дөрләп яна иде.

— Казыгыз! — диде ул, бармакларын сөнге сыман төртеп. — Пәйгамбәрнен җәсәдләрен җир өстенә ватмый күтәрегез. Аларны ул, бүтән әрвахларны, сонрак ачыкларбыз.

Солтан казу эшләрен тәмам кылганнарын кымшанмый да көтте. Күк йөзеннән янгыр сибәләп тора, ачы җил сызгыра, ә ул кыя сыман. Җәсәдләрне чатыр эченә кертеп салгач кына табибларга дәште.

— Әләмче Әюбне дә, Әбү-Хәниф шәехне дә, ерак араларда исләнмәсен өчен, мускус белән сылап кайтарганнар. Шуны ачыклагыз.

Табиблар канәгатьләнеп ым кагуга, чираттагы әмер.

— Җәсәдләрне зират башындагы, әнә, теге ачык, зур мәйданнын түренә күчерегез. Каберләре өстенә төрбә ясаттырам, яннарына чишмә казыттырам. Алар — безгә аталарыбыз шикелле үк якын, маяк тиеш җаннар. Каберләренә хаҗга баручылар да, гади узгынчы да искә алган саен килеп табынырлык булсын...

Бар мәшәкать үтеп киткәннән сон, анда да әле шүрли-шүрли генә Ибраһим сораштырды.

— Нәсара руханилары белән бер үк рәткә куеп, әләмче Әюбтан изге ясап йөрү нигә инде сина?

— Мин үзем дә мәнгелек түгел ләса. Минем каберне дә һәркем оныттсынмы? — диде Сөләйман, күз дә йоммый гына.

«Һәр гамәлнен үз корты бар, дигәндәй, Сөләйманны янә Хүррәм алдан ук

[9] Григориан календарена күчерелгән еллар.

шушы эшләргә котыртып юлламады микән?» — дип үзалдына гына нәтиҗә ясады да, Ибраһим үз уйларын керпе сыман бөгәрләнеп йотты...

Яз керүгә, Сөләйманны шәрык яктан ауган яңа бәла генә болытлардан җир өстенә төшереп куйды бугай.

— Такмасып шаһ Тәбриз каласын яңадан яулап алган!..

Сөләйман янә ияренә сикереп менде, ләкин, иң әүвәле, Баһдадтагы һәрбер бәк белән имамнарны шаһның иске сарае каршына җыярга боерды ул. Мәйдан умарта күчедәй гөжли башлагач кына, солтан үзе күперчеккә менде. Халык тын калуга, мөнадиларның азан укыгандагы сыманрак тавышы яңгырады.

— Сөләйман солтан фарсы мәмләкәтендәге Бәхрәйн, Хуҗистан, Басра белән Луристан бәйлекләрен үзенең вилаятьләре, дип игълан итә. Моннан ары алар солтан галиҗәнапләре Истанбулдан юллаган вәлиләр аркылы идарә ителәчәк. Халыклардан җыйган гошер салымы да пайтәхеткә юнәлергә тиеш...

Ил агалары Сөләйманны тагын, кыйналып ташлаган шикелле, сыңар сүз дә әйтергә кыймыйча, мал көтүе сыман өелеп озатырга мәҗбүр булды.

Юл өстендә Сөләйман Диярбакыр, Халеб атлы калаларны буйсындырып узды, дәрте гаярь иде. Өстәвенә, Каф тавына да җитә алмадылар, сөенечле хәбәр каршылады.

— Такмасып шаһ янә Шәйбани хан итәге астына чыгып качкан...

Сөләйман сәхрәдә бер тамчы суга тилмереп беткән сәйях кыяфәте белән кул селтәде.

— Этнең аксап йөрүе — бүре күргәнче генә, ди. Ары таба бармыйм, Ибраһим бәй, Истанбулга китәм. Сәхрә буенча шәүлә куып йөрүләрдән гарык. Тәбризгә үзең генә барып җит тә янә бер мәртәбә тезгә чүктереп кайт...

Топкапедагы Мәхмүт Фатыйх мөһере ясалган мәрмәр капканы атлап керүгә үк Сөләйман солтан яңа фәрман бирде.

— Баһдад каласыннан Мөхәммәд галәйһиссәламнең яу кылычын, аның аяк эзе төшкән ап-ак ташны, бер уч чәчен, гәрәбәгә төшерелгән шәхси мөһерен, көмеш тәхетен, Мөхәммәднең иң тугры иярченнәреннән саналган Әбүбәкер, Гали, Гомәр, Госман пәйгамбәрләрнең ятаганнарын, чапаннарын, чалмаларын җыеп алып кайттым. Шәрык яктагы дивар буенда өр-яңа бер сарай күтәрегез. Шунда изге динебезгә багышлап, аерым күргәзмә залы ачачакмын...

Яңа сарай әзер булуга ук, мөселман дөньясының һәрбер почмагыннан диярлек шәйхелисламнарын, ахун-мөфтиләрен кунакка чакырттырды. Топкапе мәйданы меңәрләгән инсан белән тулгач, сорнайлардан да куәтлерәк аһәңеннән бигрәк үзе үк бәян иткән фәрманнары белән Сөләйман солтан бар мөселман илен шаккатырды.

— Мин үземне Хак Тәгаләнең җир йөзендәге хәлифе, дип игълан итәм. Бүгеннән башлап һәрбер мөселманның яклаучысы, таянычы булам. Мин — нәсараларга каршы изге сугыш ачкан яугир генә түгел, моннан ары изге ислам диненең уяу сакчысы һәм корыч калканы да булып торачакмын...

Мәйдандагы меңәрләгән инсан шылт иткән дә тавыш чыгармады, һәммәсе дә сүзсез генә амин тотып куйды. Сөләйман солтан хак гамәлләр кыла, җир йөзендә асылда да бүген аның белән янәшә бастырырдай шөһрәтле һәм гаярь мөселман юк иде.

## 31

Ир-ат бик еш кына сабый бала сыман беркатлы шул. Сөләйман да буранлы-тузанлы ерак сәфәрдән соң Хүррәм солтанбикәнең кайнар кочагына башын төрткән иде, мәрхүм Искәндәр казначының әманәт хатын шуның кулларына чыгарды да бирде.

— Искәндәр югалган казнаның яртысы турында синнән сорашырга кушып калдырган, мә, укып бак.

Бүлмәсенә бикләнеп хатка күз төшергәч, Хүррәм тиргә батты. «Аh, мәкерле соран! Елан, хыянәтче! «Тәбризгә килеп житмәгән сәрмая турында солтанбикә сөйләп бирә ала», имеш. Шушы сүзләрне кәгазьгә төшереп калдырудан гына, йә, ни откан? Ибраhим паша аны барыбер дә дарга астырган бит. Ир икәнсен, сер ачмыйча, салам урынына хатын-кыз итәгенә ябышмыйча гына олак иден, кабих! Ә хәзер солтанга нинди генә җавап кайтарырга? Үзем өчен салам булырдай ни төрлерәк хәйлә табарга соң?»

Хүррәм, лышык-лышык килеп, елап алды. Сазлыктан ябышып чыгардай аркан очы һаман табылмады. Үзе дә анлап бетерә алмыйча, Искәндәрнен хатын кат-кат әйләндерде.

«Балавыз сыгудан тукта әле, тукта, солтанбикә. Нәзер итеп, әнә, казначы тагын нинди җөмлә язып калдырган бит. «Ибраhим үзенә солтан дәрәҗәсен алды.» Әh-hә! Димәк, юаш, басымчак булып кыйланган Ибраhим Сөләйман тәхетенә менеп утыру турында хыяллана. Сәфәрләрдә чакта Сөләйман белән ул-бу була калса, Ибраhим үзенә инде сукмак салып куйган. Хакимлек тә, хакыйкать тә көчле кулында ул. Тәхет хуҗасына элмәк кидермиләр. Ибраhим Сөләйман җәсәде белән кайтып керсә һәм казнаны ачса, Истанбулдагы сатлык байчура белән шәехләрнен аны каhан итеп сайлавы да мөмкин. Аклану өчен нигезе дә саллы, чөнки Ибраhимнын «Каф тау татарларының солтаны, Насретдиннәр солтаны», дигән аты да бар, имеш...»

Җәй азагында Истанбул юлында вәзир Ибраhим пәйда булуга ук, Хүррәм Сөләйман янына чәчрәп керде.

— Солтан кайта, Ибраhим атлы солтан кайтып килә! Истанбул халкы нишләп яңа солтанны туплардан атып, ярларга тезелеп каршыламый әле?

— Ни сөйлисең, Хүррәм? Нинди солтан тагын? — дип Сөләйман күзләрен акайтуга, зәһәр төтен сыман талаган кара хөсетлектән котыла алмыйча, Хүррәм тагын элеп алып китте.

— Бәрәкалла, соң син үзең Ибраhимны үз тинең итеп, солтан итеп таныгансың лабаса! Танымаган булсаң, аны күптән дарга асар идең. Ә Ибраhим айгыр кебек исән-сау бит, әнә, вәзир, паша гына түгел, солтан дигән дәрәҗәсенә хәтле исән! Әгәр бүген берәр әзәри йә фарсы «солтаным», дип аның аяк астына егылса, хәтта синең дә теге колны җирдән сөйрәп торгызырга хокукын юк. Чөнки Ибраhим да — солтан, ана Каф тау татарлары белән фарсылар Тәбриздә таҗ кидергән.

Сөләйман кара көеп чыкты да, шашкан төсле сикереп, тәхетеннән купты.

— Юк, күк йөзендә ике кояш булмый, Ибраhимны мин бүген үк дарга озаттырам!

— Ә менә бер хата артыннан икенчесен ясарга һич ярамый, — дип Хүррәм Сөләйманның кулларын күкрәгенә кысты. — Ибраhимны дарга озатырга бер нигез юк. Ул Тәбризне ике тапкыр яулап, синең каhанлыкка яңа вилаятьләр өстәп кайтып килә. Истанбулдагы кара гавам өчен Ибраhим — илне баетучы шәп сәргаскәр. Ә гавамга Ибраhимнын солтан дәрәҗәсе йөртүе турындагы хәбәрне ишеттерү гөнаh. Без капчыкта ятмый, аның иртәме-соңмы тишеп чыгуы бар. Истанбул халкы Ибраhимнын солтан дәрәҗәсе турында ишетеп өлгергәнче, аннан тавыш-тынсыз гына котылу хәерлерәк.

— Берәр катыйлны яллап озаттырам, — дип Сөләйман инде ныклы карарга килсә дә, Хүррәм иплән кенә үзе йомгаклады.

— Юк-юк, солтанкаем, пайтәхеткә кергәнче үк түгел. Күзенә төтен җибәрсән, халык тиз алдана. Җиңү яулап кайткан баш вәзирен хөрмәтенә синең сараеңда мәҗлес оештырыйк. Дивандагы бер вәзирне дә калдырма, пашаларны чакыр,

шәехне дәш. Ибраһимга иң соңыннан гына хәбәр җибәрерсең. Яраннарың алдында аны мактамыйча, данламыйча булмас. Шәраб-сөҗеләрне кызганып тормасыннар, елга булып аксын. Исергән бәндәнең тамак төбенә сөяк тыгылырга мөмкин, шәрабтән агулануы һәм, хәтта, аягы таеп егылуы, баш яруы мөмкин. Җае чыкмый калмас. Тик соңыннан мәетне халык күзенә күрсәтмичә булмый. Солтан галиҗәнапләренә күләгә төшертергә ярамый бит...

Истанбул җинүче гаскәрне кирмән тупларыннан атып каршылады. Ибраһимны шундук Топкапега, солтан сараена чакырттылар. Вәзир сарай тупсаларын һичбер төрле мәкер уены турында шикләнмичә, башын текә тоткан хәлдә атлап узды. Тәхет залының ишекләрен ачса, анда мәҗлес, диван, илнең иң каймагы.

— Синең җиңү яулап кайтуың хөрмәтенә корган мәҗлес бит бу. Син — мәмләкәтнең иң зур таянычы, син — Зөлкарнәйн белән янәшә бастырырдай зур сәргаскәр! — дип кычкыра-кычкыра, Сөләйманның каршына утырттылар.

— Уң кулым син минем, бердәнбер җан дустым, аркадашым! — дип хәтта Сөләйман үзе дә аны кочагына алды, юешләнгән борынын төрткән булды.

Салпы якка салам итеп кыстырган сүзләре байтак яңгырады:

— Баш вәзир, сәргаскәр, солтан кияве, иң олы җиңүләрне яулап биргән паша...

Шәраб касәләрен туктаусыз яңартып тордылар, бер Ибраһим гына исермәде. Төн уртасы җиткәч, вәзир белән пашаларны берәм-берәм озата башладылар. Зал бушауны чамалап, Ибраһим да аягына басты. Шул чагында шәхсән солтан үзе көтелмәгән хөрмәт тәкъдим итте:

— Мин сине беркая да җибәрмим, кияүкәем. Син солтан сараенда кунарга калачаксың. Урын-җирең әзер.

Мондый хәлнең гомердә булганы юк, Ибраһим уклау йоткан шикелле сүзсез катып калды. Сөләйман янында шәйхелислам утыра иде әле, зәнҗи хезмәтчеләр Ибраһимны сарай баскычлары буенча алып китте. Әле түшәккә менгәч тә, үзенә карата солтан күрсәткән хөрмәткә ышана алмады ул. Күзенә дә йокы әсәре кереп карамады.

Беркадәр арадан соң ишек аръягында әүвәл аяк кыштырдаган авазлар, аннары акрын гына пышылдау тавышлары яңгырап ишетелде.

— Ибраһим француз короле Франциско белән элемтәгә кергән, тегесе гаскәр юллагач, солтан тәхетенә утырмакчы булган...

Ибраһим урыныннан сикереп, ишек тышына атылмакчы иде, өлгермәде. Ул түшәктән кузгалуга, бүлмәгә айгырдай гайрәтле ике-өч ир атылып керде дә аны муеныннан буып алды. Дистәләгән орышларда җиңеп чыккан яугир тыпырчынып караган иде дә, усал куллардан ычкыналмый тынды...

Ибраһимның кара көеп чыккан гәүдәсен иртән бакча түреннән, дивар астыннан табып күтәрделәр. Яман гайбәт Истанбулның күген кара болыт сыман каплап үтте:

— Вәзир эчеп үлгән, исерек булгач, кирмән капкасын да таба алмаган, ди.

Сөләйман Ибраһим җәсәден Галата бистәсендәге дәрвишләр зиратына илтеп җирләттерде. Вәзир кәрван-кәрван алтын төяп кайткан булса да, кабер өстенә таш куярга сыңар гына дирһәм дә табылмады.

## 32

Җан көйдергеч, күңелсез хәбәрләр чир белән бер, яман шеш шикелле уяна да талый. Шундыйларның берсе тагын Сөләйманны утлы табага бастырды да куйды.

— Карл Африка ярындагы Тунис атлы портны яулап алган.

Бу явызның яуга әзерләнүе турындагы имеш-мимеш элегрәк тә ишетелгәләп

торды. «Испан короле Рум аксөякләреннән, алман, варяг, норман, хорват, саксон кенәзләреннән, үзенең энекәше Фердинандтан да таләп итә-итә олы гаскәр җыя. Бар җиһанны католиклар тез астына сузып салырга антлар эчкән король Мальта утравында күрелмәгән флот төзетә башлаган, ди...»

Валлаһи да тынмады бу көфер. Сөләйман бергә-бер чыгып орышырга чакыргач, астына әкәй иткәндәй тын чыгармый качты. Ә үзенең оясына кайтып бикләнгән иде, көчек сыман, төрек солтанының шәүләсенә өрә. Тунис порты — Сөләйманның күз уныннан бик еракта, Урта диңгезнең көньяк ярына сыенган бер кала. Ул вилаятенә барып житү өчен солтанның үзенә тулы бер ай кирәк. Сөләйман ихатасының ул як коймалары жилдә уйнаклыйдыр, дип өметләнгән бугай, куркак Карл шуна төрек калжасын элэктереп калырга җөрьәт иткән инде. Алай дисәң, Сөләйманның Урта диңгездә сакчы колы бар бит. Солтан дәрәҗәсен дә кызганып тормыйча, ул Хәйретдин атлы юлбасарны Алжир каласына бәйләрбәк һәм вәли итеп илтеп урнаштырды. Тунис аның ыстаныннан кул сузымында гына. Ул җирән сакал нишләп үз вакытында Тунисны яклап калырга гаскәр юлламаган да, нигә шундук Сөләйманнан ярдәм сорамаган? Һәр тарафта уянып ысылдаган еланнарны сыту өчен шәхсән үзе торып йөгерергә төрек солтаны ау эте дә, сасы көзән дә түгел, ләбаса. Җирән сакал ничек йоклап калган? Элеккеге казанышларына карап тормыйча, ул диңгез карагын җәллад ыстаны өстенә сузып салырга, төпченергә кирәк. Камчы тәмен оныта башлавы бар, Хәйретдинне пайтәхеткә чакыртып айнытмыйча булмас...

Паша, бәйләрбәге, солтан дәрәҗәләрен яулаган Хәйретдин Алтын Мөгез култыгында бер айдан соң гына пәйда булды. Гомер буе ачык авыз узгынчыларны талап кәсеп иткән юлбасар — шомарган таш. Хәйретдин кияү егетедәй бизәлгән кырык карабыннан ярга бүләк артыннан бүләк ташыта башлагач, моны тамаша кылырга дип җыелган пайтәхет халкының һәммәсе «аһ» итте.

— Җиһанның барча почмагыннан сайлап җыелган сылулардан-сылу бер мең җария кулындагы алтын тәпсиләрдән энҗе-мәрҗән коела башлар сыман.

— Янычарлар мәктәбенә бүләк итеп китерелгән биш мең малай күтәргән тәпсиләрнең барысы да алтын тәңкә белән шыгрым тулы.

— Даладагы кәрван урынына тезелешкән бер мең дөя өркәчләре арасына ефәк, парча, бәрхет тукымалардан гүя тау өйгәннәр.

— Түмән хәтле түмәннәрне дә йомычка урынына сытып үтәрдәй ике йөз фил.

Иң соңгы бүләк итеп Хәйретдин карабтан сөт чишмәсендә коендырылгандай ап-ак төстәге айгырны житәкләп чыгара башлагач, халык телсез калды. Әстәгъфирулла вә бәрәкәтуһ... Ходай Тәгаләнең шушындый да гүзәл, камил җимешләре булса да булыр икән!

— Ярхәмкалла, ярхәмкалла! — дип укынды Сөләйман үзе дә, төп бүләктән күзен аера алмыйча.

Ә айгыр, җир өстенә төшеп житүгә үк, «мин менә болай итеп тә шаккатырам», дигән төсле, әле алгы аякларын югарыга чөеп уйнаклады, әле арткы аякларына баскан көе адәм баласыдай атлап теркелтәде. Аннары башы белән койрыгын вәкарь чөеп, базардагы чегән аты сыман биеп йөрде. Тамаша азагын, солтан каршына тезләнгән шикелле, алгы аякларын аңа таба сузып, башын түбән иеп тәмамлады. «Әстәгы»ның, «машалла»ның берсен дә калдырмыйча, халык соклануыдан тел шартлатты, күбесенең күзенә яшь килде...

Вак мәшәкать күленә кереп чумгач, Хәйретдин Урта диңгездәге дулкын агышларын шома, тиз аңлатты.

— Тәреләрен әләм иткән нәсара алпарлары, без аларның Родостагы ыстаннарын пыран-заран китереп бетергәч, Мальта утравына баш органнар иде. Монысын да кереп айкамагач, сизмичәрәк калдык. Алар арасына качак

әһүд, рум, француз бәкләре дә кереп тулган, шулар инде мондагы ыстанны «Изге Иерусалим канаты астындагы Мальта ордены», дип үзгәрткәннәр икән. Магистрлары — король Франциско дар агачына асарга җыенгач качып котылган Жан де Ла-Валет. Үзенең куышына нинди генә башкисәрне җыймый! Алман, норман, варяг, латин, испан, мадьяр — берсе дә калмаган. Шулар хәзер хыялый Карлга караб артыннан караб төзеп кенә тора. Карлның үзенең дә Картахен дигән урында шәхси ыстаны бар. Ул да, акылыннан шашкан шикелле, һәр ай саен дистәләгән караб төзеттерә. Адмиралы — Андреа Дориа исемле тагын бер генуэз сатлыкҗаны. Монысы да элек король Франциско флотында булып, эскадрасын давылда туздыртып бетергәч, Карлга килеп ялланган бер бушбугаз. Менә шулар, безгә сиздермичә барып, Тунис каласына бәдәви гарәпләрнең Хафиз солтаннар нәселеннән чыккан Мулай Хәсәнне тәхеткә утыртты да качып китте инде. Алар белән диңгездә куышып йөрүләр хәлебездән килми, безгә флот кирәк...

Сөләйман шул көнне үк француз короле янына махсус илче куды.

«Ике якта да илчелекләр тоту гына житми, аерым солых кирәк. Син үз кулыңнан Бургундияне тартып алган кан дошманың Карлга каршы яуда миңа хәрби караблар белән ярдәм итәсең икән, мин сиңа Дориа белән Жан Валет атлы ике сатлыкҗаныңны тотып бирәм. Аннары син минем сәүдәгәрләремнән француз мәмләкәтендә тамга салымы талама, мин синекеләрне ышыгыма алам. Син үз жирендә минем флот кереп сыенырдай аерым порт булдыр, ә минем яктан синең корабларга Урта диңгез буйлап төрек әләме астында йөзәргә дә рөхсәт».

Францискодан җавап көткән арада Алтын Мөгез култыгына иллегә якын хәрби караб, галералар китереп туктаттылар. Һәммәсен дә кат-кат тикшерттергәч, махсус фәрман туды.

— Солтан галиҗәнапләренең тугры хезмәтчесе Хәйретдин Барбаросса «капитан-паша» дәрәҗәсе һәм алтын ятаган белән бүләкләнә. Хәйретдин кул астына сиксән атлы хәрби караб, аңа өстәп галералар һәм баркаслар бирәм. Корабларда хезмәт итәчәк сигез мең нәүкәр белән ике мең янычар да турыдан-туры аңа буйсыначак...

Караблардагы яңа тупларны сыныйм дигән булып, Хәйретдин Мессин бугазы аша узган чакта Неаполь корольлегендәге кирмән һәм портларны утка тотып китте. Рим һәм Мадрид аша хәбәр тиз таралган, Урта диңгездә төрек корабларының әләмнәрен күреп алуга ук кача башладылар. Ә Хәйретдин зөфаф түшәгенең тәмен татыган кияү шикелле азынуын белде, саны белән инде йөздән арткан корабларын Тунис янындагы Бизерт култыгына кертеп туктатты да туплардан ут ачты. Янда янә мөселман калканы калкып чыккач, каладагы бәдәви гарәпләр баш күтәрде, испан баскыннарын кыра башладылар. Мулай Хәсән гареб яктагы таулар аша каладан чыгып качты, Тунис үзәгендәге Кәсбә атлы ташкирмәндә төрек әләмен күккә күтәрделәр. Илчеләр чакыргач, кодагыйлар сыман нык көттереп кенә Хәйретдин дә ташкирмәнгә узды. Бәдәви бәкләр даими гаскәрсез калудан һәм Мулай Хәсәннең әйләнеп кайтуыннан бик шүрләгәч, Хәйретдин бәйлекләр буенча үзенең нәүкәр һәм янычарларын таратып җибәрергә мәҗбүр булды.

Әлбәттә, Карлның да табан астына ут йөгергән, икенче җәй башында ук Гибралтар бугазы ягында дүрт йөз караблы флот пәйда булды. Флоты гына бер хәл, уртада сигез палубалы, кирмәндәй бер караб бар, гомер күрелмәгән мондый зур албасты хәтта диңгез юлбасарларын да койрыкларына ут капкан шикелле качып китәргә мәҗбүр итә иде. «Изге Иоанн» аты кушылган шул албасты өстенә Карл үзе менеп атланган, ә һәркайсы дәү-дәү печән кибәннәрен хәтерләткән барча караблардагы сугышчылар саны утыз меңнән артып китә икән.

Карл әүвәл Тунис бугазындагы Ла-Гулетта кирмәне каршына килеп тырнак

батырды да утрауны ай буена сигез катлы албастыдагы тупларыннан тоташ утка тотты. Төрекләр белән бәдәвиләр утрауны ташлап качарга мәҗбүр булгач, алар артыннан ук Карфаген хәрабәләре өстенә сикерделәр. Хәйретдин монда да атна буе корал ташламады, әмма Карлның төмәннәренә каршы тора алмагач, дүрт меңлек кенә гаскәре белән таулар аша Алжир ягына чыгып качты.

Бәреп кергәч, Карл тунислыларга шәфкать күрсәтмәгән. Алжир белән Истанбулга кайтып ишетелгән һәрбер кара хәбәр елан төсле чакты.

— Нәсаралар мөселманнарның мәчетләрен җимереп бетергәннәр. Ул көферләр Тунисны өч көн, өч төн буена туктаусыз талаганнар. Каланың алтмыш мең кешесен кырып юк иткәннәр, тагын алтмыш мең ир-атны Карл үзенең галераларына ишкәкчеләр итеп алып киткән. Тунистагы өч әрвахның берсе генә нәсаралар кулыннан качып котыла алган. Киткән чакта Карл янә Кәсбә кирмәненә Мулай Хәсәнне утыртып калдырган, ди. Бәдәвиләрнең сатлыкҗан Хәсәнне суеп үтерүләреннән шүрләгәндер, Карл аны саклау өчен ике йөз испан укчысын калдырып киткән икән...

Кан исеннән котырынган Карл мең биш йөз дә кырык беренче елның көзендә тагын Африка ярларын талап кайтырга карар кылды.

— Нишләп яуны җәй уртасында башламадык соң без? Кыш алдыннан диңгезнең дә акылы керәле-чыгалы бит, — дип тинтерәткән испан башкисәрләренә король җавапны да җинел генә тапты.

— Ә кыш көне бәдәвиләр даими гаскәр тотмый, алар да, йомраннар шикелле, үзләренең мәгарәләренә таралып, йокы симертәләр.

Карл бу юлы инде биш йөз караб туплап юлга чыккан иде. Рум, испан, алман, Мальта орденыннан җыйган гаскәренең саны да кырык меңгә тулды. Сигез палубалы үзәк карабына алда һичшиксез дә яуланачак җиңүләрне тантана иткән чакта күңел ачу өчен йөзәрләгән баронесса һәм герцеговинялар утыртты, үзе шулар арасында кәеф-сафа корды. Карл яубаш итеп Альба атлы бер герцогны билгеләгән иде, беренче атналарда моңа чаклы бер генә ил дә күрү бәхетенә ирешмәгән гаҗәеп зур флот тоткарлыксыз, тыныч кына барды.

Алжир каласына бикләнгән мөселманнар дошман якынлашу турындагы хәбәрне октябрь башында ук ишеткәннәр иде. Шымчы итеп озатылган галералар испан флотындагы караблар санының очына да чыга алмый кайтты.

— Безнең алда ике генә тәкъдир — җиңү яки үлем! — дип эндәште Хәйретдин мәйдан тутырып баскан ир-атларга.

— Без икесенә дә әзер, корал өләш! — дигән җавап ишетелгәч, Хәйретдин корал алачыкларының ишекләрен ачты.

— Аллаһ та үзенең колларын ярдәменнән ташламастыр әле, — дип өстәде бер имам шул чагында. Аның күрәзәче булып чыгачагын кемнәр белгән?..

Карл октябрьның соңгы атнасында Матыйфа борынына укчыларын гына төшерде дә тегеләре Алжир ягына кыяклый башладылар. Ул укчылар бер үзәнлектә тукталып, чатыр корырга, казан асарга тотынды. Боларның кыланмышларын күреп гарьләнүдән үләрлек: Алжирдагы гаскәрне күз чалымына да китерми, шуларның күз алдында мәҗлес корырга азаплана бит бу мөртәт җан!

Бер тәүлек ара хәвеф белән узды, сакчылар кала диварларын ташлап китәргә дә җыенмады. Тунистагы вәхшилекне яттан белгән Алжир халкы асылда да аяк өстендәге килеш шәһид китәргә әзерләнгән иде.

Бер тәүлектән соң диңгез дулкыннары арасыннан тоташ кирмән калкып чыккан кебек булды. Карл үзенең биш йөз карабын һәм галераларын тыгыз сафка тезеп Алжир өстенә якыная башлады. Бу чаклы карабларга куелган туплар бердәм рәвештә ут ачса, ул давыл Алжирыны гына түгел, ярты җиһанынны алып очар сыман. Дәһшәт, дәһшәт!..

Менә шул минутта җиһан астындагы утлы казан телгә килде бугай. Кинәт кенә күк капусын дисттәләгән яшен телеп узды, каладагы йортларны һәм диңгез өстендәге корабларны дөбер-шатыр китереп күк күкрәде, ул да түгел, чиләкләп янгыр коярга тотынды, давыл күтәрелде. Нәсаралар ашыга-ашыга һәр корабтан диңгез төбенә тырнак төшерделәр, җилкәннәрне җыеп алу өчен йөзәрләгән матрос мачталар өстенә күтәрелде. Ләкин давыл шулкадәрле шашты-котырынды, матрослар кош каурые урынына диңгез өстенә очып төшә башлады, тимер тырнакларга бәйләгән сүс арканнар җегәрҗептәй шартлап өзелделәр. Кораблар бүре көтүе күреп шашкан ат көтүе сыман йә бер-берсенә бәрелә башлады, йә яраланган эт өере шикелле читкә сибелеште. Тик аларны читтә дә котылу һәм бәхет көтеп тормый, аерылганы берсе биек кыяларга бәрелеп юкка чыга иде.

Галераларадагы ишкәкләргә бәйләп утыртылган мөселман коллары иң беренче булып айнындылар. Шулар бер-берсенең арканнарын кисеп, палубалар өстенә ябырылды, ә аннан йөзәрләгән испан, рум һәм алман алпарлары диңгез дулкыннары арасына чәчрәп очты. Туплар турында уйлап карауучы да юк, аларның да яртысыннан артыгы, арканнарын өзеп, җәһәннәм төбенә очкан иде инде...

Давыл тынгач, комга-ләмгә батып беткән күз кабакларын, авызларын арчып, испан каһанлыгының горурлыгы булган капитан Эрнандо Кортес яр өстендә иң беренче булып аваз салды.

— Фиедро до Гамо, җаным, исәнме син? Әгәр әрәм булсаң, синең бөек атаң — Васько до Гамо рухы алдында мин ни йөзем белән җавап тотыйм? Өмет борыны аша Һиндстанга яңа юлны таптык, Гает утраулары белән Мексиканы ачтык, әмма диңгезләрдә ун меңләгән мильле аралар үтеп тә мондый хурлыкларга калмадык бит. Нигә, нигә генә алып килде безне монда бирән Карлос?!.

— Исән, исән мин, атаклы дон Эрнандо! — дигән җавап яңгырагач, икесе дә өр-яңадан яшькә күмелделәр...

Король Карл-Карлос флот калдыгын тикшереп чыгарга әмер бирде. Карангылык кереп килгән чакта гына җавап кайтардылар.

— Йөз илле караб тулысынча юкка чыккан, ике йөзләбе исән, калганнарын шуларның койрыгына тагып кайтарырлык. Унике меңнән артык сугышчыбыз вафат, тагын ун меңләбе, гомумән, качып киткән. Исән калганнарыбызның яртысы аксак-туксак. Дары юеш, тупларыбыз атар хәлдә түгел.

Кабат-кабат төпченеп торасы юк, яр өстен болай да мәет тавы тоташы белән каплап киткән иде. Теш арасындагы комны шыгырдатып, Карл йөзен дә күтәреп тормыйча сүз ташлады.

— Аякта йөри алырдай сугышчыларны исән калган корабларга төягез дә иртәгә үк юлга! Ходай каргышы төшкере бу калага бүтән киләсем юк!..

Аның каравы, Хәйретдин сыбайлары күкрәкләрен киереп юлга чыкты. Тунис — кяферләр кулында, аны сатлык Мулай Хәсәннән дә чистартасы бар бит.

Тунистагы бәдәвиләр төрекләрне туплардан ут ачтырып җәфа чиктермәде. Халык үзе килмешәк нәсараларга каршы яу күтәргән икән, Мулай Хәсән белән дар элмәге асып хушлаштылар.

Истанбулдан фәрман килеп житте.

— Капитан-паша Хәйретдин пайтәхеткә кайтсын, солтан галиҗәнапләре аны диван вәзире итеп билгеләде. Тунис вилаятендә Хәйретдиннең иң батыр сыбае Хәйдәр бәйләрбәге паша булып кала. Капитан-паша пайтәхеткә кайткач кайда яшәрмен, дип хәреф уты йотып интекмәсен. Мин аның өчен гүзәлләрдән-гүзәл сарай төзетеп куйдым.

Хәйретдин үзен алып китәчәк эскадра базларына алтын-көмештән тыш бер мең сылулардан-сылу кызлар белән мең ярымнан артык малайны тезеп

утырттырды. Кунак ашы — кара-каршы бит ул, шушы кагыйдәне саклый белеп яшәү — олы савап...

Күзәтүсез калгач, җинүләрдән башлары әйләнгән төрек нәүкәрләре тышау-йөгәннәрне гел онытты. Карлга ясак озатып яшәгән итальян-рум бәкләре, Мальта магистры ис-акылга килеп өлгергәнче, яңа Хәйдәр пашаның башкисәр эскадрасы Урта диңгездәге Болеар, Паксос, Минорка утрауларын басып алды һәм алар портында төрек әләмен җилфердәтә башлады. Ул да түгел, эскадра Рум мәмләкәтенең капкасы саналган Ницца портын тозакка бикләп куйды. Король Карл юкка гына ашыга-кабалана аны саклап калу өчен герцог Савойский кул астындагы алпарларны озаттырган булды. Бертуктаусыз очкан туп утына корыч киемнәргә төренгән алпарлар да каршы тора алмады, портның диварлары дөмбердәп кенә ауды. Яраланган герцогны дарга озаттылар, портка «кызыл әтәч» очырдылар. Өнсез калган Рум һәм Карл караблары Сицилия белән Гибралтар бугазларын да койрыгын өздергән өтек бүре төсле урап кына үтә башладылар. Урта диңгездә төрек әләмнәре генә җилферди һәм бу, әлбәттә, тулы җиңү иде.

Ә Хәйдәр паша нәүкәрләре һаман туктамады, кыйбланы да югалттылар сыман. Карак кәҗә сыман әрсезләнеп, французларның Марсель каласына да бәреп керде болар. Япь-яшь кенә герцог Бурбон Энгинский ак әләм күтәреп каршы чыкты.

— Солых турында оныттыгызмыни? Кайсар Франциско белән Сөләйман солтан берсен-берсе туганнар дип таныдылар лабаса!

Арада елгыр зиһенле сыбайлар табылмыйча калмый.

— Солых буенча, Франциско төрек караблары өчен махсус бер порт бирергә тиеш иде, ә анысы кайда? — дип чәчрәп алга чыкты шундыйларның берсе.

Тулон — Марсель түгел, коштабак янындагы бер җамаяк кына. Герцог төрекләргә шуны тәкъдим итте. Тулон икән, Тулон, анысы да кала. Әмма баргач, күңелләре кайтты.

— Безнең канга ничаклы тоз салган католиклар оясы икән лә бу, каһәр төшкересе! — дип сүгенде шул ук елгыр сыбай.

— Ә без аларның костелларын үзебезчә итеп төзәтәбез, — дигән карарга килде башка ташбашлары.

Шул ук кичтә аббатларны куып чыгардылар да ике костел манарасының очына ярымай беркеттеләр. Иртә таңда Тулон өстендә колакларны чеметерлек әче азан тавышы яңгырады. Шәһәр халкы бу төерне сүзсез генә йоткач, Алжир янында кулларына төшкән ләһ, рум, алман, саксон әсирләрен базарларда сата башладылар.

— Болар безнең туганнар лабаса, ничек аларны колыбыз итеп таныйк? — дип Тулон аббатлары зәхмәт эләгүдән курыккандай читкә таярга тотынгач, җавабын да җиңел, тиз таптылар.

— Галераларда аларның ишкәк ишкәнен күрү ләззәтлерәк икән, ярар, зынҗырларына кабат утыртырбыз инде, алай булса.

Әллә кызганудан, әллә комсызланып, тулонлылар әсирләрне дисталәп-дисталәп кенә сатып алды. Болардагы алтыннарны күреп, төрек нәүкәрләре һич көтмәгән кәсепкә керештеләр. Кичтән якын-тирәдәге авылларны талап үтәләр дә иртән базарларга француз игенчеләрен, үзләренә оя таба алмыйча анда-монда сугылып йөргән сукбайларны чыгарып бастыралар. Бу кадәр дә кимсетү бәгырьләрен ут шикелле талый, ләкин илдәшләренә төкереп тә уза алмыйлар шул.

Ахыр чиктә Хәйдәр бүреләренең барча кыланышы солтан колагына барып ишетелде. Пайтәхеттән фәрман юлладылар.

— Кичекмәстән Тулонны калдырыгыз! Сезне алла яңа яулар көтә.

## 33

Хүррәмне яңа бер хәвеф эчтән елан кебек талый. Кырыгы якыная, олыгая бит, каһәр! Икесенең дә дәрт-дәрманы саегадыр инде, Сөләйман да аны гел талымлап тормый, Хүррәм дә, симергән ана каз шикелле, качу ягын карый. Ярый әле Сөләйманның үз жене, үз чире бар, ул яу сәфәреннән ял итүне белми, үзен яңа Зөлкарнәйн итеп танытмакчы була, сирәк күрешәләр.

Гомер дала жиле, май кояшы, җәйге яңгыр кебек бик тиз узып китә. Кайтардыңмы, иске мунча себеркесе сыман беркемгә кирәгең юк. Әнә бит, чабынып таушалгач, иске миллекне дә мичкә ыргыталар. Шуны аңлаудан, ахрысы, Чыңгызхан турында да үлемнән качар өчен ике ел буена чыпчык ите ашап торган, диләр. Мәңге яшәү серен ачтырмакчы булып, Тибет тавындагы Будда ламаларын да янына чакырттырган. Иллә мәгәр житмештән дә артык яши алмаган бит. Хүррәм алай житмеш-сиксәнгә житим, дип ябышып ятмас анысы. Тешләрең һәм чәчең коелып беткәч, бөкрең чыккач, имгәк булып утыруың аңа һич кирәкмәс. Юк, жир йөзендә күп торуда түгел, берәгәйле итеп, яшьнәп яши белүдә бөтен хикмәт!

Аннары, ялгыз калулардан Ходай саклый күрсен. Ул — килмешәк, ул-бу булып, Сөләйман китеп барса, Хүррәмнең каһанлык кадәр каһанлыкта ялгыз көчеккә дә кирәге калмаячак. Картлыгында сыеныр почмак, жылыныр учак турында кайгыртырга вакыт. Кемгә таянырга? Әлбәттә, иң беренче чиратта, өмет — балаларда. Мәгәр алар һаман да яшь. Алай дисән, кызы Мәһруйга унөч тула инде, аны башлы-күзле итеп куйсаң була. Димәк, лаеклы кияү эзләп кую кирәк. Пайтәхеттә кем бар, кайсы өметлерәк?

Хүррәмнең күз алдыннан Истанбулга килеп төшкән бәхетсез көннәре йөгерешеп узды. Аны, иң беренче булып, Мисыр базарындагы коллар мәйданыннан йөзбаш Рөстәм сайлап алган иде. Аннан соң гына Ибраһим ярдәме белән солтан түшәгенә кереп ятты бит ул. Рөстәм күз атмаса, шул йөзбаш сайламыйча узса, йә, ул бүген нинди колчура куенында интегер иде дә, моңа кадәр исән яшәр иде микән? Үзенә тәүге ярдәм кулы сузган, коллык газабыннан йолып алган Рөстәм-фәрештәне нишләп оныткан ул?..

Хүррәм ашыга-кабалана хезмәтче хатыннар киеменә төренергә тотынды, йөзенә бәп-бәләкәй битлек киеп алды. Топкапе кирмәнен саклаучы янычарлар атна саен алышынып тора, алар күзенә чәчрәп кермәү, әлбәттә, хәерлерәк. Ашыкмыйча гына кирмән диварларын урап чыккан иде, эчке якта караңгы булудан бигрәк, янычарлар манарага менеп кунаклаган икән. Хүррәм бик тәкәббер генә мәрмәр капка ягына атлап китте. Мәхмүт Фатыйх солтан корган биек капка күләгәсенә дә кереп өлгермәде, каршында әзмәвердәй гәүдәле егет калкып чыкты. Көмеш аеллы бил каешына көмеш кынлы зур ятаган таккан, баш очына элгән бәрхет фәс тә көмеш жепләр белән каймаланган. Өстендәге жиләне дә парча тышлы, шикләнерлек түгел, каравылдагы жаваплы сыбайдыр бу.

— Сарайдан чыгасы хезмәтчеләр күптән чыгып бетте. Кая бара туташ?

Һе, тәвис кошыдай эре, вәкарь булып кыйланса да, тавышы нык ятышлы, хәтта ипле икән. Хәер, үзе дә кызлар куркып кача торган шыксызлардан түгел. Очкын чәчеп торган күзләр арасында кылыч борын, ияк асларына чылгыйларын салган кара мыек, чәчәк тажы сыман куп-куе каш. Төрекчәне сындырыбрак сөйли, нәсаралар кавеменнән килеп эләккәндер. «Туташ» дигән булып кармак ташлый, итәккә чос, димәк.

— Кайсы як егете син, атың нинди? — дип сүз башлады Хүррәм.

Сыбай да каршында ниндидер тутый кош торуын чамалады бугай, бер карышка чүккән кебек булды.

— Хорват угылы мин. Элекке атым Вальдомир, хәзер Вәлит булыр.

Бу — мадьяр яуларыннан Сөләйман эләктереп кайткан бер әсирдер инде, дип хөкем чыгарды да Хүррәм егеткә усал фәрманлады.

— Минем янга сарайның сак башлыгы Рөстәм бәйне чакыр.

34

Ибраһимны жирләп куюга ук Сөләйман Мисырда бәйләрбәге булып утырган Кара Әхмәтне диванга чакырып кайтарттырган иде, күз ияләшкәннән соң баш вәзир дә итеп билгеләп куйды. Әлеге бәндә зәнжи ирләр белән янәшә куярдай кара-чутыр иде, «Кара» атлы кушаматын бик белеп такканнар анысы, әмма үзе күз алдыннан югалган чагында «Карәхмәт» дип кенә сөйләшәләр.

— Карәхмәттән кыш көне бер көрәк кар да алып булмый. Карәхмәт иске кәвешен дә килененә бирми торган каенанадай саран...

Хүррәм тәүге айларда ук аның белән пычакка-пычак килде. «Топкапега мин дә хужа!» — дип кирмән эчендә яна харәм сарае төзетә башлаган иде, Карәхмәт аның бер генә әмерен дә колагына элми, жен шикелле киреләнеп, аңа каршы тора.

— Солтан галиҗәнапләренең шәхси фәрманыннан башка бер генә динар да акча бирә алмыйм. Аннары ул яңа харәм йорты солтан галиҗәнапләренә ни пычагыма кирәккән ди әле? Син Топкапега хужа булып алганнан бирле солтан галиҗәнапләренең сараена бер генә жариянең дә аяк басканы юк. Инде чакыртыйм, дисә дә, Баязит бакчасындагы иске харәм йорты исән-имин. Тук карынга корбан чалмыйлар бит, яңа харәм йорты төзетүнең бер хажәтен дә күрмим.

— Баш вәзирнең солтан түшәгендә нинди катнашы бар? Аның кайнарлыгы белән нечкәлеге фәкать минем кулда! — дип Хүррәм эт урынына ташланып караса да, Карәхмәт егылып төшәргә һич тә ашыкмады.

— Түшәк — синекедер, анысына кермим, иллә мәгәр казна капчыгының авызын кулымнан ычкындырмыйм!

— Солтан гына кайтсын! Солтан кайтсын әле! — дип янауларга да Карәхмәт ыжлап та бирмәде бит һаман.

— Ә мина солтан галиҗәнапләре шәхсән үзе синең белән акча мәсьәләсендә сак булырга боерды да инде, — дип Карәхмәт ике арадагы серне дә ычкындыргач, Хүррәм кычкырып үкси башлаулардан чак тыелып калды.

Авыртмаган башка тимер тарак, дигәндәй, таякның юан очы Сөләйманның түбәсенә төште.

— Мин кайчаннан бирле солтан галиҗәнапләренең дошманына әвереллем әле? Бөтен тырышканым синең өчен, син генә дип яшим. Ә нишләп синең тарафтан һичбер ышаныч юк?

Сөекле хатынның күз яшьләре тугры ирнең йөрәккәен чеметми каламы соң! Сөләйман тал чыбыгыдай бөгелеп кенә төште.

— Яңа харәм сарае сиңа нигә кирәкте соң? Синнән башка хатын-кызны күрәсем дә килми, һич аңламыйм.

— Солтанкаем минем, жаныкаем, — дип сырпаланды Хүррәм. — Жариләрдән башка Баязит бакчасында синең кызың белән улларың да ятим балалардай интегеп ята лабаса. Әнә, яннарына Манисседан Мостафа да кайтып киткән икән. Ул сабыйлар белән ни генә булмас та, кайсы явызы гына зәүрәт салмый калмас? Ә Сәлим углан белән хәвеф була калса? Аннары кемне генә шаһзадә дип игълан итәрсең син?

Сөләйман дәшми торгач, песи баласыдай янә сырпаланды.

— Аннары мунча кергәндә үзеңне яшь жариләрдән чабындырсаң да,

комачауламый инде. Олыгая башладык, тәннәренә яшь сылулар назы да артык булмас иде.

Сөләйман күзләрен акайткач, тезгә чүккән сыман йомгаклады.

— Чабыш алдыннан чаптарларны да яравайлап алу бик отышлы. Шуның өчен генә, янадан син яныма очып кайтсын өчен...

Ә Карәхмәт белән барыбер эш пешмәде. Солтан Топкапе кирмәне эчендә моңа аерым таш бина төзергә рөхсәт иткән. Чит мәмләкәтләрдән килгән кунакларны шунда кабул итәчәкләр, иң мөһим мәсьәләләр дә фәкать шул бинада каралачак, имеш. Әйе, мәҗлес-тамашалар уздырырдай шәп йорт төзетте ул, бер-ике илчелекне дә шунда кабул итте. Ә аннары, ашка чакырылган әрсез мулла сый табынының түренә үк менеп кунаклаган сыман, Карәхмәт тә шул илчелек йортына кереп утырды, хуҗа булып алды. Хүррәм аны яңа харәм сарае төзелешенә чакырттымы, сыңар колагын да салмый. Сөләйман яу сәфәренә чыгып югалса, солтан сараен да урап кына үтә. Нинди генә чапкыннар юллама, җавап әзер:

— Минем вакытым юк, җилкәмдә — ил йөге.

Хүррәм бик ерактан ятьмә үрергә тотынды. Таянырдай башка терәк күренми, янычарлар менбашы һәм сак башлыгы булып саналган Рөстәмне югарыга үрләтергә кирәк. Солтанбикә хәтле солтанбикә җаен тапмый калмас...

Бишенче мәртәбә мадьярлар явыннан кайтып төшкән Сөләйманны үзе ял итәргә күнеккән Сераль бакчасында һава сулап йөрергә чакырды ул. Мәхмүт Фатыйх мөһере сурәтләнгән биек капка инде тәмам күздән югалганда юл читендәге биек кипарислар арасыннан тай кадәр зур гәүдәле юлбарыс калкып чыкты. Җәнлек ниндидер ятьмә йә читлектән чыгып качкан бугай, бер як алгы ботында яра эзе дә бар. Яраланган һәм кан исеннән котырган җанвардан да куркынычрак хәвеф иясе юк, ыргылып ябышса, күз ачып йомганчы ботарлап ташлаячак. Ул корбан табылуына сөенде генә сыман, чалма очына һәм җилән якаларына тегелгән якут ташлары белән ялтырап торган солтан тарафына борылды да, яман ырылдап, аның өстенә сикерергә әзерләнде. Чәр кычкырып Хүррәм тезләренә чүкте, ни галәмәт, солтан аны каплап басты. Шул мизгелдә юан кипарис артыннан озын ятаган тоткан әзмәвердәй егет сикереп чыкты һәм шунда ук юлбарысның башын өзеп атты. Бу хәлләр шулкадәр тиз арада булып узды ки, фаҗиганең асылын хәтта тулысынча аңлап өлгерүче кеше табылмады. Солтан ис-акылга килгән чакта әзмәвердәй егет кылычын чирәмгә сөрткәннән соң кын эченә кертеп тора иде инде.

— Кем син? Каян килеп чыктың? — дип эндәште аңа Сөләйман, гыжлап сүнеп беткән тавышын ерта-ерта.

— Синең колың Рөстәм мин, солтан галиҗәнапләре, — дигән җавап ишеткәннән соң да, күзләрен акайтып, үз колакларына ышана алмый торды.

— Юк, син колым түгел, сиңа тулы ирек, — диде ул, ниһаять, элеккечә вәкарь тавыш белән. — Ерак йөрмә, кирәк булуың бар...

Бер атнадан соң Рөстәм бәйгә инде яңа сынау. Кырымдагы Сәхибгәрәй хан солтан тарафына чапкын куган. Хүррәмнең инде байтак мәртәбәләр күргәне бар иде: Карәхмәт янына илчеләр килдеме, Сөләйман гел аның таш сарае артына юнәлә дә, күләгәгә посып, шуннан нидер тыңлый. Соңыннан үзе иснәнеп баргач, бик тиз ачыклады. Баш вәзир утыра торган кәнәфи өстендәге диварда йодрык сыярдай тишек калдырылган икән. Аны челтәр белән каплап куйганнар-куюын, ләкин эчтә сөйләшкән һәрбер сүз дивар тышына яңгырап ишетелә. Сөләйман Кырым чапкынын Карәхмәт йортында гына тыңларга хәл иткәч, Хүррәм дә шундук дивар күләгәсенә барып яшеренде.

— Мәскәүдәге кәфер кенәз Иван Казан өстенә зур яу белән бара. Казандагы Сафагәрәй хан хәвефле оран салды. Ул Кырым ханыннан да, солтан

галиҗәнапләреннән дә олы ярдәм сорый. Сәхибгәрәй хан сиксән мең жайдагын Наугырытка юллап, Мәскәү кенәзенең ниятенә балта чабарга ниятли. Солтан галиҗәнапләре ана ярдәмгә ике төмән жайдак юллый алмас микән?

Сөләйман дәшми, Карәхмәтнең ухылдавы гына ишетелә.

— Ни бит, менә болайрак бит. Безнең солтан галиҗәнапләре инде болай да мәгъриб ягында да, гаребтә дә испан илә португал атлы нәсараларга каршы зур яу алып бара. Өстәвенә, гареб белән шимальда кайсар Карл илә герцог Фердинандны да тезгә чүктерәсе бар. Шуна күрә солтан галиҗәнапләре бүген генә, өзеп кенә җавап кайтара алмый. Мөмкинлекләрне бизмәндә кат-кат үлчәү хәерлерәк икәне һәр инсанга мәгълүм.

Менә шул чагында, тамак кыра-кыра, Карәхмәт йортына Хүррәм атлап керде. Әүвәл баш вәзиргә ияк каккан булды, аннары Сөләйман колагына килеп пышылдады.

— Үз-үзенә хәлиф йөге алуынны онытa күрмә, җаным. Син Ходай Тәгалә каршында һәр мөселман өчен җаваплысың. Казан ханлыгында да туганнарың яши. Хәерхаһлык күрсәт, бирәр төмән җибәр. Паша сайлыйсы юк, менбаш Рөстәм әзер...

Дүрт айдан соң гаскәр кире кайтты. Берләштерелгән татар белән төрек җайдаклары күлнең төбен күккә асмаганнар, шулай да Тула, Нижгар, Рәзән Мәскәү тирәсендәге авыл-салаларны байтак талаганнар, ә урыс кенәзе үзе пайтәхетен ташлап качкан икән. Рөстәм өчен, барыбер, зур җиңү. Ә ул зал түренә йөзәрләгән алтын чүлмәк, шәмдәл, хәнҗәр кертеп өйгәч, Сөләйманның да күнеле бик булды.

— Фәрман әзер, син тулы хокуклы паша инде хәзер...

Хүррәм Топкапеда яңа харәм йортын төзетүне тәмамлаган иде, иң беренче итеп, кызы Мәһруй белән өч улын да шунда күчерттерде.

— Сөбханалла, Мәһруебыз чып-чын кәләш булып үсеп җиткән икән! — дип Хүррәм Сөләйман янына кош тоткандай канатланып керде. — Кызыбызга унөч тулып узды, сораучы барында ышанычлы кулга тапшырырга вакыт.

— Нинди сораучы бар? Кем ул тагын? — дип Сөләйман гаилә хәбәрләренә күпчелек вакыттагыча күз акайткач, Хүррәм наян колын сыман кешнәп кенә көлде.

— Үзебезнең Рөстәм, синең коткаручың.

— Әттәгенәсе! Ә Рөстәм паша синең ниятләрең турында үзе беләме соң?

— Кайсы солтан йә кайсарның кызы белән кияvennән аларның теләкләре турында сорап торганы бар ди? Син «өйләндерәм», дип хәл иткәнсең икән, теләсә кайсы колың оҗмах бакчасына эләккәндәй биеп йөриячәк...

Хүррәм хаклы иде, Рөстәм белән Мәһруй никахтан соң асылда да биеп кенә йөрде. Ә Хүррәм төннәр буе керфек тә какмыйча янадан-яна пәрәвезләр үрде. Карәхмәт янына Тунис бәйләрбәге Касыйм паша килүен ишетеп калган иде, хәзер инде кияве Рөстәмнең бүлмәсенә атылып керде.

— Менә сиңа якут, менә мәрҗән. Ике пот алтынны сөйрәп йөри алмыйм, анысы янбакчада, капчык-капчык итеп тутырылган. Мин Касыйм пашаның чыгып олагуын күзәтеп торам, ә син, ым кагуга, асылташларны да, алтынны да Карәхмәт йортындагы сандык артына кертеп яшерерсең.

— Мин өстемә гөнаһ алмыйм, — дип Рөстәм кияү авыз ачкан иде, Хүррәм елан кебек ысылдап шып туктатты.

— Тес-с-с, Ибраһим паша тәкъдирен онытa күрмә берүк!..

Рөстәм Карәхмәт йортының ишекләрен ябып чыгуга ук Хүррәм инде тәхет залына чәчрәп кереп җитте. Ике күз карашы да елан угы сыман, үзе каһкаһәләп көлүдән чак тыела.

— Мине — үзеңне өзелеп сөюче, аяк табаннарыңны үбеп яшәүче бердәнбер

хатынынны ил казнасын әрәм-шәрәм итүдә гаеплисең, ә артында вәзирләренә тикле барча соран синең байлыгынны талап-имеп ята, — дип күз яшьләре аша текәлгән Хүррәмнең сүзләре Сөләйманның аңына бик тиз генә барып өлгермәде.

— Нинди байлык тагын? Кемнәр талый? — диде ул, гаҗәпләнүдән тартасуза гына.

Хүррәм ачыргаланып елаган тавыш белән өр-яңадан тезде.

— Сине Карәхмәт, жирбит, астан гына талап-имеп ята. Әнә, янына Касыйм паша килеп киткән иде, Карәхмәт, карайөз, аннан ике капчык алтын талап калган. Аның өстенә фирүзә, якут, алмаз, энже-мәрҗән. Синең казнаңа керергә тиешле байлыкны үз өенә ташый. Симерүе житүгә, теләсә кайсы падишаһ кул астына чыгып качачак бу. Икмәк тотып ант итәм, валлаһидыр, менә!

— Ул капчыклар кайда? — дип ярсый-ярсый сорады Сөләйман, йөзеннән дәһшәт бөркеп.

Хүррәм күлдән үрдәк алып чыккан аучы этедәй тугрылык белән башын түбән иде.

— Караңгы төшмәде бит, Карәхмәт алтыннарны чыгарып яшерергә өлгермәде әле. Алар барысы да илчелек йортында шул көенчә ята.

Солтан әмерен ишетеп алгач та, баш казначы белән каравылбаш илчелек сараеның эченә ябырылды. Берничә минуттан тәхет залының уртасында асылташ һәм алтын кәшелләре үсеп чыкты. Күп тә сузмый Карәхмәтнең үзен дә сөйрәп китерделәр. Сорау бирүче юк, ә солтанның усал фәрманы әзер иде инде.

— Вилаятьләрдәге бәйләрбәкләреннән ришвәт талап, солтан галиҗәнапләренең казнасына һәм шул җөмләдән мәмләкәтнең нигезенә зыян салган өчен баш вәзир Карәхмәтне дар агачына асып үтерергә!..

Бер ай чамасы вакыттан соң Хүррәм түшәктә чагында былбыл кебек сайрап телгә килде.

— Ил казнасын савып яту өчен баш вәзирлеккә чит-ятларны билгеләп булмас инде. Киявебез Рөстәм менә дигән егет. Гомер чаклы гомереңне саклап калган икән, синең байлыгыңның тузанына орынырга да җөрьәт итмәячәк. Бия каплатам, дип чит утардагы айгырларны чакырып симерткәнче, үз таеңны ашат...

## 35

Шайтан белән Иблис, икесе тиң, чиратлашып, ялкын өстенә утын белән кузны ташлап торалардыр, кайнаудан һәм болганудан туктамады Казан!

Тәхетләрендә сабый Иван утырган урыс боярлары татар мәмләкәтен бишалты ел чамасы, «үзегез үк чукынмассызмы әле», дигән төсле, тынычлыкта калдырып торган иде, берзаманны, асылда да, Казан эчендә Мәскәү ягына карап сәҗдә кылучылар күтәрелде бит, әй!

Гәүһәршад бикә белән Булат Ширин Казан морзаларын, имам-хатыйбларны, олысбәкләр һәм Алабуга, Чаллы, Арча наибләрен мәҗлесләргә чакырып сыйлау өчен кырыкмаса-кырык сәбәп табып кына тора.

— Җангалинең исән калган малае Ак-Мөхәммәдкә ун яшь тула икән.

— Казансу буендагы Ташаяк базарына Бохара белән Сәмәркандтан олы кәрван килә. Сәүдәгәрләр Коръән-Шәрифнең бер уч төбенә сыеп бетәрлек бүләк нөсхәләрен дә китерәләр, имеш.

Ә табын тирәли тезелеп утырдылармы, телләрендә гел бертөрле сырхау.

— Сафагәрәй хан, Мәскәү тарафына артын куеп, безне урыс белән алышбиреш итүдән мәхрүм калдырды бит.

— Без нугайлар түгел, алар китереп өйгән куй тиреләре илә киезләрдән тирмә корып куйыйк та, таш сарайны ташлап, шунда күчикмени? Алар мичкәләп ташыган куй мае да гаурәт җирне сылаудан башка бер гамәлгә ярамый.

Мәскәүнекеләр китергән балык теше шамаилләр вә диварларны бизи торган сыннар ясау өчен бик мәслихәт иде.

— Сафагәрәйнең тәкәбберлеге сәбәпле, урыс наибләре безнең кәрваннарны Мәкәржә ярминкәсенә һәм хәтта Лыскаба, Балахна ише вак-төяк кала базарларына да кертми. Сәүдә аксагач, казна коргаксыды. Сафагәрәйгә ансат, ул Мамай илә Йосыф каенаталарының малларын Казан белән Арча базарларына китертеп байлык туплый. Ә без, Мәскәү белән ике арада тауар алышып яшәгән бичаралар, ялан тәпиле, кылка киемле сәүче кыяфәтендә хәер теләнергә чыгып китикмени?..

Болар коткы тарату һәм котыртудан гына тәм тапмаган, ахры, итәк астыннан ут йөртү белән дә шаяра башлаганнар. Казан урамнары чыш-пыш килгән хәбәр белән тулды.

— Гәүһәршад бикә Мәскәүдәге Иван кенәзгә яшерен хат юллаган. «Үз косыгы эчендә тончыга башлагач, Казан сазлыкка кереп баткан мал урынына йончый-дөмегәдер, ә синең кенәзлегең, Мәкәржәгә бөтен җиһан малын туплый-туплый, көзге үгез төсле көрәя, безне көнләштереп, һаман үр менәдер», дигән шатлыгын белдерүдән дә тыелып калмаган, ди.

Ул да түгел, Булат морза үзе үк кайчандыр Гәүһәршад итәге янында бөтерелеп йөрүче Сәед угланны, Шәгъбән һәм Шаһбулат Япанчыларны, Чура батыр, Карамыш, Яулуш шикелле бәкләрне хосусан мәсләгенә күндергән дә, Мәскәүдән илче битлеге астында килгән Морозов вә Путятин атлы жасус-шымчылар белән бәйләнешкә кергән.

— Без — Мәскәү бирадәрләре. Казан-йортта сезнең белән туганлык җепләре ялгап яшәргә атлыгып торучыларны санап бетергесез. Әмма ләкин безнең карамакта Сафагәрәй ханны Казаннан куып җибәрердәй хәрби көчләр юктыр. Сез Мәскәү тарафыннан аз булса да гаскәр юлласагыз, без Казанның үз эчендә түнтәреш әзерләп, Кырым килмешәген кулга алыр идек. Безгә Шаһгалинең хан тәхетенә утыруы кулайрак, аны әзерләгез.

Болай да киек өстенә ташланырга әзер торган ау этенә тиң Мәскәү боярларына астан гына эш йөрткән сүрән чакыру да җитә калды, пайтәхетнең үзеннән дә, Нократ елгасы буйлап та гаскәр юлладылар. Дошман нияте буенча, ике гаскәр Казан астына килеп җиткәч бергә кушылырга тиеш иде. Үз вакытында кисәтү алуга ук Сафагәрәй үзе Нократ яклап якынлашкан баскын чирүенә каршы чыкты. Кенәз Львов кул астында килгән Пермь чирүен Чаллы каласы тирәсендә туздырып ташладылар. Сафагәрәй инде Казан каласына төбәп кайту юлына да чыккан иде. Кулай морза утары янында пайтәхеттән очкан чапкын ханның юлын бүлде.

— Чура, Карамыш, Яулуш морзалар котыртуы белән, кара гавам казна кибетләрен вә сәүдә алачыкларын ут төртеп яндырды. Раст морза белән Гали Шаһкол акылга килүләрен ялварып каршы чыккан иде, аларны Кечек Гали илә Камай морзалар кылычлары белән турап атты. Котырынган халык Кырымнан сиңа ияреп килгән яугирләрне чыра агачы урынына тоташ телә. Сак башлыгың Кушчак углан гына, Сөембикә ханбикәне алып, каенатаң Йосыф мирза ышыгына качып котыла алды. Пайтәхет эчендә давылдай болганыш, син Казанга әйләнеп кайта күрмә.

Яңаклары буйлап яшьләр түгә-түгә, Сафагәрәй янә, ханлыгын калдырып, Йосыф каенатасының җәйләвенә качты. Мәскәүнең үзеннән юл алган кенәз-сәрдәрләр тәҗрибә туплаган, каешланып беткән баскыннар шул, алар арба урәчәсенә Шаһгалине тагып чыгарга да онытмаган. Казан тәхетенә инде икенче мәртәбә шушы соранны китереп утырттылар.

Сафагәрәй, нугай җәйләүләренә керүгә үк, ике каенатасы алдына да килеп ауды.

— Тагын да яшәп торуымның мәгънәсе юк. Йә кабаттан тәхетемә кайтам, йә суелып үләм. Тәхетемә кайтарып утыртсагыз, нугайларга һәр тарафта капкам ачык булыр. Чиру җыеп китерегез миңа, ярдәм күрсәтегез!?

Сафагәрәйгә егерме меңгә дә тулмаган җайдак кына бирделәр бит юкса. Ләкин шушы кадәр көпшәк гаскәр дә Казан диварлары каршында пәйда булуга ук, Мәскәү дошманнары капкаларны ачты. Мәркәз эчендә курчак Шаһгалине яклап калырдай җитди көчләр юк, Казан морзалары ул Касыйм каласыннан ияртеп килгән өч мең җайдакны, кирмән капкалары аша үткәреп тә тормыйча, кире куган иде. Шүрәледәй җирәнгеч кыяфәте белән генә дә казанлыларны укшытып бетергән һәм ике кулсыз калган Шаһгали «хан» янә, биштәр-төенчекләрен дә җыерга өлгермичә, Мәскәү тарафына чыгып качты.

Сафагәрәй Чура батырдан соң тагын дистәләгән морзаны дарга озатырга нийт иткән иде, өлгерә алмады шул — берьюлы җитмеш алты морза Мәскәү итәге астына качып киткән икән. Инде ике мәртәбә куылып, өченче тапкырына тәхет түренә ингән һәм сансызланып беткән килмешәк ханга, ачы хәсрәт диңгезенә чумып, уйланырга-сызланырга калды.

«Кырымнан ияртеп килгән җансакчыларымны кабул итмәделәр, аларның яртысын һавалы вә монафыйк Казан морзалары суеп бетерде. Каенаталарым алдында биргән бигать сүзләрем бар. Әйдә, бер Кушчак угланны гына сак башлыгым итеп калдырыйм да, башка Кырым яугирләрен кирмәннән чыгарып, гадәти гаскәргә кушып куйыйм әле. Алар урынына нугай җайдакларын кертеп карыйм. Шуннан ары Казан соранннары телләрен тешләмәсме?»

Ни галәмәт, шушы гамәл морзалар күңеленә ләйсән яңгырыдай хуш килгәндәй булды, Казан-йортның һичбер почмагы да хан идарәсенә ризасызлык-дәгъва белдермәде. Сафагәрәй инде һәр гамәлен «аксакаллык инде», дип сөенә-сөенә һәм унга-сулга бәрелмичә генә үлчәп бара иде. Юк икән шул, ошбу салмак көннәр коточкыч гарасат килүен кисәтеп куя торган бер бушану һәм тынлык кына булган.

Сафагәрәй: «Җитмеш алты морза читкә чыгып качты, соранннарын дарга озаттырдым. Ил эчендәге икейөзле дошманнардан котылдыммы әллә?» — дип юкка гына сөенеп йөргән икән. Иң явыз дошманның үз канаты астыннан үсеп чыгачагын абайламый калган.

Әле ханбикәне Казан эчендәге мәхшәрдән аралап, Нугай юлына чыгып качуга ук, Сафагәрәйнең җансакчылар башлыгы Кушчак углан, ялкын телләредәй көйдерә торган сүзләр тезә-тезә, Сөембикәнең үзәгенә үтте.

— Ассаң — ас, телемне өздерсәң — өздер, әмма сине күргәннән бирле җанымны ут шикелле талаган хисләремне яшереп кала алмыйм. Миңа инде кырык тулып килә, иллә мәгәр башлы-күзле булу турында уйлаганым да юк. Синнән башка һичбер хатын-кызга күзләремне күтәреп карый алмыйм... Син — ханбикә, ир хатыны, балалар анасы, ә мин — синең читегең йөзенә кунып әрсезләнгән тузан бөртеге, меңәрләгән колларыңның фәкать берсе генә, барысын да аңлыйм. Әмма йөрәккә әмер биреп булмый, мин сине күрмичә бер көн дә тора алмыйм...

— Мондый сүзләр һич урынлы түгел, әрсез гамәл белән шәхсән мине һәм илтотмыш иремне рәнҗетәсең. Яуга киткән ир хатынына мондый сүзләр кушу аның иренә үлем-хафа теләгәндәй була, — дип Сөембикә аны урынына утыртырга тырышып караса да, Кушчак углан тын алу өчен дә туктап вакланмады.

— Син уйлама, мин Сафагәрәй хан галиҗәнапләренә аны сөяр, аны күккә чөяр өчен хезмәт итмим, әгәр икеләнү уе елан төсле чакса, мин ике дә уйлап тормыйча, аны ташлап, Кырымыма кайтып китәр идем. Кулымда гайрәтем бар,

мин юлыма аркылы төшкән йөз ирне дә турап ташлый алам. Мине Казанда фәкать син, бер син генә тотып торасың. Мин Сафагәрәй ханга ул түләгән алтын-якут түгел, синең белән хозурланып яшәү бәрабәренә хезмәт итәм.

Кушчак углан беркадәр тын алырга тукталып калган иде. Сөембикә каш астыннан гына аның килеш-килбәтенә күз ташлады. Юк, үз бәһасен үзе белә бит бу, аны һичбер яктан кимсетерлек түгел. Бүтәннәргә караганда бер башка югарырак буй-сын. Бау шикелле ишелгән сеңер-җептән хасил беләкләрендә бер сугуда үгез кадәр үгезләрне егып салырдай гайрәт. Агач төбе төсле таза муен. Һәм шуның өстендә, йә ни хәйран, хатын-кызларны да көнләштерердәй сылу, килешле йөз.

Сөембикә кат-кат күз ташлады. Бөдрәләнеп торган чем-кара чәч монда. Кылыч очы шикелле төп-төз борын. Кайнар ашка пешеп кабаргандай калын, сусыл иреннәр. Эт баласыдай нәүмиз булып текәлгән тугры караш. Ирен читләрендә тыйнак елмаюдыр. Кызык, Сөембикә нишләп аны элек менә шушындый кыяфәттә бер дә күрмәгән соң?

— Сүзләремне иренә, хан галиҗәнапләренә дә, тапшыруың мөмкин. Әмма мин курыкмыйм. Синең хакка дар агачына менәргә дә әзер. Ходай Тәгаләдән һәрбер таңда шуны гына сорыйм. Йә Раббым, ул мине шушы гүзәллектән аермаса иде...

Нугай иленә качу соңыннан Сафагәрәй килеп кушылу белән төгәлләнсә дә, Сөембикә Кушчак угланның һичбер сүзен озак вакыт буе онытмады. Ә Сафагәрәй үзе һичнинди шик күрсәтми, ханбикә янәшәсендә гел Кушчакны тота. Җангали, бик яшь булса да, Сөембикәдән тыш тагын бер хатынга, Казандагы иң бай морза кызына өйләнергә өлгергән иде. Тик ул бичара хатынга озын гомерле булырга язмаган икән шул, ул беренче баласын тапкан чагында ук дөнья куйды. Аннан туып, исән калган Сәҗидә атлы кызны Сөембикәнең үзенә карап үстерергә насыйп булды. Менә шул Сәҗидәне Хаҗитархандагы Аккүбек морза үзенең Хәйбулла атлы улына кәләшлеккә сорап яучы кугач, ахырында Сөембикәгә шул ук Кушчак белән Идел буенча сәяхәт кылырга һәм туйда кодагый булып утырырга туры килде. Аннан соң да һәрбер җәйдә әтисенең җәйләвенә кайтып, сәхрә күреп, кымыз эчә-эчә хушландылар. Кушчак аның белән, нәкъ ире шикелле, янәшәдә йөрде, мәгәр, ни галәмәт, яман киная ташлап, әрсезлеген-мазар күрсәтмәде. Кайвакытта Сөембикә хәтта үзе Кушчак угланның тотнаклыгына сәерсенеп, гаҗиз булып йөрде. Бу хакта, үтә яшерен сер итеп, сабый чактан бирле бергә үскән ахирәтенә чишкәч, тегесе камил җавап белән авызын япты:

— Асыл ир-атны үзен-үзе әрсезлектән тыеп тора белү азгын эттән аера да инде. Сиңа әүлиядәй изге ир белән янәшәдә йөрү бәхете эләккән бит.

Сөембикә шуннан ары бер Кушчакка, бер иренә карап гаҗәпләнде. Сафагәрәй аны гел Кушчак белән озатып җибәрә, нигә үзе тырнак очы кадәрле шик-шөбһә дә тотмый?

Ә Сафаның аның үз кайгысы. Мәскәүдәге Иван кенәзгә унҗиде яшь тулуны көтеп житкергәннәр дә, аны өйләндереп куйганнар, ди, әнә. Румлыларга иярен, Иван үзенә «кайсар» атын алган, ул үзен Истанбулдагы Сөләйман солтан йә алман илендәге Карл каһан белән бер дәрәҗәгә куярга маташадыр инде. Әнә, аның янында йөргән Макарий-атакай белән Адаш атлы бояр Иван кенәзне ничек итеп котырталар икән:

— Бакыр туптан ядрә очыруда төрекләрдәге маһирлыкны өйрәнергә кирәк. Безнең гаскәрдәге сәфәр йөрү, тоташ һөҗүм ясау ысулларын шул ук төрекләрдән күчереп алсаң да артык булмас иде. Син — кайсар, исемең янгырасын өчен сиңа бертуктаусыз яу сәфәренә йөрү мәслихәтрәк. Тора-бара син дә җиһанда, төрекләрнең Мәхмүт солтаннары кебек, «Фатыйх» атлы дан алырга тиеш!

Өстерә торгач, Иванны сындырганнар. Мәскәү өчен иң зур дошман һаман Казан инде, урыс кенәзе гомерендәге тәүге яу угының очын Сафагәрәй өстенә төбәп килде. Иванда тәҗрибә юк, алдын-артын карамыйча, күз ахырында юлга чыккан бит бу. Мәгәр Нижгардан кузгалып унбиш чакрым ара да узмаганнар, елга аша үткәндә боз ярылып, урыс олауларындагы барча туплар су төбенә киткән. Шулай да, тәүге үк сәфәрдә «булачак Фатыйхның» канатларын сындырырга ярамый бит, боярлар барча исән калган гаскәрләрен сатлыкҗан Шаһгали белән Бельский атлы бер кенәзгә биреп, һаман алга куган.

Сафагәрәй аларны Арча кырына җайдакларын тезеп каршы алды. Йөзгә-йөз килеп орыша башлагач, казанлылар ягыннан Арак белән Азык кебек иң шөһрәтле баһадирлар ауды. Урыс гаскәрендәге яубашлар да әллә ниләр майтара алмады, барча меңлекләр дә, мәет белән ганимәтләрен дә җыеп ала алмыйча, кире торып чапты. Иван «кайсар» Мәскәү каласына күз яшьләре белән кайтып егылган, ди.

Сафагәрәй үзе тантана шатлыкларын кичерергә дә өлгерә алмый калды. Тәненнән бигрәк җанын юарга дип, парлы-кайнар мунча эченә кергән генә иде, шома ташлы идән өстенә түшәлгән хәтфә келәм урыныннан кубып, Сафагәрәй бер як яны белән җиз юынгыч читенә чәчрәп төште. Юк, үлмәгән иде. Янына тезләнеп, бугазыннан алган ике җасус морзаның йөзен таныды ул. Буар елан сыман каптырган катыйлләрнең кулларыннан ычкынырга гына өлгермәде.

## 36

Сөләйман солтан әүвәл Казан тарафыннан килеп җиткән хәбәрләрне ишетүдән телсез калган иде, тын алырга да ара калдырмыйча, эссе мунча пары сыман яңасын да китереп өстәделәр.

— Кырымдагы Сәхибгәрәй Казан илә Мәскәү өстенә яу чапмакчы була. Борадәре Сафагәрәйнең гомерен кыйган өчен бар җиһанны канга батырмакчы. Казан морзалары Сәхибгәрәйдән Сафагәрәйнең Кырымда үскән Бүләк атлы угылын үзләренә хан итеп озатуны ялынып сораганнар, ә Сәхиб, җавап урынына, Бүләк шаһзадәне Инкирмән атлы кала зинданына кертеп япкан. Хәзер синнән Истанбулда тоткынлыкта торган борадәре Дәүләтгәрәйне Казан тәхетенә озатуны таләп итеп ята. Ул бәйдән ычкынган эт шикелле хәзер, тагын ниләр кылыр?

Учакка ут элдерерлек ара да узмагандыр, Сөләйман усал-усал фәрманнарын атты.

— Сәхибгәрәйгә тилерергә дә, Мәскәү белән араны бозарга да ирек куеп булмый. Каф тау битләрендә, әнә, чиркәс бәге Хәзәр миңа ясак җибәрүне тыйган. Сәхибгәрәй, иң әүвәле, шул гыйсъянчыны иманга утыртырга чыгып китсен әле. «Солтан шаһзадә Дәүләтгәрәйне Казанга илтеп утыртуга ризалыгын бирә, иллә мәгәр син әүвәле Хәзәр бәкне тезгә чүктер», дип Сәхиб фетнәченең күзләренә төтен җибәрегез. Монда болай да Сәгадәтгәрәй, картлач, үзенең малае Дәүләтгәрәйгә тәхет даулап үзәгемә үтеп бетте инде. Менә шул Сәгадәт картлач белән Дәүләтне Кырымга озатыгыз. Кайткач та, алар мәрхүм Сафагәрәйнең улы Бүләкне зинданнан азат итсен. Бүләкгәрәй Казанга барырга ризалык бирәме, әллә Кырым тәхетенә борынын сузачакмы — үзләре ачыклар. Мәгәр, иң беренче чиратта, бәйдән ычкынган Сәхибкә тышауларның иң усалын кидерергә кирәк.

Ике ай чамасы вакыт узуга ук котчыкмалы хәбәр кайтып төште.

— Дәүләтгәрәй Кырымга кайткач, синең фәрманыңны үтәп, мәрхүм Сафагәрәйнең улы Бүләкне Инкирмән зинданыннан азат иткән булган. Аннары Сәхибгәрәйнең унөч яшьлек улы Шаһбазны чакырткан да, теге сабыйны, «яшең

житте, Кырым тәхетенә син дә менеп утырырга хаклы», дип атасына каршы котырткан, ди. Бүләкгәрәй белән Шаһбазгәрәй Каф тавында яу кылып йөргән Сәхибгәрәй янына чыгып чапкан. Шулар, икәүләшеп, Сәхибне чатырында буып үтергәннәр. Бүләкгәрәйне, инде сон булса да, Сәхиб мәрхүмнең сакчылары кылыч белән чапкалап бетергәннәр. Ә «мин тәхетне бушаттым, Кырым миңа тиеш», дип котырып кайткан Шаһбазның башын Дәүләтгәрәй үзе бүкән өстенә салып чаптырган, ди. Барча көндәшләрен кырып чыккач, хәзер Дәүләтгәрәй үзен Кырым ханы урынына игълан иткән икән.

— Тфү, кадалгыры! Мин ниятләгәнчә килеп чыкмады бу. Казан тәхете безнең кулдан китеп бара бугай, — дип яман сүгенде дә, Сөләйман солтан үз мәмләкәтенең мәшәкатьләре эченә кереп чумды.

## 37

Сөләйман мәмләкәтенең иге-чиге күренми, байлыклары мәңге бетмәс сыман, шуларның барысына да шөкрана кылып, хозурланып, дан һәм шөһрәткә күмелеп кенә яшә иден дә бит, юк шул, солтан сараеның диварларында кырыкмаса-кырык ярык табып, эчпошыргыч, йөрәк яндыргыч хәбәрләрне дә китереп житкерәләр.

— Триполи бәйлеген тагын испаннар Хәйдәр паша кулыннан тартып алган.

— Солтан галижәнапләренә антлар эчә-эчә Аден каласының бәйләрбәге булып калган Әмир икейөзле соран булып чыкты. Ул португалларга Аденга тимичә узып Фарсы култыгына керергә рөхсәт биргән, ә теге нәсаралар, «бармагыңны бирсәң, терсәгеңне йота», дигән төсле, култыкның нәкъ уртасындагы Ормуз утравына тоташ таштан кирмән төзеп куйган. Шул әрсезләр, кире кайтып, Кызыл диңгезне дә кулга төшергәннәр.

— Һинд ярында яшәүче мөселманнар хакиме Баһадир шаһ Сөләйман солтан-хәлиф галижәнапләреннән ярдәм сорый. Португаллар аның Гүлжарат атлы мәмләтендәге яр буйларын яулап, Диу атлы яңа кирмән калкыта башлаганнар.

«Шушы кайгылар гына житмәгән иде шул миңа, — дип сүгенде Сөләйман, өтек хәбәрләргә күмелеп калганнан соң. — Португаллар Истанбул белән Һиндстан арасындагы юлны бикләгән бит. Мәмләкәткә алтын, ефәк, чәй, энже, көмеш, борыч, дөге, фасоль, зәйтүн, филләр, ахыр чиктә шахмат кайту бетә, ике арадагы сәүдә, гомумән, өзеләчәк. Башны иеп калсам, кылыч белән кыеп төшерергә дә бик күп сорамаслар. Итәк астыннан йодрык күрсәтү — зур егетлек түгел. Гаскәрне яңа иярләргә кирәк».

Яшерен фәрман буенча диванга жыелдылар. Сөләйман якын-тирәдәге бәйләрбәкләрен-вәлиләрне дә дәште. Манисcадан Мостафа да кайтып житкән иде, тыенкы гына итеп исәнләште дә, мәдрәсә шәкерте сыман, бер почмакка сеңде. Каһирәдән үзенең адашы булган, сиксән яшьлек Сөләйман паша да килгән, аны жиң очларын иелеп үптермәскә, киресенчә, үзенә аның каршында баш ияргә туры килде. Мондый гамәл кайбер вәлиләргә бик ошады, ахры, «машалла» авазлары чыгарып, чыш-пыш килештеләр. Сөләйман Мисырдагы флот башлыгы, капитан-паша Пәри Рәисне шәхси фәрман белән чакырттырган иде, залга ул ингүгә, барча вәзир-вәли куырылып калды. Аның бастырык шикелле озын, какча гәүдәле булуы бер хәл, иң нык өшәткәне — кылчыклардай сирәк, озын, саргылт төстәге йон каплап алган йөзе төшләренә керсә дә куркып уятырлык дәрәҗәдә килбәтсез һәм бик тә котсыз иде. Дистә еллар элек ул харәм сараенда халим булып торган, әмма аны күргән бер жария һуштан язып егылганга күрә, Сәлим солтан Пәри Рәисне пайтәхеттән еракkарак озаттырган, диләр.

Хәритәләр таратып бик озак баш ваткач, йомгак сүзен фәрманга төшерделәр.

— Солтан галиҗәнапләре утыз караб җыеп, аларны Пәри Рәис карамагына бирә. Пәри Рәис Юлбарыс белән Җәфар-ат дәрьялары[10] тамагында утырган Басра портыннан кузгалып, Фарсы култыгы аша Аден каласына юнәлергә, аннары коры җирдәге төмәннәр белән кушылып, Кызыл диңгез буен нәсаралардан чистартырга тиеш.

— Кызыл диңгезнең уңъяк яры һәм Нил дәрьясы арасыннан төбәләчәк җайдаклар төмәнен җитәкләү бурычы бу мактаулы гамәлне үтәүгә үзе теләп алынган сиксән яшьлек Сөләйман пашага тапшырыла.

— Янычарлар төмәнен җитәкләячәк шаһзадә Мостафага Кызыл диңгез белән Фарсы култыгы арасындагы кирмәннәрне нәсара португаллар кулыннан тазарту бурычы йөкләнә.

— Һәрбер сәрдәр биш көн саен солтан галиҗәнапләре тарафына чапкын юллап тора, фәрманнан тайпылган явызны дар агачы көтә...

Мостафа белән Сөләйман паша төмәннәре пайтәхет капкаларыннан икенче көнне үк чыгып югалдылар. Чапкын юллау тәртибе даими бозылса да, хәбәрләре һаман кайта торды. Сиксән яшьлек паша, иярennән дә төшмичә, Асуан, Судан, Төкәр, Массау, Аксым калаларын айкап узды, ләкин Кызыл диңгездән Аден култыгына кадәр сузылучы Мәнди бугазы өчен сугышларда эзсез юкка чыкты.

Мостафа, Амман каласын узгач та, Каһирәдән качкан Мәмлүк нәселенең калдыклары белән яуга кергән иде. Янычарларның бөҗра ясап чабулый-чабулый, бертуктаусыз ук ташкыны яудырып торуына түзә алмадылар, гарәп нәүкәрләре үзләре үк, мәмлүк бәкләрен арканнарга бәйләп, тезләренә чүкте. Мостафа ризалык сорап та, үгетләп тә вакыт уздырмады, гарәпләргә алтын тәнкәләр генә өләште дә, чүл буенча тегеләрне ермак итеп куды. Алтын исен сизгәч, бәдәви гарәпләрнең җайдаклары Табук, Хәләл, Касыйм, Борай төбәкләрендә дә гел өстәлеп торды. Ләкин Әл-Гобәй каласы янында португал баскыннарының тәүге алайлары белән яуга кергәч, шулар иң беренче булып ташлап качты. Чүл күрмәгән нәсара җайдакларын янычарлар, ком бураны вакытында авыз-борыннарына яулык бәйләп орышканга күрә, пыран-заран китереп бетерделәр. Үзләре арасыннан да яуда ике меңнән артык җайдак ауды. Ком бураны тынгач, Фарсы култыгының уңъяк ярындагы соңгы терәк булган Маскат кирмәненә таба юнәлгәннәр иде дә, Мәдинә каласыннан юлланган чапкын куып җитте.

— Солтан галиҗәнапләре Фарсы култыгына озатылган яу сәфәреннән һич канәгать түгел. Бергә укмашып орышу турындагы фәрманга буйсынмыйча, Пәри Рәис үзбелдеге белән Фарсы култыгын ташлап, бөтенләй кире якка, Һинд ярына киткән. Солтан фәрманы буенча, ул Фарсы култыгыннан Кызыл диңгезгә керергә, шуның ярында сезнең белән кушылырга тиеш иде, юкса. Хәзер сез ике дәрья арасында япа-ялгыз. Якын-тирәдә сезгә ярдәмгә килердәй бер көч тә юк, яна фәрман булганчы Мәдинәгә кайтып урнашыгыз.

Янычарлар Ходай Тәгаләнең мәрхәмәтлелегенә рәхмәт укый-укый, Мостафа сәрдәрләрен куккә чөя-чөя, кайтыр юлга чыкты...

Ә Пәри Рәис, күрми кургән — чабатасын түргә элгән дигән шикелле, баштук һаваланды, шуңа хаталанды. Утыз карабка төялгән уналты мең нәүкәр өстеннән башлык булып алу җинел сынау түгел, башы тиз әйләнде. Ул Әл-Хатыйф портындагы португалларны туплар белән куып тараткач, төрек әләмен дә элеп вакланмыйча, Маскатка юл алды. Ике атна буе утка тотканнан соң аңа бәреп керде. Монысы инде португаллар өчен зур җиңелү иде, калдык гаскәрләрен

[10] Юлбарыс — Тигр, Җәфар-ат — Евфрат елгалары.

тәяп, алар Оман култыгына чыгып югалдылар. Иннәренә канат үскән сәрдәр Мостафа янычарларын да, сиксән яшьлек пашаны да көтеп маташмады. «Тагын ике әрәмтамакны көтеп житкерсәң, аш табынында үзең ач каласың. Шуның кебек, мин нигә болар белән дан бүлешим әле?»

Маскаттан соң Пәри Рәис Аден каласына юнәлде. Карабларын порт каршына таш дивардай тезгәч, бәйләрбәгә Әмиргә аның карабына башын иеп килергә әмер бирде. Аумакай бәйләрбәк капитан-пашаны үз ягына аударып, бу юлы да судан коры чыгарга чамалаган, ахры. Ул алтын тулы сандыкларын күтәреп палубага менде, әмма капитан-паша каршында тез чүгәргә дә өлгермичә калды. Бәйләрбәк Әмирне, кул өстенә чөеп, палубага корылган дар агачы астына озаттылар. Бәйләрбәк тынуга, төрек нәүкәрләре Аден каласындагы сарай һәм алачыкларга ябырылды. Халык тезгә чүккәч, янә Пәри Рәис өскә күтәрелде.

— Аден бәйлеге кабат төрек вилаяте дип игълан ителә. Бәйләрбәге, әмир ише дәрәҗәләр әрәм, сезгә хаким итеп сыбай калдырабыз...

Һаваланган Рәис, менә шул чагында нәфесен тыя алмыйча, карабларын Фарсы култыгының уртасында торган Ормуз утравы каршына тезеп куйды. Бер ай буена утрауда корылган таш кирмәнне утларга тотып та, нәүкәрләрне һөҗүмнәргә ташлап та карадылар. Ормуз — португалларның Һинд океанда төзелгән төп ыстаны һәм үзәк кирмәне иде шул, ул төрек солтаны каршында тез чүгүне күз чалымына да китереп карамады. Кирмән капкалары ачылып, португаллар баркас ишкәкләренә ябышкач, Пәри Рәис, караб тырнакларын күтәреп, эскадрасын Һиндстан ярына борырга мәҗбүр булды. Анда житкәч португаллар төзи башлаган Диу кирмәнен утка тотып караган иде дә, ядрәләрнең мәрмәр шикелле дивардардан борчак урынына кире сибелүен күргәч, карабларын Баһадир шаһ ышыгына борды. Тик бәхетсезнең чалкан егылса да борыны каный бит ул. Бактың исә, Баһадир шаһ күптән түгел генә фани дөньяга китеп барган икән. Аның урынына калган энекәше, Пәри Рәис күпме генә чакырып караса да, төрек карабына таба аяк та атламады.

— Аденнан хәбәр килеп иреште, мин үземне нинди язмыш көтүен нык чамалыйм. Мәгәр португалларга Диу кирмәнен төзетүдә Баһадир шаһ абыемның һичбер катнашы юк. Ул Сөләйман солтан каршында гөнаһын юу өчен баркас-баркас алтын-көмешләр дә җыеп куйган иде. Хасталангач, бар байлыгын исән-сау саклау өчен Мәккә каласына озаттырды. Ышанмасагыз, чапкын җибәрегез. Баһадир шаһның хәзинәсе шунда солтан галиҗәнапләрен көтеп тора.

— Безнең сәфәр Ходайның «амин», дигән чагына туры килмәгәндер, булмады бу, — дип яман сүгенде дә, Пәри Рәис инде кабат Басрага юл алды.

Ләкин португаллар искә-анга килеп өлгергәннәр, Ормуз утравы янындан үтеп барган чакта кирмән диварларыннан да, Оман ягыннан да ядрә яудырдылар. Караблар ике багана арасына килеп кысылган арба үрәчәсе сыман гел тетелеп бетте, трюмнар тишелде, мачта колгалары шартлап ауды. Бер карабта дары шартлаган иде, анда купкан янгын тиз арада күршеләргә күчте.

— Басра ягына, Басра ягына чыгып ычкыныгыз! — дип шартлау тавышларын да күмеп әмер биргән чакта болай да котсыз Рәис тагын да шыксызланган, кыргыйланган иде.

Давыл тынгач артына әйләнеп караса, яу кырыннан тагын ике генә караб исән-имин чыккан. Басрага кайтып борын төрткәч, тын алырга да ирек бирмәделәр.

— Солтан галиҗәнапләре сиңа Каһирәгә кайтырга боерды.

Каһирәгә керсә, дар агачы көтә. Маскат белән Аден кирмәннәрен яулап алуларны да, Мәккә каласыннан кайтып житкән алтын тауларын да — барчасын онытканнар. Колга — кол язмышы...

Сөләйман аннан соң да Басра каласы аша Фарсы култыгы белән Кызыл диңгез ягына ике флот куды. Морат паша дистә еллар буе сәүдә карабларына дәһшәт бөркүче диңгез бүресе булып саналса да, солтан эскадрасын Ормуз бугазы аша алып чыга алмады. Мусандам борыны янында португаллар пыран-заран китереп бетергәч, ул эскадра калдыгы белән янә Басра портына кайтып егылган иде дә, солтан җәлладлары бу бәхетсезне дә дарга асты.

Шулчак кайчандыр диңгездәге туктаусыз җиңүләре белән сөендергән, хәзер исә инде бөкрәеп беткән Хәйретдин пашаны искә төшерделәр. Шул карт киңәше буенча, Сөләйман Хәйретдиннең юлбасары булган Сәйди Галине яңа флот башлыгы итеп билгеләде. Гали паша әүвәл Бәһрәйнне, бераздан Кызыл диңгездәге барча порт-каланы португаллардан азат итеп күңелләрне үсендерде хәтта. Ләкин нәсаралар Маскат порты янында тозак корып, Кызыл диңгездән Аден култыгына күчкән Гали флотын да тар-мар китерделәр. Басрага әйләнеп кайтса дар агачы көтеп торачагын чамалаган Сәйди Һиндстан ярына барып борын төртте. Ул өч ел газаплардан соң фарсы, пуштун, үзбәк, әзәри сәхраләре аша Истанбулга кайтып егылганда солтанның мунча ташыдай кызган ярсулары сүнгән иде инде.

— Их, үзем бара алмадым! Әһ, үзем барган булсам! — дип әрни-әрни сүгенде Сөләйман, һәр хурлыклы җиңелү турында ишетеп алган саен. — Үзем барсам, барыбер, җиңә идем. Минем сәфәрләрем һәрчагында догалы булып чыга. Юлга чыксам, җиңми кайтканым юк. Их-ма, адәм баласы бишкә ярыла алмый, шунысы бик кызганыч!

Сөләйманга вәзир-пашалары бертөрле дә җавап таба алмады. Сәере шул — солтан хаклы иде.

## 38

Сафагәрәйне кирмән эченә җирләп куюга ук Казан илен пычрак гайбәт белән имеш-мимеш басты.

— Ике яшьлек Үтәмешгәрәйне, күз буяу өчен генә, хан ясаган булып игълан иттеләр лә. Имеш, Мәскәүдән үрнәк ала инде болар. Андагы Иванны шулай, атасы Василий җанын тәслим кылгач, өч яшендә олуг кенәз дип атаганнар икән, янәмәсе. Иван бәләкәй чакта анаң анасы Елена васый[11] булып торган да, безнең Үтәмеш үсеп житкәнче ил белән Сөембикә ханбикә идарә итәчәк ди, имеш. Хатын-кызга дилбегә тоттырсаң, ул әле ат булып атны да тыңлата һәм буйсындыра алмый. Ил кадәр ил белән ничек итеп хатын-кыз ялгыз көе идарә итсен инде? Уен бит, уен!

— Әй, Сөембикәне васый ясап куюлары да шул күз буяу гына. Диванга хәзер Кырымнан килгән Кушчак углан менеп атланган. Ханбикәнең шәхси гаскәре шул ук Кушчак кулында. Ул, нәкъ Сафагәрәйнеке шикелле, Үтәмешгәрәйнең дә җанын кыячак та берзаманны, Сөембикәгә өйләнеп, тәхетне дә үз кулына эләктерәчәк инде, валлаһидыр менә.

Имеш-мимеш үз этлеген эшләп өлгергән шул, ун меңләгән кеше Мәскәү тарафына чыгып качкан, диләр. Боларын да ишеткәч, халык кына түгел, Сөембикә үзе дә иксез-чиксез пошаманга калды. Үтәмешгәрәйнең ханлыгына ризалык алырга дип Мәскәүгә Чапкын морзаны илче итеп юллаганнар иде, «кайсар» атын таккан япь-яшь Иван аны себеркеләп куган. Шуннан соң, Мәскәүнең Нугай Урдасын үз ягына аударырга җыенганын нык белгәнгә күрә, ничарадан бичара кыяфәттә, Сөембикәнең атасы Йосыф морзаны да ике арада солых төзү максатыннан юллап карадылар.

[11] Васый — регент, опекун.

— Мәскәүнең дә, Казанның да бер-берсе каршында һичнинди бурычы юк, ике күрше сәүдә итешеп, дус яшәргә тиеш. Урынсыз җирдә кан коюны Коръән-Шәриф белән Инҗил дә һич хупламый, — дип Йосыф морза юкка гына куәт сарыф итте.

— Нишләп Казанныкылар үз морзаларын юлламыйлар әле, нигә алар сине яллаганнар? — дип Иванның үзен дә уздырып, Сильвестр атакай белән Адашев атлы икейөзле, җасус кенәз яман җикеренде. — Казанныкыларның Үтәмешгәрәйне тәхеткә утыртырга хокукы юк. Анда хан булып торган Шаһгали исән. Алар Шаһгалине чакырып китерергә тиеш иде.

Шуннан ары Йосыф морза инде ялвару һәм очсызлануга кадәр барып житте.

— Ярар, ярар, без Шаһгалине чакырып китерергә дә риза, тик Казан өстенә генә яу чапмагыз. Минем Сөембикә кызым янәдән тол калды. Шаһгалине җибәрәсез икән, Сөембикә белән кавышырлар да ил белән икесе бертигез дәрәҗәдә идарә кыла алырлар иде, дип беләм мин...

Йосыф морзаны бер җавапсыз кәе кире аткардылар. Илленче елның кышы керүгә үк Иван-кайсар Казан өстенә яна гаскәр куды. Әүвәл гаскәрбашлар итеп һаман шул ук Шаһгали белән кенәз Бельскийны гына юллаган иде дә, февраль башында Әстерханда хан булып утырган Касыймның улы Ядегәрне житәкләп, шәхсән үзе дә килеп житте. Йөз меңнән дә артык нәүкәр белән Казан каласын ун көн буе камап карадылар. Казан эчендә боларга каршы тора алырдай җитди көчләр дә юк, әмма Ходай Тәгалә аларны яклау-саклау ягына чыгып басты бугай. Көн дә күз ачкысыз буран, көн дә күк капусы ертылгандай тоташ карлар. Ул да түгел, бер иртәдә тоташ карны көзге айлардагы шикелле яңгыр алыштырды, карлар эреп, юлны ташкын басты. Урыс кенәзләре бакыр вә чуен тупларын чокырларга батырып бетерделәр, ә төнге салкыннарда чатыр түбәләрен генә түгел, хәтта ат-бичараларның сыртын да боз элпәсе тоташ сырып алды. Иван-кайсар йөз меңлек гаскәреннән нибары егермеләп мең генә, анда да әле чыбыркылап куа-куа гына, Казан кирмәненең диварларына ташлый алды. Ләкин казанлыларның мондый гына көчкә буйсынасы килмәде, ис-акылны җуеп орыштылар. Алар ягыннан гаскәрбашы булып саналучылардан Чалбак морза белән Сафагәрәйнең әсирлеккә төшкән урыс хатыныннан туган улы шәһид булып ауды. Үзенең бернинди дә җиңүгә ирешә алмаячагын аңлап өлгергән Иван-кайсар, янә күз яшенә батып, кайтыр юлга чыкты.

Тик, кайту юлында, сатлыкҗан Шаһгали моңа бернинди энҗе-мәрҗәннәргә тиңсез зирәк акыл биргән. Зөя елгасының Иделгә коя торган җиренә җитүгә үк, Иванны җитәкләгән дә, шундагы түбәтәй шикелле түм-түгәрәк утрау-тау өстенә алып менгән бит бу.

— Менә моннан кара. Нижгар юлы да, Нократ белән Сембер тарафы да, хәтта Казан каласы үзе дә бишектәге шәп-шәрә бала шикелле шыр-ярылып ята. Синең атаң Василий кенәз, чирмеш илендә үз исемендәге кирмән корып коеп, Казан җиренә йөгән кидергән иде. Әгәр син менә шушы утрауда кирмән төзеп куйсаң, менә монысы Казан иленә чып-чынияр булыр.

— Монда нәсара кирмәне төзеп куячакбыз! Бик хуп урын, гаҗәеп шәп урын! — дип тай шикелле сикергәләп очына башлады шундук Иван кайсар.

Икенче көз керүгә чирмеш урманнары эчендә, йөзьяшәр нарат-карагайны егып, бура ясау эшенә тотындылар. Сильвестр атакай Мәскәү уртасында агачлардан чиркәү төзетте дә, шуны сүттереп, Идел буйлап түбән озаттырды. Иван фәрманы буенча, кирмән төзү өчен Касыйм каласыннан Халик морза белән Нократ олысыннан Бәхтияр атлы яна бер сатлыкҗан останы озаттылар. Шулар икенче язда бер атна эчендә Зөя тамагында әр-яңа бер кирмән калкытты

да куйды. Хәзер инде Казан иле чулак бичарага охшап калган, мәмләкәтнең Тау ягы дип аталган олыслары кулдан киткән иде.

Илгә нинди хәвеф янавын төшенеп алуга ук Сөембикә янына Кушчак углан чәчрәп килеп керде.

— Кулдан ил китә, илне югалтабыз. Синең атаң Йосыф морза юллаган өч мең җайдак белән генә Казан каласын егылудан саклап калып булмый. Кырымдагы Сәхибгәрәй ханны суеп үтергәннәрен күптән беләм. Мәгәр аның тәхетен әләктергән бәдбәхет Дәүләтгәрәй дә татар ханы, кардәш ханыбыз бит. Мин Бакчасарайга кайтам да аның алдына егылып карыйм әле. Үтәмешгәрәй аңа җиган тиеш, җаны булса, ярдәм итми калмас.

Кушчак күзләрен яшерә, читкә карап кына сөйли иде, Сөембикә сүнеп барган шәм шикелле тоныкы кына дәште.

— Ярар, барып кара. Бәлкем, ярдәм итәр. — Кушчакның ишеккә юнәлә башлавын күргәч, ягымлы өстәп куйды. — Ә мин сиңа ышанам һәм... барыбер көтәм.

Юк, насыйп булмаган шул. Кушчак үзенең өч йөз җайдагы белән кайтырга юнәлгәч, Нократ елгасы ярында аларны урыс ялчылары, тозак корып, көтеп торган булган. Яуга кергәч, ике йөз илле кырымлыны турап ташлаганнар. Кушчак углан белән бергә кырык бишләп җайдак әсирлеккә төшкән. Аларны Мәскәү каласына алып киткәннәр дә җәза мәйданында башларын чаптырып юк иткәннәр икән.

Шушы явыз хәбәрдән соң ук Казан каласына Мәскәү тарафыннан фәрман килеп төште.

— Казан-йортның Тау ягы олысларына моннан ары Мәскәү генә хуҗа. Чирмеш-мукшы җирләрен мәңгегә онытыгыз. Илне канга батырасыгыз килмәсә, Сөембикә ханбикә белән Үтәмешгәрәйне Мәскәүгә җибәрегез. Алар Иван Василич каршында буйсымчаклык итсә, кайсарыбызның Сөембикә ханбикәне Шаһгалигә кияүгә биреп тә куюы бар.

Казан иле күз яшенә батты.

## 39

— Мостафа абый кайткан! Солтан, ниһаять, үзенең угылына да паша дәрәҗәсен биргән! — дигән хәбәр белән Баязит энекәше Җиһангирны кочагына алып өлгермәде, артта янә ишек ачылды да, май кояшы сыман елмаеп, Мостафа шәхсән үзе дә пәйда булды.

Шап-шоп килеп, кабат күрештеләр. Унсигез яше тулуга ук, Баязитны да солтан үзенең тәхет рәшәсеннән бик еракка, Конья каласына бәйләрбәге итеп куган иде. Шуннан бирле Истанбулга Баязит бик тә сирәк кайта, Мостафаның юлына Хүррәм йозак элгән, ике-өч елга бер генә күрешкәч, ихлас сагынышканнар.

Бергә җыелуның сере тиз ачылды.

— Солтан Топкапеда диван өчен махсус сарай төзегән, шуны ачу хөрмәтенә мәҗлес үткәрәчәк, — дип, берсен-берсе бүлә-бүлә, ике абзый кеше төпчек энекәшләренә соңгы яналыкны җиткерделәр. — Түбәсенә зур манара куйган, бу йорт моннан ары «Гадәләт сарае», дип аталачак икән.

Кызып киткәч, солтан галиҗәнапләрен янә мактадылар.

— Безнең атайга яңа бер чир йоккан. Ул Истанбулны бар җиһанның мәркәзе итеп үзгәртергә алынган бит әле. Рум каласыннан Синан атлы бик тә мәшһүр мигъмарны чакырткан, ди. Тегеләрдә гөмбәзләренең биеклеге кырык аршинга җиткән София мәгъбәде бар, ә безнең атай, шуны уздырып, манаралары алтмыш аршинлы үзәк мәчет төзетмәкче икән.

Мостафа — өлкәне бит, дилбегәне күбесенчә үз кулыннан җибәрмичә тотты.

— Сәлим әниегезнең куенында яши, аның турында нинди хәбәрләр бар?

— Аның бар кайгысы — җария итәкләре, — дип Баязит яман төкеренде. — Тагын бер чире бар — шәраб мичкәсеннән аерылмый. Халык үзенә «сәрхуш» дигән яманатны тагып өлгергән дә бугай...

Абзыйлар сөйләшкәндә Җиһангир икесенә дә ялт-йолт кына итеп күз йөгертте. Мостафа утыз бишне генә тутырды бит әле, ә ике як чигәсенә дә ап-ак бәсләр кунган. Баязитка, гомумән, егерме биш кенә, тик аның да маңгаенда, күз тирәләрендә тирән җыерчыклар. «И-и, тәхеттән читкә тибелеп яшәүләр дә җинел түгел икән, — дип җинел сулап куйды Җиһангир. — Минем тәхет өчен янасы-көясем юк, һич югы шуның хакына Ходай Тәгаләгә рәхмәт укыйсыңдыр».

— Синең икенче малаең тууы турында хәбәр килгән иде, бик тә мәмнүн булдым. Иллә мәгәр, барыбер дә, миннән калышасың, — дип Мостафа Баязитның җилкәсенә сугып шаярткач, тегесе дә авыз гына ерды.

— Сәфәрләрдә йөреп, соңга калгансың бит, мин өч малайның атасына әверелдем инде. Синеке дүрт кенә, озакламый куып җитәчәкмен.

— Ә син һаман үз өеңне ташлап китә алмыйсың, элеккечә Баязит бакчасында. Топкапедагы яңа сарайда синең башыңа урын тапмыйлармы әллә? — дип Мостафа инде Җиһангир тарафына шаярткан шикелле киная ташлагач, төпчек энекәшләре чебен куган сыман кул селтәде.

— Әй, ул сарайның миңа нигә кирәге бар? Яңа кәвеш аяк кыра, хәтта чыбыркының да янасы тәнне яра торган була бит ул.

— Сине газәл, робагыйлар язуда бик шомарган, диләр. Халык теленә кергәч, мөгаен дә, хактыр?

— Тырмаштырып азапланам гына, күкрәк сугып сөйләрдәй газәлләр юк, халык күпертергә ярата ла инде, — дип Җиһангир оялудан башын түбән игәч, Мостафа белән Баязит та бик кызганып кына энекәшләрен күздән кичерделәр.

Их, энекәшләре туган җанлы, бик бай күңелле дә, бөкре, кызганыч шул. «Сиңа да башлы-күзле булырга вакыт инде», дип киная ташлар идең, гарьләндереп яисә җәрәхәтләп куюың бар. Ә һаман болай, мәгарәгә йә хөҗрәгә[12] кереп бикләнгән дәрвиш сыман, шушы сарай ышыгына гына качып ятса, гомер буе ялгызлыкта чиләнер микәнни соң?

Кәтмәгәндә чынаяклар зеңләгән тавыш ишетеп, ишек тарафына караш ташладылар. Сөбханалла, яңнарына мөлаем йөзле, бик җыйнак гәүдәле унөч-ундүрт яшьлек кенә бер кыз кереп килә. Яңаклары алма кебек алсу, кашлары сандугач канатларыдай кыйгач, иреннәре пешкән җиләк сыман, күз тимәсен. Кунакларга таба күтәрелеп багудан да оялмы инде, карашын Җиһангирдан аермый да үзе.

Мостафа белән Баязитның бизмәннәрен тоемлады, ахры, яшүсмер кыз ишектән тавыш-тынсыз гына чыгып югалуга, Җиһангир кыяр-кыймас кыяфәттә телгә килде.

— Сарайдагы кырнак кызларның берсе Разия бу. Менә аннан сораштырып карасагыз була иде. Язган газәлләремнең күпчелеген, беренче булып, мин аңарга укыйм.

Абзый кешеләрнең җанына җылы йөгергәндәй булды. Бик хуп, бик хуп. Бу газәлләр уку учак кебек кабынып китсә генә ярар иде.

Байтак вакыт буе гөрләшеп утыргач, Мостафа китәргә дип кузгалды. Саубуллашу алдыннан шактый катгый итеп сүз башлады.

[12] Хөҗрә — борынгы мәдрәсәләрдә дәрвишләр бикләнеп яши торган бүлмә.

— Сезнең икегезне дә ерак бабабыз Морад солтан язып калдырган кансыз канун белән таныштыр, дип беләм. Аның «Тәхет варислары турындагы» канунын хәтергә төшерүем. Ул тәхеткә юл арчу өчен, җанкыярлар яллап, үзенең унтугыз туганын үтерттергән. Шушы җинаятен, вәхшилеген аклау өчен соңыннан нәкъ әнә шул канунны чыгарган да инде. Әмма начар гадәт йогышлы була, дигән шикелле, Морад солтан язып калдырган ул канунны башка варислар да үзенә калкан иткән. Явыз Сәлим бабайны гына искә төшерегез. Әтисен агу биреп үтерткәнме-юкмы, ул хәтлесе өчен бәхәсләшә алмыйм, андый сүзләр әле булса йөри. Иллә мәгәр үзенең ике энекәшен үтерткән бит, монысы инде һәр кешегә мәгълүм.

Баязит белән Җиһангир тын да алмый тыңлап тордылар, ләкин Мостафа алар карашында яшерен аптыраш, хәтта шомлану чаткылары да күргән кебек булды. Шуңа инде үзенең төп тәкъдимен дә көттермичә генә әйтеп салды.

— Ходай Тәгалә безгә нинди тәкъдир язгандыр, анысын белеп булмый. Әмма бизмәнгә салып үлчи башласаң, безнең өчебез дә тәхетне дәгъвалау хокукыннан мәхрүм ителмәгән. Атаебыз мине әле сабый чакта ук шаһзадә, дип атаган, анысы сезгә дә мәгълүмдер. Шул ук вакытта ул әллә кайчан Сәлим турында да булачак шаһзадә, дигән сүзне ычкындырган. Мин шәхсән үзем тәхет чирен йоктырмадым әле. Ә менә Сәлим абыегызның да, тора-бара сезнең дә андый яман чиргә тап булуы мөмкин. Шуңа күрә үз вакытында, кулга кылыч элэктергәнче үк сүз беркетик, димен. Кем генә, кайсыбыз гына солтан вә хакимдар булуга ирешмәсен, ул бер туганына да кул күтәрергә тиеш түгел. Чит мәмләкәткә чыгып качарга ирек бирәме ул, үз канаты астында вәзир яки көтүче итеп яшәтәме — анысы солтан булуга ирешкән кеше хөкемендә. Тик аның һичбер вакытта да, бернинди хәйлә йә мәкер белән дә үз туганнарының канын коярга хокукы юк. Сез шушының белән килешәсезме? Шул вәгъдәме?

— Килешәбез, абый, вәгъдә, вәгъдә, — диде әүвәл Баязит энекәше.

— Вәгъдә генә түгел, ант итәбез! — дип хуплады шундук бөкре Җиһангир да.

Шуннан соң алар янә кайнар итеп кочаклашып хушлаштылар.

## 40

Сөембикә мәликә белән Кушчак угланнан соң Казан эчендәге идарә Ходайкол һәм Нургали Ширин кебек икейөзле морзалар кулына күчеп беткән иде. Шулар Зөядәге баскын кенәзләр тарафына Себер морзасы Бибарс белән Колшәриф сәетне илче сыйфатында мәҗбүриләп-куып юлладылар.

— Без Мәскәү күз уңында тоткан ханны утыртуга риза. Шаһгалине тизрәк китерегез.

Август уртасында Мәскәү дәүләтенең балта сабы булган курчак Шаһгали өченче мәртәбәсенә Казан иленең тәхетенә инде. Сөембикә мәликәнең якташ булуыннан файдаланып, кирмән-диван тирәсенә нугай морзалары оялап беткән икән. Шуларны үз ягына аударырга ниятләп, Шаһгали Сафагәрәйдән калган бер тол ханбикәне — нугай киленен — рәвешен китереп һәм никахлап, үзенә хатынлыкка да алып куйган булды. Ләкин, юк, төп бәла кодалыкта-кардәшлектә түгел, Казан морзалары курчак ханга арты белән торуны барыбер туктатмады.

— Тау ягының Мәскәү кул астында калуыннан без нәразый. Ханлык таҗын киеп алгансың икән, чирмеш илә мукшы җирләрен Казан тәхетенә кире кайтар.

Морза белән сәүдәгәрләр шундый бердәм таләп тәкрарлый башлагач, Шаһгали әүвәл әле ыҗламаган иде, мәгәр шушы ук җырны диван утырышларында кабатлап та тынгы бирмәделәр.

— Иделнен унъяк ярындагы олысларны кайтару өчен көрәшмисен икән, тәхет хакына урыс ягына сатылгансын, димәк.

Гайрәт күрсәтмәкче булып, Шаһгали Зөядәге Серебряный атлы кенәз каршына барып басты.

— Ясак җыеп чыгу өчен мина Идел аръягында чирмеш илә мукшы олысларын әйләнергә кирәк.

— Һәй, хан галиҗәнапләре, сөякне тешләренә каптырган эт аны кире бирәмени? Иделнен аръягын оныт инде син, мәнгелеккә оныт, — дип урынына тиз утыртты аны баскын кенәз. — Кайсарыбыз Иван аларны өч ел буена ясак түләүләрдән азат итте, морзаларынын һәркайсына кеш яисә тиен тиресеннән тегелгән тун өләшеп чыкты. Чирмеш морзаларының күпчелеге шулар бәрабәренә Иван-кайсарга буйсыну турында бигать китерделәр. Син Мәскәү кайсарыннан да бөегрәк хаким булырга маташма. Үзенне кем хан тәхетенә китереп утыртуын оныта күрмә берүк.

Зөядән кайтканнан бирле Шаһгалинең баш түбәсенә сугылган песи баласы урынына тын да чыгармыйча, шыпан-шыпан гына йөрүен чамалагач, бертуган Себер морзалары Бибарс белән Җанбарс, һәм дә Кадыш баһадир, Карамыш угланнар Нугайдагы Йосыф мирза янына, аннары бер үк вакытта Кырым тарафына да чапкын юлладылар.

— Шаһгали — хыянәтче. Ул Казан-йортка элмәк кидерү өчен китереп утыртылган. Анын урынына хан булырдай шаһзадә йә күренекле морза табып җибәрегез. Без сатлыкҗан Шаһгалине тәхетеннән чәнчелдереп төшерүгә әзер.

Кырым тарафына юлланган чапкын монафыйк бер бәндә булып чыкты, ул Шаһгали каршына килеп тезгә чүккән. Казандагы фетнә оеткысы турында белеп алуга ук, Шаһгали дә мәкерне шәп корган.

— Мәскәү белән бик тә мәртәбәле килешү әзерләнә. Шул форсаттан хан галиҗәнапләре үзенең сараенда мәҗлес үткәрәчәк.

«Хан сыена бик санаулы вә мөхтәбәр инсаннар гына чакырыла», дип тә өстәгәч, Казан морзалары җинел сатылдылар. Бертуган Бибарс белән Җанбарс та, Кадыш баһадир, Карамыш углан, Кулай морза — барысы да ашыга-ашыга, хәтта әле узыша-төрткәләшә килеп житте. Кенәз Серебряный үзенең укчы-җәлладларын әле алдан ук сарай чоланнарына тутырып куйган иде. Татар морзалары мәҗлес өстәле янына тезелеп утыруга, шул җәлладлар житмештән артык кунакны тоташ суеп чыкты. Кан исеннән котырган урыс җәлладлары аннары Казан урамнарына атылды, анда да һәрбер тыкрык һәм ихата диярлек гөнаһсыз корбан мәетләре белән бик тиз тулды.

Исән калган, әмма өннәре алынган татар морзалары ашыгыч рәвештә Иван-кайсар тарафына чапкын аткардылар.

— Шаһгали — залим вә эштән чыккан мәрхәмәтсез кассап[13]. Аны ханлыктан төшер дә, инде чыдамасаң, урыс кенәзен булса да баскак итеп җибәр.

Мәскәү тарафыннан, артына ут капкандай, таныш кенәз Алашев килеп житте. Анын Шаһгали өстенә түккән һәрбер сүзе елан угыдай мәкерле һәм усал ысылдады.

— Казан халкы синең урынына башка ханны сорый. Өч мәртәбә менеп утырып та, үшән алашага авызлык кидерә алмаган нинди бәндә соң син?!

— Ходай Тәгалә нинди ләгънәт укыгандыр инде, Казан халкы мине яратмый бит, — дип күз яшенә батты курчак хан актыгы. — Мәмләкәтне түгел, үземнең башны сакларлык та көчем-гайрәтем юк.

[13] Кассап — ит чабучы.

— Ну, алайса, сине Иван кайсарыбыз яңа хаким белән алыштыра инде, — дип котыртуын белде икейөзле кенәз.

Мондый янаудан соң Шаһгали ярсый-ярсый, яман котырынды.

— Юк, юк, үземнән соң Казанга бернинди яңа ханның да килүен теләмим мин! Төшерәсез икән, минем урынга урыс идарәчесен, Мәскәү баскагын китереп утыртыгыз! Мин барысына да риза, яңа ханны гына эзләмәгез!

— Алайса, Казанны урыс баскагын каршыларга әзерлә, — дип киңәш биргән булды төксе йөзле Адашев. Бик өметле итеп өстәп куярга да онытмады. — Синең тырышлыкны Иван кайсарыбыз бәяләми калмас...

Кышкы бураннар үтеп язга керүгә үк пайтәхет эчендә хәбәр тараттылар.

— Шаһгали хан тәхетне ташлап китүне максат итми микән? Байчуралар алдында миһербанлы күренмәкче булып, ул кала морзаларының һәммәсен дә үзе белән олы ауга дәшә.

«Ауга» булгач, корал аласы бит, шуны уйлап биш йөзгә якын Казан мөхтәбәре, җәя-кылычларын калдырмыйча, каланы ташлап чыкты. Шаһ-Гали үзе Бишбалта артындагы Елантау өстендә көтеп тора иде. Аның каршына килеп тезелүгә, биш йөз морза белән сәүдәгәрне дә урыс җайдаклары урап алды. Ризасызлык авазларының куеруын да көтмичә, әрнүле тавышлар белән Шаһгали телгә килде.

— Сез мине башка хан белән алыштырырга йә үтереп ташларга ният иткән идегез ләбаса. Хәзер минем сезне коралсызландыруыма нигә шаккатасыз? Кунак ашы — кара-каршы була, шуны онытмагыз.

Ирләрнең сүз кушмыйча, буйсымчаклык күрсәтүен аңлагач, ул җил кабарткан учак кебек ярсый гына бирде.

— Сез минем урынга баскак сорап, Иван-кайсар янына үзегез үк чапкын кудыгыз бит. Менә, мин үз теләгем белән тәхет ташлап чыктым. Инде рәхәтләнеп, җаныгыз кемне тели, шуны чакырырсыз, шуңа буйсынырсыз. Әмма белеп торыгыз, мин Казан эчендә бер туп та калдырмадым, барысын да монда җыеп чыктым. Онытылып калганнарының да, барыбер, дарысы юк. Бу — сезнең миннән йөз чөерүегез вә мине хан итеп танымавыгыз өчен тәнгәл җавап.

Ирләрнең күзләре акаешып чыкты, кайсы берсе як-ягына төкеренеп алды. Әмма Шаһгалигә каршы күтәрелеп бәрелүдән, барыбер, шөллиләр шул. Ә ул инде, әнә, җанын ашъяулыгы сыман ачып салган.

— Сез мине яратмадыгыз, әй, тәкәббер булып кыйландыгыз инде! Иллә мәгәр оныкларыгыз өчен дә ятлап калдырыгыз. Яхшымы-яманмы, мин сезнең берегезнең муенына да кәчли-кәчли тәре кидермәдем. Мине өченче вә актык мәртәбәсенә куып җибәрдегез. Хәзер, әйдә, урыс итеге астында чукыныгыз инде!..

*Ахыры киләсе санда*



Рүзәл
Мөхәммәтша

# ҖАНГА ТӨШӘ АВЫР КҮЛӘГӘҢ

***

Мин кояшсыз да яшәргә әзер.
Ансыз көнегелер ничек тә. –
Елмаюың калсын! Иlaһ нурын
Алыштырыр өчен – шул җитә.

Мин сусаудан тилмерергә риза,
Әйткәннәрем буш сүз булмасын!
Кизләү кебек күзләреңне эчим,
Чәчләреңнең сыйпыйм елгасын.

Мин һавасыз йөзгә җитә алам! –
Кем кабатлар... шуның ише, дим? –
Карангыда, дөнья уйга баткач,
Сулыш алуыңны ишетим...

Миңа табын тулы ниғъмәт нигә,
Ни югалттым соң ул табында?
Иреннәрең чияләрдән кызыл,
Хөрмәләрдән татлы чагында...

Син барында мин мәңге бәхетле!
Тик сынауның бирсәң авырын,
Бер мизгелдә сукыр, тын житмәүчән
Һәм тәм сизмәс булып калырмын.

Рүзәл МӨХӘММӘТША (1989) — *шагыйрь; «Каралама», «Бүре мин» исемле китаплар авторы. М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Ястү

Тәрәз урынына
Рамда — төнге рәсем:
Тонык урам. Мәчет.
Имән күләгәсе.

Жирне коендырып
Күкшел нур моңында,
Ай — «киндер»гә кунган
Чебен зурлыгында.

Дөнья бер тамчыга
Артык түгел шуннан.
Мулла сагыш өсти
Тынлык тавышына,

Һәм тарала илгә
Безненчә сүз әллә:
— Исәннәргә сәлам!
— Исәннәргә сәлам!

Кара, караңгы йорт.
Ак япмалы ятак.
Шунын уртасында
Тынсыз карчык ята.

Янәшәдә — олан.
Шөбһәлекне өзеп,
Борын тартып ала...
Тәрәзәдә күзе.

Ә уемда анда,
Рамда — төнге рәсем:
Тонык урам. Мәчет.
Зират күләгәсе.

Һәм дертләтә жанны
Килеп ингән вәхи:
— Исәннәргә сәлам!
— Үлгәннәргә... бәхил!

## Минеке

***(Хәдис-шәриф)***

Ике күрше жир бүлеште.
И зы кубып!
— Бу — минеке!
Ызан-межа сызыгының
Аръягына сузгансың кул, — диде берсе.
Икенчесе тезеп салды үз дөресен:
— Юк, минеке!
Һәр зар-ялаң — язык, — диде, —
Сыңар аршын эчкә кергән казык, — диде.
— Жир минеке!
— Жир минеке!
Кызу хәлләр!

Жир шулвакыт телгә килде, әйтте хәбәр:
— Сүз тузанын тузгытмагыз, бик ансат ул —
Сез икегез дә минеке, адәм заты...

## Кырым — 2014

Сыңар күзен йомды,
Язмышына күнеп,
Илаһ Тәгаләнең
Нәүбәттәге көне.

Баш житмәслек түгел,
Артык түгел йә ким:
Акмәчеттә хәзер
Карангылык хаким.

БеТеэРлар йоклый,
Тик йокысы уяу:

Көпшәләрен, тормыш,
Сиңа төбәп куя!

Люк өстендә берәү.
Актаныштан, ахры.
Башын игән, елый,
Елый... акрын-акрын...

Хәтер төпкеленнән
Кабат чыга йөзеп
Кырым карчыгының
Агарынган йөзе...

Һәм нәрсәдер суга
Сул яктарак, түштә.
Иртәгәсен медаль
Урнашасы төштә.

Акмәчеттә шау-шу,
Акмәчеттә бәйрәм! —
Сызгырулар тынмый,
Барабаннар бәрә!

Шатлык авазлары
Сау гакылдан өстен!
Бу тавыштан колак
Канап чыгар төсле!

Бу тавыштан миең
Кайнап чыгар сыман!
Бактерия мыжгый
Кырым ярасында!

Салют чәчрәвеге,
Чиркәү чаңы... Ура!
Ә ул елый, никтер,
Ә ул елый... Дурак!

Улап җибәрмичә
Көчкә-көчкә түзеп...
Люк өстендә — солдат.
Актаныштан үзе.

***

Мин хәзрәткә «әйе» дигән чакта
Ихлас идем...
Ни дим тагы ла?
Нәрсә вәгъдә итим?
Кесәмдә — җил...
Шул җил, шомландырып, өстәвенә,
Бәгырь кылларына кагыла.

Кабат көең киткән:
— Кайда йөрдең? —
Бәйдәге эт түгел соң ла мин!
Сабыйныкы төсле күз яшьләрең...
Елап җибәр, юкса...
Сокланыйм.

Әмма сөю үлчәвеннән хисне
Нәфрәт үлчәвенә күчермә!
Кичер мине, рәнҗеткәнем булса,
Кичер... рәнҗетәсем өчен дә...

Мин янадан салмыш!
Күкрәк төеп,
Әрлә!
Котыр!
Соңрак коч кына...
Ә мин башым салындырган килеш
Шуып төшим аяк очына...

— Болай барса, озак сузмассың ич! —
Җанга төшә авыр күләгәң...
Ни афәте аның — рәхәтләнеп
Итәгенә ятып үлгәндә?..

Ә Илаһка әйтермен дөресен:
«Тәүбә кылыйм, дидем... соңардым».
...Һәм үтенеп, хәрәм гомерем белән
Шул гомеремдә бердәнбер хәләлем —
Син ярымны кире сорармын!



Зөлфәт
Хәким

# ГАЗАП

БӘЯН

## 1

Җәй башының эссе бер көнендә ачык һавада җилләнеп кайтыйм дип чыккан идем.

«Зур Кызыл» урамның күләгәле ягыннан әкрен генә барганда, каршыма йончыган кыяфәтле бер агай очрады. Өс киеме болай пөхтә булса да, чырай төсеннән, шактый җиткән кыл сакал-мыегыннан, күз карашыннан — аның махмырдан икәнен һәм инде шактый вакыт салып йөргәнен абайларлык иде. Мин аның бу халәтенә болай тәфсилле ригая бирмәгән дә булыр идем, ул бит үзе мине җиңемнән тотып туктатты. Мондый дорфалыктан башта аптырабрак киттем, әмма аның күз карашын күргәч, аннары ул мине танып, сүз башлагач, шундук тынычландым.

— Исәнме, Зөлфәт — диде ул һәм аның «сез» дип түгел, үзебезчә, татарча «син» дип эндәшүе күңелемә хуш килде.

Ул үзенең мине очратуына чиксез шат икәнен ничек аңлатырга белмәде.

Минем иҗатым турында сүз башларга маташты, мәдәниятебез турында нидер әйтергә теләде һәм мине җентекләп күзәтә-күзәтә, бу көтелмәгән очрашуга шаккатуын әйтер өчен сүзләр табалмыйча җәфаланды. Шатланганда да аның тирән сагышлы күзләренең гел мөлдерәмә дымланып торуына игътибар иттем.

Мин монарда ниндидер җан газабы барлыгын шәйләдем һәм аның белән сөйләшергә үзеннән-үзе теләгем туды — кыяфәте, үзен тотышы, күз карашы, сөйләшү манерасы — барысы бергә, ни гаҗәп! — аның белән аралашырга тартып тора иде.

— Ярый очрадың әле, — дип әллә ничә тапкыр кабатлады ул. — Мин бит сине бик ихтирам итәм. «Нәрсә булды сиңа бүген?» дигән җырынны туксан икенче елны хатын белән өч ай буе көн саен тыңладык.

Исеме Рашат икәнне, Казанның «Зур Урам»ының башында ук урнашкан биш катлы йортта яшәвен, соңгы вакытта беркайда да эшләмичә, хатынының нәфрәтен яулаганын, кызының да, улының да үз гаиләләре белән аерым яшәүләрен, өч оныгы барлыгын, сагыш катыш горурлык белән, яңа танышым тиз арада миңа сөйләп тә бирде.

---

Зөлфәт ХӘКИМ (1960) – *драматург, прозаик. Дистәдән артык китап һәм күпсанлы җырлар авторы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Хисләнеп, вакыт-вакыт кайнарланып сөйләүдән аның хәле бетте, йөзеннән төсе тәмам качты, баш төзәтәм дип салган дозасының шаукымы чыгып беткәне шундук күзгә ташланды.

— Бер йөзәр грамм аракы эчмибезме? — диде ул.

Икеләнеп торуым аның эчәргә теләвен көчәйтте шикелле, ул мине, беләгемнән тотып, урамның мин барган юнәлешендә алып китте. Юл уңаеннан мин, кибеткә кереп, бер шешә затлы аракы, кабымлыкка сыр белән сок алып чыктым.

Кремль стенасына өч йөз адым чамасы калгач, уң якта ачык җәйге кафе бар иде, шунда барып, кырыйдагы өстәл янына урнаштык.

Ачык һавада йөзәр граммны «каплап» куйдык.

— Яшь чакта син төрмәдә утырган булгансың икән? — диде ул көтмәгәндә.

— Әйе, булды, — дидем мин, аның бу хакта сүз башлавына аптырап. — Яшь чакта булды инде әллә ниләр. Егерме бер яшь кенә иде миңа ул вакытта.

— Маладис кеше син. Төрмәдә утырганыңны да яшермисең...

— Аны барыбер беләләр бит, — дип көлеп куйдым мин.

«Шешәдәшем»нең чырае тагын кинәт агарып китте. Шушы аралашкан вакыт эчендә генә дә мин аның йөзенең төрле төскә кереп, йә тартылып, йә бүртебрәк киткәнен чамалаган идем инде.

— Мин бит үзем дә төрмәдә утырырга тиешле кеше, — дип уйга калды ул. — Йә башка төрле җәзага тартылырга тиеш. — Вакытың булса, мин сиңа бүгенге көнгә кадәр җанымны газаплаучы бер вакыйганы сөйләр идем.

— Мин беркая да ашыкмыйм, — дидем мин. — Тыңлыйм.

Ул тагын башын салындырып уйга калды.

Бу урта буйлы, башы яртылаш пеләшләнгән, инде шактый гомер яшәгән кешенең ниндидер авыр газабы бар икәне күренеп тора иде. Кайнар сулы мичкәгә тыгып алганнар диярсең — зәңгәр-соры күзләре гел акаеп, дымланып, кызылланып тора. Киеме чиста үзенең, төс-бит кенә эчүдән таушалган. Житкән сакал-мыегы арасыннан аска таба кинәт кинәеп борыны калкып тора, йөзе түгәрәк, ләкин нормаль тазалык түгел иде бу. Битендә төрле төсмердәге нәзек капиллярларын, калын иреннәренең зәңгәрсу төстә булуын күреп, мин моның йөрәк авыруы бардыр дип уйладым. Эмоцияләре үзгәргәндә, чырай төсе уйнаклый һәм куллары да, каны качып, ап-ак булып куя. Аның сакал-мыегы да агарган инде. Шулай да эссе көндә кия торган житен чалбары, өстендәге шакмаклы күлмәгенең төсе унса да, чиста, үтүкләнгән булуы аның «урам кешесе» түгел икәнен күрсәтеп тора иде.

Мин аны уйларыннан арындырырга ашыкмадым, стаканнарга аракы салдым. Әйе, очрашу белән үк дөрес абайлаганмын — бу кешенең ниндидер җан газабы бар. Ул миңа күңелен ачарга, ниндидер серен сөйләргә җыена һәм мин аның бәянын тыңларга әзер идем. Ниһаять, ул сөйли башлады.

## 2

— Без аның белән армиядә бергә хезмәт иттек, — дип башлады ул бәянын. — Автобатта. Ул армиягә кадәр, медучилище тәмамлап, ниндидер лабораториядә эшләргә өлгергән, шуңа күрә санинструктор иде, ә мин «Урал» машинасын йөртүче булып хезмәт иттем — мәктәптән соң автошколада укыган идем. Ул Башкортстанның Z районыннан иде, мин — Татарстанның N районыннан. Бик якын дуслаштык без аның белән, бер-беребезгә һәрвакыт терәк булдык. Дүрт татар идек без частьта, әмма үзара татарча сөйләшеп, бер-беребезне милләттәшләр буларак, хөрмәт итеп, нык дуслашучылар икебез генә идек. Калган ике татарның берсе Чиләбе өлкәсеннән килгән иде, ул үз телендә сөйләшергә әллә курка иде, әллә сөйләшә белми иде — тәки аңламый калдым. Тагын берсе — Пензадан, урыслашкан татар иде.

Дустымның исеме Кафил иде. Сафин Кафил.

Әйе, туганнар кебек якын идек без.

Безнең автобатка ракетачылар дивизиясен дежурствога йөртү вазифасы йөкләнгән иде. Шәхси составтан тыш машиналарда автомат, пулемётише корал, яшник-яшник патроннар булганга, фельдшерлар, санинструкторлар да чыгалар иде.

Тугызынчы полкка беркетелгән дүрт машинаның берсен мин йөртә идем. Шушы дүрт машинага Кафил санинструктор булып билгеләнгән иде. Бик башлы, акыллы егет иде ул.

Әйткәнемчә, бер-беребезгә терәк булдык. Үзебез «салагалар» чагында авыр эшләр эшләгәндә, бер-бербезгә гел ярдәм иттек. «Картайгач», яшь солдатларны бергәләшеп «биеттек», ләкин чаманы белеп кенә. Конфликтларда бер-беребезне яклап, йодрык төйнәргә дә туры килгән чаклар булгалады.

Солдат хезмәтенең ачысын-төчесен, авырлыкларын, кызык чакларын — барысын да бергә татыдык.

Әлбәттә, Кафилнең тормышы җинелрәк иде. Ул минем кебек гади шофёр түгел, ә спиртлы, дарулы һәм башка кирәк-яраклы әйберләргә ия вазифада иде. Ләкин армиядә кем булып хезмәт итсәң дә, хәрби тормыш җиңел түгел инде ул. Аны да тик тотмыйлар иде, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында әллә кайларга чакыртып алалар, кайларгадыр ерак частьларга командировкаларга да йөртәләр иде үзен, эшенең җаваплылыгы да зур иде.

«Дембель» килеп җиткәч, гражданкада бер-беребез белән элемтәдә торырга, кайсыбыз кайда гына яшәсә дә, аралашырга вәгъдәләштек. Армиядә туган дуслыкны гражданка тормышы юк итә алмас, вакыт та, чакрымнар да араларыбызны суытмас, бер-бербезне югалтмабыз дигән өмет белән хушлаштык.

### 3

1980 елның җәй башында, гражданкага кайтып, район үзәгендәге военкоматта учёттан төшкәннән соң, эшкә урнашып йөри башлаганда ук, мин аңардан хат алдым. Башкортстаннан Казанга килеп урнашкан икән. Поликлиникадагы рентген лабораториясенә эшкә кергән, киләсе елда мединститутка имтиханнар бирергә әзерләнәчәген дә әйтеп язган иде.

Ә мин ПАТОга уранышып, ЗИЛ самосвалы белән төзелешләргә Кама буеннан баржалар бушаткан чуерташны ташый башладым. Минем дә киләсе елда энерготөзелеш техникумына укырга керергә хыялым бар иде.

Язышып, хәл-әхвәлләребезне белешеп, хат саен армиядәге хәлләрне кузгатып, аларны бер-беребезнең исенә төшереп, почта аша аралаштык.

...Армиядән кайтканга бер елдан артык вакыт үтеп киткәнне сизми дә калдым. Июль аенда отпуск алдым һәм дустымның да ялы июльдә икәнне белгәч, аның янына Казанга киттем.

Чуйков урамындагы тулай торакта ул мине көтеп, әзерләнеп торган — аракы алган, ашамлыклар әзерләгән. Янәшәдәге тулай торактан аның янына ике кыз килеп керде — белмим, ул махсус чакырылгандырмы, тегеләр үзләре болай гына аның янына кунакка килгәннәрме. Тиздән мединститутта имтиханнар бирәсе бар, дип Кафил аракы күп эчмәде. Мин исә тартынып тормадым, тәмам «тугарылып», каты гына «җиффәрдем», әмма егылганчы түгел. Кызларның берсе: «Кафил имтиханнарны бирмәсә дә керәчәк — җизнәсе укыта бит анда», — дип әйтеп ташлагач, Кафил уңайсызланып куйды. Мин бу турыда белми идем, ләкин моны ишеткәч, бик сөендем, чөнки дустымның ничек булса да институтка керүен ихластан тели идем.

Армиядәге вакыйгаларны көлә-көлә сөйләп, тулай торак бүлмәсен дер селкеттек. Музыка яңгырады, җырладык, биедек һәм кызлар белән мәш килеп,

бөтенләй йокламадык. Икенче көнне Казан елгасы буена барып учак яктык, аннан төн уртасында гына кайттык. Өченче көнне, имтиханнарына әзерлән дип, уңышлар теләп, кызлар белән дә, аның белән дә очрашкандагы кебек хисле хушлашып, мин Nга кайтып киттем.

... Дустымның институтка кергәнен хаттан укып белдем, чын күңелдән аның өчен куандым.

Көзге каникулда Кафил сөйгән кызы Илмира белән N каласына мина кунакка килде. Өйләнешергә җыенучы бу ике матур кешегә карап сокланып туймадым. Менә дигән пар! Табиблар гаиләсе булачак! Икесе дә бергә укыячак!

Минем дә йөри торган кызым бар иде. Энерготөзелеш техникумын тәмамлап, КПД заводында технолог булып эшли башлаган Галия исемле акыллы кыз белән йөри идек. Кызганычка, юк кына сәбәптән аның белән ачуланышкан чагым иде. Беренчедән, шуның өчен кунакларым алдында уңайсызландым, икенчедән, мин яши торган тулай торак күптән ремонт күрмәгән һәм шапшак иде. Өченчедән, бүлмәдә минем белән, күрше районнан килеп, ЖКУда балта остасы булып эшләүче, инде утызга якынлашып килүче тагын бер егет яши иде. Бүлмәне алар килер алдыннан пөхтә итеп җыештырган булсам да, тулай торакның тышкы ишегеннән керү белән үк кәеф кырылырлык иде. Әмма Кафил белән Илмира бергә булулары белән бәхетлеләр һәм тирә-якта нинди мохит икәне аларның бу халәтен һич кенә дә бозарлык түгел иде.

Аннары, Илмираның ике туган абыйсы шушы калада яши икән, кунарга шуларга барачакларын әйткәч, минем эчемә җылы йөгерде.

Шактый күңелле итеп утырдык. Күршем дә безгә кушылды, әңгәмәдә катнашмаса да, аракыны тартынмыйча эчте, ашауны да үтә җитди кыяфәт белән башкарды.

Кунакларым йокларга Илмираның абыйсына киттеләр, ә мин бүлмәмдә калып, күршем гырлап йокыга киткәч, иртәгә Кафил белән Илмираның ничек күңелләрен күрергә, кая алып барып, ни белән шаккатырырга дип баш ватып утырдым.

Икенче көнне мин аларны N каласында үземчә сәяхәт иттердем. Паркта йөрдек, базарга бардык. Кинотеатрда комедия карамакчы идек, кире уйладык. Аннары ресторанга кереп утырдык та кичне шунда уздырдык. Шактый исердек һәм кунарга миңа кайтырга булдык. Күршем авылга кайтып киткән иде. Кафил белән Илмира минем караватта йокладылар, мин — күршемнекендә.

Өченче көнне, барыбызның да кәефен күтәреп, тулай торак бүлмәсенә сөйгәнем Галия килеп керде. Галиям беркайчан озак ачу сакламый иде һәм үзем дә гомергә тиз онытучан булдым. Аның килүенә барыбыз да куандык, ә Галия-җаныкаем югалып калды. Кунакларымны сөйгәнем белән таныштырдым һәм, мөмкинлектән файдаланып, аңардан тагын бер тапкыр гафу үтендем. Галия, оялып, үзен кая куярга белмәсә дә, араларыбыз рәтләнгәнгә, татулануыбызга сөенеп туймады.

...Алга таба Казан белән N арасында телефоннан шалтыратышып, ара-тирә хат язышып аралаша тордык.

Озакламый Кафил белән Илмира өйләнештеләр. Туйны Казанда ясадылар, һәм без Галия белән анда булдык.

Алардан соң, ел ярым вакыт узгач, без дә өйләнештек. Икесенең дә сессия вакыты булу сәбәпле, безнең туебызга килә алмадылар.

Тормыш дәвам итте.

Энерготөзелеш техникумының кичке бүлеген тәмамлагач, КПД заводына, Галия эшли торган цехка, мастер булып урнаштым. Башта «малосемейка»да (өч бүлмәле фатирның йокы бүлмәсендә) яшәдек. Шунда кызыбыз туды. Заводта икебез дә яхшы специалистлар саналдык, абруйлы булдык, һәм алга таба «үзгәртеп корабыз» дип глобаль рәвештә ил-көннең тәрәкләрен чалшайтсалар да,

заводтан ике бүлмәле фатир алуга ирештек. Озакламый улыбыз туды, яшәвебез тагы да тулыланды, катлауланды.

...Ул «перестройка» дигән нәрсә колачын киңәйткәч, алга таба илнең бөтенләй асты өскә килде. Ярый әле фатирны вакытында алып калдык.

Бөтен нәрсә күз иярмәс дәрәҗәдә үзгәрә башлады, тормыш-көнкүрештәге кыйммәтләр алышынырга тотынды, яшәешнең кыйбласызлыгы сәвит чорында туып үскән адәм балаларына каты удар булды.

Кафилләр белән аралашмый башладык. Тормышның болганулы-тугланулы агышында батмаска, исән калырга, үз йөзеңне югалтмаска кирәк иде, шул сәбәпле яңа кануннарга, моңарчы таныш булмаган яшәү рәвешенә ияләшү дәверендә элеккеге дуслар, узган еллардагы бәйләнешләр каядыр җуелып, онытылыбрак китте.

Илдә әллә нинди вакыйгалар кайнаса да, тормышлар әллә нишләп бетсә дә, Кафил беркайчан исемнән чыкмады. Барыбер күрешербез, ил генә бераз тотрыклансын, элемтәләр янарыр, гаиләләребез белән аралашып, гөр китереп кунакка йөрешеп яшәрбез, дигән өметем беркайчан сүрелмәде.

Һәм без, әлбәттә, очраштык. Ләкин Казанда да түгел, без яшәгән Nда да түгел.

## 4

Хатынымның апасы үгетләп, 1995 елны без, Nдагы фатирыбызны, кем әйтмешли, «баш на баш» алыштырып, D каласына күчендек. Бу болгавыр заманда алга таба ничек яшәрбез дип баш ватканда, Галиянең апасы безгә кызыклы гына тәкъдим ясады. Алар ире белән анда өйләнешкәннән бирле яшиләр, шактый тирән тамыр җәеп, бергәләп төзелеш фирмасы ачканнар иде, без дә шунда урнашып, әйбәт кенә яши һәм эшли башладык. Кызыбыз — ун яшьтә, малайга сигез яшь иде ул вакытта.

Галиянең апасы бик елгыр, иргә баш булып, гаиләләрен дә, бизнесны да алып баручы искиткеч хәлле ханым булып чыкты. Аларның бер генә бала иде — ул вакытта уллары ундүрт яшьтә иде бугай. Үзләренә шундый шәп йорт салганнар иде инде шул вакытта ук. Кыскасы, аякларында нык басып торучылар иде.

Тиз арада ияләштек, күнектек. Авырлыклар булмады түгел, яшьлегебез, тырышлыгыбыз белән яңа мохиттә әйбәт кенә гомер итә башладык.

Мин фирмада материаллар ташу өчен җаваплы итеп билгеләндем, ә Галия апасының (апасы генераль директор иде) ярдәмче вазифасын башкаруга керешге.

Үзара мөнәсәбәтләр бигүк җайлы булмаса да, түзәрлек иде. Апасы да Галия сыман сабыр холыклы иде, гәрчә гаять таләпчән булса да. Ире, ягъни Галиянең җизнәсе, фатирларның эчке отделкасы өчен җавап бирүче иде. Ул бераз кәпрәюечән, гел вәкарьлек күрсәтеп торучы һәм безне әзергә килгән «везунчиклар» диебрәк саный иде. Әмма Галиянең апасы безгә аңардан беркайчан «җил-яңгыр» тигездермәде. Иренең кырын карашын сизү белән аны урынына утырта яисә игътибарын бөтенләй икенче якка борып куярга җаен тиз таба иде.

Заман агымында йөзеп, кешеләрчә эшләп, кешеләрчә яшәдек. Минем Галиям гаилә җанлы булу өстенә эштә дә бик булдыклы, заман сулышын тоючан зирәк акыллы хатын булып чыкты. Аннан башка бу дөньяда аягымда басып тора алыр идемме, юкмы — белмим. Тормышта ул миңа караганда көчлерәк иде. Төшеп калганнардан булмасам да, проблемалар алдында бераз югалыбрак калучан идем. Хатыным минем шикелле коелып иңә торган булмады, әллә нинди авырлыклар килсә дә, тыныч кына, сабыр гына чынбарлыкны кабул итеп, шул авырлыкны җиңү чараларын эзли, көрәшә торган иде һәм гомер агышында үзем генә җинә алмаслык күп нәрсәне без аның белән ерып чыга алдык. Рәхмәт яусын минем Галиямә!

Без үзебез дә йорт салырга хыяллана башладык. Әмма «D»да безгә йорт салырга насыйп түгел икән. Алга таба булган вакыйга безне моннан китәргә мәҗбүр итте.

... «D» каласының зур түгеллеген беләсеңдер инде. Хәзер бераз кинәйде әле ул, элек алай ук түгел иде. Һәрвакыт яшеллек күп булды ул шәһәрдә, завод-фабрикалар булмагач, анда һава да чиста. Тора-бара тагы да ямьләнәнде ул шәһәр — яна йортлар, затлы биналар калыкты, юллар да төзекләнде.

Без күчкән елларда анда бераз аламалык бар иде, яшел шәһәр булса да. Минем иң яраткан урыным анда һәрвакыт базар булды. Мин кайда гына яшәсәм дә, кая барсам да, шәһәрдәге базарга йөрергә яратам. «D»дагы базар ул чын калхуз базары иде — анда сатучылар күбесенчә авыл кешеләре һәм алар авылдан алып килгән азык-төлек, вак-төяк, мал-туар саталар иде.

Кызыбызның туган көне иде, ашка авыл тавыгы, кишер, суган һәм аш-су өчен тагын нәрсәләрдер алырга дип Галия мине базарга җибәрде. Хатын кушкан нәрсәләр пакетларымда урын алгач, мин юл унаеннан азык-төлек маркетына кереп берәр шешә шәраб алырга булдым.

Инде кассада акчамны түләп чыгып барганда, арттан мина кемдер эндәште:

— Рашат!

Карасам — дустым Кафил басып тора. Туеннан сон унике ел вакыт үтте, шуннан бирле күрешкән юк. Мәгърур кыяфәтле, кәчтүм-галстуктан, әмма танырлык, ничек инде ике ел бергә хезмәт иткән дустынны танымыйсын ди!

— Кафил!

— Рашат, синме бу, әллә күземә генә күренәсенме?

— Әгәр дә син чынлап та Кафил икән, димәк, мин дә саташмыйм! — дидем мин, шулай ук үз күзләремә ышанмыйча.

Әйе, Кафил иде бу, ике ел армиядә бергә хезмәт иткән җан дустым Кафил иде. Без кочаклашып күрештек.

— Нишләп йөрисен монда? — диде ул, гаҗәпләнүдән әле бераз артка чигеп, әле якынрак басып.

— Мин шушы калада яшим, — дидем мин. Ә үзенең нишләп монда йөргән сорарга тел әйләнми торды, чөнки мин шок халәтендә идем.

— Шулаймыни?! Мин дә шушында бит, — диде Кафил. — Ничә ел күрешкәнебез булмады безнең?

— Унике, — дидем мин. — Синең туйдан соң бер дә очрашканыбыз юк, хатлар да язмадык бер-беребезгә.

— Тормыш өермәсенә ияреп киттек шул, малай. Монда син кайда, кем, ничек дигәндәй?..

— Гаиләм белән күчендек, әле дүрт ай элек кенә. Ә син үзең? Бүлнистәме, поликлиникадамы?

— Мин психо-неврология диспансерында бүлек мөдире булып эшлим. Бик ялындылар, бик чакырдылар, хезмәт хакы югары була дип кызыктырдылар. Ике ел инде эшлим, болай зарланырлык түгел, эшемнән барысы да канәгать, әмма кире Казанга китәрмен, ахрысы. Хәзер анда да яхшы урыннар тәкъдим итәләр.

Без тагын, җилкәләребезгә шап-шоп сугып, ирләрчә кочаклашып алдык.

— Кафил! Ай-яй нык үзгәргәнсен!

— Син дә үзгәргәнсен, Рашат! Ләкин без синең белән бер-беребезне миллион ел узгач та таныр идек, мөгаен.

— Шулай.

Үзгәрсә дә шул ук Кафил иде бу! Үзгәргән дип... Шул ук гел йөгереп торучы зәп-зәңгәр күзләр, сары чәч, сары каш, сары керфек. Бер тапкыр армиядә чакта аны «дуңгыз керфек» дип үпкәләткән идем. Гел йөгереп торучы күзләр, кин

жилкәле, уртачадан озын гәүдәле, кин яңаклы, зур борынлы, бераз тырпаебрак торган колаклар. Ияге дүрт почмакланып тора. Муены армиядә үк юан иде аның. Йөргәндә көрәшчеләр кебек кулларын як-якка «келиндерләтебрәк» йөри икән хәзер дә.

Үзгәргән дә кебек, шул ук вакытта элеккеге Кафил дә иде бу. Ну кәчтүме шәп кәнишне. Ул галстук, малай! Күлмәгенең каты якасы муенын кырып авырттырадыр шикелле. Шәп хушбуй исе килә үзеннән.

— Кафил, бүген кызымның туган көне. Әйдә безгә! — дидем мин.

— Рашат туган, башка вакытта, яме, — диде ул. — Синең йортка болай урамнан гына барып керү дөрес булмас. Хатыным белән парлашып, алдан әзерләнеп, сезгә җайлы вакытта килербез. Бәлки башта сез үзегез безгә килерсез — анысын жаена карарбыз. Ә хәзер... — Ул сәгатенә карап алды. — Минем бераз вакытым бар, аннары вакытны тагын өстәрбез, киттек ресторанга. Без синең белән очрашуыбызны билгеләп үтәргә тиешбез. Күп эчмәбез, кызыңның туган көненә матур гына елмаеп кайтып керерсең.

Интеллигент ул интеллигентларча карарлар кабул итә инде, маладис!

Кафилнең служебный машинасына утырып, юл уңаеннан алган ризыкларымны өйгә кертеп, Галиядән гафу үтенеп, озакламый кайтам дип, Кафил белән бу шәһәрнең иң затлысы булып саналаган «Дулкын» ресторанына киттек.

Кафилне монда беләләр, ихтирам итәләр икән. Безне шәрәфле кунаклар бүлмәсенә кертеп утырттылар, администратор үзе безгә хезмәт күрсәтергә тотынды.

Кафилнең хатыны Илмира шәһәр поликлиникасында терапевт булып эшли, ике кыз үстерәләр, фатирлары шәһәр үзәгендәге затлы йортта икән. Элекке кеше түгел иде инде Кафил, әмма якын чалымнары, яшьлектәге сыйфатлары сакланган иде. Бай яшәгәне кыяфәтеннән, үзен тотышыннан ук аңлашыла иде. Медицина буенча бизнесы да бар икәнне пышылдап кына әйтте — шәхси аптекалар тоталар икән. Институтны тәмамлап, Казанда медицина өлкәсендә төрле эштә, төрле вазифаларда эшләгәннән соң, ул Ленинградта психиатрга укып кайткан булган.

Армиядәге дуслык, егетләрчә, содатларча туганлыкны үзе хәрби хезмәт үткән кеше генә аңлыйдыр шул. Сөйләшеп туя алмадык.

Затлы виски эчкәч, аның чыннан да башка кеше икәне тагы да ачылыбрак китте. Эше турында сөйләгәндә, үзе турыдан-туры әйтмәсә дә, алга таба карьера ясау аның өчен иң зур максат икәне аңлашылды. Казанда яңа психо-неврология үзәге төзелгәч, шунда баш врач булып кайтырга хыялы бар икәнне әйтте һәм ул урынны анда аның өчен инде тотып торалар, имеш.

Мин аңа карап сокланып туймадым. Маладис! Афәрин! Дустым армиядә хезмәт иткәндә үк акыллы, башлы иде шул.

— Әле министр да булырсың, — дидем мин аңа, — син бит әле яшь.

— И Рашат, медицинада көрәш бик каты шул, — диде ул үтә житди кыяфәт белән. — Министр булырга хыялланучылар, омтылучылар, тырышучылар бик күп.

— Соң, өскә үрмәләргә тырышучылар һәр өлкәдә күп инде алар.

— Медицинада аеруча күп. Әмма араларында министр булырлык шәхесләр бармак белән генә санарлык.

Өч сәгать чамасы рәхәтләнеп сөйләшеп утырдык. Ике шешә вискины бушаттык, әллә нинди тәмле ризыклар ашадык. Сөйләшәсе сүзләрнең чигекырые юк иде. Шулай да кузгалырга вакыт җиткәнне ул да, мин дә сизендек.

Рестораннан чыккач, руль артында йокымсыраган шофёрны уяттык та, мин дустымның затлы машинасында күкрәк киереп, сабыйларча шатланып, йортым янына кайтып төштем.

Кафил минем белән машинасыннан чыгып хушлашты.

— Югалма, Рашат, — дип мине ирләрчә, солдатларча кочаклады ул.

— Хәзер инде бер-беребезне югалтмабыз, — дидем мин. — Бер шәһәрдә яшибез бит.

Адресларыбызны, телефон номерларыбызны бирештек. Кат-кат кочаклашып саубуллаштык, шимбә яки якшәмбе көнне очрашырга вәгъдәләшеп теләр-теләмәс кенә хушлаштык.

Кайтып, сөекле кызымны туган көне белән котлагач, алдан әзерләнгән бүләкне сервантның аскы өлешеннән алып бүләк иткәннән соң, армиядәге хезмәттәшемне очратуымны сөйләп, өйдәгеләрнен тенкәсенә тидем. Аннары, йокыга киткәнче жан дустым турында хатыныма сөйләп яттым. Инде ул йокыга киткәч тә беркавым сөйләп ятканмын икән әле.

5

Берничә көн үтүгә, алар беренче булып безне үзләренә кунакка чакырдылар. Аннары алар бездә кунакка килделәр. Әйткәнемчә, элекке Кафил түгел иде инде ул, ә шулай да Кафил — минем армиядәге тугры, якын дустым иде. Дуслык хисе болай көчле буладыр дип уйламый идем, үсмер вакытта бар иде дуслар, аннары олыгая төшкәч тә дус-ишсез яшәмәдем, ә Кафил белән безнең мөнәсәбәтләр жылы иде, вакыт та, профессия аермасы да бетермәслек дуслык хисләре иде безнең арада.

Мин аңа шул көннәрдә үк дачасын рәткә кертергә ярдәм иттем. Яхшы материаллар китертеп, үзебезнең фирмадагы иң оста егетләрне алып барып эшләттем. Кафил эшчеләргә шәп кенә түләде. Миңа да акча тәкъдим итте ул, әмма минем моңа ачуым килгәнне күреп:

— Гафу ит. Ачуың киләсен алдан ук белдем, шулай да нервыңда бераз уйнап аласы иттем, — дип елмайды.

Ә менә затлы коньяктан баш тартмадым, без аны икебез саф һавада, яңа пешә башлаган виктория жиләкләрен каба-каба «хәл иттек».

Ул мине эш урынына чакырды.

— Рашат, килеп кит әле диспансерга. Күреп чыгарсың. Бигүк күнелле урын түгел дә инде, шулай да барыбер кызык булыр. Кызык — көлке мәгънәсендә түгел. Дөньядагы кешеләрнең тагын ниндиләре бар икәнне күрерсен. «Кызык булыр» дип кызыксындырыр дәрәҗәдә әйтелде. Син, әлбәттә, нечкә күңелле кеше буларак, йөрәгең жу иткәнне тоярсың, авыр хисләр кичерерсен. Шулай да син кереп күр, дустың Сафин Кафил кемнәр белән, нинди шартларда эшләгәнне мәгълүм кылырсың. — Ул елмаеп өстәп куйды. — Һәм, иманым камил, миңа ихтирамың артыр.

— Мин сине болай да шундый ихтирам итәм, — дидем мин, дустым белән чиксез горурланып. — Берәр көнне керермен.

— Алдан шалтырат.

— Ярар.

...Беркөнне эштән көн уртасында ук бушадым да дустым хезмәт иткән диспансерны күрергә дип киттем.

Кафилнең заманча жиһазлы эш бүлмәсе шактый киң булса да, әллә инде нинди бүлнис икәнне белгәнгә, түшәме әкрен генә өстенә төшеп киләдер сыман тоелды, һәм киштәләрдә тезелеп өелгән папкаларның саргылт төсләре монда бөтен нәрсә, бөтен кеше саргая диган хәбәрне анкыталар шикелле иде. Түрдәге киң экранлы телевизор да, тәрәзә янындагы аквариум да, почмактагы агачка охшап биек булып үскән гөл дә кабинетның шыксызлыгын бетерә алырлык түгел иде һәм мондагы атмосфера бастырыгын мин диспансерга керү белән үк өстемдә тоя башладым.

Аның караваы эленеп торган люстра, өстәлдәге лампа һәм компьютер экраны сирпегән утларны бергә кушсаң да, дустым Кафилнең чыраеннан яктырак балкыш барлыкка килмәс иде, мөгаен.

Ул мине бик җылы каршы алды. Бөтен эшен читкә куеп, игътибарын миңа юнәлтте.

Гел көндезге сменада эшли торган Ризәлә исемле зәңгәр-соры күзле, коңгырт чәчле шәфкать туташы Кафилнең ярдәмчесе һәм секретарь вазифаларын да башкаручы урта яшьләрдәге, ир-ат битараф калмый торган серле магнитка ия хатын — нәзакәтле хәрәкәтләр белән, йөзендә һәрвакыт чак кына сизелгән елмаюын саклап, безгә чәй ясады. Аның уртачадан чак кына түбән гәүдәле төз буй-сыны, кулларының матур хәрәкәте, тавышының назлы тембры — болар барысы, кабинетның салкын шыксызлыгыннан вакытлыча гына булса да арындырып, мондагы һавага җан кертте. Аның туры, ләкин кыска борыны, кысыграк күзләре, очлаеп торган ияге, тәмле печеньега охшаган нәфис колаклары — барысы да башында төз урнашкан ак калфагы астына илаһи бер рәссам җыеп ясап куйган кебек иде. Түш турыннан халатын калкытып торган күкрәкләреннән соң астарак барлыкка килгән нечкә биленә хәтта халатның ул урынында тарайтуның да кирәге булмаган. Аның макияжы да монда түгел, башка сферада эшләүченеке сыман иде. Башындагы калфагы да үзенчәлекле, халаты да гади түгел иде. Бер карауда үзе дә мондагы кешегә охшамаган, ләкин үз эшен яратканы да, Кафил «Ахатович»ны ихтирам итүе дә күренеп тора һәм беркавым күзәткәннән соң, аның үз урынында икәнен аңларлык иде.

Ул үзе дә безнең белән бергә утырып чәй эчте. Ирдән аерылган булса да, аның гаилә җанлылыгы гел сизелеп тора иде. Ә бәлки ул вакытта ирсез яшәгәнгә аңарда бу җылылык күп булгандыр — кем белгән. Үсмер яшьтәге бердәнбер улын телгә алып, хулиганлана дип ачынып зарланганда да битәрләү түгел, улын нык яратуы, улы белән горурлануы алга сөрелде.

Аннары Кафил үзе миңа палаталарны күрсәтеп чыкты. Мин сүз белән генә анда күргән кешеләр турында да, үземнең халәтемне дә беркайчан сөйләп аңлата алмам, ахрысы.

Кафил палатадан палатага йөргән арада, пациентларның аянычлы язмышлары, коточкыч вакыйгалары, саташып бимазалanулары хакында берсеннән-берсе тетрәндергеч мисаллар китерә-китерә сөйләде.

«Менә кайда икән ул бәхетсез кешеләр!» — дип уйладым мин.

Сәламәт кешеләр бөтенләй белми торган, уйларына да килмәслек диагнозлар бар икән. Үзләре авырмаган кешеләр өчен акылдан язган кешеләр аерым бер категория булып кына санала, ә бит ул катламда аңга сыймаслык күп төрле чагылышлары бар икән акылдан язуның. Психика чалышаюның меңләгән төре бар дип кенә әйтү дөрес түгелдер, дөньяда ничә пациент бар, шуның кадәрле ул чирнең төрләре дисәң, дөрес булыр.

Дүртенче палатадагы бер пациент игътибарны аеруча җәлеп итте. Нык тәэсир итте ул миңа. Башкалардан шактый аерылып тора иде ул. Анда әллә нинди имәнгеч кыяфәтле, бөтенләй төссез чырайлы, күз карашларын томан баскан, кот очарлык ямьсез авырулар бар, әмма бу пациентның күз карашыннан гына түгел, һәр кыймылдавыннан, хәтта сулышыннан да газап саркып тора иде һәм дә аның бу халәте аныкы гына түгел, ул аны вакытлыча каяндыр алып торгандыр, ул аны бимазаланыр өчен асрамага алгандыр шикелле иде, гүя бу нindидер бер миссия аңа йөкләнгән — аңа беравык карап торгач, менә шундый уй-фикерләр килерлек иде. Дарулар эчеп, уколлар кабул итеп, мондагы шәүләләрнең күбесе битарафлыкка әсир төшкән иде. Эчке импульслар битарафлыкның чаршавын йолкып бәреп чыккаласалар да, чарасызлык дигән ятьмә боларны беркая җибәрми иде. Ә теге — минем

игътибарымны җәлеп иткән пациентта, бернинди агрессия юк, ул чынбарлыктан ваз кичкәнгә охшаган, әмма үзе дучар булган шартларга күнеп, сабыр гына сорауларына җавап табу омтылышы бар иде анарда. Хәзер аңлавымча, сорауларга җавап эзләү дә булмагандыр ул, ә бәлки үзе дучар булган фаҗигагә ачыклык кертергә, үзенен бүгенге халәтен акларга һәм шул ук вакытта җавап тотарга омтылыш булгандыр. Үзе өчен генә түгел, тагын кемнәрдер өчен яшәеш куйган ниндидер коточкыч бер сорауга җавапны табарга тырышу сизелә иде анарда. Аннары гына аңладым мин: үзен акларга теләү булып тоелса да, ахыр чиктә үзен түгел, яратуын, мәхәббәтен йөгәнли алмавын аңлатырга теләү, үз хисләренең колы булудан котыла алмау газабын кичереп, шул фаҗигасенең тирәнлегенә төшенергә теләүдән булган ул.

Бәлки мин ялгышамдыр...

Тумбочка өстендә хат язып утырган чагы иде аның. Безнең кергәнне сизмичә, ул кәгазьне әкрен генә каләме белән кыштырдатуын дәвам итте. Безне күргәч, урыныннан сикереп торды:

— Исәнмесез, Кафил Әхәтович!

— Исәнме, Туктар! — диде Кафил коры гына.

— Мин хатыныма хат язып утырам. Язып бетергәч, сезгә кертермен, яме. Күп калмады.

— Ярар, — диде Кафил, елмайган сыман итеп.

— Зинһар, җибәрегез хатымны.

— Җибәрәм, җибәрәм.

— Тегеләренә һаман җавап килми.

— Хатыныңның язарга вакыты юктыр.

— Бәлки, — диде Туктар, кинәт боегып.

Туктар уртача буйлы, какча гәүдәле, башы алдан шәрәләнә башлаган, күптән кайчы-машинка күрмәгәнгә, ике яктан чал кергән чәче чуаланып як-якка куерак үскән сыман иде. Буй-буй «кәҗүнний» кием, аягындагы соры тапочка ничектер моның тән төзелешенә, кәкрәебрәк торган аякларына сәер рәвештә килешә дә сыман иде — бәлки мондый газаплы кыяфәттәге кешене кәчтүм-галстук белән күз алдына китереп булмагангадыр. Тавыш-тынсыз, хәрәкәтсез басып торса, аңа илле-илле биш яшьләр бирерлек, ә аралашканда, күзләренең төс алуын күргәч, тавышын ишеткәч, аңа әле кырык тулмаганны аңларлык иде.

Чергән имән яфрагы төсендәге күзләре, томан пәрдәсе белән капланса да, күп нәрсәне күрү сәләтенә ия иде аның. Озынча, чак кына сикертмәле борыны, чыгып торган янак сөякләре, житкән чәче арасыннан шәйләнгән зур колаклары, житлегеп бетмәгән слива төсендәге иреннәре, күптән кырмаган кыл сакалмыегы, озынча чыраеннан өстәрәк урнашкан киң маңгаендагы җыерчыклар — бу чалымнарны бер сурәт итеп күзәткәч, монарда берөзлексез эчке «хезмәт» барганын — күңеленең коточкыч авыр эш башкарганын күрергә мөмкин иде. Мин аннары гына аңладым — жан газабы булган ул.

Ул миңа, бу кем икән диптер инде, шактый вакыт карап торды.

— Язып бетергәч, миңа кертерсең, кайтканда почта яшнигенә салырмын, — диде Кафил. — Ашыкмыйча яз, яме, Туктар.

— Мин хатынымны нык рәнҗеттем, — дип миңа мөрәҗәгать итте Туктар. — Нык ялыктырдым мин аны. — Ул кинәт кыҗрый башлады: — Клара мине гафу итәчәк! Мин бик яратам аны! — Ул миңа якын килеп, йөземә туп-туры карап торды. — Сез аның нинди гүзәл зат икәнен белмисез!

Мин, ни әйтергә белмәгәч, Кафилгә карадым.

— Сез миңа ышанмыйсызмы? — диде пациент еламсырак тавыш белән, һәм бу мәлдә мин аның җаны елаганны тойдым.

— Ышанам, нишләп ышанмаска, — дидем мин, шундый нык каушап.

— Шуңа күрә мине монда яткырганнарына каршы килмәдем, хәтта үз теләгем белән дәваланырга адым ясадым диярлгә дә була, — диде ул, чынлап та бик әһәмиятле адым ясаганына эчке инану белән.

Палатадан чыгып барганда, ул йөгереп килеп, минем беләгемнән тотты:

— Монда ятучыларны юкка кызганасыз.

— Ник алай дисез? — дидем мин, туктап.

— Кызгану — башкалардан өстен булырга тырышуның бер формасы.

— Әллә ниләр уйлап чыгарма инде, Туктар, — диде Кафил, пациентны иңеннән җинелчә генә кагып. — Монда кем синнән өстен булырга тырышсын инде!

Кафилнең кабинетына кереп, чәй эчеп утырганда, әлеге дә баягы пациент ниндидер чәчәк рәсеме төшерелгән конверт тотып килеп керде. Шунда мин аның бармакларының буын-буын төз түгеллегенә игътибар иттем.

— Тумыштан ул минем, — диде Туктар, аның бармакларына күз төшергәнемне абайлап. Шуннан соң ул миңа карап тирән сулыш алды. — Сез миңа ярдәм итәрдәй кешегә охшагансыз, — диде ул, күгәргән иреннәрен чак кына кыймылдатып.

— Ничек ярдәм итә алам икән мин сезгә? — дидем мин, никтер уңайсызланып.

— Туктар, — диде Кафил кырыс тавыш белән, — яздыңмы хатыңны?

Туктар аның соравына игътибар бирмичә, минем белән сөйләшүен дәвам итте:

— Сез мондагы кешеләрне күреп шаккаткансыз, шулаймы?

— Шаккаттым дип... Шундый ук кешеләр, дәваланырга гына кирәк... — дидем мин.

— «Дәваланырга кирәк» дип ихластан әйттегез. Әмма «шундый ук кешеләр» диюегезгә ышанмыйм.

— Ә сез башкалардан нәрсә белән аерыласыз соң? — дидем мин, аның сорауларына җавап биргәндә сак булырга кирәк икәнне аңлап.

— Менә, сезне инде монда ук җиңегездән эләктереп була, — диде ул борчулы кыяфәт белән. — Сез: «Башкалардан нәрсә белән аерыласыз?» — дип сорадыгыз, ә нишләп: «Башкалар сездән нәрсә белән аерылып тора?» — димәдегез?

Бу чыннан да мине чеметеп тотардай урынны тапты шикелле.

— «Башкалар сездән нәрсә белән аерылып тора?» дип сорасам да, мәгънәсе шул ук кала түгелме? — дип акланырга маташтым мин.

— Юк, мәгънәсе үзгәрә. Тулаем нәрсәнең өлеше була. Тулаем белән аның өлеше арасында аерма ничек, башкалар белән монда ятучылар арасында да шундый ук аерма. Шуңа күрә сез башта әйткәне дөрес һәм сез аны ихластан әйттегез. Өлеш тулы әйбернең сыйфатларына ия дип әйтеп була, ә тулаем нәрсә үзенең өлешләренең сыйфатларына ия дип әйтеп булмый. Дөрес, ул үз өлешенең сыйфатларына да ия, ләкин тагын аңардагы башка сыйфатлар өлештә булмаска мөмкин. Ялгыш әйттем микәнни дип үзегезне битәрләмәгез һәм миңа ярарга теләп, күңелемә хуш килердәй сүзләр әйтергә тырышмагыз.

— Шулай да мин ике төрле әйтсәм дә, мәгънәсе бер үк булыр иде, — дип бәхәсләшеп карадым, аның миңа үпкәләмәвен күреп.

— Ялгышасыз. Әйтәсе фикереңне бертөрле генә әйткән суәттә дә әле мәгънәсе төрле булырга мөмкин. Мәсәлән, хәтта «дөнья ямьле» дию генә дә төрле вакытта төрле мәгънәдә әйтелә.

— Ничек инде?

— Кеше бер халәттә бер мизгелдән артык тора алмый. Аның халәте гел хәрәкәттә, гел кыймылдый, гел мыймылдап тора, шуңа күрә бер үк фикерне бер үк сүз белән әйтү дә башкачарак мәгънәгә ия була. Бер үк сүзгә төрле вакытта төрлечә мәгънә салына. Чөнки кешенең халәте гел үзгәреп тора.

— Син хаклы, Туктар, — диде Кафил, әңгәмәдән туеп. — Бир хатынны.

— Бүген үк җибәрегез, — диде Туктар һәм, хатны Кафилгә биреп, тиз-тиз атлап чыгып китте.

Ул чыгып киткәч, Кафил, елмаеп:

— Менә нинди кешеләр ята монда, — диде.

— Аның диагнозы нинди? — дип кызыксындым мин.

Кафил ниндидер латин сүзен әйтте, мин аңламадым.

— Көнләшеп психикасы какшаган. Ә бәлки психикасы какшаганга көнләшкәндер.

— Аның берәр җире авыртамы?

— Ник алай сорыйсың?

— Ул гел авырту тоеп тора шикелле.

— Җаны сызлый аның.

Өстәлдәге телефон чак кына ишетелерлек итеп зеңгелдәде. Кафилне баш врач үзенә чакырды.

Ул чыгып киткәч, Ризәлә, борсаланып, кабинет буйлап йөрергә тотынды. Күңеленә ниндидер коткы кергәндәй, ул, бер предметта да карашын туктата алмыйча, нидер эзләгән булды, минем аны күзәтеп утыруым кинәт исенә төштеме — ул, көтмәгәндә миңа туры карап:

— Мин укып барам аның хатларын, — диде. — Беренче хатын укыганнан соң, мин бер атна һушыма килә алмыйча йөрдем. Аннары башкаларын да укып чыгарга үземдә көч таптым.

— Хатыны кайда соң аның?

— Ничек инде кайда?

— Бу шәһәрдә түгелмени дип соравым.

— Шушында яши.

— Алайса ник хатлар яза соң ул ана?

— Хатыны килми аның янына.

— Аерылганнармыни?

— Юк әле.

— Хатларына җавап язадыр бит?

— Җавап хатлары да килми.

— Хатлары барып җитми микән әллә? Адресын дөрес язадыр бит?

— Аның язган хатлары барысы да монда. — Ризәлә шкафның аскы тартмасын ачып күрсәтте. — Менә, җиде хат язды ул, җидесе дә монда ята.

— Нишләп алай? — дидем мин аптырап.

— Кафил Әхәтович ул хатларны соңрак җибәрергә кирәк дип саныйдыр, — диде Ризәлә, тартманы ябып.

— Бәлки ул аларны өйрәнәдер, кем әйтмешли... Алай дисәң, ксерокопиясен алып калып җибәрергә була бит.

— Дәвалау өчен шулай кирәктер инде, — диде Ризәлә хафалы тавыш белән.

Шул вакытны Кафил килеп керде һәм кабаланып, кабинет буйлап кирәкле папкасын эзләгән арада, гафу үтенеп, исполкомга барырга кирәклеген әйтте. Минем дә үзәк урамда йомышларым бар иде, ул мине үзе белән алырга булды.

Регистратурадагы ак халатлы хатынга һәм кытыршы чырайлы сакчыга мине тәкъдир итеп:

— Бу кеше минем бик якын дустым, кайчан килсә дә, тоткарламыйча миңа кертә торган булыгыз, — дияе булды, барсеткамны аның бүлмәсендә калдырганым искә төште.

Мин ана, барсеткамны кереп алырга кирәк икәнне әйтеп:

— Син мине көтмә, мин автобус белән барырмын, — дидем.

Кафил миннән тагын бер тапкыр гафу үтенде һәм җәһәт кенә чыгып машинасына утырды да китеп барды.

Дөресен әйткәндә, барсеткам калганга сөендем. Минем кире керәсем килгән иде. Ризәләне кабинеттан чыгып барган чагында туктатып, теге пациентның хатларын укырга теләвемне әйттем.

Ризәлә мина жиде хатның да ксерокопияләрен ясап бирде һәм бу турыда Кафилгә әйтмәскә кушты. Бу игътизарын ул әллә ничә тапкыр кабатлады. Хатларны биргәндә, мин Ризәләнең йөзеннән төс качканны һәм куллары калтыраганны күрдем.

## 6

Рашат тынып калды. Сөйләве авыр булса да, бушану теләге көчле иде аның, мин моны аермачык күрдем.

— Шуннан? — дип бәянның дәвамын көттем мин.

— Син аның хатларын укырга тиеш, — диде ул. — Син — язучы, син аларны укып тетрәнергә тиеш. Мин әнә теге йортта яшим. — Ул Зур Урамның борылышындагы биш катлы кирпеч йортка күрсәтте. — Әйдә безгә, мин сиңа аның хатларын укытам. Аннары алга таба сөйләрмен.

Мин инде үзем дә ул хатларны укырга кирәк дигән карарга килгән идем һәм без, эчеп бетермәгән шешәбезне пакетка тыгып, Зур Урамның иң башындагы йортка таба киттек.

Ике бүлмәле җыйнак кына фатирда тәртип хөкем сөрә иде, монда эчә торган кеше яши димәссең. Кыйммәтле җиһазлар күзгә ташланмаса да, монда бөтен нәрсә тыныч кына яшәр өчен уңай иде. Хатынының яулыгы кырыеннан чәчләренә чал кергәне күренсә дә, сагыш эченнән күзләренең төсен тиз генә билгеләп булмаса да, аксыл йөзендә арыганлык чагылса да, аның яшь чагындагы чибәрлеге әле ничектер сакланган, йорт җанлы чын хатын-кызларга хас эчке гүзәллекне еллар тәмам сөртеп бетерә алмый икәнне шушы хатынга карап әйтеп булыр иде. Ире чит кешене ияртеп кайтканны ошатмавы шундук йөзенә чыкты.

Аның чәй төсендәге күзләрендә ягымлы монсулыкны күргән кеше үзе дә монаймый калмыйдыр. Буй-сыны зифа килеш сакланган, бары тик чак кына муенга житәрәк гәүдә бөкрәйгәнрәк кебек, әмма бу бөкрәю түгел, тормыштан арыганлык билгесе иде. Халатын бил турысында шактый тыгыз итеп буган, яулыкны матур итеп чөйгән, аягында тапочка түгел, ап-ак йон оекбашлар — шушы өйдә кия торган гап-гади киеме аның сөйкемле, йорт җанлы, әйбәт, түземле хатын, яхшы ана һәм искиткеч әби икәненә шик калдырмый иде. Борыны очына таба чак кына өскә калку, иреннәре тигез, «дөрес» һәм чак кына табигый кызыл төстә иде.

Көтелмәгән кунакның ана бер кирәге юк икәнне керүгә үк аңладым.

— Галия, таныш бул — Зөлфәт Хәким — син үлеп яраткан «Нәрсә булды сиңа бүген?» дигән җырның авторы, — диде Рашат, тузанланып беткән туфлиен салып.

— Исәнмесез, — дидем мин, читенсенеп кенә.

Галиянең йөзе бераз яктырып китте, ул, бер-ике адым артка чигеп, беравык миңа карап торды.

— Исәнмесез, — диде ул, елмаеп. — Ә мин сезне танымадым.

— Минем күптәннән инде телевизордан чыгыш ясаганым юк, — дидем мин, аяк киемемне салып. — Еллар тиз үзгәртә кешене.

— Сез ничек таныштыгыз соң? — диде ул, аптырап.

— Затлы кешеләр бер-берсен табалар алар, — диде Рашат эчүчеләргә хас пафос белән.

— И сөйләшүе, — диде Галия, кашларын җыерып һәм иреннән аңкыган перегар исенә чыдамыйча, чыраен сытып, артка чикте.

— Без урамда очрашып таныштык, — дидем мин. — Рашат мине таныды да... Сез гафу итегез инде... Бераз салдык...

— Сез үзегез моның шикелле, дөньяны онытып, эчеп йөрмисездер әле, — диде ул, иренә ямьсез карап.

— Ярар, ярар, мин дә башкалардан артыгын эчмим, — диде Рашат. — Син, Галия, теленә салынып торма, безгә капкаларга бирәр нәрсә әтмәллә.

— Кайчан туктарсың соң син бу эчүдән! — дип Галия кухняга китте.

— Менә шушында хатыным белән өге-җөге килеп яшәп ятабыз, — диде Рашат, хатынының мырлавын инкарь итеп. — Балаларның үз гаиләләре, алар да Казанда яшиләр.

Хатыны кәтлит белән кукәй кыздырган арада Рашат балаларын, оныкларын мактады, аларны ничек яратуын, аларның аны ничек яратуларын сөйләргә өлгерде. Ул сөйләгәндә, Галия ире ягына кат-кат ямьсез караш ташлаганнан мин Рашат сөйләгәнчә аллы-гөлле тормыш белән генә яшәмәүләрен чамаладым.

Алдыбызга ризык куйгач, Галия, тирән сулап, миңа мөрәҗәгать итте:

— Ичмаса сез сөйләшеп, аңлатып карагыз әле шушына — эчеп үзен бетерә бит инде.

Мин үземне бик уңайсыз хис иттем. Иренең аракы белән нык мавыгуы хатынның зур проблемасына әйләнгәне күренеп тора иде.

— Сез мине ачуланмагыз инде, — дидем мин, ни әйтергә белмәгәч.

— Нишләп сезгә ачуланыйм мин, ни өчен! Киресенчә, мин бик шат сезнең белән танышуыма. Киләсегезне алдан белгән булсам, өйләрне җыештырып, ашарга пешереп торган булыр идем. Иҗатыгыз ничек соң, язасызмы?

— Минем шул иҗат инде яшәвемнең мәгънәсе.

— Бәхетле кеше сез, — диде ул, кухня ишегенең яңагына сөялеп.

— Бәхетне һәркем үзенчә аңлыйдыр инде ул. Кайчан бәхетсез, кайчан бәхетле икәнне үзе генә белә инде ул кеше, — дидем мин.

— Җаны тыныч булса, кеше бәхетле диган сүз инде ул, — дип куйды Галия.

— Җаны тыныч кеше бармы икән соң ул? — дип сүз кыстырды Рашат.

— Эчкән кеше белән яшәп, ничек җан тыныч булсын! — диде аңа хатыны, кырыс итеп.

— Булды, булды, җитте, — диде Рашат, ачуланып. — Бер үк балык башын чәйнәмә инде. Вакыты ул түгел. — Ул елмаеп өстәп куйды: — Мондый шәхес белән эчәргә дә ярый. Зөлфәт әфәнде теләсә кем белән чәкештереп эчмәс.

— Сезне үз өемдә күрермен дип кем уйлаган, — дип тагын елмайды миңа Галия. — И, киләсегезне белгән булсам, өчпочмаклар пешереп куйган булыр идем.

Ул, безне калдырып, кухнядан чыгып китте.

Йөзәр грамм тотып куйгач, Рашат теге пациентның хатларын алып килде.

Ул миңа җиде хатны язылу тәртибендә алдыма куеп, укырга тәкъдим итте.

## 7

Рашат биргән хатларның җидесен дә шундук укып чыктым һәм шактый вакыт һушыма килә алмыйча утырдым. Җиде хатында да ул үзен гаепле санап, Кларны өзелеп яратуын, дәвалангач, әйбәт кенә яши башларга өметләнеп язган иде. Тормышка, үзенә, башкаларга фәлсәфи күзлектән карап, һәр нәрсәне дөрес анализлый белә торган кеше икәне аның хатларыннан күренеп тора иде. Шунысы кызык һәм сәер: ул Кларны барысы өчен дә берсүзсез гафу итеп, үзен исә гафу итәргә ашыкмыйча, моның өчен нигез булырдай сәбәпләр эзләү белән

мәшгуль иде. Хатларының җидесе дә бер үк темага, бер үк нәрсәләр хакында, бер үк мәсьәләгә төрле карашлар белән сугарылып язылган иде. Мин, укучым, сиңа җиде хатның берсен тәкъдим итәм.

«Исәнме, Клара, исәнме, сөеклем, исәнме, күз нурым!

Менә инде ике ай буе мин монда ятам. Яныма килеп хәлемне белерсең дип, беренче көннән үк көтә башладым. Ләкин син юк та юк.

Синең белән танышуыбызга бүген биш ел тулды — хат язарга шуңа күрә нәкъ бүген тотындым. Әмма төп сәбәп — сине сагынуымда.

Ничек бер-беребезгә гашыйк булганны хәтерлисеңме? Мин ул вакытта ялгыз идем. Син дә унсигез яшьлек кызыңны кияүгә биреп, Казанга озаткан гына идең, ягъни үзең генә калган чагың иде.

Ул көннәр минем хәтеремдә иң кояшлы көннәр булып саклана. Безнең һәрбер көнебез тулы, тыгыз, хәрәкәтле, җырлы-биюле, тәмле ризыклы һәм киләчәккә өметле иде.

Коттедж төзергә карар кылгач, мин заводтан китеп дөрес эшләдем, чөнки минем төзү-кору буенча сәләтләрем анда барыбер кулланoccupу табалмады, мин анда абруйлы инженер идем. Син мине формаль рәвештә бер фирмага урнаштырдың да коттеджны төзү белән генә шөгыльләнергә куштың.

Һәм мин җаным-тәнем белән үзебезнең булачак җылы оябызны (оябыз дип әйтү дөрес түгел), затлы сараебызны коруга тотындым. Өч ел эчендә төзеп куйдык без аны. Аннары минем ике бүлмәле фатирны, синең өч бүлмәлене саттык та, түлисе бурычлардан котылып, төзүчеләр белән расчёт ясап, затлы җиһазлар алып, шунда яши дә башладык.

Боларны ник искә төшереп язып утырам дип сорасаң, җавабым гап-гади: минем ул рәхәт, бәхетле көннәребезне гел искә төшерәсем килеп тора һәм синең дә бер генә көнебезне дә хәтереңнән җуймавыңны телим.

Әмма, рәхәт кенә яши башладык дигәндә, минем күңелгә шом кереп урнашты һәм ул миңа алга таба гел тынгылык бирмәде. Ул аңарчы да бар иде, ләкин мин аңа йорт төзү ыгы-зыгысында зур игътибар бирмәгәнмендер. Сүз минем көнчелегем турында бара. Сине эштән озата килүләренә, төрле банкетларга йөреп, аннан синең таң атканда гына кайтуларыңа, көтмәгәндә төрле командировкаларга китеп баруыңа, Эдикның оятсыз рәвештә сине машинасында кочып үбүләренә мин битараф кала алмадым инде. Киләчәгебез хакына бәлки боларга күз йомылырга тиештер дә, әмма сине өзелеп яраткач, мин бу нәрсәләргә ничек битараф калыйм?!

Гафу ит, мин хатны болай язармын дип уйламаган идем. Табибларны чакырып син дөрес эшләдең. Көнләшергә сәбәпләр булган суреттә дә мин тормышыбызны көнләшеп, казынып, төпченеп бозарга тиеш түгел идем. Шуңа күрә, монда дәваланып, көчле препаратлар кабул иткәннән соң, холкым үзгәрер һәм синең яшәү рәвешеңнең кайбер якларына күз йома алырлык көч үземдә табармын дип ышанам.

Мин мең кат гафу үтенәм синнән — көнләшеп, сине бимазалаганым өчен. Ләкин сине нык яраткач, көнләшми дә мөмкин түгел. Син сәүдә директоры белән командировкаларга йөргәч, сине өзелеп яратучы кеше ниләр уйларга тиеш? Шуңа күрә син дә мине аңларга тырыш.

Минем беркемне дә сине яраткан кебек яратканым булмады һәм булмас та инде. Син дә мине ярата идең, бәлки хәзер дә яратасыңдыр.

Коттеджыбызны төзергә өч ел гомеремне багышладым, мин моны горурланып әйтәм, чөнки йорт салу ул кешенең гомерендә иң зур казанышларның берсе санала. Мин тизрәк савыгып, якты дөньяга чыгып, синең белән шул йортыбызда гөр килеп яшәү турында хыялланам.

Мин беләм: элегрәк бәлки аңлап житкермәгәнмендер, газаплы вакытлар шактый булды безнең. Мин көнләшеп, элеккеге ирләреңне телгә алып, бүгенгеләре белән битәрләп, төпченеп, кем белән кая барганыңны сорап, артыннан күзәтеп, аннары гаугага куптарып, үземнең дә җанымны ашап, синең дә җелегенә үткәнмендер. Мин килешәм: мәхәббәт кешеләрне бәхетле итәргә тиеш. Әгәр дә ул газапка сала икән, мәхәббәтнең ник кирәге бар?!

Күрәсеңме, мин моны аңлыйм. Менә мин дарулар ярдәмендә ирешкәнмендер дип уйламыйм. Син дә алай уйлама.

Мин безнең арадагы чатырның ничек килеп чыкканын аңладым шикелле.

Синең яратуың белән минем яратуымны бер үк үлчәмнәр белән үлчәргә ярамый. Ярамый түгел, үлчәп булмый. Минем сөюем белән синең сөюең төрле яссылыкта ята. Син мине монда, Җирдә яраттың (яраткан булсаң инде), ә мин сине Мәңгелеккә перспектива белән, Космос чиксезлегенә дәгъва иткән һәм Җиһан дигән коточкыч парадигмада мәхәббәтем үзенә урын табар дигән өмет белән яраттым. Һәм яратам!

Мин монда үземә үзем каршы киләм, ахрысы. Чөнки шул ук вакытта барыбер Җиһанның да чиге бардыр дип ышанасым килә. Чөнки чикле нәрсә генә гүзәл була ала. Һәрнәрсәнең чиге бар, шуңа аның матурлыгын күреп, тәмен татып була. Картина чиксез зур булса, аның шедевр икәнен аңлап булмас иде. Чәчәк тәмамланган чикләр белән матур итеп ясалган, әгәр дә чәчәк күз карашы тоталмаслык зур булса, аның матурлыгын күреп булмас иде. Әсәрнең азагы булмаса, ул әсәр булмый. Йорт, бакча — алар да чикле булса гына ямьле. Кеше гомере дә шуңа күрә котылгысыз рәвештә чикләнгән. Әгәр кеше мәңге яшәсә, аның гомере гомер булмас иде, кызыгы да, яшәвенең яме дә булмас иде.

Минем мәхәббәтем дә чиксезлеккә дәгъва кылганга күрә газап чигәмдер мин бәлки. Ләкин алай булмаган очракта минем сөюем ул вакытлыча гына, үтеп китә торган гына булып чыга... Ә мин һәрвакыт үтеп барган, вакытлы, юкка чыга торган, мизгел эчендә генә яшәгән нәрсәләрне кабул итә алмыйм. Нишләргә? Ничек хәл итәргә бу проблеманы? Бу минем шәхси, эчке проблемам диярсең син. Ә нигә соң ул миндә туган? Нигә ул миңа? Шушы миллиард еллар буе әйләнгән Җир шарында мине — бер ялангач кешене шуның уртасына бастырып, ни өчен миңа мондый катлаулы, чишеп булмаслык мәсьәләләр куелган?

Уйлана торгач, барыбер Мәңгелектән башка бернәрсә дә мәгънәгә ия булалмый, дигән фикергә киләм мин. Һәрбер сулышыбыз Әбелхәят итәгенә тау астына сарылган томан сыман барып иңә. Инде шик юк, сөюем Мәңгелеккә дәгъва кылганга күрә, мин сине көнләшә-көнләшә үлеп яратамдыр.

Әмма уйлана торгач, чиксез күкнең үзен күреп булмаганны аңлыйсың. Күкне яктыртсаң (кайвакыт яктыртмасаң да), анда йөзеп барган болытларны яки йолдызларны күрергә мөмкин. Ә Күкнең үзен күрү мөмкин түгел. Анда йөзгән болытлар, яктылык сирпегән йолдызлар — Күкнең символлары гына.

Тагын, ахыр чиктән башка, тәмамлана торган формалар булмаса, бернәрсәнең дә яме булмас иде дигән нәтиҗәгә киләм. Нәтиҗәгә киләм, шул ук вакытта миндә моңа каршы протест уяна — менә шундый парадокс. Бит, тәмамланган формалар булгач, камиллеккә чикләр куела түгелме?

Шуңа күрәдер мин классицизмны яратмыйм — камиллек чикләнгән нәрсәләрдә ята дигән иллюзиясе өчен. Камиллеккә чиксезлектә генә ирешергә мөмкин. Җырның гүзәллеген чиксез рәвештә арттырырга мөмкин. Камиллекнең чиге юк. Җырның көен үзгәртүнең чиге юк. Тоннарны чиксез рәвештә бүлергә мөмкин, аңа әле кеше ирешә генә алмый. Темпны чиксез арттырып, чиксез акрынайтып була.

Гүзәллеккә чикләр, формалар кирәк! Камиллекнең чиге юк!

Мәхәббәттә дә мин камиллек эзлим, ахрысы. Шуңа күрә мин тормышымның ямьле, бәхетле мизгелләрен тота алмыймдыр. Бәлки тота алмаганга бәхетле

түгелмендер. Бер мизгелне башка мизгел алыштыруы мине куркуга сала. Миндә аңлатып булмаслык мизгелне югалтудан курку чире бар. Мизгел белән хушлашуны авыр кичерәм. Ул мине алдый шикелле. Мизгел минем нәрсәмнедер урлый шикелле.

Дөньялыкта реальләшү — фәкать Мәңгелеккә һәм Чиксезлеккә омтылуның символлары гына.

Мәхәббәтнең символлары дип нәрсәне атап була?

Мин төзегән коттеджнымы?

Сине яратудан саташып-көнләшеп ятуымнымы?

Синең хыянәтләреңме безнең мәхәббәтнең символлары?

Безнең кыска гына вакытлы интим мөнәсәбәтләребезме?

Артык күп казынам, шулаймы?

Шунын өстенә бер үк уйлануларда әллә ничә тапкыр үземә-үзем каршы киләм, әйеме?

Әмма үз-үзеңне аңлар өчен дә, тормышта урыныңны барлар өчен дә казынмыйча булмый. Кеше, кирәкме-юкмы, гомере буе казына, төпченә, әмма барыбер ни дөньянын, ни үзенең асылына төшенә алмый. Ахырына кадәр үзеңне аңлау — үлү дигән сүз.

Сорауларның чиге юк. Араларында бөтенләй ваклары да бар, ләкин алардан башка җавап эзләү шулай ук мөмкин түгел. Кешедә сораулар туа дип әйтү дөрес түгел. Дөньялыкта кеше түгел, тормыш үзе куя сорауларны. Кеше исә җавап бирүче һәм җавап тотучы.

Хәтта йөзгә кызыллык китерерлек дәрәҗәдә пүчтәк сорауларга да җавап табарга кирәк бит.

Мин үземнең сөю хисемне чиксез югарылыкка күтәрергә телим. Синең Эдик белән рестораннарга йөрүеңә, директорың белән әллә кайларга командировкаларга баруыңа, банкетларда башка ирләр белән чуалып, икешәр көн өйгә кайтмаганыңа ачуым килә!.. Мәхәббәтемне илаһи дип саныйм икән, нишләп үзең өйдә юк чакта киемнәреңне исним, фотосурәтләреңне үбәм?..

Инде мин җүләрләр йортында ятам икән, бер серемне ихластан ачыйм әле: миндә берничә тапкыр сине үтерү теләге туды. Миннән читләшә башлавыңны аермачык сизгәч, сине үтерсәм, башка берәүнең дә кочагына керә алмаячаксың дигән уй мине нык мавыктырды. Сине үтерсәм, син беркемгә дә бүтән тәтемисен, мәңге минеке булачаксың, дип уйладым мин, чөнки минем сөюем Мәңгелек кануннарына буйсына, имеш. Аннары, сине үтергән сурәттә, тәнең белән теләсә нәрсә эшли алыр идем. Куркынычмы? Куркыныч! Бу уйлардан мин үзем дә котсыз калдым.

Нәкъ менә шундый уйлар белән йөргән көннәрнең берсендә син табиблар чакырдың һәм мин моңа үзем дә каршы килмәдем.

Мин аермачык хәтерлим: беркөнне көнләшеп, сиңа бәйләнә башлагач, син миңа: «Җүләрләнәсең бит инде көнләшеп», — дидең. «Әйе, мин инде авырыйм бугай», — дип килештем. «Дәваланырга кирәк», — дидең син. «Мин риза. Минем үземнең дә көнләшәсем килми», — дидем мин.

Шуннан соң син сөенеп мине назлый башладың һәм без караватка яттык. Бер-беребезне сөеп, күңелләребезне күргәннән соң, ятып йокладык. Йокыга киткәндә, һәр икебез бу тотрыклылыкның вакытлыча гына икәнен һәм барыбер безнең арага тиздән көнләшү дигән кара мәченең тырнакларын тырпайтып килеп керәсен онытмадык.

Икенче көнне өебезгә мәчеләр түгел, ике табиб килеп керде. Тыныч, ягымлы әңгәмәдән соң алар мине, машинага утыртып, психушкага алып килделәр.

Мәңге онытасым юк: килү белән миңа шәфкать туташы елмаеп, укол

калады һәм мина шундый рәхәт булып китте. Ә уколдан айныгач, мин яшисем килмәгәнне тойдым.

Менә ике ай инде сине күргәнем юк. Янымa килми калмассың дигән өметем әкренләп сүрелеп бара. Минем хәлем яхшырамы, юкмы — әйтүе кыен. Көнләшүем кимегән шикелле. Синең башкалар белән чуалуына күзләремне йомарга әзер мин. Яна төзелгән йортыбызда көн саен бергә булырга гына язсын — берничә сәгать кенә булса да.

Мина күп кирәкми. Мин — детдомда үскән бала, минем бер туганым да юк. Минем син генә бар, Клара!

Дөресен әйткәндә, мин синең белән танышуыма язмышка рәхмәтле түгел. Синең белән язмышым бәйләнмәгән булса, мин дә, син дә болай газапланмас идек. Ләкин язмыш безне очраштырды һәм бу дөньяның газабыннан бер өлешне мина бирде. Бу — котылгысызлык!

Син мина җавап язмыйсың.

Сина кадәр мин беркемне дә яратмаганмын икән. Беренче хатыныма карата да мондый тирән хисләрем булмады. Ник яратмаганымны белмим. Бәлки элекке хатыным мине нык яратканга күрә, мин аны яратмаганмындыр. Бер шагыйрь әйткән бит: «Хатын-кызны азрак сөйгән саен, үзең ана күбрәк ошыйсың». Ә бәлки ул мине яратам дип алдый торган булгандыр.

Ул вафат булгач, мин, никтер, кайгырмадым. Аның йөрәк авыруы тумыштан булганга микән?.. Ярый әле аның белән балаларыбыз булмады. Бала дигәннән... Сина кырык өч яшь кенә әле, Клара. Бала табарга соң инде, димә. Кызың әүхәтле кешегә чыкты, аның өчен борчыласың юк. Тагын берәрне табу турында уйларга кирәк. Мин алдан ук куркып торам: алай-болай балага узарга ниятләсәң, мин тагын яна газапка кереп батачакмын. Бала миннән түгелдер дигән шикшөбһә инде менә хәзерге минутта ук туды. Бигрәк сәер: син янымда юк, бәлки син мине оныткансыңдыр да, ә көнләшү дәвам итә. Димәк, мәхәббәт кенә түгел, көнләшү дә — трансцендентaль нәрсә. Син бәлки беркайчан мине якын китермәссең, ә менә балага узуың һәм ул бала миннән түгел, башка кешедән булу ихтималы бугазыма ябышты. Бәлки син мине оныткансыңдыр, ә мин сине яратам. Син бу дөньядан, Аллам сакласын, китеп барсаң һәм мин бу хакта белмәсәм, мәхәббәтем дәвам итәчәк бит.

Бу нәрсә дигән сүз? Монда дәваланып ятуым нинди нәтиҗәләр бирә? Белмим. Дарулар, уколлар тәэсиреннәнме, вакыт арасы озыная барганнанмы — минем синнән көнләшүемә (сина түгел!) мөнәсәбәтем үзгәреп бара шикелле. Аңлыйсыңмы, үземнең көнчелегемә мөнәсәбәтем үзгәреп бара. Синең тирәдәге ирләрнең күбесе мина танышлар, аларның төс-битләрен күреп беләм. Синең алар белән булуың төрлечә фантазияләр белән күз алдыма килә, әмма дарулар җанымның әрнүен бераз оета, ахрысы, элеккечә шашынып көнләшмим. Ләкин җан газабын бернинди дару бетерә алмаячак, ул синең сурәтеңә кочаклап үзәгемдә утыра һәм аны берничек аннан каезлап чыгару мөмкин түгел. Минем элек тә бар иде җан газабына предрасположенность. Көнләшүем, синең турыдагы уйларым, сине яратуым — болар газабым шытып чыккан тарафка туклыклы ашлама булып ята.

Мин сагындым сине! Мин яратам сине, Клара! Мин үземне сина, синең мәхәббәтеңә лаеклы дип саныйм. Җаныңны нык биздергән булсам, гафу ит. Ә син мине гафу итәчәксең, чөнки сине ничек яратуымны беләсең. Югыйсә минем газабымның мәгънәсе булмас иде. Газап мәгънәсез булмый. Син минем хатларыма җавап бир ичмаса. Син мине онытырга тиеш түгел, сине минем шикелле яратучы беркайчан булмаячак.

Мин тизрәк йортыбызга кайтып, сине кочагыма аласы көнне зарыгып көтәм!

Сине югалтудан элеккечә куркам. Җүләрләр йортында ятуым минем репутацияне бозар инде, син хурлана башламагаен. Мин элек тә белә идем, монда ятканда, тәмам инандым — кешенең психикасы турында кайда норма, кайда чалышлык башланганны медицина билгели алмый.

Чөнки, кем әйтмешли: «Күнелендә җеннәр оя корган икән, димәк, анда фәрештәләр яшәгән».

Сау булып тор, кадерлем!

Синең Туктарың».

## 8

Рашат үзе башлады сүзне:

— Җүләр кеше яза алыр идеме болай?

— Белмим, — дидем мин.

— Аның хатларын укыганнан соң, мин нәкъ менә синең хәзерге халәтеңдә өнсез калып утырдым, — дип дәвам итте Рашат кафеда башлаган бәянын. — Минем ул кешене күрәсем, аның белән сөйләшәсем килә башлады. Берәүгә евроремонт ясаганнан соң, күчтәнәч итеп бирелгән ике шешә затлы вискины алып, мин Кафил янына юл тоттым. Кафил Казанга киткән булган һәм мин мона, дөресен әйткәндә, куандым. Чөнки хатлардан алган тәэсиремне Ризәләгә җиткерәсем килгән иде, эчке кичерешләрем турында никтер аның белән уртаклашасым килде.

Ризәләнең баш врачтан чыкканын көтеп коридор башында торганда, Туктарның палатадан чыкканын күрдем, ул мине әллә каян танып ашыга-ашыга яныма килде, әйтерсең лә аның хатларын укыганымны сизенгән.

— Исәнмесез, — дип кулымны кысты ул, елмаерга тырышып. Аның кулы салкын иде.

— Исәнмесез.

— Мин сезне әллә каян танып алдым. Ярый күрдем әле сезне. Күңелгә хуш килгән кешеләр сирәк очрый. Сезнең белән сөйләшәсем килә.

— Мин сезгә ярдәм итәрдәй кеше түгел бит... — дидем дә, болай дип теге көнне инде әйткәнем искә төште.

Алайса ник мин тагын шулай дип кабатладым икән? Күрәсең, ничек тә ярдәм итәргә теләвем күнел төпкелендә шытып ята иде инде. Мин әйткән сүздән Туктар да көлемсерәп куйды.

— Заманы шундыйдыр инде, күрәсең — хәзер бер кеше икенчесе белән ярдәм, файда кирәк булса гына аралаша. Мин кадимчедер инде, якты күңелле кеше белән аралашу үзе ярдәм, үзе файда дип саныйм.

Монда ятучыларның барысы да аксыл чырайлы иде, мондый төсмерне башка беркайда да очратканым булмады. Психик авыруның специфик төсе микән бу, дарулар шундый төсмер белән тышка чыга микән? Туктарның да чырае ак иде, ләкин башкалардан аермалы буларак, аның ул «битлеген» салып ташлап буладыр шикелле иде. Тышкы кыяфәтен, әгәр дә теләсә, ул үзе бөтенләй үзгәртеп, таный алмас дәрәҗәгә китерергә сәләтледер кебек иде. Дарулар томанландырган күзләре барыбер тере иде аның, аның эченә, үзегенә бер чиләк башваткыч уенчыклар тутырганнар да, ул аларны бертуктамый җыярга, чишәргә, төзекләндерергә һәм барысын да, гәрчә төрле уеннар булса да, бер корылмага җыеп тупларга, һаман анламаган күп нәрсәнең асылына төшенеп, алардан бер зур мәгънәле объект калкытырга омтыла шикелле иде.

Коридорның икенче башыннан хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Туктар! Уколга!

Туктар бу чакыруны игътибарсыз калдырды.

— Ә сез беләсезме, кешегә тышкы яктан тәэсир иткән нәрсәнең ярдәме

була алмый, чөнки табигать тарафыннан кешегә инде барысы да салынган, аның үзенен эчендә бар инде витаминнары да, дарулары да, — диде ул, укол кадарга теләүчеләр ягына борылып та карамыйча. — Ә читтән, тыштан кемдер укол ясау кешене яхшы якка үзгәртәдер дип уйламыйм.

— Сез бит үзегез дәваланырга телисез дип беләм.

— Әйе. Чөнки минем яхшы якка үзгәрәсем килми. Мин — көнләшеп монда эләккән кеше. Көнләшүдән дәваласалар, бу мине яхшы якка үзгәртү дигән сүз түгел.

— Көнләшкәндә сез яхшыракмыни?

— Көнләшү минем табигый сыйфатым. Табигать яхшырак белә, ул безгә караганда акыллырак, ул миңа нинди булырга кирәк икәнне белә.

— Димәк, сез начар якка үзгәрергә телисез булып чыга?

— Мин Клараны яратам. Аңа мөнәсәбәтемне үзгәртеп яратасым килә. Көнләшмичә яратасым килә. Аны газапламас өчен. Беләсезме, көчле яктылык сукырайта. Көчле дару белән үтерергә мөмкин. Артык көчле мәхәббәтнең эчтән яндырып харап итүе ихтимал.

Коридорның теге башыннан инде ачулы тавыш яңгырады:

— Туктар! Сиңа махсус чакыру кирәкмени?!

— Их, рәхәтләнеп сөйләшеп булмады сезнең белән, — диде ул. — Ярый, киттем мин.

Туктар процедура кабинетына кереп киткәч, коридорда Ризәлә пәйда булды. Коридор буйлап ул аккош кебек йөзеп бара иде. Тикмәгә Кафил бу хатынны гел үзе тирәсендә тотмый дип уйлап куйдым мин. Чибәр хатын-кыз һәрвакыт үзенең чибәр икәнен бер мизгелгә дә онытмый, аларның атлап китеше, кул селтәүләре, башны җинел генә янга борулары, күрешкәндә елмаюлары, чак кына кашларының калкуы, папканы бер кулдан икенчесенә күчереп куюлары — барысы-барысы аның гүзәллегенә хезмәт итә, хатын-кызның сылулыгында һәр чалым, һәр хәрәкәт, һәр элемент үз вазифасын башкара.

Ризәлә мине күрүенә сөенде шикелле.

— Кафил Казанда, — диде ул, килеп исәнләшкәч.

— Миңа әйттеләр инде, — дидем мин.

— Хатларны укыдыгызмы? — дип сорады Ризәлә, башын читкә борып, әйтерсең лә ул хатларда аны оятка калдырырдай нәрсә бар иде.

— Укыдым, — дидем мин. — Аларны нишләп почтага салмыйсыз соң?

— Кафил Әхәтович үзе беләдер инде, — диде Ризәлә, папкасын ике куллап кысып. Ул кинәт миңа туры карады. Мин инде нинди дә булса берәр яналык әйтер дип көткән идем, ә ул аның урынына: — Чәй эчәсезме? — диде.

— Мин яхшы виски алып килгән идем, әйдәгез, шуны бераз кабыйк, — дип тәкъдим иттем.

Кафилнең кабинетына кергәч, Ризәлә чәй кайнатты, вискиның бер шешәсен Кафилнең шкафына тыгып куйдык, икенчесен башлап, стаканнарга илleшәр грамм салдым. Ризәлә вискидан баш тартып чәй эчте, мин йөз илле грамм хәмерне «кабул иттем».

Ризәләнең күңеле урынында түгел иде. Ул сөйләшергә сүз тапмыйча утырды, ә миңа исә озакламый Кафилнең үзен очратып сөйләшергә теләвем тынгылык бирмәде.

Ризәлә көтмәгәндә:

— Туктар нәрсәләр сөйли? — дип кызыксынды.

— Бик акыллы кешегә охшаган ул, — дидем мин.

— Мин дә шаккатам аның интеллектына.

— Ә син ничек уйлыйсың, Ризәлә, аңа мондагы дәвалану ярдәм итәме соң?

— Ничек инде ярдәм итмәсен. Ярдәм итмәсә, дәвалап тормас идек бит. Тик менә... күпме дәвалар икән аны монда?

— Аңа башка төрлерәк дәва кирәк түгел микән?

— Нинди?

— Мондагы препаратлар, уколлар аңа уңай тәэсир итә микән соң? Фикерләвенә, үзенә игътибар иткәч, медикаментлар аңа зыян гына китерәдер шикелле... Бәлки мин ялгышамдыр...

— Чәй ясыйммы? — дип сорады Ризәлә кинәт.

— Юк, рәхмәт, — дидем мин, аның тавышы калтыраганны сизеп.

Ризәләнең сылу йөзе кинәт сүренкеләнде, ул миңа нидер әйтергә теләде, ләкин дәшмәде, барып тәрәзәдән тыштагы агачларга карап торды. Мин аның уйларына комачауламадым, китәргә дип урынымнан кузгалдым.

Ризәлә борылгач, аның елаганын күрдем һәм аптырап киттем.

— Нәрсә булды, Ризәлә? — дидем мин, аңа таба атлап.

— Әллә тагы, — диде ул, иңнәрен сикертеп. — Күңел тулды.

— Берәр проблемаң бармы әллә?

— Кеше проблемаларсыз яшәми инде ул, — дип күз яшьләре аша елмайды ул.

Ул елмайгач, мин дә шаярырга маташтым:

— Синең кебек күз явын алырдай гүзәлнең дә проблемалары булырга мөмкинмени?

— Киресенчә, гүзәлләрнең проблемалары күбрәк була әле ул.

— Нәрсә булды? Эштә берәр төрле күңелсезлек килеп чыктымы әллә?

— Юк ла. Сөйгән кешем белән ачуланыштык. Минем сөяркәм бар. Инде бер турны никахлашырга да җыенган идек, кичектердек, аннары тагын ниятләр башка юнәлеш алды. Юктан гына ызгыштык та, хәзер ни, эшлисе килми... кыскасы, кул да кыймылдатасы килми.

— Үтә торган нәрсә бу, татулашырсыз, аңлашырсыз, мәхәббәттә барысы да була, тормышның үзендәге кебек, — дигән булдым мин, гадәттә мондый очракта әйтелә торган дежур сүзләрне тезеп.

Ә үзем сиздем, Ризәлә миңа елавының чын сәбәбен әйтмәде. Әйе, бәлки чынлап та ир-егете белән аралары бозылып киткәндер, әмма болай хәсрәтләнүенең чын сәбәбе башкада иде. Ниндидер бер газабы бар иде — кинәт аның йөзендәге чибәрлек бөтенләй юкка чыкты, бит тиресе тартылып, күзгә күренеп сулыгып калды, күзләренең акайганын мин аермачык күрдем. Чырае палаталарда ятучыларныкы кебек аксыл саргылт төскә керде, аңа бу мәлдә алтмыш яшь тирәсе бирерлек иде. Мин котсыз калдым.

— Ризәлә! Син авырыйсыңмы әллә?

— Әйе, әллә ничек. Инде берничә тапкыр шулай булды. Баш эчендә мигә авыр плитә прессы баскан кебек. Күзләрем күрә дә шикелле, шул ук вакытта бер ноктага текәлеп карый алмыйм. Хәлем бетә. Ул өстәл каршындагы диванга утырды.

— Врач чакырыйммы?

— Юк, кирәкми. Хәзер үтә ул.

Мин аңа графиннан су салып бирдем.

— Нәрсәдән соң ул? Кайсы төшең авырта?

— Хәл юк, — диде ул, су йотып куйгач. — Аннары... курку бар...

— Нәрсәдән курку?

— Белмим.

— Бәлки көннәр буе психлар арасында булгангадыр?

— Юк, сәбәбен мин үзем беләм, — диде ул. — Төпченмә.

Шуннан соң ул халат кесәсеннән ниндидер дару алып капты, артыннан стакандагы суны эчеп бетерде.

— Куптәнме бу синең? — дидем мин, шундый гүзәл затның кинәт әллә нинди ямьсез кыяфәткә керүеннән котсыз калып.

Ул, диван артына терәлеп, күзләрен йомды:

— Күптән түгел.

— Дәваланырга кирәк.

— Дәвалану ярдәм итмәячәк, — диде ул, иреннәрен чак кына кыймылдатып. — Нәрсәдер эшләргә кирәк... Син бар. Мин үзем генә ятып торыйм әле.

— Ризәлә, син бит әллә нишләдең, — дидем мин, аны монда үзен генә калдырасым килмичә. — Син бөтенләй башка кешегә әйләндең.

— Әйе, кызганычка каршы, мин элеккеге түгел инде.

— Баш врачны чакырыйммы?

— Кирәкми. Син бар, мин ятып торыйм әле. Үзем генә буласым килә. — Ул диванга сузылып ятты. — Бар, бар, курыкма, хәзер үтә ул.

Коридорга чыккач, бу тетрәнүдән мин хәтта ишекне табалмыйча беравык коридорда адашып йөрдем.

## 9

Шешәбез төбенә кадәр бушаса да, сөйли торгач, Рашат бөтенләй айнып китте. Мин үзем дә, ярты шешә аракы эчүгә карамастан ап-аек идем — җиде хатны уку җиде тапкыр саунага кереп чыккан кебек тәэсир итте дисәм дә ялган булмас, мөгаен. Мин саф һавага чыгарга тәкъдим иттем.

Галиягә рәхмәт әйтеп, тагын бер тапкыр гафу үтендем дә, чыгып киттек. Хатынының сукранып калуына күнеккән Рашат баскычтан төшкәндә:

— Искиткеч олы җанлы кеше минем хатыным, — диде. — Ул яктан бәхетле мин.

— Син аның сүзенә колак сал инде, Рашат, — дидем мин. — Син бит хатыныңнан алда әле үзеңне бетерәсең болай эчеп, синең белән хатының да сулыга.

Дөнья күргән, шактый олы яшьтәге кеше буларак, аңлыйм: бу сүзләремнең аз гына да тәэсире булмаячак, ләкин мин аларны әйтергә тиеш идем. Аракыга көн саен тотынуның һәрвакыт эчке, тирән сәбәбе була. Рашат та эчеп рәхәт булсын өчен генә эчми иде. Тирәнрәк психологик сәбәбе бар иде аның. Барыбер эчәчәк бит инде ул. Мине очраткач, минем белән эчте, мин очрамасам, башка кеше белән эчәр иде, кеше очрамаса да, үзе генә эчми калмас иде.

— Мин бит шул «N» каласында, психушкадагы вакыйгадан соң каты эчә башладым, — диде ул, урамга чыккач. — Минем башка чарам юк газабымны хет аз гына булса да басарга. Әйе, бу минем эчүемне аклау түгел, әлбәттә. Беләм мин, аңлыйм, сизәм көннән-көн түбәнгә тәгәрәгәнемне. Шулай да, акчаң булса, тагын бер ярты ал инде.

Мин Галиянең аһ-зарларын да оныттым, Рашатка эчүен ташларга кирәк икәнне дә инкарь иттем — кибеткә кереп, тагын бер шешә аракы алып чыктым. Минем Рашатның бәянын ахырына кадәр тыңлыйсым килде — ниндидер коточкыч вакыйга булган «N» каласында.

Казан елгасы буена барып ярга утырдык, пластик стаканнарга салып эчтек, аннан соң берәр банан ашадык. Рашат, җанланып, сөйләвен дәвам итте.

## 10

— Ярты ай чамасы вакыт үтте.

Туктар исемле пациент башымнан чыкмады.

Мин аның турында хатыныма да сөйләдем, хатларын күрсәттем. Аларны укыгач, Галия сәгать буе елады.

Отпускыга чыкканымның икенче көнендә үк Кафилнең эш урынына юл тоттым. Аңарчы шактый вакыт аралашмый торган идек. Туктарга дип ике пакет ризык, җиләк-җимеш, сок ише күчтәнәчләр алып бардым.

Мина бер сорау тынгылык бирмәде: нишләп Туктарның хатларын почта аша хатынына җибәрмиләр? Кафилдән бу хакта сорарга кирәк дигән карарга килдем.

Кафил урынында түгел иде, кая киткәнен беркем дә әйтә алмады. Хәзер кайтырга тиеш, диделәр.

Ризәләнең каян килеп чыкканын да сизми калдым. Аның киеренкелеге төсенә чыккан иде, һәр ишетелгән авазга кинәт борылып, эндәшсәләр сискәнеп, ул үзен кемдер эзәрлекләгән, янау сизгән сыман хис итә иде. Ул мине ашыктырып, өлкән сестра бүлмәсенә алып китте.

— Зинһар, теге хатларның ксерокопияләрен йә миңа алып килегез, йә ертып ташлагыз, — диде Ризәлә, өзгәләнеп. — Хәзер инде аларны сезгә укытканыма үкенәм.

— Нишләп алай? Нәрсә булды?

— Бәлки психиатр гына аңлый торган нәрсәләр бардыр аның хатларында... Авыру кешенең хисләре адекват булмау да бар бит... Ярамый аның хатларын чит кешеләргә уку... Хәтта Туктарның хатыны да укырга тиеш түгелдер... Кафил Әхәтович шуна җибәрмидер хатларын. Берүк, аларны укыганыгызны беркемгә дә әйтмәгез. Теге мин биргән копияләрне алып килегез.

— Алып килермен. Бу кадәре үк борчылмагыз, Ризәлә. Туктагыз әле, сезнең тарафтан бернинди кара эш булмады, ник болай ачыргаланасыз? Мин беркемгә әйтмәм бу хатлар турында.

— Куркам мин, куркам, — диде ул, як-ягына каранып.

Ризәләнең кыяфәте үзгәргәнне күреп куркуга калдым, теге көндәге өянәге кузгаламы әллә?

Мин аңа бер тармак банан белән ике апельсин бирдем һәм:

— Мин сезне авыр хәлдә калдырмам, бер дә борчылмагыз, — дидем.

Әйе, Кафилгә турыдан-туры хатларның эчтәлеге турында сүз кузгатсам, нишләп кешегә пациентның хатларын укыттың дип, Ризәләне ачуланачак. Ризәлә шуннан куркадыр.

Коридорның кайсыдыр тарафыннан «Кафил Әхәтович кайтты!» дигән тавыш ишетелде.

Кафил мине гадәттәгечә шат йөз белән кабул итте. Хәл-әхвәлләрне белешкәч, ул армияне искә төшерә башлаган иде, әмма минем солдаттагы хәлләрне сөйләшеп утырасым килмәде, мин Туктарның хәле белән кызыксындым.

Ул врачларга хас салкынлык белән:

— Аның хәле беркөе, — дип җавап бирде.

— Хатлар язамы һаман?

— Соңгы вакытта язмый башлады. Дәвалау тәэсир итәдер.

— Хатыны килмиме?

— Юк.

— Хатлары барып җитмәде микән әллә?

— Барып җиткәндер. Шәһәр эчендә почта әйбәт эшли ул.

— Минем аны күрәсем килә. Менә бераз җиләк-җимеш алып килгәнием, — дип ишек катында калдырган пакетыма күрсәттем.

Кафил гаҗәпләнеп миңа карап торды.

— Зур кызыксыну уятты бу пациент синдә, — диде ул, көлемсерәп.

— Яратудан шашкан кешене моңарчы күргәнем юк иде, — дидем мин. — Гомумән, мондагы пациентларны күрү миндә күп нәрсәгә карашларны үзгәртте, мин үзем дә үзгәрә башладым шикелле.

— Кирәгеннән артык дәрәҗәдә үзгәреп, минем пациентыма әйләнә күрмә, — диде Кафил, көлеп. — Әйдә, чәй эчәбез.

— Юк, рәхмәт, эчәсем килми, — дидем мин. — Көнләшүдән дәвалау — яратудан дәваларга тырышу түгелме?

— Яратучы кеше болай ук көнләшә микән соң ул? — дип куйды Кафил.

— Нык яратмаса көнләшмәс иде бит.

— Яратудыр да ул, ләкин ярату гына түгел. Шул яраткан кешесен югалту куркынычы көнләштерә кешене, шуна күрә ул аны үзенең милке итмәкче була. Шәхес буларак хәлсезлеге яраткан кешене югалтудан куркыта һәм ул үзенең ратуын зур мәгънәгә, бөек хискә саный. Шәхес буларак пүчтәк булган саен кеше катырак көнләшә.

— Ул пүчтәк кешегә охшамаган, — дидем мин һәм анын хатларын укыганымны чак кына ычкындырмый калдым.

— Көнләшү — рухи импотентлык галәмәте. Көнләшү — шәхес буларак үз-үзенә ышанмаудан. Үз милке итеп, үзенә хосусыйлаштыру теләге шуннан килә. Көнче кеше бөтенләй өйләнергә тиеш түгел. Ул мәңге көнләшәчәк. Ул үзен дә бәхетсез итә, яраткан кешесен дә. Андый кешенең садо-мазохистлыгы үзе теләгәннән түгел, үзеннән-үзе шулай килеп чыга, ул шундый инде. Андый кеше, әлбәттә, галәти булмый. Анын шәхес потенциясе нормаль юнәлешләрдә тармакланасы урынга башкача юллар белән трансформацияләнә. Шул сублимация инде ул.

— Анысы нәрсә тагы?

— Әйдә, менә болай аңлатып карыйм. Кешегә һәрбер көнгә күпмедер психик энергия бирелгән ди. Син аны ничек, нәрсәгә, күпме дәрәҗәдә сарыф итәсең — үз ирегеңдә. Мәсәлән, ике тирән чокыр казыган көнне син ике хатын янына женси мөнәсәбәтләргә керергә бара алмаска мөмкин, шулаймы? Ике кеше белән сугышып кайтса, утырып ике битле хикәя яза алмыйдыр язучы. Ике кубометр утын кискәннән соң, ике кеше белән сугыша алмыйсыңдыр. Ике эштә эшләсәң, ике сәяркән булуы икеле. Шул бер психик энергия трансформация ясый инде — зиһен аша, мускулатура аша, нервылар, аяк-куллар аша. Шул бер система инде ул — баш мие белән тән... — Ул, сөйләүдән туктап, миңа текәлде. — Син ник болай кайгыга баттың соң әле? Рашат, служак! Кичә армиядә төшкән фотоларны карап утырдым әле. Арыгансың син. Бигрәк тиз үтә вакыт. Әйдә, ял көне елга буена шашлыкка чыгабыз.

— Минем Туктарны күрәсем килә, — дидем мин һәм ишек катындагы пакетларны барып алдым.

Кафил шкафтан ак халат алып иңемә салды. Ул мине дүртенче палатаның ишегенә кадәр озаткач, кире кабинетына китте, мин палатага кердем.

Палатада дүрт кеше, уртадагы ике караваттагылар йоклый иде. Туктар үз караватында тәрәзәдән тышка карап утыра иде, тәрәзә биегрәк булганга, ул ачык һаваны, күкне генә күрә иде бугай. Ишек янындагы пеләш башлы, тәбәнәк буйлы урта яшьләрдәге агай, сикереп торып, күзләрен челт-челт йома-йома, каршыма басты:

— Кефирның бәясе арткан диләр, дөресме?

— Юк, ишетмәдем, — дидем мин.

Туктар борылып карады һәм куанып, миңа таба йөгереп килде:

— Сезне күрүемә шат. Исәнмесез. Син, Жәүдәт, кефир турында башка вакытта сөйләшерсең. Кефирга килеп терәлгәнмени тормыш?!

— Миңа көн саен кефир бәясен әйтәләр, көн саен яна бәя, — диде пеләшбаш зарлы тавыш белән. — Житмәсә бер үк көнне төрле кеше төрлечә бәяне атый. Акылдан язарга була. — Ул, караватына утырып, кайгылы кыяфәттә башын салындырды.

Безнең сөйләшүдән урта караватлардагылар уянды һәм алар торып, миңа текәлделәр. Берсе инде алтмышны узган олы яшьтәге кеше иде — ап-ак чәчле, башкалар кебек үк ак чырайлы, акайган күзле. Яшь чагында физик яктан көчле булгандыр, хәер, хәзер дә җегәрлегә охшаган — киң җилкәле, эре сөякле, зур иякле кеше иде ул. Яшькелт-сары тырнаклы аякларын тапочкалары өстенә куеп, ул караватында үз биләмәсендә хуҗа булып утырган җанварны хәтерләтә иде. Аның күз карашы усал иде, мин аңа карамаска тырыштым.

Туктар елмаеп аңа эндәште:

— Фердинанд абый, таныш бул, бу — Рашат әфәнде — Кафил Әхәтович белән армиядә бергә хезмәт иткәннәр.

Фердинандка әлеге хәбәр берничек тәэсир итмәде, ул миңа ничек караган, шулай текәлгән иде.

Икенчесенә исә — утыз тирәсендәге ябык, озынча гәүдәле яшь егетнең күңеленә Кафилнең служагы булуым хуш килде бугай. Ул, караватыннан торып, миңа еракган ук кулын сузып килде. Чем-кара күзле, кара чәчле, кара кашлы кешенең чырае ап-ак булгач, берәр тамаша өчен махсус грим салынган дип уйларлык иде.

— Исәнмесез, — диде ул, миңа шыр сөякле коры кулын сузып. — Мин бик шат. Исемем — Сабир. Ишеткәнегез бармы?

Аның минем белән сөйләшәсе килгән иде, җитешә алмады, Туктар мине җитәкләп, тәрәзә янында урнашкан караватына таба алып китте. Ул үзе караватка утырды, миңа читтәрәк торган урындыкка ымлады.

— Кафил белән армиядә бергә хезмәт иткәнне кем әйтте? — дидем мин, урындыкны алып килеп аның каршысына куйгач.

— Оныттым инде, — диде ул, елмаеп, чөнки чынлап та моны кем әйткәне беркем өчен дә әһәмиятле түгел иде.

Пеләш башлы пациент, йөгереп килеп, колагыма пышылдады:

— Беләсезме, тәмле катык кайсы кибеттә бар? «Ямашев» урамындагы «Рассвет» дигән кибеттә.

— Рәхмәт, — дидем мин, — белмәгән идем, хәзер беләм инде.

— Җәүдәт! — дип җикерде аңа Туктар. — Комачаулама безгә сөйләшергә!

Җәүдәт үпкәләде, ахрысы, палатадан коридорга чыгып китте.

— Хәлләрегез ничек соң? — дип кызыксындым мин урындыкка утырып һәм ризыклы пакетымны караватка аның белән янәшә куйдым. — Монда алма, банан, груша, сок, тагын вак-төяк — витаминлы нәрсәләр.

— Рәхмәт, — диде ул. — Миңа витаминнар ярдәм итәрме соң? Хатынымны сагынам. — Аның йөзенә газап саркыды. — Араларыбыз бозылуда мин гаепле, мин, мин!

— Бөтен гаепләрне үз өстегезгә алырга ашыкмагыз әле.

— Мин барыбер көнләшүдән бер туктармын һәм без Клара белән тыныч, рәхәт тормыш башлап җибәрербез. Тик менә... Эдик бар шул... Мин ул Эдикны хәзер, никтер, башкаларга караганда ешрак искә алам. Эдик нык чуалды минем Клара белән... Ирдәге хатын икәнне белә бит ул югыйсә...

— Эдик кем?

— Кем дип... Автосалон директоры. Шәһәргә керә торган юл кырыенда ул автосалон. Иномаркалар саталар. Клара белән мин аны берничә тапкыр күрдем.

— Берничә тапкыр күрү бит әле ул...

Ул минем сүземне кырт кисеп бүлде:

— Алай димәгез. Күңел сизә бит ул.

— Димәк, көнләшергә урын бар дип саныйсыз? — дигән булдым мин.

— Әйе, көнләшергә сәбәпләр бар һәм сәбәпләр күп шикелле. Ләкин бит көнләшкән саен, Клара белән араларыбыз суына бара. Шунысы аяныч.

— Ә көнләшмәсәгез, ул сезне ныклап ярата башлаячакмы?

— Мин өметләнәм. Чөнки минем өчен анардан башка яшәүнең мәгънәсе юк.

— Ничек инде яшәүнең мәгънәсе булмасын! — дидем мин. — Бүген мәгънәсе юк булып тоелса, аны иртәгә мәгънәле итәргә мөмкин бит.

— Беләсезме, проблема нәрсәдә — Җирдәге шәһвәтле сөю чын рухи, илаһи мәхәббәтне каплый, үзе астында калдыра. Әмма парадокс шунда ки — шәһвәтле сөю үзе генә моны булдыра алмас иде. Шәһвәтле сөюдә рухи мәхәббәттән дә нәрсәдер бар. Шуңа күрә көче җитә аның.

— Туктар, бәлки артык күп уйланулар сине көнләшә торган итәдер? Син мәхәббәтне дә төрле формаларга бүлеп утырасың...

— Бәлки шулайдыр. Минем һәркемгә аңлатасым килә: женси мөнәсәбәтләрдә индивидуальлектән берни калмый, шәхсилек юкка чыга — син бөтен хайваннар дөньясы белән берләшәсең. Женеснең йөзе юк, ул үзе дә башка йөзләрне күрми, танымый. Мәхәббәт — шәхси эш, кабатланмас кешенә, бердәнберенә юнәлтелгән ул. Женси сөю алмашу белән килешә һәм җиңел генә бер кешене икенчесенә алмаштыруга ризалаша.

Туктарның фикерләре белән килешми мөмкин түгел, әмма сөйләгәндә, аның, фәлсәфәгә кереп, чынбарлыктан ерагаюы аермачык күренеп тора иде.

Фердинанд ягына күз салдым — ул караватында кымшанмыйча да миңа текәлгән килеш утыра иде. Чуаланып беткән саргылт төстәге сыек чәче астыннан ике күз һаман акаеп миңа карап торалар иде. Шул вакытны Сабир янымa йөгереп килеп, алдыма иелде:

— Сез килешәсезме, иң вәхши халык — немецләр, шулай бит? — диде ул, пышылдап.

— Бөтен халык турында алай дип әйтеп булмый инде, — дидем мин. — Фашизмны күздә тотып әйтәсездер...

— Фашизм нәрсә ул! Фашизмга кадәр үк алар коточкыч нәрсә уйлап чыгарганнар.

— Нәрсә уйлап чыгарганнар?

— Сәгать. Фашизмнан да коточкычрак нәрсә ул — сәгать.

— Сабир, син безгә сөйләшергә комачаулыйсың! — дип җикерде Туктар.

Сабир тиз генә китеп барды. Ул үзенең караватына түгел, Фердинанд янына барып утырды.

Туктар кинәт боекты — күрәсең, җанланып сөйләгәндә сүзе бүленгәч, ачуы килгәндер.

— Аңламыйм, ник яшим мин?! — диде Туктар, кинәт кыҗрап. Ул үзенә-үзе кыҗрый иде сыман.

— Яшәү кызык, — дидем мин, башка тынычландырыр сүз тапмагач. — Шул Кларага гына килеп төртелсә, дөнья дөнья булыр идемени? Чиксезлек, мәңгелек дигән төшенчәләрне астына җәеп ятасы кала, әгәр дә бер... хатын-кыз аркасында син яшәүдән ваз кичәсең икән.

— Нишләргә миңа?! — дип урыныннан сикереп торды Туктар.

— Яшәргә, — дидем мин тыныч кына. — Яшәү ямен, яшәү тәмен татып калырга кирәк. Бу дөньяга бүтән килмибез. Күреп кал, яшәп кал.

Кинәт Фердинандның калын ямьсез тавышы ишетелде:

— Син кайчан миңа егерме сум әҗәтеңне түлисең?

— Мин инде сиңа әллә ничә тапкыр әйттем — минем синнән әҗәткә акча алганым юк, — диде Туктар. — Рашат әфәнде, әйдәгез, чыгыйк әле моннан.

Без палатадан чыгып киттек.

— Фердинандка түлисе бурычың булса, мин сиңа егерме сум бирәм, — дидем мин, палатадан чыгып, коридор башындагы тәрәзәгә таба барганда.

Туктар елмаеп кул селтәде:

— Минем анардан акча алганым юк. Ул торымнан-торымга бөтен кешегә шулай бәйләнә. Берәр атна үткәч, башка кешедән акча даулый башлаячак. Аңа агрессия өчен сәбәп кирәк. Аңа агрессиягә каршы бик көчле укол кадыйлар. Монда килгәндә ул бик куркыныч иде. Хәзер, дәвалый торгач, аның агрессиясе егерме сум сорарлык кына калды.

— Ә теге кефир турында сораучының диагнозы нинди?

— Жәүдәтнеңме... Шизофренияләр инде. Тормышның һәр күренеше аның үзенә кагыла дип саташкан ул. Йорт стенасына ниндидер плакат эленгән булса, ул аны үзен мыскыл итү дип кабул итә. Кибеттә берәр товарның бәясе артса, ул аны үзен кимсетер өчен, хәтта ачтан үтерер өчен эшләнә дип ышана. Бөтенләй үзенә кагылмаган нәрсәләрне тырнакларын тырпайтып кабул итә, ачуы килә, чыгырыннан чыга.

— Ә теге, Сабир исемлесен монда ник яткырганнар?

— Мин аның диагнозын төгәл белмим. Сабир өчен вакыт бик озак үтә. Күрәсең, аның үзенең эчке ритмы бик каты чаба, ә сәгать аның өчен бик акрын йөргән сыман тоела. Аның кайчакларда, вакыт йөреше туктады дип уйлап, асылыныр дәрәҗәгә житкән мәлләре булган.

Без коридорның аулак башына барып життек

— Сез минем халәтем белән кызыксынасыз... — диде ул, ике куллап тәрәзә төбенә таянып. — Сезгә бәлки берәрсе кушкандыр — шыпырт кына белеш әле аның хәлен дип?..

— Юк, юк, Туктар, сезнең фикер йөртүегезне, Кафил белән сөйләшүегезне ишеткәч, күргәч, монда ятуыгызга битараф булалмыйм. (Мин шунда аның белән төрле вакытта төрлечә — йә «сез», йә «син» дип сөйләшкәнемә игътибар иттем.) Аннары, бит сез үзегез миңа мөрәҗәгать иттегез. Ярдәм итәрдәй кешегә охшавымны әйттегез түгелме?

— Сез бит белмисез ул сүзләремә нинди мәгънә салганымны, — диде ул миңа серле итеп.

— Ничек кенә булмасын, мин ихластан сезгә риясыз ярдәм итәргә телим, ләкин ничек ярдәм итәргә икәнне белмим.

— Димәк, сез — альтруист, — дип елмайды ул. — Минемчә, альтруизм — үзендә гаеп хисе тоюдан килә. Гаеп-гөнаһларын юу теләге кешене альтруист итә.

— Алайса мине башка сүз белән ата, — дидем мин, көлемсерәп. — Мин алай бик ярдәмчел дип тә санамыйм үземне һәм гел дөрес юлдан йөрүче гаепсез кеше дип тә атый алмыйм.

Ул, кинәт миңа таба борылып:

— Менә әйтегез әле, минем хәлем кызганычмы, көлкеме? — дип сорады.

— Сезнең хәлегез абсурдлы. Күрә торып үзегез упкын кырыннан барасыз шикелле.

Ул тагын тәрәзә төбенә таянып, урамга карады:

— Нишләргә соң миңа? — дип сытып чыгарды ул өч сүзне.

— Хатының белән ничек булса да очрашырга, сөйләшергә кирәк, — дидем мин. — Ахыргача ачыклык кертергә, тәгаен хәл итәргә үзара мөнәсәбәтләрегезне.

— Мин моннан качып, аны эзләргә жыенган идем инде. Моннан качу мөмкин түгел. — Ул тирән сулап куйды. — Их, Клара, Клара... Кешене берьюлы ярату да, хөрмәт итү дә мөмкин түгелдер бәлки.

— Ничек инде?

— Хөрмәт итүдә аек акыл бар, дистанция саклана. Хөрмәт итүдә үз-үзенә карата ихтирам исән кала. Ә мәхәббәттә син рәхәтлекнең кочагында изрәгәндәй буласың да, бервакытны кеше күнелендәге, үзара мөнәсәбәтләрдәге

пычракның барлык палитрасына буялганынны тоясың. Мәхәббәттә дистанция сакланмый, проблема әнә шунда. Артык якынайгач, сине кимсетергә җайлы, артык якынайтып сине алдарга җиңел. Якынайткач, синең белән туганлашырга мөмкин, якынайткач, сине аннары дошман итеп була, якынайткач, сине тегендә-монда файдалана алалар. Якынайгач, сиңа төкерергә ара якыная, аңлыйсыңмы? Якынайган кешегә хыянәт итеп була...

Ул нык дулкынланып сөйләде. Мин тын да алмыйча аны тыңладым.

— Якынаймыйча, яратышмыйча кешеләр яши алмыйлар, — дип куйдым мин, аның хәл алырга туктавыннан файдаланып.

— Шуңа күрә кешеләрнең яшәве адым саен түбәнсеңү белән үч алу арасында бара. Җиңелүче дә юк, җиңүче дә юк, — диде ул.

— Хаклы кеше җиңәргә тиештер, — дидем мин.

— Ягъни дөреслек җиңәргә тиеш дигән иске сүзне кабатламакчы буласың инде? — дип усал итеп карады ул миңа. — Дөреслек җиңәргә тиеш дигән сүз мине һәрвакыт куркыта. Менә шул кешеләр эзләгән дөреслек ялганның, алдауның, мәкернең, хәйләнең — кыскасы, кешеләр арасында иң пычрак, иң түбән төшенчәләрнең нигезе булып тора да инде.

Ул миңа күп нәрсәгә күзләремне ачты, аны тыңлаганда, тирән мәгънәле акыллы бер китап укыган сыман булдым. Ул шулкадәре нечкәлекләре белән, тирәнтен аңлый иде кешеләрне, дөньяны. Кешеләрне үтәли күрә иде ул. Ничек инде хатынының фальшларын, чалыш юлда йөрүен, хыянәтен күрмәсен бу кеше?! Башкалар күрмәгәнне күрү үзе авырдыр, аларда казыну тагы да авыррактыр.

Шул ук вакытта Туктар бит дөрес бәя бирә, үзенең дөньяны тоемлавына да, башкалардан аерылып торуына да дөрес бәя бирә, дөрес аңлый.

— Син бит дөрес язгансың хатыңда: синең яратуың белән аның яратуын бер үк үлчәмнәр белән, бер үк үлчәүләргә салып үлчәргә мөмкин түгел, — дидем мин.

— Ә сез минем хатымны ничек, кайда укыганыгыз бар? — диде ул, аптырап.

Мин чак кына аның хатларын укыганымны әйтеп ташламадым һәм:

— Кафил Әхәтович хатыгыздан берничә цитатаны яттан әйтте, — дип ялганладым. — Сез бит хатыныгыз белән башта әйбәт яшәгәнсездер?

— Әйе, без бәхетле идек.

— Хыянәт итәдер дип шикләнә башлагансың...

— Әйе.

— Ә сез шикләнә башлаганчы, ул сине нык ярата идеме?

— Әйе.

— Сиңа кичекмәстән хатының белән очрашуны оештырырга кирәк, — дигән фикеремне кабатладым.

— Соңгы вакытта безнең сөйләшүләр гел скандал белән тәмамлана иде. Сез хаклы, сөйләшергә кирәк. Өй телефонына моннан рөхсәт сорап берничә тапкыр шалтыратып карадым, трубканы алучы булмады, ә ике тапкыр... ир кеше тавышы ишетелде... Эдик иде бугай... — Аның йөзе тагы да ныграк агарды. Ул, миңа туп-туры карап: «Хатларыма җавап язмый», — дип пышылдады. — Минем аны күрәсем килә. Сез дөрес әйтәсез, кичекмәстән очрашырга кирәк аның белән. Сөйләшергә кирәк, аңлашырга. Ләкин сөйләшер алдыннан, иң беренче чиратта, минем аны кочагыма аласым килә. Мин бик сагындым аны.

Аның иякләре дерелди башлады һәм ул тыела алмыйча елап җибәрде.

— Хатыныңны күреп сөйләшимме? — дидем мин.

— Сез чын әйтәсезме? — диде ул, күз яшьләрен җиңе белән сөртеп.

— Миңа аның эш телефонын, фамилиясен, кайда эшләвен әйт.

Пинҗәгемнең кесәсеннән блокнотымны алып, ул әйткәннәрне язып куйдым.

— Сау булып тор, — дидем мин аңа һәм коридор буйлап Кафил кабинетына таба киттем.

Үтеп барышлый, Туктар палатасында ятучы пеләш башлы псих мине туктатып, сөт продукциясе хакында сүз катмакчы иде, мин бу мәсьәләләргә башка вакытта ачыклык кертергә вәгъдә биреп, тизрәк китеп бардым. Ашыгуымның сәбәбе — Кафил чыгып киткәнче, аңа бер-ике сүз әйтәсем, дөресрәге, сорыйсым килгәннән иде.

Кафил кабинетында ниндидер кәгазьләр актарып утыра иде.

— Туктарның бу дөньяда бер кадерле нәрсәсе дә юк, аны тормыш гел кимсеткән, ул гомере буена югалтулар кичереп яшәгән, — дидем мин кергән уңайга. — Аның хәзерге вакытка беркеме, бернәрсәсе калмаган. Аның үзенә ышануы бетеп бара. Ул, кырмыска саламга тотынган сыман, тотынмакчы була. Барыбер батачак ул салам... болай дәвам итсә...

Кафил шаккатып миңа карап торды:

— Син бит психоаналитик сыман сөйлисең, — диде ул аннары, елмаеп.

— Мин бит психиатрның дусты, — дидем мин шаярусыз. — Аның халәтен аңлар өчен, психиатр булу кирәкми.

Ул тәгәрмәчле креслосын, кулы белән өсталдән этеп, чак кына артка чигерде дә:

— Ник син аның өчен болай кайгырасың? — диде.

— Белмим, — дидем мин, аның каршындагы урындыкка утырып. — Күңелем сизә — ул авыру түгел. Монда үзең дә чын психка әйләнерсең. Аны көнләшүдән дәвалап маташуда мәгънә юк. Күренеп тора: алга таба хатыны белән тора алмаячак — юкса харап булачак үзе дә... бәлки хатыны да... Әгәренки тагын ялгыз калырга язган икән, ул очракта бигрәк тә аның урыны монда түгел.

— Ә кайда аның урыны? — диде Кафил, күзләрен чекерәйтеп.

— Яшәү мәгънәсен табарга ничектер башкача ярдәм итәргә кирәк. Уколлар, көчле препаратлар ярдәмендә түгел.

— Яшәү мәгънәсе турында киңәшләр бирүе җайлы, ләкин кешене көнләшмә дип кенә көнләшүдән туктату мөмкин түгел.

— Сәбәпсез көнләшү патология булырга мөмкин, ә сәбәпләр булганда...

Кафил, минем сүземне бүлеп:

— Сәбәп булса да, булмаса да, көнчелек — авыру ул! — диде. — Көнләшү — чир ул, аңлыйсыңмы?

— Бәлки чир дип санарга ярыйдыр. Кешеләргә игътибар белән карасаң, кайвакыт сау-сәламәт кешедә бөтенләй нормадан читләшкән сыйфатлар күрергә мөмкин.

Кафил көлеп куйды.

— Сиңа табиб буласы калган. Синнән менә дигән психотерапевт чыгар иде. Әмма артык кызганучанлык эшеңдә комачаулар иде.

— Туктарның көнләшүе ниндидер психоз, шизофрения яки саташу белән бәйле түгел бит, — дип үзем белгәнне тукырга маташтым мин.

— Ә син каян беләсең? — диде Кафил, гаҗәпсенеп. — Туктале, син табиблар гына белә торган кайбер нәрсәләрне өйрәнгәнсең бит...

— Мин психиатрия буенча китаплар таптым... укыдым...

Бу аңарда зур кызыксыну уятты:

— Ник кирәк булды алар сиңа?

— Монда, сезнең диспансерда булганнан соң, кызыксына башладым.

— Алай икән. — Кафил тирән сулыш алды. — Туктарны без көнләшүе психоз, шизофрения стадиясенә җиткәнгә күрә дәвалыйбыз. Көнләшү чире, башка психозлардан аермалы буларак, акрынлап көчәергә мөмкин. Көнче кешенең көтмәгәндә әллә нинди коточкыч адымнарга баруы ихтимал. Соңгы стадияләрдә үзенең халәтенә тәнкыйть күзлегеннән карый алмый, адекватлыгын югалта.

Андый кеше белән яшәү куркыныч була башлый. Аны стационарда дәвалау яхшырак. — Ул кулындагы сәгатенә карады. — Син төшке ашны ашадыңмы?

— Юк әле.

— Әйдә, «Космос»ка, анда бик тәмле комплексный обед бирәләр.

## 11

Телефон номерын җыйганда, эчтә ниндидер көч мона каршы килгәндәй булды. Элемтәнең теге очында карчыкларга хас тамак төбенә утыртылган тембрлы хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Алло.

— Исәнмесез! Гафу итегез... — дигәч, мин каушадым, сүзне нәрсәдән башларга белмичә тоткарланып тордым.

— Алло, кем бу? — диделәр элемтәнең теге очында.

— Минем исемем Рашат. Сезнең белән очрашырга иде. Мөмкин булырмы икән?

— Кем соң сез? Нинди йомышыгыз төште миңа?

— Минем бер туганым ята психо-неврология диспансерында, — дидем мин. — Сезнең ирегез дә шунда дәвалана.

— Шуннан?

— Миңа сезнең белән кичекмәстән очрашырга кирәк.

Телефон шактый вакыт дәшми торды.

— Сезгә нигә минем белән очрашу? — дип сорады ул, ниһаять.

— Мин сезгә аның хатларын тапшырырга телим.

— Нинди хатларын?

— Аның сезгә язган хатларын.

— Сәгать ничә хәзер?

Мин, сәгатемә карап, вакытны әйттем:

— Дүртенче ярты.

— Сәгать алтыда «Алсу» кафесына килегез.

...Мин, кафега керү белән үк, әллә каян «кычкырып» торган причёскалы чибәр хатынга игътибар иттем. Кафеда шактый кеше бар иде, ә аны бер күрүдә таныдым. Мин килеп исәнләшкәч, ул да аптырамады, каршысындагы утыргычка утырырга ымлады.

Ни гаҗәп, бу яшел күзле, почык борынлы, сап-сары чәчле хатын тулаем алып караганда гына чибәр икән, җентекләп күзәтә торгач, аның төс-битендәге чалымнар, сызыклар, төсмерләр һич тә күз карашын иркәли дип әйтерлек түгел иде. Читтәнрәк караганда тулы, кызыл булып торган иреннәре дә калын итеп буялганнан гына икән. Урта буйлы, блузкасын тырпайтып торган олы күкрәкле бу хатынның нәрсәсе ясалма, нәрсәсе табигый икәнне тиз генә аңларлык түгел иде. Зәп-зәңгәр күзләре дә курчакныкы шикелле иде аның. Ә инде күрү белән үзенә тартып торган ниндидер серле гүзәллеге каян, кай төшеннән чыга — бу һичкайчан чишелмәслек табышмактыр, мөгаен. Дөресен әйтергә кирәк, ир-ат кызыга торган, күпләрне гашыйк итә торган зат иде бу. Гәрчә тавышы кыяфәтенә тәңгәл килмәслек дәрәҗәдә салкын һәм әбиләрнекенә охшап ярык такта кискәндәге авазны хәтерләтсә дә.

Кофе эчә-эчә, ул минем сүз башлаганны көтеп утырды. Мин, официантка бер чәйгүн чәй китерергә кушып, кесәмнән Туктар язган хатларның ксерокопияләрен Клара алдына куйдым. Ул шактый вакыт хатларга кагылмыйча утырды, башын читкә борып уйга калды. Аннары калтыранган кулы белән беренче хатны алды — мин конвертларга, кайсы артыннан кайсын укырга икәнне белер өчен, номерлар язган идем.

Хатның беренчесен укыганда ук, аның бите буйлап күз яше тәгәрәп төште.

Хатларның жидесен дә укып чыгуына шикләнгән идем, ләкин ул үзен кулга алды, укып чыкты.

— Ничек ул анда? — диде Клара, кульяулыгы белән күз яшьләрен сөртеп.

— Анда ничек булалар инде... Ята шунда. Дару эчертәләр, укол кадыйлар, — дидем мин.

— Сезнең үзегезнең кемегез ята анда?

— Хатынымның ерак туганы, — дип алдадым мин.

— Ир кешеме, хатын-кызмы? — дип кызыксынды ул никтер.

Мин, бер мәлгә югалып торганнан соң:

— Ир кеше... Олы яшьтә инде, — диген булдым. Һәм шундук үземнең төп соравымны бирдем: — Сез нишләп Туктар янына килмисез?

Ул минем соравыма һич кенә дә аптырамады:

— Анда баруымнан ни файда, аңа да, миңа да? — диде. — Аның ниләр әйтәсен алдан ук беләм мин. Барсам, нинди әңгәмә буласы алдан билгеле. — Ул авыр сулап, башын чайкады. — Белсәгез иде аның, көнләшеп, үзен дә, мине дә ничек бимазалаганын.

— Аңа бик авыр... — дидем мин, бу хатынның ихласлыгы ни дәрәҗәдә икәнне анлар өчен, аны җентекләп күзәтеп.

— Ә миңа? — дип тавышын күтәрде ул. — Көнче кеше белән яшәүдән дә авыррак нәрсә бар икән?

— И, дөньяда әллә нинди кайгылар, әллә нинди газаплар бар, — дидем мин, чәемне йотып куйгач.

— Юкка көнләшеп, минут саен төпченеп... Алай яшәп булмый.

— Анда ятып ул үзгәрмәячәк, — дидем мин.

— Ул үзе теләде дәваланырга. Ул анда үз теләге белән ятты.

— Беләм. Ләкин көнләшүдән дәвалап була микән соң?

Клара, уйга калып:

— Юктыр, мөгаен, — диде. Аннары өстәлдәге хатларга беравык карап торганнан соң: — Бу хатларны кем бирде сезгә? — дип сорады.

Мин ни әйтергә белми тордым.

— Туктар үзе бирде, — дип ялганлыйсы иттем. — Ул җиде хат язган, берсенә дә җавап килмәгән. Бәлки хатлар барып җитмәгәндер дип, ксерокопияләрен ясатып алып килдем.

Клара миңа ышанмыйча, куркып карап торды. Аның күңеленә шом керде.

— Сез кайдан? — диде ул калтыравык тавыш белән.

— Ничек инде кайдан? Тумышым беләнме?

Кларaның күзләрендә чын курку чагылды.

— Сез каян?.. Кайда эшлисез диюем?..

— Төзүче мин. «Радуга» төзү фирмасында эшлим.

Ул шактый икеләнеп миңа карап торганнан соң, ниһаять:

— Мин аңа җавап язармын, — диде.

— Хатлар язышып ятудан мәгънә юк, — дидем мин. тавышымдагы ачуны тыя алмыйча. — Сез үзегез аның янына барыгыз. Сез анда барырга тиеш.

— Мин анда барсам, тагын көнләшеп, төпченеп, җелегемне суырачак, — диде ул еламсырак тавыш белән.

Мин дорфалыгымны йөгәнли алмыйча, әйтеп ташладым:

— Көнләшергә сәбәп булмаса, алай чирлегә сабыша-сабыша көнләшер идеме икән ул?!

Мин җикереп сөйләшергә тиеш түгеллегемне аңлап, үземне шундук тынычландырдым һәм:

— Көнләшүе шул дәрәҗәдә булгач, сезгә барып, аның белән сөйләшеп, чак кына булса да хәлен җиңеләйтү турында уйларга кирәк, — дидем. — Ярты сәгать әңгәмә эчендә аның көнләшүеннән әллә ни авырлык тоймас идегез әле.

Клараның йөзе агарганы макияж астыннан да күренде, хәтта күзләренең төсе үзгәрде шикелле. Ул күзләрен йомды һәм, иреннәрен юкартып:

— Мин аны күралмыйм! — диде. Аннары күзләрен ачып, чак кына алга иеленкерәп, минем күзләремә карады. — Сезнең җаныгыз бизгән кеше белән яшәп караганыгыз бармы?

— Юк, — дидем мин һәм, аның күз карашындагы коточкыч нәфрәтне күрмәс өчен, кафедан чыгып йөгерердәй булдым.

— Шулай булгач, миңа акыл өйрәтеп утырмагыз! — диде ул тыныч, ләкин усал тавыш белән.

Ул урыныннан сикереп торды да, үтеп барышлый официантка кофе өчен акча түләп, кафедан чыгып китте.

13

Мин әле отпускыда идем, йокыдан унберенче яртыда гына тордым. Хатын эштә, балалар авылда әбиләрендә кунакта иде.

Кафилнең машинасы йортыбыз каршына килеп туктагач, мин аптырамадым, әмма аның атлавыннан, хәрәкәтләреннән киеренкелекне әллә каян күреп, мин аңладым — кунакка түгел, теге хатлар турында сөйләшергә килгән бу.

Һәм ялгышмаганмын. Коры гына күрешкәннән соң, ул, чәйдән баш тартып, килүенең сәбәбен әйтеп салды.

— Син кичә миндә ятучы пациентның хатыны белән очрашкансың икән.

— Әйе, мин аның хатыны Клара белән очрашып сөйләштем, — дидем мин, тавышымны аның тонында чыгарып. — Минем сезнең пациентка ярдәм итәсем килде.

— Ничек ярдәм италасың син аңа? — дип текәлде миңа Кафил.

— Ул кешенең киләчәге мине борчый.

— Армиядә дә син нечкә күңелле идең. Аңлыйм мин сине. Үземнең дә үзәкләрем өзелә кайвакыт. Нишлисең бит — Ходай биргән авыру инде.

— Ә ул чирлегә бөтенләй охшамаган.

— Хатыны аның янына килмәсә яхшырак булыр. Мин — врач, мин яхшырак беләм.

— Хатыны белән сөйләш. Туктарның хатларын да тапшырырга тиеш син аңа, — дидем мин һәм сынаулы караш белән Кафилнең йөзенә туры карадым.

— Тапшыргансың бит инде, — диде Кафил усал тавыш белән. — Ничек кенә булмасын, диагноз куелган инде, аны дәваларга да дәваларга кирәк хәзер.

— Көнләшүдән дәвалап туктатмакчы буласыңмыни?

— Анда синең эшең юк! Син ник болай борчыласың? Ул синең туганың түгел...

— Анда пациентлар арасында берсе дә синең туганың түгелдер, әмма син аларның барысы өчен дә борчылырга тиеш, шулай бит? Ул башкаларга охшамаган, кызыклы шәхес... Гадәттә, психик авыру кеше үзен авыру дип санамый һәм диагнозы белән килешми, шулаймы?

— Әйе, гадәттә шулай.

— Ә Туктар үзе дәваланырга тели. Бу факт сине сагайтмыймы?

— Психик авыруларның зиһене кайвакыт нормаль кешеләрнекеннән югарырактыр шикелле тоела — көтелмәгән фикерләр әйтүләре, әллә нинди таң калырлык тәкъдимнәр уйлап чыгарулары белән. Ләкин бу гына әле сәламәтлек билгесе түгел. Туктар үзен җүләр түгел дисә, аны барыбер җүләр диячәкләр,

шуна күрә ул үз теләгем белән кердем, ди. Үзен җүләр түгел дип уйласыннар өчен — шулай ике катлы иттереп алдамакчы була.

— Кемне?

Кафил миңа көлемсерәп карап торды да:

— Үзен, — диде.

Нык кайнарланган иде Кафил. Аңардан эсселек бөркелеп тора иде. Ул саубуллашып та тормыйча чыгып китте.

Кафилнең күзләре куркыныч иде бүген. Ул чыгып киткәч, мине бер уй сискәндереп куйды — армиядәге дустыма охшамаган бит бу. Шулмы соң ул? Аралар якын түгел бит безнең. Күңел никтер шомлана башлады. Нәрсә булды миңа? Кафилгә нәрсә булды? Бөтен нәрсә үз урынында кебек. Гаиләләребез исән-имин, үзебез сау-сәламәтләр. Аралар бозылды сыман... Туктар исемле пациент язмышы өчен борчылуым — ул бит инде Кафилнең эшенә тыгылу дигән сүз. Аны аңлап була.

Шулай да мин инде катгый рәвештә Туктарның язмышында катнашырга тиеш дигән карарга килдем. Монда нәрсәдер эшләргә кирәк. Алга таба да дәвалап кешене харап итүләре ихтимал бит. Моннан чыгарырга кирәк аны, мин бит күрәм, мин табиб түгел, ләкин аермачык күрәм, иманым камил, аны моннан азат итәргә кирәк. Әлбәттә, Туктарга Клара сине яратмый дип аңлату мәслихәт. Фәкать шуны гына аңлау кирәк Туктарга. Югыйсә монда тупыйк килеп чыга. Алар бергә яши алмаячаклар. Дәвалаудан да мәгънә юк. Ник дәвалыйсың аны, нәрсәдән?..

## 14

Туктарның язмышы, аның киләчәге мине ныгытып борчый башлады. Кафил хатларның ксерокопиясен кем ясаганны, әлбәттә, аңлагандыр. Ризаләгә эләккәндер инде моның өчен дип тә кайгыра башладым.

Мине Туктарның язмышы шулкадәр үзенә алып кереп китте, хәтта Кафилнең яшьлек дустым икәнен дә, гаиләләребез белән дустанә мөнәсәбәтләрдә икәнебезне дә оныттым. Кафилгә дустыма караган кебек карамый башлавымны сиздем. Югыйсә, аның гаебе юк. Пациентка диагноз куелган, диагнозны комиссия раслаган, дәваланырга теләк бар...

Стоп! Аның дәваланырга теләге бар. Тагын кем тели аның дәвалануын? Диспансерга беренче тапкыр килгәч үк, Кафилнең пациентларга мөгамәләсен күреп гаҗәпкә калган идем. Ул аларның һәрберсенең диагнозын, хәлен белә, әмма һәрберсе белән һәрвакыт салкын, коры һәм еш кына илтифатсыз аралаша иде.

Мин диспансерга киттем. Баш табиб барысын да кинәшмәгә җыйган. Коридорда эленке-салынкы авырулар йөри. Буфеттан коридорга аш исе чыккан.

Коридордан кызу-кызу атлап барганда каршыма очраган сестра, халатсызнисез ят кешенең йөрүен өнәмичә, артымнан усал итеп карап калды. Палатага кереп, Туктарга сүз әйтергә дә ирек бирмәдем, җиңеннән тотып коридорга алып чыктым. Палатадагы күршеләре, әле генә ясалган уколлар тәэсирендәдер инде, берни аңламый карап калдылар.

— Син нишләп үзең теләп монда кереп яттың? — дидем мин, аны коридорның аулак очына алып китеп.

Туктар бер карусыз сөйләргә тотынды, шул бер үк сүзләрне кабатлаудан тәм дә таба иде бугай ул:

— Үзем теләп дип... Клара врачларны өйгә чакырды да, мин каршы килмәдем. Чөнки үзем дә туйдым... Кларалы Эдик машина белән китереп куйгач, аны үтерү теләге туды.

— Кемне?

— Кларалы. Мин аңа турыдан-туры әйттем: үтерәм сине, дидем.

— Димәк, хатынының сиңа хыянәт итүен тәгаен беләсең?

— Минем монда ышанасым килми, — диде Туктар сыктанулы тавыш белән.

— Монда ятып, уколлар кабул иткәч, ышанмый башлармын дип уйлыйсынмы? — дип кызып киттем мин. Ә син беләсенме, көнләшү ничек карасаң да мәгънәсез. Әгәр хатынын хыянәт итә икән, син бернишли алмыйсын, көнләшүдән файда юк. Әгәр дә ул сина хыянәт итми икән, көнләшүдән бөтенләй мәгънә юк. Шушы ике варианттан башка очрак булалмый. Икесендә дә көнләшү мәгънәсез. Димәк, көнләшүдән беркайчан файда юк. Монысы сина киләчәк өчен. Син бүгеннән Клара синеке тугеллекне анларга тиеш. Күңеленнән иң ачык, иң чиста урыннарына төкергән кешене яратырга мөмкинме соң — шуны уйла әле син!

— Сез нишләп мина кычкырасыз? — дип жикерде ул.

— Гафу ит, мин синең кеше булып калуыңны телим, — дидем мин, тавышымны йомшартып. — Яшәү дигән бөек төшенчә бар. Анда барысы да кирә — мәхәббәте дә, хыянәте дә, шатлыгы да, кайгысы да. Шулкадәр кызык, рәхәт, күпкырлы яшәү дигән бөек халәт. Анардан мәхрүм булу, яшәүне тәмуг газабына әйләндерү — үз-үзен алдында жинаять. Дөньядагы барлык чибәр хатыннарны жыйсаң да, синең гомереңнең бер минут бәһасенә тормый алар. Анаң яки кызың булса, башка нәрсә... Мин иртәгә төштән соң килермен. Ачуланма мина, Туктар. Кеше ихтыярына буйсыну һәрвакыт һәлакәткә илтә. Хатын-кыз бетмәгән дөньяда... Ә гомерен бер генә.

Кинәшмә тәмамланды, ахрысы, бер-бер артлы табиблар, сестралар күренде.

Бер табибтан: «Кафил кайда?» — дип сорагач: «Ул әле баш врачта калды, бер ярты сәгатьтән генә бушар», — диде.

Каяндыр Ризәлә дә килеп чыкты. Ул минем Туктар белән сөйләшеп торуымны күреп сискәнеп куйды.

— Туктар, бар палатана! — диде ул үзенә хас булмаган боерулы тавыш белән.

Туктар берсүзсез буйсынып, үз палатасына элдерде.

— Ник бардыгыз Клара янына? — дип жикерде Ризәлә мина.

Мин дәшмәдем һәм кызу-кызу адымнар белән чыга торган ишеккә таба юнәлдем, ә ул мина ияреп барды.

— Ник тыгыласыз? Сезнең монда ни эшегез бар?! — диде ул, ярсуын көчкә тыеп.

— Гафу ит, Ризәлә, мин Туктарның хатларын хатынына укытмыйча булдыра алмадым.

— Моның өчен мине эшемнән куулары ихтимал, — диде ул, өзгәләнеп.

— Кумаслар. Мин Кафилгә: «Кабинетында үзем генә калгач, шкафыннан ул хатларны алып ксерокстан чыгардым», — диярмен.

— Кирәкми. Мин инде ана үзем алып биргәнне әйттем.

— Гафу ит, Ризәлә, — дидем мин тагын бер тапкыр һәм коридордан чыгып киттем.

## 15

Автосалон директоры Эдуард Нәфыйковичны (Туктар еш телгә алган Эдикны) мин нәкъ шушындыйдыр дип күз алдыма китергән идем. Килеш-килбәте, төс-кыяфәте мин күзаллаганча булып чыкты, әмма шунысы бар: аны мондый яшь кешедер дип уйламаган идем.

Мин аны офисында түгел, машиналар салонында «тоттым». Озын буйлы, кыска итеп алдырган кара куе чәчле, кавказ борынлы бу чибәр егетне актёрга да, илләр арасында йөрүче бизнес-курьерга да охшатырга мөмкин иде. Аның кәчтүме дә дипломатларныкы шикелле затлы иде. Әйе, бу Эдик кына түгел, бу Эдуард Нәфыйкович! Куе тембрлы тавышы белән тәбәнәк буйлы механикка

бармагын селки-селки нәрсәдер тукый иде ул. Ниһаять, механик ул кушканны үтәргә китеп баргач, мин аңа мөрәҗәгать иттем:

— Исәнмесез.

— Исәнмесез, — диде ул һәм, миңа бер генә караш ташлап, офисына менә торган баскычка таба атлады, ә мин аңа иярдем. — Нинди соравыгыз бар?

— Сез мине кабул итмәссез микән?

— Тыңлыйм сезне, — диде ул, туктамыйча.

— Минем сезнең белән бик житди темага иркенләп сөйләшәсем килә, — дидем мин, тавышымны көрәйтеп.

Ул туктап миңа карады:

— Сез кайдан, кем?

— Минем бер туганым психушкада ята... Шунда Туктар исемле кеше белән таныштым. Клара белән дә таныш мин... Минем сезнең белән сөйләшәсем, киңәшләшәсем килә. Бәлки кайберәүләргә сезнең ярдәмегез кирәк булыр...

Ул мине салонның икенче катында урнашкан кабинетына алып менеп китте. Заманча, коры, әмма кыйммәтле җиһазланган кабинетында бер артык әйбере дә юк, һәрбер предмет кул астында һәм кулланышка җайлы итеп оештырылган иде.

Яшь булса да, житди житәкче булып өлгергәнгә охшаган иде бу кеше.

Ул үзенең түрдәге креслосына утырып, миңа бүлмә уртасына сузылган өстәл артындагы утыргычка утырырга тәкъдим итте һәм сүз башлаганымны көтте.

— Гафу итегез, бик күңелсез йомыш белән килдем мин сезгә, — дидем мин. — Сезнең Клара белән мөнәсәбәтләрегез миңа мәгълүм...

— Шуннан? — диде ул, һич кенә дә исе китмичә.

— Аның ире Туктар психодиспансерда ята.

— Беләм.

— Аның янына Кларанын килгәне юк...

— Һәм ул аның янына бармаячак та, — диде ул битараф тавыш белән. — Ә минем монда ни катнашым бар?

— Аның янына бармау — рәхимсезлек, хәтта вәхшилек дип әйтер идем мин... Туктар көнләшеп... Кларанын көнләп, авыруга әйләнгән... Авыру да түгел ул... Бәлки аны дәваларга түгел, берәр ничек тынычландырырга кирәктер.

— Шул тынычландырыр өчен аны психушкага алып киткәннәр бит инде, — диде Эдик ваемсыз гына.

— Туктарга хәзерге вакытта бәлки сезнең сүзегез ярдәм итәр иде.

Ул аптырап миңа карап торганнан соң:

— Нинди сүзем? — диде. — Нишләп мин аңа ярдәм итәргә тиеш? Сез шаярасыздыр?

— Шаярмыйм, — дидем мин, нык каушаганымны сизеп. — Клара турында сөйләгәндә, Туктар сезне еш телгә ала... Әгәр дә сез барып: «Клараң белән минем арада бернәрсә дә юк һәм булмады», — дисәгез дә, күпмедер дәрәҗәдә тынычланыр иде ул, мөгаен.

— Сез ни сөйләгәнегезне аңлыйсызмы? — дип көлеп җибәрде Эдуард Нәфыйкович.

Мин бу егет алдында үземнең мескен хәлдә калганымны тойдым һәм:

— Хәер, аны алай гына коткарып булыр микән... — дип куйдым.

— Мин аңлыйм сезне, — диде Эдуард житди кыяфәт белән. — Сез аның авыр хәлдә икәнен күреп борчыласыз. Ләкин минем барып алай дип әйтүем аларның мөнәсәбәтләрен яхшыртмаячак, Туктарның да хәлен җиңеләйтмәячәк. Сез ничек күз алдыгызга китерәсез минем аның янына психушкага барып керүемне? Клара белән мин араларны инде моннан ике ай элек өздем. Әйе,

роман булып алды. Кайнар ул, дәртле, бигүк яшь булмаса да. Дөрләп янып алды безнең мәхәббәт. Туйдым мин анардан. Ә ул, иреннән котылгач, мәңге минем белән булырмын дип хыялланган иде. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә ана әллә ниләр вәгъдә иткән идем... Урын өстендә... андый вакытта вәгъдәләр күп бирелә бит инде ул.

— Сез аны ташладыгызмы? — дип сорарга җөрьәт иттем мин.

Эдик ихластан җавап бирде:

— Мин яшь кызга гашыйк булдым. Шушы арада өйләнешергә җыенабыз. Миңа егерме сигез яшь, инде өйләнер вакыт җитте.

— Алай икән... Димәк, сезнең Клара белән элемтәләр юк инде?

— Юк.

— Ире янына килеп китсә, ни булган инде, — дидем мин. — Алга таба икесе өчен дә яхшырак булачак — бергә торсалар да, аерылышсалар да. Туктар анда хатлар язып ята... Мин бит Клара белән очраштым. Туктар язган хатларның ксерокопияләрен укыттым. Клара хатларны укыганда елады.

— Куркудан елаган ул. Һәм үзен кызганудан, — диде Эдик, көлемсерәп. — Хатларның ксерокопияләрен күргәч, әллә ниләр уйлагандыр, хокук саклау органнары тотынганнар мәллә дип курыккандыр. Клара үзен бәхетсез дип бөтен дөньяны каргап ята. Ана һаман кирәк тә кирәк. Кирәкнең аның чиге юк бит. Ул үзенең эгоизмы артыннан беркемне, бернәрсәне күрергә, санларга теләми — аңа гына рәхәт булсын, аңа гына барысы буйсынырга тиеш, аны гына барысы да яратырга тиеш. — Эдикның йөзе усал төс алды. — Кара эчле хатын ул. Мин аның эчке пычрагын тоеп таң калдым. Андый стерваны минем әле моңарчы күргәнем юк иде. Ярый котылдым әле анардан.

— Туктар гел сезне телгә ала, шуңа килдем мин монда.

— Аның Клара белән мине бергә күргәне булгандыр да минем кем икәнне, кайда эшләвемне берәр ничек белгәндер. Ә Кларанын башка сөяркәләренең кем, кайда икәнен белмидер. Шуңа күрә мине күбрәк телгә аладыр.

— Бәлки.

— Араларны өзгәч, Кларанын миңа ничек янаганын белсәгез иде сез, — диде Эдик, усал кыяфәткә кереп. — Хәтта Сиринәне очратып куркытырга маташкан.

— Сиринә кем?

— Минем хәзерге вакыттагы ярым. Булачак тормыш иптәшем. Шуннан соң Кларaны очратып, үзенә бераз «лекция» укырга туры килде.

— Димәк, сез, Туктар янына барып, мин хатынынның сөяркәсе булмадым, дип әйтмәячәксез? — дидем мин, үҗәтләнергә үземдә кыюлык табып.

— Кеше көлдермәгез инде, — диде ул, елмаеп. — Нишләп мин алай йөрергә тиеш?

— Чак кына булса да хәле җиңеләер иде бәлки. Аның хатыны сезнең белән хыянәт иткән бит.

Эдуард Нәфыйкович, креслосында киерелеп, тирән сулыш алды да:

— Ана ул кемнәр белән генә хыянәт итмәде икән! — диде.

— Әйе шул, сез анда барсагыз да, бернәрсә дә яхшы якка үзгәрмәячәк, — дидем мин, аның әйткәннәренә күнеп.

— Ул хатынның нинди дер җене бар, үзенә гашыйк иттерә белә ул, аннары анардан тиз генә ычкынып та булмый, — диде Эдуард, кашларын җыерып. — Мин шактый вакыт аның белән очрашып йөрүемә хәзер гаҗәпләнәм. Миннән унбиш-уналты яшькә олырак булса да, үзенә нык тартты ул. Хәзер котыла алганыма сөенеп туймыйм. Бердәнбер үкенечем — аңа ике йөз мең доллар акча биреп ялгыш эшләдем.

# *100 нче бит: чор, милләт, вазгыять*

## БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ НИК ҮГИ?

**Соңгы вакытта яшь буынны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү турында аеруча күп сөйлиләр һәм язалар. Ләкин ватанны ярату хисе үгет-нәсихәт белән дә, төрледән-төрле директивалар ярдәмендә дә тәрбияләнә алмый торгандыр. Бу вазифаны бездә гомер-гомергә нәфис әдәбият башкарып килде. Балалар өчен иҗат ителгән бәян-хикәяләр, шигырь-поэмалар яшь буынны үз ана telendә матур итеп сөйләшергә дә, язарга да, образлы итеп фикерләргә дә өйрәтә.**

**Мин үзем малай чакта, йөз меңләгән яшьтәшләрем кебек үк, «Ялкын» журналын һәм «Яшь ленинчы» газитен (хәзерге «Сабантуй» журналы!) укып үстем. Әгәр алар үзләренең төп вазифалары саналган октябрят, пионерлар тормышы турында гына язып матавыкланса, мин, ихтимал, әлеге басмаларны алай ук көтеп тә алмас идем. Иң кыйммәте — «Ялкын»да да, «Яшь ленинчы»да да язучыларыбызның повесть-хикәяләре, шагыйрьләребезнең көлтә-көлтә шигырьләре басылып чыга иде. Белмим, ул чакта аларны укудан да ләззәтлерәк куаныч булды микән? Булса да — шул үзең гыйшык тоткан классташ кызыңның илтифатлырак күз карашын искәреп калу гына булгандыр инде...**

**Ни аяныч, бүген көндәлек матбугатта балалар әдәбияты дигән мөкатдәс бер жанр безнең күз алдында җан тәслим кылып ята. Татар балалары өчен язылган әдәби әсәрләрне хәзер бер басма да кирәксенми бугай.**

**Дөресен әйткәндә, бүген балалар әдәбиятына хаерхаһ булган бердәнбер мәркәз — ул Татарстан китап нәшрияты. 100 яшен тутырып килгән нәшриятыбыз яшь буынны әлгәрләребезнең күркәм традицияләре үрнәгендә тәрбия кылуда гаилә һәм мәктәпнең иң зур таянычы, ярдәмчесе булып торды, һәм әлеге вазифаны хәзер дә лаеклы рәвештә башкарырга омтыла. Гәрчә, без бүген балаларның китапны чагыштырмача аз укуы яки бөтенләй укымавы турында әледән-әле искәртергә яратсак та, чынлыкта хәлләр башкачарак тора. Шөкер, әлегә бездә балалар һәм яшүсмерләргә атап чыгарылган әдәби китапларга — һәм чәчмә, һәм тезмә әсәрләргә — ихтыяҗ гаять зурдан. Әйтик, нәшрият ел саен уртача 5-10 мең тираж белән 25-30 исемдә балалар китабы бастырып чыгара һәм алар тиз арада сатылып та бетә икән. Дөрес, бу өлкәдә шактый җитди проблемалар да бар, ди нәширләр. Мәсәлән, хәзер яшь укучыларыбызга тәгаенләнгән югары сыйфатлы, заманча әсәрләргә зур кытлык күзәтелә. Сәбәбе дә аңлашыла кебек: балалар матбугаты балалар әдәбиятын кирәксенми, ә бер китап нәшриятына гына күз текәп тору иҗат дәртенә дәрман өстәмәскә дә мөмкин. Ә бит элеккерәк чорларда бездә махсус балалар өчен генә язган дистәләгән каләм әһелләре, аның үз корифейлары да бар иде. Бари Рәхмәт, Дәрҗия Аппакова, Зәкия Туфайлова, Әминә Бикчәнтәева, Ләбибә Ихсанова, Хәкимҗан Халиков, Шәүкәт Галиев... Балаларның ничә буынына тел ачкычы биргән, күпме нарасыйларны ана теле бишегендә тибрәткән тәрбиячеләр дә, мөгаллим-мөгаллимәләр дә булган алар. Хәзерге гайре табигый шартларда да балаларыбыз өчен яхшы әсәрләр иҗат итү татар язучысының намус эше саналырга тиештер. Заманында бу вазифаның үтә дә мөһимлеген аңлап Г. Тукай да, Дәрдемәнд тә, Һ.Такташ та, Г.Ибраһимов та, М.Җәлил дә, Ф.Кәрим дә, Х.Туфан да, Т.Миңнуллин да язган. Алар үрнәгендә, бәлки, безнең балалар матбугаты да балалар әдәбиятына йөз белән борылыр.**

**Газинур МОРАТ**

— Гафу итегез, нәрсә өчен бирдегез ана ул кадәр акча? — дип сорадым мин.

Акча турында сүз чыккач, Эдуард Нәфыйковичның йөзе тартылып китте шикелле.

— Ул аны әҗәткә дигән булып алды инде. Биш айдан бирермен дип. Ә үзе, хәйләкәр хатын, без киләчәктә барыбер бергә яшәрбез, бу ике йөз мең доллар тора-бара бурыч булмас дип уйлагандыр. Мин инде әллә ничә тапкыр шалтыратып, әҗәте турында сүз кузгаттым, янына да барып карадым, әмма акчаны миңа бирергә уйламый да. Расписка яздырмаган идем шул... — Ул кыжрап, йодрыкларын төйнәде. — Мин барыбер алам анардан ул акчаны! — Аннары беркавым дәшми карап торды. — Әллә нинди серләремне ачып ташладым инде сезгә...

— Ике йөз мең ник кирәк булган соң ана? — дип кызыксындым мин.

Эдик миңа текәлеп карады. Аннары башын читкә борып, шактый вакыт уйланып торды.

— Дөресен әйтимме? — диде ул кинәт.

— Әйтегез.

— Ул ике йөз мең доллар ирен психушкага ябып, мәңгегә шунда яткырырга кирәк булган.

— Сез чын әйтәсезме? — дидем мин, аның сүзләренә ышанасым килмичә.

— Ә ник кирәк миңа мондый коточкыч ялган? Ул үзе миңа исерек баштан сөйләп ташлады. Беркөнне рестораннан кайтып, постельдә ятканда, мин аңа: «Бергә яши башласак, Туктарың артыннан йөреп йөдәтәчәк», — дигәнием, ул миңа: «Туктар тора-бара бөтенләй йөрми торган булачак», — дип җавап бирде. Мин өнсез калдым. «Бер ел психушкада ятса, аңы томалана аның», — дип өстәде ул. Туктарны психушкага ябып котылыр өчен миннән акча алганын шунда әйтте дә куйды. Ай-яй, вәхши хатын! Иргә хыянәт итүне ничек тә аңларга була, ә менә бу гамәле... акылыма сыймый.

Бу сүзләрне ул ихластан әйтте.

Мин шактый вакыт телсез калып тордым.

— Туктарны психушкага яткырмыйча да иреккә ирешергә мөмкин булгандыр бит ана, — дидем мин, тетрәнеп.

Эдик миңа тыныч кына аңлатырга кереште:

— Монда бит комсызлык та бар әле. Клара белән Туктар төзегән коттедж ярты миллион доллар торадыр. Шул сәбәпле дә Клара Туктардан котылырга теләде. Бетте-китте, Туктарның кирәге калмады ана. — Ул усал иттереп көлеп куйды. — Ха-ха, ксерокстан чыккан хатларны күргәч, әлләниләр уйлагандыр ул — хокук саклау органнары тотындылармы икән әллә дип астына җибәргәндер.

— Коточкыч бит, ә, кеше язмышы, җан газабы, мәхәббәт фонында — акча, мал, коттедж өскә калка... — дидем мин. — Акчаны кемгә түләгән соң ул?

— Каян белим мин, — диде Эдик.

— Акчаны ни өчен алганын сез белә идегезме?

— Алган чакта белми идем. Ниндидер недвижимость алып куярга телим, дип алдады. Аннары тотты да исерек баштан дөресен әйтеп ташлады.

— Акча түләгәч, Туктарны мәңге чыгармаслар дип ышанды микәнни ул?

— Психушкада озаграк яткыргач, тулы кеше дә тора-бара иләсләнә бит ул. Аннары психушкадан чыкса да, аны алдап, төрле ялган документларга кул куйдырып була. Алдарга җайлы була андый кешене. Ире психбольной дип танылгач, развод ясавы да җиңел, мал-мөлкәтне бүлү дә унай, урам эте урынына читкә тибәргә дә мөмкин.

## 16

Эдикның автосалоныннан чыккач, әле яңа гына булган әңгәмә тәэсирендә кайсы якка барырга икәнне онытып исәңгерәп тордым. Менә нигә жаным тынгысызланган икән Туктарны күргәч. Хатларын укыгач, бигрәк тә күңелем дөрес сизенгән, дөрес аңлаганмын, дөрес күргәнмен икән бит — ул анда ятарга тиеш түгел!

Мин туп-туры Кафил янына юл алдым.

Кабинетының ишеге кысып кына ачылган килеш тора иде, шакымыйча гына кереп киттем.

Болай шат булып күренсә дә, аның күзләрендә усаллык шәйләдем.

— Ничек хәлләр? — диде ул, күрешкәндә кулымны жибәрми торып. Психиатр буларак, ул кеше белән күрешкәндә, аның халәтен чамалый иде. Бу юлысы да минем эчке киеренкелекне тойгандыр, әлбәттә.

— Ярыйсы. Үзең ничек? — дигән булдым мин, каршысындагы урындыкка утырып.

— Үзем турында уйларга вакыт юк, — диде ул, чыраен жыерып. — Дуамаллар бүлегендә тагын сугышканнар. Көчкә тыйдык.

— Тынычландыlармы соң?

— Тынычланмый... Минем санитарлар арысланны да бөгеп сыгарлар. Аннары хәзер бит шәп, яңа төрле көчле уколларыбыз бар...

Ризәлә кабинетка кереп, кабалана-кабалана киштәдән нәрсәдер эзләргә тотынды. Ул бүген караңгы йөзле иде, минем белән хәтта исәнләшмәде дә. Минем моңа хәтерем калмады — эш кешесе бит ул. Аннары, минем башымда Эдикның сөйләгәннәре гүләп тора иде.

— Минем янга килденме, әллә Туктар исемле пациентны күрәсең киләме? — дип сорады Кафил көтмәгәндә.

Аның бу соравыннан Ризәлә дә, эшеннән туктап, әле аңа, әле миңа карап куйды.

— Аңламадым? — дидем мин.

Ризәлә, кирәкле папканы табып, тиз генә чыгып китте.

— Шул аңламаганга күрә хатларны алып аның хатыны янына киткәнсең дә инде син, — диде Кафил усал тавыш белән.

Аның минем белән беркайчан да мондый тонда сөйләшкәне юк иде.

— Ризәләне, зинһар, ачуланма. Мин аңа Туктарның хатларын беркемгә дә күрсәтмәскә вәгъдә биргән идем. Сүземдә тормадым, гаебемне таныйм.

— Туктарның язмышы мине борчымый дип уйлыйсыңмы әллә? — диде Кафил, кайнарланып. — Аның хатларын хатынына жибәрмичә үземдә яткыруның миңа ник кирәге бар?

— Менә мин дә шуңа аптырадым әле, — дидем мин, батыраеп.

Кафил миңа чәнчүле караш белән:

— Әллә монда эшкә керәсеңме? — диде. — Башта санитар булып, аннары читтән торып медучилище тәмамларсың, медбрат булырсың, читтән торып институтны тәмамларсың — раз сине монда тарта!

Мин аның нәфрәтле йөзен күрмәс өчен читкә карап:

— Кеше яши-яши нык үзгәрә икән ул, — дидем.

— Дөнья үзгәреп, син үзгәрми торырсыңмыни, — диде ул, өстәл тартмаларын бер-бер артлы ачып.

Эдик белән сөйләшкәннәрне житкерәсем килеп, көчкә тыелып утырдым. Мине бер уй котсыз калдырды — яшьлек дустым Кафил шулай түбән төшәргә мөмкинме икән?

— Синең отпускыңның да рәте булмады бит шушы Туктар өчен кайгырып, — диде ул, урыныннан кузгалып.

— Әйе, отпускым үтеп китте инде минем, — дип көрсенеп куйдым мин.

Ул, тәрәзәдән карап торганнан соң, мина таба борылып:

— Яши-яши кеше нык үзгәрәмени? — диде. — Син хаклы түгел. Кеше холкының төп сыйфатлары шул ук кала, фәкать вакытына күрә төрлечә чагыла, төрлечә кулланыла. Син бит, яшь чактагы Рашат булмасаң да, армиядәге шикелле юкка борчылучан, башкалар өчен кайгыручан, гаделлек эстәүчән булып калгансың. Син бит хәтта призывтагы дусларыңны «салагаларны» җәберләүдә гаепли идең.

Мин дә тавышымны көчәйттем:

— Ә син, җегәрлегеңнән файдаланып, яшьләрне мыскыл итәргә махир идең. Каты кеше идең син яшь чакта ук, хәзер исә күзләреңдә нәфрәтне элеккегә караганда ешрак күрәм.

— Эшемнең спецификасы шундый минем, — дип урынына килеп утырды ул. — Монда шәфкать туташының психологиясе белән булмый, монда педагогика белән дә берништә алмыйсың. Монда кичеп чыккысыз фаҗигагә дучар булган кешеләр ята. Аларны кайвакыт ничек дәваларга белмисең. Аның заманы да бит тыныч түгел — тоташ психозлы атмосфера, сәламәт дип саналган кешеләрнең дә пациент булырлыклары күп.

— Пациентлар арасында, нормаль кешеләргә караганда, акыллыраклары бар, шулаймы?

— Син беләсеңдер инде, — диде Кафил, көлемсерәп. — Соңгы вакытта махсус китаплар укыдым, дисең бит.

Утырган урынымнан торып, ишеккә таба юнәлдем.

— Син минә заман турында, кешеләр турында әйттең, — дидем мин, туктап. — Кешелеклелек заманга карамый ул. Игелеклелек кайсы заманда да шул ук. Ә минә заманына күрә андый изге төшенчәләрне инкарь итү, оныту үзен акыллы дип санаучылар арасында бихисап.

— Син талчыктың соңгы вакытта, — диде Кафил, мине озатырга дип урыныннан торып. — Әйдә, мин сиңа витаминнар кадыйм. Тынычландыра торган дарулар бирәм.

— Минем синең пациентың буласым килми, служак! — дип жикергәнемне сизми дә калдым.

— Син нишләп минем белән дорфа сөйләшә башладың? — диде Кафил, гаҗәпләнеп.

— Гафу ит, — дидем мин, шундук үземне кулга алып. — Бик еш кызып китә башлаганымны үзем дә сизәм.

— Шкафымнан кеше хатларын алып укыганыңа, әлбәттә, ачуым килгән иде... Алай ярамый. Син миңа үпкәләргә тиеш түгел... — Минем дәшмәвемнән файдаланып, ул: — Галия ничек, балалар сау-сәламәтләрдер бит? — дип сорап куйды.

— Аллага шөкер! —дидем мин һәм чыгып киттем.

Аякларым үзләреннән-үзләре дүртенче палатага таба алып киттеләр.

Палатада ятучыларның дүртесе дә йоклый иде. Туктарны уятырга тотындым. Ул күзләрен ачты һәм шуны гына көткәндәй сикереп торды. Мин карават читенә утырдым. Ул башта мине танымый торды, ахрысы, аннары, ниһаять, таныды һәм өзек-өзек итеп аңлатырга тотынды:

— Көнләшүдән арынасым килде... Минем аны үтерергә теләгем дә булгалады... Башта Клара психушкадан врач чакыртты... Врачлар стационарга ятарга кирәк, диделәр... Чөнки үземә дә авыр, Кларага да...

— Син авыру түгел, Туктар. Сиңа моннан ычкынырга кирәк. Дарулар, уколлар белән чын тиле ясамасыннар өчен, качарга кирәк сиңа моннан.

— Ә кая кача алам мин? — диде ул, ачынып.

— Мин сине моннан барыбер коткарам! — Ул тормакчы булды. — Ят, ят, мин үтеп барышлый гына кердем.

Ул команда тынлагандай сузылып чалкан ятты. Шунда мин аның чыраеның тагы да ныграк саргайганын абайладым.

Мин тиз генә палатадан чыгып киттем, чөнки миңа, саф һавада уйланып, алга таба нишләргә икәнне хәл итәргә кирәк иде.

Инде урамга чыккач, артымнан Ризәләнең тавышы ишетелде:

— Рашат!

Ул мине куып житте.

— Тыңлыйм, Ризәлә, — дидем мин, туктап.

Анын күзләрендә курку иде.

— Ник бардыгыз аның хатыны янына?

— Ә ник бирдең соң ул хатларны миңа? — дип сорауга сорау белән җавап бирдем һәм җавабымның мәгънәсез килеп чыкканын шундук аңладым.

— Эш вакытым тәмамлангач очрашыйк әле... — диде ул көтмәгәндә.

— Сәгать ничәдә?

— Җидедә. Гагарин урамы, 23 йорт. Бу минем адресым.

— Фатирыңның номеры?

— Шәхси сектор ул. Мин үз йортым белән яшим. Моннан ерак түгел, Яшьлек урамы тәмамлангач, трасса башлана, юлның сул ягында кирпеч йортлар тезелеп киткән.

— Табармын, — дидем мин.

— Җидедә шунда кил.

— Ярар.

## 17

Бер катлы кирпеч йортның верандасында гөлләр күп иде.

— Дүрт бүлмәле йортымда җәй көне бу минем иң яраткан урыным, — диде Ризәлә, чәйнекне алып килеп, түгәрәк өстәлгә китереп куйгач. Минем кулларым белән өстәлнең кырыйларын сыпырып утырганны күреп, ул елмайды:

— Әти белән әни бу өстәлне 1975 елны иске промтоварный кибеттән алып кайтканнар иде. Истәлек итеп саклыйм. Мин шушы йортта туып үстем.

Ризәләнең хәле юк иде. Чәй ясагач, ул урындыкка утырып, күзләрен йомды.

— Белсәң иде ничек туйганымны... — дип ыңгырашып куйды ул.

— Кемнән, нәрсәдән?

— Барысыннан да, бөтен нәрсәдән дә. Врачлардан да, чирлеләрдән дә, диспансердан да, йорт эшләреннән дә, миңа өйләнергә йөргән сөяркәмнән дә, хәтта үземнән дә. Улымны гына үстереп аякка бастырырга иде.

— Кайда соң әле ул?

— Чаллыга туганнан туган апама кунакка китте. Аның малайларын бик якын итә.

— Ризәлә, иртәгә килимме әллә? — дидем мин, аның халәтен күреп. — Син бүген бик арыгансың.

— Юк, юк, кичектерергә ярамый, — диде ул, җанланып. — Кафил белән бу шәһәрдә очрашуың да, аның янына диспансерга килүең дә бик яхшы булды... Алла шулай кушкандыр.

— Мин сине әлегә аңламыйм.

— Син бик сизгер, үткен күзле кеше, ахрысы. Туктарны күргәч син нәрсәдер сизендең, монда нинди дер хата, ялгышлык бар икәнне аңладың... — Ул авыз чите белән генә елмайды. — Сине өемә чакыргач, әллә нинди пычрак уйлар килгәндер башыңа, әйеме?

— Юк, Ризәлә, мине монда ник чакырсаң да, синең хакта начар уйларга

хакым юк. Ә синең миңа хатын-кыз буларак ошавынны әйткәнем бар инде. Дөресен әйткәндә, ник чакырганыңны түземсезлек белән беләсем килә.

— Ашыктырма, яме. — Ул тирән сулап куйды. — Мин менә-менә иргә чыгарга торам... Мин сине йокларга дип чакырмадым... — Ул тагын күзләрен йомды һәм шул килеш дәвам итте: — Минем хәлем бик начар әле... Киләчәгем өчен, дөресрәге, улымның киләчәге өчен куркам... Бик зур гөнаһым бар бит минем... Сиңа бер коточкыч серемне ачарга телим. Туктарның көннән-көн шәлперәеп барганын күрәсең инде син...

— Сез аңа нинди уколлар кадыйсыз? — дип кызыксындым мин.

— Анысы сиңа нигә инде, — диде ул.

Кинәт Ризәлә сулкылдый-сулкылдый еларга тотынды:

— Ничек яшәрмен мин бу гөнаһ белән? Яши алмам мин. Нишләргә?

— Сөйлә миңа, тынычланачаксың, җиңеллек тоячаксың.

— Клара бу көннәрдә инде әллә ничә тапкыр Кафил янына килеп китте, — диде ул, өстәлдәге салфетка белән күз яшьләрен сөртеп. — Бүген дә килде. Әмма ире янына бер тапкыр да кермәде. Белсәң иде Туктарны ничек кызганганымны. Мин инде аңа билгеләнгән кайбер даруларны бирмим, яшерәм, уколларны да дүрт урынына икене генә кадыйм.

— Димәк, ул чирле түгел?

— Чирле түгел дип... Дәваланырга кирәктер инде... Ой, гөнаһ инде бу, гөнаһ, нишләргә дә белмим...

— Клара ник килгән соң Кафил янына? Иренең хәлен сораштырырга гына түгелдер бит?

— Белмим.

— Ризәлә, дөресен әйт, Туктарны диспансерга ябуны хатыны оештырган бит, шулаймы?

— Шулай бугай.

— Син беләсең, Ризәлә, шулай бугай гына димә, син күбрәк беләсең.

— Аны исбатлау мөмкинме соң? Диагноз куелган. Шул диагнозга хас признакларны күреп була. Норма белән чир арасында төп-төгәл сызык булмаска да мөмкин...

— Туктарның больнискә ятуына үзенең каршы килмәвен ничек аңларга?

— Аңарда астенический психоз. Көнләшкәнгә шундый ул дип әйтеп булмый, шундый булганга көнләшә дисәң, дөресрәк булыр. Психопатияләр күп төрле. Мин хәтта аларның барысын да яттан хәтерләмим, гәрчә шактый вакыт бу өлкәдә эшләсәм дә. Туктар астеничныйлар, ягъни хәлсезләр төркеменә керә.

Бу төркемдәгеләр йомшак күңел, психик тәэсирләнүчәнлек һәм тиз арыклану белән аерылып тора. Аларга физик һәм психик нагрузкаларны (йөкләнешләрне) күтәрүе авыр, алар кыюсыз, куркак булалар. Һәрвакыт үзләренең фикерләреннән, кылган гамәлләреннән шикләнәләр, икеләнәләр. Карар кабул итү алар өчен һәрвакыт авыр була.

— Димәк, ни дисәң дә, ул авыру кеше, — дидем мин Туктарны яклар өчен Ризәлә сөйләгәннәрдә берниндн тотынырлык урын тапмыйча.

— Авырумы, юкмы, монда хәзер берниндн аерма юк!!! — дип кызып китте Ризәлә. — Мин, гомумән, чирлеләр белән сәламәтләре арасында аерма күрмим. Син диспансерга килеп, аның белән кызыксынгач, хатларын сорап алгач, башта минем эчемә жылы керде. Миңа уртаклашыр кеше кирәк иде... Гаебем зур булганга күрә, үзем генә күтәрә алмаган йөкне күтәрешергә кеше кирәк иде миңа. Ул син булып чыктың.

— Нәрсә турында сөйлисең син? — дидем мин, аның ни әйтергә теләгәнен аңламыйча.

— Ашыктырма. Аннары син мине тикшерергә телисең микән әллә дип курка башлаган идем. Сез Кафил Әхәтович белән якын дуслар идегезме?

Ризалә сизгән инде — без Кафил белән кайчандыр якын дуслар булганбыз, хәзер исә ул якынлык инде юкка чыккан иде.

— Әйе, бик якын дуслар идек, — дидем мин.

— Ә хәзер?

— Озак аралашмый торганнан соң очрашкач, якынлык бар иде, соңгы вакытта әллә ничек, әйтеп булмый торган, нәрсәдер араларны ерагайтырга маташкан сыман.

— Дөресен әйт әле: син Туктарны элек тә белә идеңме?

— Юк, беренче тапкыр мин аны диспансерда күрдем. Ул үзе миңа беренче булып мөрәҗәгать итте.

— Акыллы кеше акыллы кешене әллә каян күрә, таный инде ул.

— Син мине акыллы кешегә саныйсыңмы? — дип сынаулы караш белән карадым мин аңа.

— Син чын кешегә охшагансың, — диде ул, миңа туры карап. — Туктар да чын, дөрес кеше.

— Аны кемдер махсус яптымы диспансерга?

Ризалә минем күзләремнән нидер укырга тырышкан сыман карап торганнан соң:

— Син беләсең, ахрысы... — диде.

— Минем беләсем килә.

— Син миңа сүз бирәсеңме серне сакларга, беркемгә дә сөйләмәскә... әлегә...

— Сүз бирәм. Син миңа дөресен генә сөйлә.

— Бу серне алга таба барыбер икебез арасында гына саклап калып булмас, — диде ул. — Ләкин, зинһар өчен, әлегә үзеңдә генә тот.

— Сүз бирәм.

— Аны махсус яптылар, озакка дип. Аннары, тәмам ихтыярсызлангач, бәлки чыгарырлар.

Мин иң төп соравымны бирергә булдым:

— Аның хатыны акча түләгәнме моның өчен?

Ризалә өстәлгә таянып, ике куллап башын кысты:

— Шулай бугай. Әй, белмим. Бәлки акчасыз гына сөйләшкәндер... — Ул кинәт сискәнеп, башын күтәрде һәм кычкырып җибәрде: — Син үзең беләсең икән бит барысын да! Аны ничек япканнарын, акча түләгәннәрен беләсең бит! Син юри миннән төпченеп утырган буласың.

— Юк, шулайдыр дип уйлыйм гына. Бәлки алай түгелдер. Син үзең дөресен әйт миңа. Туктарны диспансерга хатыны яткырганны беләсеңме?

— Беләм, — диде Ризалә. — Син милициядә эшләмисеңме алай-болай?

— Төзүче булып эшләвемне беләсең бит инде.

— Бәлки син осведомительдер?

— Юк, Ризалә, андый пычрак кеше түгел мин.

— Гафу ит. Минем сеңлем бар — Замирә. Клара эшли торган сәүдә йортында эшли. Директорның секретаре булып. Миңа Замирә әйтте. Ул бер банкеттан соң урамга чыккач, шыпырт кына Кларның яшь сөяркәсе белән сөйләшкәнен тыңлап торган булган.

— Эдик беләнме?

Ризалә арткарак каерылып, күзләрен акайтты:

— Син бөтенесен дә беләсең!

— Кызма, тыныч бул. Туктарның Эдик турында сөйләгәне бар, шуңа гына ул исем миңа таныш.

— Кларанын Эдикка: «Туктар психушкада ятачак!» — дигәнен сеңлем аермачык ишеткән. — Ул чынаягындагы суынган чәен йотлыгып эчеп бетерде. — Әйдә, Туктарны коткару турында бергәләп уйлыйк әле.

— Нәрсәдән башлыйк соң? — дидем мин, аның бу тәкъдименә куанып.

— Бу вакыйганың ин куркыныч урынын әле сина сөйләмәдем, — дип уйга калды ул. — Сонрак анысын да белерсең.

Минем кичектермичә барысын да беләсем килә, ачыклык кертергә теләгем көчле иде.

— Кафил япканмы Туктарны, әллә Кафилгә кушканнармы? — дип сорадым.

— Ә?.. — дип ул, әллә аңламыйча, әллә аңламаган булып кыланып, миңа карады.

— Кафилгә түләгәннәрме акчаны?

Ризәлә калтыранып, алдындагы салфетканы ике куллап бөгәрләргә тотынды.

— Белмим... Юктыр... Кафил Әхәтович андыйга бармас...

— Өстән кемдер боерган микәнни?

— Бәлки, — Ризәлә, урыныннан торып чәйгүнне алды. — Син берүк бу сорау белән Кафил Әхәтовичка керә күрмә!

— Ярар.

— Чәйне кайнарлатыйммы?

— Кирәкми, — дидем мин, аның әңгәмәне дәвам итәргә теләге юклыгын чамалап.

Ул чәйгүнне өстәлгә куеп, урынына утырды.

— Менә шундый хәлләр... — дип тагы уйга калды ул.

— Туктарның буйсынуы, хатынының хыянәт итүен белә торып, шулай түбәнсенүе аяныч.

— Ярата инде ул Кларане, ярата, — диде Ризәлә, еламсырап. — Бичара, нишләсен инде ул!

## 18

Икенче көнне Кафилнең эш телефонына шалтыраттым. Ул миңа төшке ашны ресторанга кереп бергә ашарга тәкъдим итте. Мин баш тарттым һәм: «Әбит ашаганнан соң, берәр ничек очрашырга җай булмасмы?» — дидем. «Ярар, өендә булсаң, янына кереп чыгармын», — диде ул.

Хатын эштә, балалар һаман авылда иде әле. Мин булачак әңгәмәгә эчке әзерлегем юклыгын тоеп каушадым.

Өйгә кергәндә якты йөзле булып кыланса да, күрәсең, нинди әңгәмә буласын сизенептер, күзләреннән «юк белән баш катырасың» дигәнне укырлык иде.

— Күптән бер-беребезгә кунакка йөргәнебез юк, күптән табигатькә бергәләп ял итәргә чыкканыбыз юк, — дип суза-суза, ул диванга киерелеп утырды.

Шунда игътибар иттем — әле генә тәмле ашап чыккан бу тук чырайлы кеше миңа бөтенләй ят иде инде.

— Әйе шул, — дигән булдым мин. — Отпускым да әллә ничек шыран-быран үтеп китте.

— Синең отпускың теге «Отелло» өчен борчылып үтеп бара.

— Әйе, мин аның өчен нык кайгырам.

— Чөнки синең башка кайгың юк. Кешегә гел нинди дә булса «тормыш геморрое» кирәк инде ул. Бигрәк тә синең кебекләргә. Син бит гомергә газапсыз яши алмыйсың. Бөтен нәрсәң урынында, бар нәрсәң житеш булган суратта дә, син кай төшеннән булса да чак кына кан саркуын телисең. Шундый кеше инде син.

— Нәрсә, миндә дә психика тайпылышы бар дип шикләнә башладыңмы әллә?

— Рашат туган, дөресен әйткәндә, синең менә болай өзгәләнеп, хәлеңнән

килмәгән килеш кемгәдер ярдәм итәргә тырышып йөрүең психиканың тайпылышы дип әйтергә мөмкин... күпмедер дәрәҗәдә.

— Нишлисең бит... Соңгы көннәрдә төрле тайпылышлар хакында күп уйланам мин. Кемнең акылы үз урынында, кемнеке чалышайган — тормыш ыгы-зыгысында моңа игътибар гына итмибез. Һәм бәлки кирәк тә түгелдер. Кеше булудан тайпылмаска кирәк, Кафил Әхәтович.

— Син мине ник чакырдың? — диде ул коры гына. — Кеше булудан тайпылмаска өндәр өченме әллә?

— Туктарны чыгар, выписка яса, — дидем мин, кыюлыгымны җыеп. — Ул көннән-көн бетә бара, күрмисеңмени?

— Аны бу хәлендә чыгару ярамый. Кайткач, өендә бер-бер хәл булса, кем җавап бирә? Мин. Аңа диагноз куелган, дәвалау курсы дәвам итә... Пациентларым өчен иң беренче чиратта мин җаваплы.

— Алар өчен җаваплы булгач, Клара белән сөйләшеп, Туктарга вакытлыча яшәп торырга урын табып булмас микән? Хатыны янына кайтмасын ул. Аннары хәл итәрләр коттеджларының язмышын... Клара синең янга кергәләп йөри бит...

— Туктар барыбер Клара янына барып йөдәтәчәк, берәр фаҗига килеп чыгарга мөмкин. Мин чынлап та шикләнә башладым әле — сиңа дәваланырга кирәк түгел микән?

— Әйе, миндә кеше язмышы өчен борчыла торган тайпылыш бар! — дип кычкырдым мин. — Әмма минем ул чиремнән дәваланасым килми. Ә менә берничә йөз мең доллар хакына талантлы, акыллы кешене харап итүчеләрне көчләп дәваларга кирәк (ысулларын табып), чөнки бу психиканың отклонениесе генә түгел, кеше булудан отклонение!

— Аңламадым?.. — дип Кафил урыныннан кузгалды. — Син нәрсә әйтмәкче буласың?..

Мин дә утырган җиремнән торып, урындыгымны читкә алып куйдым.

— Беркөнне гәҗиттән укыдым: Красноярскида бугай... бер кешене акча түләп психушкага япканнар... — дигән булдым мин. — Врачларга уголовный эш ачканнар ди... Шул вакыйга ык тетрәндерде мине.

— Бездә андый җинаятькә баручы врачлар юк! — диде Кафил катгый тавыш белән. — Бездә Гиппократ антына тугры кешеләр эшли. — Ул килеп минем инемә кулын куйды. — Тынычлан инде, Рашат. Нишлисең син? Менә дигән гаиләң, эш урының шәп, ни җитми сиңа? Синең берәр конкрет җитди соравың бар идеме, әллә болай гына сөйләшергә теләгән идеңме?

— Болай гына, — дидем мин, аның күзләренә туп-туры карап.

Ул:

— Син берәр кеше хокукларын саклау оешмасына кермәдеңме? — дип күз карашын идәнгә төшерде.

— Юк.

Кафил ишеккә таба юнәлде һәм чыгып китәр алдыннан:

— Берәр үтенечең бар идеме әллә миңа? — дип сорады. — Читенсенмә, әйт.

— Туктарны азат ит! — дидем мин таләпчән тавыш белән.

— Ул бит тоткын түгел, — диде Кафил, гаҗәпсенгән сыман итеп. — Безгә ятып дәвалануга үзе дә каршы булмады.

...Кафилнең машинасын урам борылышы каплагач, мин Эдик янына барырга булдым.

Миңа киңәш кирәк иде.

Килүемне ул караңгы чырай белән кабул итте.

— Алай-болай эшләр милициягә барып җитсә, ни өчен Клара синнән акча

алганын әйтерсенме? — дип сорадым мин. — Акчанны Кларадан түләтергә дә җайлырак булыр.

— Акчаны ни өчен алганны барыбер исбатлап булмаячак, — диде ул, кул селтәп һәм гасабилана башлады. — Берүк мине катнаштырмагыз бу эштә. Ул сукадан мин барыбер акчамны алачакмын. Ә аның психушкада ятучы ире мине бөтенләй кызыксындырмый.

— Мин синең янга киңәш сорарга дип килдем. Ул кешене ничек коткарырга икән? Ризәлә, шунда эшләүче хатын, мина Клараның акча түләп Туктарны психушкага яткырганын әйтте. Аның сеңлесе Замирә Клара белән бергә эшли икән. Туктарны хатыны психушкага яптырганны сез беләсез, диспансерда эшләүче Ризәлә белә, аның Клара белән эшләүче сеңлесе белә... Менә бит күпме кеше белә! Нүжәли исбатлар өчен шул җитми икән?

Эдик утырган урыныннан алга иеленкерәп пышылдады:

— Ике йөз мең доллар торган эшне аларның белүе белән генә ерып чыгалмассың. Маташма. Хәлеңнән килмәс барыбер. Клара янына бүтән барып та торма. Сине дә, барысын да, мине дә клеветада гаепләп, үзебезне хөкемгә тартулары ихтимал. Мине бөтенләй катнаштырма. Акчаны мин Кларага бирдем, Кларадан үзем алачакмын, беркая да качып котылмас.

— Гафу ит, борчыганым өчен, — дидем мин, торып. — Әйе, Кафил генә хәл итә ала моны.

— Кем ул?

— Диспансерда бүлек мөдире.

— Шул алганмы взятка? — диде ул пәрвайсыз кыяфәт белән. Аны кемгә кемнең ришвәт биргәне һич кенә дә кызыксындырмый иде, ахрысы. Шулай да ул соравын кабатлады: — Шул алганмыни взятканы?

— Белмим, — диярго кирәк таптым мин. — Бәлки бөтенләй башка инстанциягә түләгәннәрдер... Диспансерда эшләмәүче кешенең алуы ихтимал... Ә баш врачка «өстән» боерганнардыр.

— Ришвәт алганны кем танысын, — диде Эдик, минем чыгып китүемне көтеп. — Исбат итеп була торган нәрсә түгел бу. — Инде мин ишек катына җиткәч, ул сорап куйды: — Кемең соң ул синең?

— Кем турында сорыйсыз? — дидем мин, туктап.

— Теге... Клараның ире...

— Беркемем дә түгел. Аны күргәч, аралашкач, язмышына битараф кала алмыйм.

— Ә нинди туганың ята диспансерда?

— Бернинди туганым да ятмый минем анда. Мин юри әйттем. Бүлек мөдире Сафин Кафил Әхәтович белән без армиядә бергә хезмәт иткән идек, Уральский военный округта. Шуның янына кергәч очраттым ул пациентны. Мина хәзер бигрәк тә ул эшнең очына чыгарга кирәк. Яшьлек дустымның кем яки нәрсә икәнен белү теләге дә бар миндә хәзер.

— Әллә йөрмисенме... Үзенә хилафлык килмәгәе. Сина бу эштә кем ярдәм итсен?

— Ризәлә ярдәм итә ала... Ничек уйлыйсың, баш врач белән сөйләшеп карасам...

— Нәрсә диярсең ана? Диспансерыгызда акча түләп урнаштырылган пациент ята диярсеңме? Ул сине тыңларга да теләмәячәк. Әле үзенә җүләр дип диагноз куюы ихтимал. Нинди киңәш бирергә дә белмим. — Ул сәгатенә карап алды. — Гафу ит, мин хәзер механиклар белән кыска гына киңәшмә үткәрергә тиеш.

— Гафу итегез, борчыганым өчен, — дидем мин. — Сау булыгыз.

Мин ишектән чыгып киткәнче ул:

— Бик куркыныч нәрсә белән маташып йөрисең син, — дип әйтеп калырга өлгерде.

... Мин җәйге шәһәр буйлап атладым.

Отпускым бетеп килә...

Нишләргә?.. Хәзер инде Туктарның бәлагә дучар булганлыгы көн кебек ачык иде.

Милициягә барудан мәгънә юк, мин беркемгә берни исбатлый алмаячакмын... Туктарның җүләр түгел икәнен «өстән» килгән комиссия генә билгели аладыр. Ә мона монда кем юл куяр икән соң?..

Баш врачка керсәм...

Шунда йөрәгем жу итеп куйды — мин бит армиядә бергә хезмәт иткән жан дустым Кафил белән дошманлашканыбызны сизми дә калганмын икән!

Кайнар каланың эссе һавасын көчкә ерып, шактый вакыт йөргәннән соң, шулай да бөтен булган хәлемне җыеп, баш врачка керергә булдым.

... Баш врачның секретаре — шыр сөяктән торган, әмма көр тавышлы егерме ике-егерме биш яшьләрдәге кыз — кем икәнемне, ник керергә теләвемне, нинди сорау белән килүемне сорап тенкәмә тиде.

Бер пациентның хәле турында сөйләшергә теләвемне аңлаткач, минем кем икәнем һәм нинди документларымның барлыгы белән кызыксынырга тотынды. Мин түзмәдем, чираттагы ак халатлы берәү баш табиб кабинетыннан чыккач, сикереп тордым да кереп киттем. Секретарь кыз усал кыяфәт белән миңа иярде, ә баш врач, рөхсәтсез керүемне аңласа да, кызга кул селтәп, мине калдырырга кушты.

Баш врач — пеләш башлы, юантык, карап торуга менә-менә алтмыш яшь тулырга тиешле агай — графиннан су салып эчте дә икенче стаканга миңа да су салып бирде.

— Тынлыйм сезне, — диде ул мин су эчкән арада. — Утырыгыз.

Ул психиатр буларак минем гасаби киеренкелекне аермачык күрде.

— Тынычланыгыз, берничә тапкыр тирән сулыш алыгыз, — диде ул, минем сүз башлый алмыйча калтыранып утыруымны күреп. — Нәрсә булды?

Каршыма утырып, текәлеп каравы, бер яктан, каушатса да, икенче яктан, минем менә хәзер, шушында үземне борчыган мәсьәләне хәл итәргә мөмкинлегем бар дигән уй жанландырып җибәрде.

Мин аңа кем икәнемне, Кафил Әхәтовичның яшьлек дусты икәнемне, дүртенче палатада ятучы Туктарның язмышы турында, аның янына хатыны килмәве хакында барысын да бәйнә-бәйнә сөйләдем. Акча төртеп, аны монда махсус яптырганнар дигән шигемне генә әйтмәдем, курыктым.

Курилов (кабинет ишегенә баш табибның фамилиясе шулай дип язылган иде), битендәге, маңгаендагы тирне кулъяулык белән сөрткәч, тирән сулап куйды.

— Көнчелек — коточкыч һәм төзәтеп булмаслык нәтиҗәләргә китерә торган авыру, — дип башлады ул сүзен, студентларга лекция сөйләгән интонация белән. — Яраткан хатынының хыянәте — иң авыр стрессларга китерә торган сәбәп. Моны мин хәтта якын кешенең үлүенә тиңләр идем. Көнләшкәндә, кешенең канына бик зур күләмдә вазопрессин кушыла, ә бу үз чиратында мышцаларга канны күбрәк йөгертә. Көнчелек өянәге вакытында адреналин белән эндофрин да күп эшкәртелә. Бу бик житди физиологик үзгәрешләргә китерергә мөмкин. Көнләшү психик тайпылышларга китерә, бигрәк тә, әгәренки көнләшүче үзенең хисләрен тыярга, яшерергә тырышса. Ә үзен тыймаса — әллә нинди фаҗигаләр булуы ихтимал — кан, үтерү...

— Нигә боларны миңа сөйлисез? — дидем мин. — Боларны һәрбер кеше аңлый.

— Һәм сез дә анлыйсыздыр дип ышанам.

— Аңлыйм, нишләп аңламаска.

— Шулай булгач, сезнең монда тыгылып йөрүегез урынсыз, киракмәсез икәнне дә аңларга тиешсез. Әле монарчы безнең профессиональлектә шикләнүченен булганы юк. Бәлки армиядә бергә хезмәт иткән дустыгыз белән конфликтка кергәнсездер дә, ана үч итеп, безгә тап төшерергә телисездер?

— Кафил Әхәтович белән минем конфликтка кергәнем юк. Ник алай дидегез әле?

— Тормыш бит бу... ә без — кешеләр... Әлеге дә баягы, пациентка килгәндә... Монда әллә нинди язмышлар, әллә нинди хыянәтләр, фаҗигаләр... Барысын да тирәнтен уйларга тотынсаң, шул көнне үк үзең акылдан язачаксың.

Әңгәмәнең файдасыз, мәгънәсез якка борылуын аңлап, мин чак кына ришвәт турында сүз катмадым, көчкә тыелып калдым.

Куриловның чырае мин кергәндә ничек тыныч булган, хәзер дә шул төсмердә сакланган иде.

Кабинетыннан чыгып барганда, артыма типкән сыман булып, аның тавышы ишетелеп калды:

— Бер атна-ун көн сукыр кычыткан кайнатып эчегез.

## 19

Икенче көнне мин кичекмәстән Туктарны күреп сөйләшергә карар кылдым. Качарга кирәк аңа диспансердан, качарга, качарга, качарга!

Мине вахтадан кертмәделәр. Кафил үз урынында түгел, диделәр. Пациентлар янына исә беркемне дә кертергә кушмаганнар, имеш. Ризәлә янына керәм дигәч, ярамый, диделәр, персонал белән пациентларның туганнарына гына очрашырга рөхсәт бар дип кисәткәннәр икән.

Психушканың ишегалдына йөк машинасы килеп туктады. Нәрсәдер бушатырга тотындылар. Бу ишектән кереп, стационар бүлеккә үтәргә мөмкин булырга тиеш.

Арткы ишектән ниндидер җиһазлар ташыйлар иде. Мин күп уйлап тормадым, грузчиклар машинадан авыр әрҗә төшереп маташкан арада йөгереп кереп киттем һәм өченче катка ничек менеп җиткәнемне сизми дә калдым.

Уң якта ишек күренде, мин аны әкрен генә ачтым һәм Туктар яткан бүлеккә бөтенләй башка тарафтан килеп кергәнемне аңладым. Монарчы бу ишекнең ачык чагын күргәнем юк иде. Ашханәдән әкрен генә чыгып килүче берничә кеше арасында Туктар да бар иде. Мин аңа эндәштем. Ул мине күрде һәм як-ягына карап алгач, яныма килде.

Мин исәнләшеп тә тормадым:

— Сиңа качарга кирәк! — дидем.

— Кемнән? — диде ул, аптырап.

Мин аңа озак уйлап торырга ирек бирмәдем, медперсонал күргәләгәнче, җиңеннән йомарлап тотып, ишеккә таба йолкыдым.

Баскычтан төшеп барганда, каршыбызга ниндидер ящиклар күтәреп, теге грузчиклар очрады. Стенага елышып, без аларны үткәреп җибәрдек.

— Башта моннан качарга кирәк! — дидем мин, аска таба төшә-төшә. — Аннары Клараннан качарга кирәк! Хәтта үзең төзегән коттеджлан да качарга кирәк!

Туктар, аякларын терәп:

— Мин Клараны яратам! — диде. — Мин анардан башка яшь алмыйм. Синең яратканың бармы?

— Бар. Хәзер дә яратам — хатынымны, балаларымны.

Мин аңа авыз ачарга да ирек бирмәдем, беләгеннән тотып, аска таба сөйрәдем.

— Миңа урамга чыгарга ярамый, — дип ыңгырашты ул, баскыч рәшәткәсенә ябышырга тырышып.

Мин көчлерәк булып чыктым:

— Сиңа анда калырга ярамый, — дип аны төшәргә мәҗбүр иттем.

Тышка чыккач, аны диспансер каршысында нәрсәдер төзергә җыенган эшчеләр будкасы артына алып киттем. Анда әле беркем дә юк иде, төзелешкә әзерлек кенә бара иде бугай.

— Ул сука сине мәңгегә моннан чыгармаска маташа, ә син ярату турында сөйлисең. Үзеңне таптаучыларны яратасыңмыни? Нинди мәхәббәт соң ул үзеңне мескен итүчеләрне ярату? Тыңла мине, Туктар, игътибар белән тыңла. Син тиле түгел. Синең хәтле генә бөтен кеше көнләшә. Мин дә көнләшәм. Синең кадәре генә һәрберебез җүләр. Бәлки син артык хислерәктер. Мин күрдем синең хатыныңны. Мин Эдикны да күрдем. Син монда бер генә көнгә дә калырга тиеш түгел. Син качарга тиеш моннан.

— Минем хат язасым бар...

— Нинди хат?! Дурак син! Тфү, нинди дурак... Гафу ит. Киресенчә, син дурак түгел бит. Нигә һаман шул бер үк халәткә кереп батарга омтыласың соң син?! Мин сиңа бер серне ачам хәзер. Сине монда Клара яткырган. Дөресрәге, яптырган.

— Беләм. Мин дә, Клара да дәвалану кирәк дип саныйбыз.

— Газабыңның сәбәбен дә, табигатен дә, алга таба нишләтәсен дә син үзең аңлыйсың — синең хатларыңда барлык сорауларга җаваплар бар. Син үзеңнең сорауларына үзең җавап тапкансың бит инде. Син бит дөрес анализлагансың халәтеңне.

— Дөрес анализлау әле ул хак юлга бастым дигән сүз түгел. Ә хак юлга басмый торып, үзеңне җиңә алу мөмкин түгел.

— Син монда ятып, үзеңне җиңә алмассың, ә менә сине җиңәчәкләр.

— Ник миңа кычкырасың?

— Кычкырмыйм бит. Минем әйткәннәрем сиңа ошамый, шуңа кычкырам шикелле тоеладыр. Ул сине мәңгегә яптырган монда. Ул акча түләгән! Эдиктан алып! Ике йөз мең доллар! Ышанмыйсыңмы? Менә аның визиткасы. Менә, Эдик үзе миңа бирде. Мин аны күрдем, сөйләштем. Кларәны да күрдем, Эдикны да. Мин бит сиңа беркем дә түгел алдарга! Синнән аласы әйберем юк, уртак малым юк, бирәсем юк, аласым юк, кем әйтмешли.

— Алайса ник миңа булышырга маташасың?

— Сине коткарасым килә. Син бит үзең дә мине беренче күрүеңдә: «Сез миңа ярдәм итәрдәй кешегә охшагансыз», — дигән идең.

— Ә нигә син алайса миңа мондый яман хәбәр белән килдең?

— Сине коткарырга. Клара Эдиктан акча алып, монда кемгәдер түләгән — сине озакка, бәлки мәңгегә чыгармаска. Ник ышанмыйсың миңа?!

— Мин ышанам сиңа. Ник син дөресен ачыкладың. Нигә миңа бу дөреслек? Миңа бик авыр. Клара мине монда мәңгегә калдырырга телимени? Мин бит шундый йорт төзедем, мин булган көчемне, малымны, акчамны, сәләтемне сарыф иттем шул йортыбызны булдырырга. Чөнки мин яратам Кларәны! — Ул тешләрен шыгырдатып, миңа төссезләнгән караш белән карап торды. — Син — фашист, садист!

— Тынычлан, Туктар.

— Мин тынычлана алмыйм. Мин инде хәзер мәңге тынычлана алмам. Минем җаным да, мәңге кунар урын табалмый, тынгысыз очып йөрер.

— Ник син мине дошман итәсең? Мин бит хәлеңне яхшыртыр өчен, сиңа дөресен әйттем.

— Син дөресен әйткәнгә ачуым килми минем. Син ул дөрес хәбәрне

ышанырлык итеп әйттең. Мин ышанам син әйткән дөреслеккә, шуна күрә сине мин күралмыйм.

— Мине синең хатының да күралмый. Мине служагым Кафил дә дошман итә, Ризәлә дә нәфрәтле, синең көндәшең Эдик мина сәерсенеп карый. Өстәвенә баш врач мыскыл итеп чыгарып җибәрде. Хәзер инде син мине дошман итәсең...

— Менә бит, димәк, сина үзең турында утырып уйланырга кирәк.

— Син һаман үз газабына кереп батарга тырышасың. Синең газаплануыңның мәгънәсе бармы соң?

— Газапта мәгънә бармы дип сорыйсың икән, димәк, анарда мәгънә бар дигән сүз инде бу. Нәрсәнең дә булса мәгънәсе турында сорау — аның мәгънәсе бар икәнне әйтә. Чөнки мәгънә эзләү, мәгънә эстәү — үзе мәгънәгә ия.

— Гафу ит, Туктар, вәләкин, зинһар, чүбек чәйнәмә, яме. Синең газабың да, фәлсәфәң дә үзең өчен генә. Башкалар, хәтта син яраткан кешеләр дә, төкерәләр синең мировоззрениеңә!

— Син Кларaны күрдеңмени?

— Күрдем.

— Сина ошадымы ул?

— Юк.

— Алдыйсың. Син аңа гашыйк булгансың, шуна күрә нахак сүз сөйлисең.

— Миннән дә көнләшмә инде. Син хәзер көнләшү хисенне мин әйткән хәбәргә каршы кулланырга телисең. Юк, Туктар, мина андый хатыннар беркайчан да ошамады. Аларга синең кебек мудаклар гына батып гашыйк була. Гафу ит, зинһар.

— Ай-яй, усал кеше икән син, — диде Туктар, башын чайкап.

— Хәзер автобуска утырабыз да минем өйгә барабыз. Хатыным Галия эштән кайткандыр инде. Ашатыр, эчертер, юынып чыгарсың, киемеңне алыштырырбыз, минем киемнәрне киеп торырсың. Минем хатыным менә дигән кеше, борчылма, оялма. Аннары күз күрер.

— Мина диспансердан качкан өчен эләгәчәк. Подсуд җибәрсәләр?

— Җибәрмәсләр. Эләкмәс тә. Сине эзәрлекли башласалар, барыбер Кларанның кемгә акча биргәнен ачыкларга тотыначакмын һәм дәваланырга риза булуыңнан файдаланып, сине бөтенләй чыкмас итәргә җыенганнарын исбатлаячакмын.

Туктар шактый вакыт мина карап торды.

— Чынлап та алдан сөйләшеп, акча түләп, мине монда яткырганнармы?

— Әйе. Исбатларга гына кирәк ничектер.

— Теге өебезгә килгән врачлар инде шул заказны үтәргә килгән булганнармы?

— Сина нәрсәгә инде нечкәлекләре? Ник ризалаштың син монда ятарга?!

— Безнең үзара мөнәсәбәтләрдәге ямьсез нәрсәләргә индефферент рәвештә буласым килеп диспансерга яттым мин. Хәзер тагы да катлаулырактыр шикелле тоела башлады. Клара белән минем арага әллә кемнәр, әллә нинди ят кешеләр керде — шуна әрни күңел. Сөяркәләр, табиблар, Ризәлә, син... Дөнья ике кешенең бер-берсен яратуын белергә, күрергә тиеш түгел.

— Син җебегән булгач, бөтен нәрсәнне аермачык күрә бу дөнья. Гафу ит, Туктар, мин сина хәзер аямыйча әйтәм: көнчелек — иң җанбизләргеч хис — коллар хисе, түбәнсетә, буйсындыра, мыскыллый торган хис. Көнчелек иректән мәхрүм итә. Көнчелектә собственность һәм хакимлек инстинкты бар, ләкин түбәнсеңү халәтендә. Кеше өстеннән кеше тираниясе ул көнчелек. Син тиран һәм шул ук вакытта мескен кол.

— Бәлки мин чын мәхәббәткә ышанып карап булганмындыр. Мин чын Кешегә, чын Мәхәббәткә, тугрылыкка ышанып яшәдем һәрвакыт.

— Синең язган хатларыңда мәхәббәтенә кагылышлы бөтен сораулар һәм аларга тулы җаваплар бар лабаса!

— Син алдамыйсың... Күрәм, алдамыйсың син...

— Ниһаять, тәгаен ышандың, — дип кенә әйтергә өлгердем, Туктар шартлап өзелер дәрәҗәдә тарттырылган бер кылга әверелде, аның күзләре акайды, кинәт каяндыр җегәре барлыкка килде, ап-ак чыраенда тимгел-тимгел кызыл таплар хасил булды.

— Үтерәм! — дип минем бугазыма ябышты ул. Мин аның кулларын ычкындыра алмый иза чиктем. Аның корычтай каты бармаклары муенымны кысканнан-кыса барды, мин артка таба чигендем, ә ул миңа ияреп, кулларын ычкындырмыйча бууын дәвам итте. Мин инде гырылдый башлаган идем, күз алларым да томаланды, шул вакытны ир кеше тавышы ишетелде — үтеп баручы бер агай булган икән:

— Әй, нишлисез! Сугышмагыз!

Шунда гына Туктар кулларын ычкындырды.

Буй-буй киеме аның кем икәнен әйтеп тора иде, минем турыда шул арада җыелган кешеләр ни уйлаганнардыр, белмим, мин тирән-тирән сулыш алып күкрәгемне һава белән тутырырга ашыктым. Туктар исә томырылып шул без чыккан арткы ишеккә таба чапты һәм диспансерга йөгереп кереп китте.

Мин бераз хәл алып торганнан соң автобус тукталышына юнәлдем.

**20**

Кайтып, бу вакыйганы Галиягә сөйләдем дә шаккаттым — хатынымның мине монарчы бу кадәре беркайчан ачуланганы булмаган икән. «Ник аны диспансердан качарга үгетлисең! Кафил белән сөйләшеп хәл итеп булмыймыни аны!» — дип кат-кат бәйләнде ул миңа. Кларанын кемгәдер акча түләгәнен әйткәч, минем чиста күңелле хатыным, гаилә дустыбызга андый пычрак тап төшерәсе килмичә, кат-кат: «Кафилгә түләмәгәннәрдер инде, Кафил андый кеше түгел», — дип кабатлады.

...Икенче көнне, нишләргә икән дип борсаланып, үземне кая куярга белми йөргәндә, өйгә Ризәлә шалтыратты. «Мин бүген эштән сорап, иртәрәк кайтып китәм. Сәгать дүрткә өемә кил», — диде ул.

Әлегә ни уйларга да белмәдем.

Туктарны диспансердан качырырга маташуым мәгълүм булгандыр... Тышка чыккач эләгешкәнебезне күрделәр микән... Туктар үзе дә барысын сөйләгәндер бәлки... Шушы уйлар өстенә, тагын йөзләгәне өстәлеп, башымда уйлар бураны купты.

Шунда мин зур хата җибәргәнемне аңладым — монда ришвәт түләп яткырганнарын Туктарның үзенә ачыктан-ачык әйтергә ярамый иде лабаса.

Мин сәгать ярымга алдан барып, Ризәлә йорты каршындагы сәрви агачының күләгәсендә аның кайтканын түземсезлек белән көттем.

Ризәләнең кыяфәте бүген роботныкына охшаган, причёскасын да гадәттәгечә матур ясамаган, буянмаган, аягында затлы туфли түгел, ниндидер чүәк һәм хәтта күлмәге дә искегә охшаган иде.

...Верандадагы яшел диванда ул шактый вакыт күзләрен йомып дәшми утырганнан соң гына телгә килде һәм диспансердагы хәлләрне сөйләде.

Бүген иртәнге якта Туктар, Кафил кабинетына кереп, диспансердан чыгаруларын таләп иткән. «Мине монда акча түләп хатыным яткырган! Мин бүтән чыкмаслык итеп, мәңгегә яптырган!» — дип кычкырган. Истерикасы башлангач, санитарлар ярдәмендә палатасына алып китеп, уколлар кадап тынычландырганнар үзен.

— Нишләргә, нишләргә?... — дип әллә ничә тапкыр кабатлады Ризәлә үзалдына.

— Взятканы исбатлый алмаячакбыз, — дидем мин. — Ичмаса акчаны кем алганны белергә иде.

— Кем алганы билгеле, — дип кул селтәде Ризәлә, моны белмәгән кеше юк инде дигән кыяфәт белән.

— Кем? — дидем мин, сискәнеп. — Кем алды?

— Кафил алды ике йөз мең долларны, — диде ул тыныч кына.

Мине ток суккандай булды.

— Чын әйтәсенме? — дидем мин, әле һаман ышанасым килмичә.

— Әйе, — диде ул, чак кына ишетелерлек итеп.

— Исбатлый аласыңмы?

Ул өстәл янына килде, чынаякка чәй салып, шундук йотып куйды:

— Аның алганын минем үзем өчен исбатлау кирәкми... Башкаларга исбатлап булмас, мөгаен...

— Ә нишләп син Кафил алды дип ышанып әйтә аласың?

Ризәлә янә диванга барып утыргач, күкрәгең тутырып сулыш алды да:

— Чөнки ул акчаны мин ана үзем тапшырдым, — диде. Моның миңа ничек тәэсир итүенә ул инде битараф иде һәм тигез тонда сөйләвен дәвам итте. — Минем алга таба бу гөнаһ белән яшисем килми. Болайга калса, мин беркайчан бәхетле була алмаячакмын. Үземә бәла килмәсә улыма килергә мөмкин. Клара мине сеңлем аша ресторанга чакырды. Клара шунда миңа ире турында зарлана-зарлана сөйләде. Диспансерга яткырып, диагноз куеп, дәваларга кирәк иде, дигән теләген белдерде. Шикчел, көнче, тузга язмаган фантазияле кешене нинди диагноз белән яткырырга мөмкин дип кызыксынды һәм акча түләячәген кат-кат әйтте. Сеңлем исә миңа ничегрәк эш итәргә икәнне өйрәтте: «Ирен психушкага ябар өчен, Клара зур акча түләргә җыена, ирен диспансерга япканда, үзенә дә өлеш тисен өчен, Кларaның бөтен килешүләрен үзең аша эшләтергә тырыш», — дип котыртты. Шулай итеп, Клара белән врач арасында элемтәче шәхсән үзем булачагымны шарт итеп куйдым. Табиб турыдан-туры сезнең белән килешү ясарга шүрләячәк дигән булдым. Беркөнне Кафил Әхәтович белән бу хакта сөйләштем: бик каты көнләшүче кешенең хатыны мөрәҗәгать иткәнне һәм акча түләргә җыенуын аңлаттым. «Миңа килсен», — диде Кафил. Мин аңладым — әгәр дә Клара турыдан-туры аның янына килсә, минем акчасыз калуым ихтимал. Ә миңа акча бик кирәк иде... Хәзер дә кирәк... Улымны укырга кертергә, аннары аны армиядән алып калыр өчен дә бик күп акча кирәк булачак... Оялып тормадым: «Клиентны, ягъни пациентны мин таптым, алдан сөйләшик — миңа күпме бирәсез?» — дип сорадым? «Ун процент», — диде Кафил шундук. Дөресен әйткәндә, әле үзен күрмәгән килеш, кешене стационарга яткырырга җыенуыбыз мине эчтән тетрәндерде. Ләкин кесәмә җайлы гына андый акча керү ихтималы минем аңымны әсир итте. Сеңлем миңа Кларaның инде якынча күпме бирәсен әйткән иде — ике йөз мең доллар тирәсе. Мин Кафилдән сорадым: «Ике йөз мең доллар түләсәләр, миңа күпе бирәсең?» «Егерме мең доллар синеке була», — диде Кафил Әхәтович, ике дә уйламыйча. «Ә ире сәламәт булса, бернинди диагноз куярлык булмаса?» — дидем мин, сагаеп. «Нык көнләшә дисең бит... Конфликтлары кызган чакта шалтыратсын. Мин моннан ике кеше җибәрермен, җаен табарбыз», — дип җавап бирде ул. Шулай итеп, беркөнне, Клара шалтыратуы буенча, ике табибны Кафил аларга җибәрә. Туктарны алып киләләр. Аны яткырырга җайлы булды, чөнки үзенең дә көнчелектән дәваланасы килгән иде. Мин башта курыктым — хәзер инде кирәгем беткәндер, Кафил Әхәтович миңа акча бирмәс дип уйладым. Чөнки Туктарны стационарга салгач, Клара

үзе килеп, Кафил белән очрашып танышты. Ләкин Кафил алдамады, тиешле сумманы түләде. Их, алдаган булса, мин мондый кайгыга батмаган булыр идем. Икенче көнне чакырып, ул миңа егерме мең доллар акча бирде. Димәк, Клара ана чынлап та ике йөз мең биргән булып чыга.

Ризәлә почмактагы тумбочкадан бер кәгазь кап алып өстәлгә куйды:

— Менә ул акча, тотылмаган килеш ята. Егерме мең доллар. Биш меңен сенлемә бирергә тиеш идем. Ул соңга таба, Туктар турында сөйләгәннәремне тыңлагач, үз өлешеннән баш тартты. Миңа да кирәк түгел. Зур хата ясадым мин. Бу беренче мәртәбә... һәм соңгысы. Бу акчаны нишләтергә соң хәзер?

Мин китәргә кузгалдым:

— Акчаны нишләтергә икәнне хәл итәргә беркайчан да соң түгел, — дидем мин аңа. — Иң элек баш врачка кереп сөйлә барысын да.

— Карга карганың күзен чукымас. Акчаның күпмедер өлеше баш врачка бирелгән булуы мөмкин.

— Ничек мондый эшкә бара алдың син, Ризәлә?! — дидем мин веранда ишеге катыннан.

— Мин бит аны вакытлыча гына яткырып тотарлар, берничә айдан чыгарырлар дип уйладым.

— Сайра, сайра, — дип мыскыллы елмайдым мин.

— Минем кире бирәсем килә бу акчаны. Ләкин кемгә бирергә икәнне белмим.

Миндә кинәт нәфрәт шулкадәр көчле күтәрелде һәм мин:

— Үзенә сакла — үлемтеккә, — дигәнемне сизми дә калдым.

Ул диванга йөзтүбән капланып, үкси-үкси еларга тотынды.

Ә мин чыгып киттем.

## 21

Төнлә бөтенләй йоклый алмадым дияргә була, уяулы-саташулы яттым. Иртән отпускымның соңгы көне бүген икәне искә төште. Түзмәдем, Кафил белән кичектермичә күзгә-күз карап сөйләшергә дип диспансерга киттем.

Менә сиңа мә! Ризәлә оештырган икән бит бу эшне... Кем уйлаган! Ризәлә сенлесе белән башласалар да, эшнең төп өлешен Кафил башкарган инде барыбер. Ришвәтне дә алучы — ул. Әллә керү белән үк Ризәләнең икърар итүен әйтергәме? Ә ул алуын танымаса? Шаһитлар юк бит... Ризәлә нахак сүз сөйли дип жавапка тарттыруы ихтимал.

Шулай да Кафилнең күзләренә карап, бер-ике сорау бирергә тиеш мин! Шушы уй-ният белән диспансерга барып җиттем.

Вахтада каршыма моңарчы күренмәгән алагаем гәүдәле сакчы килеп басты. Мин:

— Кафил Әхәтовичны күрергә телим, — дигәч, сакчы корыч тавыш белән:

— Беркемгә дә аның янына керергә рөхсәт юк! — диде.

Регистрациядәге хатынга мөрәҗәгать итәргә теләвемне күргәч, сакчы миңа чыгып ук китәргә кушты. Мин каршы килә алмадым, эчтә протестым кабынса да, аның боерыгына ничектер шундук ихтыярсыз буйсындым. Минем арттан вахтадагы сакчы да чыкты. Моннан да куар микән дип уйлап куйган идем, ул тәмәке тартырга чыккан икән.

Мине хәзер монда якын да китермәскә боерганнардыр дип уйлаган гына идем, сакчы, тәмәкесен тирән суырып, авызыннан бер метр чамасы озынлыкка төтен агымын өргәннән соң, минем алда акланган сыман иттереп әйтеп куйды:

— Бүген төнлә өченче каттагы бәдрәфтә бер псих асылынып үлгән.

Мин аңа карап өнсез калдым.

— Ничәнче катта? — дип сорадым мин.
— Өченче.
— Кем асылынган?
— Шунда ятучы бер пациент.
— Исемен беләсенме?
— Каян белим мин. Бүген беренче көн эшкә чыгуым. Иртәнге алтыда заступать иттем. Беренче көндә үк асылынып каршы алдылар... Мин килгәндә, баш врач та, бөтен персонал да шушында иде. Милициядән, тагын әллә кайлардан әллә кемнәр килгән. Мина кадәр дежур торган сакчы да шунда әле.
— Ничәнче палатадан икәнен дә белмисенме?
Сакчы, ишекне ачып, регистратурада утыручы хатынга эндәште:
— Ничәнче палатадан асылынганнар?
— Дүртенче, — дигәнне ишеттем мин һәм инде бернинди шигем калмады.
Мин әкрен генә китеп бардым.
...Кичкә таба, диспансерда көндезге сменаның эш вакыты тәмамланырга ике сәгать кала, Ризәләнен чыкканын урамның икенче ягында көтеп тордым.
Шактый вакыт көтәргә туры килде. Ниһаять, ул чыкты һәм автобус тукталышына житәрәк мин аны куып життем.
— Туктармы? — дип сорадым мин.
— Туктар, — диде ул, каядыр еракка карап. — Ник сөйләдең син ана барысын да?
— Әйе шул, зур ахмаклык эшләдем мин.
Ризәләне тукталышта калдырып, мин җәяүләп өемә кайтып киттем.
...Галиягә сөйләгәч, өйдә кайгы хөкем сөрә башлады.
— Сине төрмәгә утыртачаклар, — дип елады Галия. — Аларның взятка алганнарын берничек исбатлап булмый, ә синең Туктарга ашарга ташыганыңны, аның белән сөйләшкәнеңне күп кеше күргән, әле качарга өндәгәнеңне дә ишеткәннәрдер. Аның асылынуын сиңа сылтасалар? Утыртып куйсалар үзеңне?..
— Утыртсыннар, — дидем мин, дөньядан тәмам ваз кичеп. — Аның асылынуында минем дә гаебем бар.
— Ә без? Мин ике бала белән нишләрмен?
Мин, ынгырашып, башымны ике куллап кыстым: «Ник дөресен сөйләдем мин, ник! Нәрсә бирде дөресен сөйләвем?!»

## 22

Туктарның фаҗигале үлеме буенча мине беркем беркая чакырмады, хәтта кызыксынучы да булмады. Суицид очрагы, дип Туктарның авыру тарихына нокта куйганнар. Аңа карап гаеп хисе миндә кимемәде, киресенчә, көчәйде. Минем аркада кеше асылынып үлде дигән уй мине бер көнгә дә ташламады. Ярдәм итәм дип харап иттем мин ул бичараны.
Мин аракы белән мавыга башладым.
Дөреслек үтердеме аны? Минме? Кларасымы? Үзен үзе үтердеме ул? Ришвәт алган табибларлармы? Бу сораулар мине гел эзәрлекләргә тотынды. Ләкин гел бер жавап өстенлек ала иде: мин үтердем аны. Мин аңа ике йөз мең доллар турында әйттем... Кларанын анардан тәмам котылырга теләвен әйттем. Мин, мин, мин гаепле!
Галия:
— Акылдан язасың бит инде, — дип елагач, мин гел бер генә җавап бирә торган булдым:
— Минем урын йә психушкада, йә төрмәдә.

Кафил белән бүтән бер дә аралашмадык, хәтта очраклы рәвештә дә күрешкән булмады. Ул минем өчен үлде, бетте, юкка чыкты.

Гаеп хисе каядыр үзәктә урын җәеп ятты да минем өстән хакимгә әверелде. Мин аны аракыда батырырга тырыштым, әмма ул бата торган хис түгел икән, киресенчә, аракы эчүемә ул анда сөенеп, рәхәт кичереп ятты. Эшемнән чыгарга туры килде, чөнки үз вазифаларымны үти алмый башладым. Галия, апасына ялынып-ялварып, мине читкә типмәскә күндерде, гәрчә җизнәсе миңа каршы булса да. Төзү материаллары складына хисапчы сыманрак бер пүчтәк кенә эшкә урнаштым.

Берзаман аракы эчүдән туктый алмавымны аңладым. Мин инде алкоголикка әйләндем.

Минем шәхсән аска таба тәгәрәвем шулай дәвам итте. Галиям, изге кешем минем, рәхмәтләр яусын, ташламады. Балаларым да игелекле булды, ата икәнемне беркайчан онытмадылар.

...Бер тапкыр салган баштан мин Ризәлә йортына киттем. Күреп сөйләшәсем килде.

Шактый вакыт аның йорты тирәсендә капкасын ачарга базмыйча йөрдем.

Өч йөз метр чамасы арада шул ук урамның ике катлы йорты каршында бер төркем яшьләр тора иде. Шуларның берсе, минем Ризәлә йортының тәрәзәсенә карап торганны күргәч, кычкырды:

— Нәрсә кирәк сиңа монда? Бар кит моннан яхшы чакта!

Һәм ул миңа таба якынлашты. Үсмернең спорт киеменнән булуы мине шүрләтте. Чөнки ул мине карак дип белеп кыйный башларга да мөмкин иде бит. Үзенә генә бирешмәсәм дә, анда бит аның дуслары басып тора.

Шул вакытны капка ачылды һәм Ризәлә чыкты. Элеккеге чибәрлеге сакланган, әмма ябыккан, картаебрак киткән, күзләрендә битарафлык. Өстендә соры халат, аягында ниндидер танкетка, чәче җыелмаган. Минем белән исәнләшеп сөйләшеп торуын күргәч, миңа кычкырган егет тынычланып, дуслары янына борылып китеп барды — ул Ризәләнең малае булып чыкты.

Ризәлә минем кыяфәтне күреп шаккатты.

— Нишләдең син? — диде ул, чыраен чытып.

— Бу арада катырак җиффәрдем, — дидем мин.

— Син болай эчми идең бит.

— Җан тыныч түгел, шуңа эчәм.

Ризәлә бу юлысы мине өенә керергә чакырмады. Капка төбендә генә бераз сөйләшеп тордык. Диспансердан китеп шәһәр поликлиникасына сестра-хозяйка булып урнашканын әйтте. Туктарны зиратка күмү мәшәкатьләрен үз өстенә алган, кабер ташы куйдырган, рәшәткә ясаткан. Калган акчаны ниндидер медицина фондына тапшырган.

— Мине дә чакырырга идең, ярдәмем тияр иде, — дидем мин.

— Ярдәм итүчеләр табылды, — диде ул.

— Син иргә чыгарга җыенган идең теге вакытта...

— Улыма мөнәсәбәте яхшы булмасын аңладым, шуңа чыкмаска булдым. Аннары беркавым очрашып йөрдек тә, араларыбыз тәмам суынды. Синең гаиләң урыныңдамы соң?

— Аллага шөкер.

— Хатының әйбәт кешедер синең.

— Галиям алтын минем, алтын.

— Бик нык үзгәргәнсең, — дип кабатлады ул никтер.

— Ә син һаман шулай ук чибәр, мөлаем, — дигән булдым мин.

Ризәлә минем комплиментыма сөенмәде генә түгел, хәтта авыз чите белән генә дә елмаймады.

— Чибәрлек көннән-көн эри бара инде, — диде ул сыктанулы тавыш белән.

— Кафил үз урынында эшлиме?

— Эшли. Теге вакыйгадан соң ул сине еш телгә алды. Прокуратураларга барып йөрерсен дип уйлады бугай. Аннары тора-бара тынычланды.

— Диспансердан китәргә булдың инде, алайса?

— Китүен киттем, әмма үзеннән китү мөмкин түгел шул. Авыр, караңгы уйлар бимазалый.

— Синең китүенне Кафил ничек кабул итте?

— Башта китмә дип ялварды. Аннары поликлиникага күчкәч, шактый вакыт, диспансерга кире кайт, дип ялынып та йөрде әле. Соңгы вакытта йөдәтми, арыды бугай.

— Дөрес әйттең, үз-үзеннән качып булмый. Җан газабы, кая барсаң да, синең үзең белән йөри шул.

Ризәлә, йөземә туры карап:

— Эчүдән туктарга кирәк, Рәшат, — диде һәм елмаерга үзендә көч тапты.

Моны мин ул әйтмәсә дә белә идем. Икебез дә апатияле халәттә шулай ярты сәгать чамасы сөйләштек, әмма рәтле әңгәмә килеп чыкмады, һәм ул булырга да тиеш түгел иде. Салкын гына хушлаштык. Ризәлә, улын өйгә чакырыргадыр дип, ахрысы, яшьләр төркеменә таба атлады, ә мин урамның икенче тарафына — кайда баш төзәтим икән дип эзләнеп китеп бардым.

## 23

Эчүне ташлый алмадым мин. Өйдәгеләр тарафыннан дәваланырга кирәк, дигән сүз чыкты, әмма наркология шул ук диспансерда икәнне белгәч, мин анда ятудан баш тарттым, хәтта амбулатор рәвештә дәваланырга да теләмәдем.

Галиянең бу каладан китәргә тәкъдимен исә мин шатланып кабул иттем.

1998 елны без Казанга күчендек. «D» каласындагы өч бүлмәле фатирыбызга акча өстәп, Казанга алыштырдык. Бик авыр вакытка, дефолт чорына туры килде безнең күченүебез.

Галиянең техникумда бергә укыган иптәш кызы, кайчандыр читтән торып төзелеш һәм архитектура институтын тәмамлап, ул вакытта Казанда министерствода эшли иде. Галия үзе дә бухгалтерлар курсын тәмамлаган иде, иптәш кызы аңа «G...» төзү фирмасында экономист булып урнашырга ярдәм итте. Миңа ул фирмада урын табылмады. Алган белемем буенча да, яшь чактагы кебек шофёр булып эшләргә дә минем хәлем юк иде. Төзү объектларын саклаучы оешмага гади каравылчы булып эшкә кердем.

Алкоголизм миндә көчәя барды. Ниһаять, хатынымның шул ук иптәш кызы ярдәме белән мин дәвалану курслары үттем, кодировкадан соң шактый вакыт эчмәдем, шуннан соң хәтта дүрт ел прораб булып та эшли алдым. Дөрес, прораб булып эшләгән дәвердә дә «ычкынгалап» алдым. Галиям мине вакытыннан алдан гүргә керүдән саклады, гаиләне таркатмады, аңарадан башка инде күптән беткән булыр идем.

Без Казанның «Вторые Горки» дип аталган тарафында яшәдек. Балаларыбыз үсеп җиттеләр. Кызыбызны бик яхшы, төпле егеткә кияүгә бирдек. Алар үз фатирлары белән Сәвит районында яши башладылар. Аннары улыбыз өйләнде, килененнән дә бик уңдык, фатирны икегә бүлеп, бер бүлмәлесен улыбызга бирдек. Үзебез, шулай итеп, Казан Кремле янындагы иске йортка күчтек.

Монда күчкәч, минем эчүем каты оборот алды. Тагын өч тапкыр дәваланырга туры килде. Төрле фобияләр башлангач, психотерапевтка да мөрәҗәгать иттек. Мине хәтта стационарга психодиспансерга яткырырга теләделәр. Мин аяк терәп каршы килдем.

Барыбер туктый алмам инде мин эчүдән.

Хәзерге вакытта мин рәтле эшкә яраклы түгел инде. Хәл юк минем. Ярый әле менә янәшә генә Казанка буен рәткә китереп маташучы фирмага урнаша алдым. Шлагбаум күтәреп торам шунда.

Минем тормышым дөрес юлдан башланган иде, нишләп минем язмыш мондый чалыш юлга чыкты дип аптырыйм. Галия фикеренчә, эчә башлавым да, бу хәлгә калуым да, Туктар асылынып үлгәннән соң башланды. Ул кешенең язмышына тыгылып, аның үзенә кул салуына мин дә өлеш керттем шул. Галия исә төп гаеп миндә түгел, Туктарның хатынында, аның взяткасын алган табибларда дип миңа тукый. Шулаен шулай да...

Миндә гаеп хисе Туктар үлгән көннән бүгенге көнгә кадәр яши. Ул мине эчтән ашый. Мин үтердем аны, мин аңа дөресен әйтеп хата җибәрдем. Ярдәм итәм дип, харап иттем мин аны.

«Әгәр әйтмәгән булсаң, яхшырак булыр идеме?» — дип сорыйм да үземнән, «Асылынмас иде һәрхәлдә», — дип җавап бирәм.

Әгәр дә, аның үлемендә мин дә гаепләнеп, төрмәдә утырып чыккан булсам, бәлки алга таба гомерем якты булыр иде, бәлки мин тормышның төбенә төшеп, кешеләрнең аяк астында буталып йөрмәс идем. Әйе, әйе, мин егылам, ауныйм, Галия мине күтәреп ала, аякка бастыра, юындыра, ашата. Ә мине тагын авыр йөк — гаеп, гөнаһ йөге аска бөгә, сыга, ега.

Туктарның газабы, аның авыруы миндә хәзер. Авырулар да, газаплар да кешедән кешегә күчеп кенә йөри. Җир йөзендә газап белән бәхет тә, мәрхәмәтлелек белән явызлык та, мәхәббәт белән нәфрәт тә мәңге бер чама. Төрле кешегә төрле дозада кереп урнаша алар. Бу дөньяда газап гел үзенең корбанын эзләп кенә йөри. Туктарның газабы миндә, ул мине бетереп маташа. Туктар үзе юк, аның чире миндә калды. Ул газап элек Туктарныкы булмаган, аңа да кемнәрдәндер ничектер трансформацияләнеп күчкән. Моны миңа ул үзе әйткән иде.

## 24

Рашатның чыраена бераз төс керде. Өч сәгатьтән артык сөйләгәннән соң, бушану кичерде. Ләкин вакытлыча иде бу. Аңа бераздан тагын читен булачак, тагын авыр уйлар белән бимазаланачак. Тагын аракыга тотыначак.

Мин аңа бер шешә аракы алып бирдем дә без ул көнне саубуллаштык. «Син бу турыда берәр әсәр яз», — диде ул хушлашканда.

Минем инде ул сөйләгәндә үк андый теләк туган иде.

...Аның бәянын болай тулы итеп язар өчен, Рашат белән тагын берничә тапкыр очраштык (кафеларда, тагын аның өендә, ике тапкыр мин аны үз өемә чакырдым), чөнки минем аңа бу вакыйгага бәйле сорауларым бик күп иде һәм ул үзе тагын күп нәрсәне исенә төшереп, өстәмә рәвештә сөйләде.

...Бер ай вакыт узгач, шалтыратып, Рашатның хәлен белергә булдым. Кесә телефонының номерын җыйдым, әмма ул үзе түгел, хатыны Галия җавап бирде.

— Рашатны узган атнада җирләдек, — диде Галия тоныкк кына тавыш белән. — Йоклаганда йөрәге туктады. Вафатына берничә көн кала сезне бик күрәсе килеп йөргән иде.

Кайгыларын уртаклашуымны әйткәч, мин:

— Шалтыратырга иде, телефон номерымны белә иде бит, — дидем.

— Үләрмен дип уйламагандыр, шалтыратырмын әле дигәндер.

— Вафат булгач, сез берәр ничек миңа хәбәр итәргә идегез.

— Кайгы шулхәтле басты, бу турыда уйламадым да.

— Урыны җәннәттә булсын.

— Үзен үзе бетерде шул... Әле житмәсә моннан бер ай чамасы элек супермаркетта Кафилнен хатыны Илмираны очраткан булган.

— Кафилләр Казанда яшиләр микәнни?

— Юк, алар Петербургта психотерапевтик үзәк ачканнар, шунда икән алар хәзер. Казанга кунакка килгәннәр. Озакламый Универсиада карарга киләбез, дигәннәр.

Озак сөйләшеп, Галияне ялыктырасым килмәдә һәм кайгысын уртаклашуымны кабатлап, түземлек, сәламәтлек теләп саубуллаштым.

## 25

Дөнья кайный. Казан да кайнап тора. Бу көннәрдә ул аеруча нык кайный — Универсиада көннәре житте. Халыкнын күбесе бу вакыйгага битараф булса да, башкалабыз тормышында беренче тапкыр уздырылган мондый бәйрәм турында массакүләм мәгълүмат чаралары, телевидение сәгать саен сөйләп торды. Ә менә килгән кунаклар өчен, республика житәкчеләре өчен, байлар өчен зур бәйрәм, аларга күнел ачарга сөйләп бетергесез мөһим сәбәп иде бу.

Кафил, хатынын ияртеп, Универсиадада күнел ачып йөридер, дип уйладым мин. Монда курсташлары, коллегалары, дуслары, әшнәләре белән очрашадыр. Кайчандыр ин якын дусты, бик яхшы күнелле, олы жанлы, чын кеше — Рашат вафат булганны Кафил белә микән? Кайчан да булса Рашатнын бу дөньядан киткәнен белсә, анын үлеменда Кафил үзенең гаебен танырмы икән? Дустын үзе үтергәнне анлар микән Кафил?

Рашат сөйләгән персонажларнын калганнары нихәлләрдә икән? Клара, Эдик, Ризәлә...

Минем аларны күрәсем килә башлады. Алар белән очрашсам, Рашат сөйләгәннәрне әсәр итеп язганда, мина әллә нинди яна детальләр өстәләчәк дип юлга жыендым.

...Мин озак уйлап тормадым, беркөнне машинамны кабыздым да «D»га киттем.

Гагарин урамындагы 23 нче йортны мин тиз таптым. Йорт искергән, капкасы буялмаган.

Мин күрше йортнын албакчасында өрәнге төбендәге чүпләрне жып йөрүче апага эндәштем:

— Исәнмесез.

Олы яшьтәге апа, кызарып бүртенгән йөзен калкытып:

— Исәнмесез, — дип жавап бирде.

— Ризәлә монда яшиме?

Апа кул арты белән мангаен сыпырып, мина беравык карап торды.

— Әйе, шушында яши.

— Өйдә түгел микән?

— Юктыр, эштәдер ул.

— Поликлиникадамы?

— Поликлиника дип аталадырмы ул, белмим, стоматологиядә смена дежуры булып эшли ул.

— Димәк, шәһәр поликлиникасында түгел?

— Аннан китте ул. «Венера» дигән стоматология кабинетында ул хәзер. Үзәк урамнын ин очында.

...Теш дәвалау кабинеты каршында утыручы дежур хатынны Ризәләдер дип уйламаган идем, ул каядыр чыгып киткәндер дә, анын урынында башка кеше калып торгандыр дигән идем.

— Миңа Ризәлә исемле ханым кирәк иде, — дигәч, ул аптырап китте һәм:

— Мин Ризәлә, — диде.

Аны мин Рашат сөйләве буенча бөтенләй башкача күз алдыма китергән идем, бәлки дөрес күзаллаган булганмындыр да, күпме вакыт үткән бит инде, Рашатның аны соңгы тапкыр күрүеннән соң шушылай үзгәргәндер, күрәсең.

Күз төпләрендәге кара таплар, тәссез күз карашы, зәңгәрсу калфагының кыр-кырында күренгән чал чәче, ирен өстендәге җыерчыкларның авызны ямьсез бөрештереп торуы — тулаем алганда, аны хәтта бу эше өчен дә картрак күрсәтеп тора иде.

Мин кыскача гына кем икәнемне, Рашат белән таныш булуымны, күптән түгел аның бу дөньядан киткәнен әйткәч, ул яшь медсестраны чакырып, үзе урынында ярты сәгать утырып торырга сорап, мине чәй эчә торган бүлмәләренә алып кереп китте.

Ясаган чәйләрне эчмичә, мин аннан-моннан йолкып сораштырып, ул теләр-теләмәс кенә җавап биреп, ярты сәгатьнең узганын сизми дә калдык. Күп нәрсәләр белдем мин үзем өчен шул ярты сәгать эчендә. Сөйләргә атлыгып тормаса да, миннән бернәрсә яшерергә теләмәгәне күренеп торды. Улының наркотиклар белән тотылып, төрмәдә утыруын да ничектер тыныч кына тон белән әйтте, әйтерсең лә ул язмыш агымына бөтенләй бирелгән һәм аңардан берни тормый. Кларaның коттеджны сатып, Казанга күчеп киткәнен, аның кызы, иреннән аерылып, ике бала белән калганын мәгълүм кылдым. Клара кызы, оныклары белән торадырмы — анысын Ризәлә белми иде.

Ризәлә үзе Рашат турында күп сораштырды. Мин белгән хәтлесен сөйләдем, хатыны Галияне мактадым. Рашатның соңгы көннәрен тәфсилләп бәян иттем һәм үзендә мәңге юылмаслык гаеп-гөнаһ тоеп китеп барганын аңлаттым.

— Рашат барысын да төгәл белми китте бу дөньядан, — диде Ризәлә әңгәмә ахырына таба.

— Нинди мәгънәдә?

— Туктар асылынмаган.

Мин хәтта урынымнан сикереп тордым:

— Асылынмаган?..

— Аны асып үтергәннәр, — диде Ризәлә тыныч кына.

— Моны каян, ничек белдең?

— Шул төнне аскы вахтада торган сакчы Җәлил сөйләгәннән аңладым. Туктарны санитарлар бәдрәфкә алып кереп асып куйганнар. Бәлки башта буып үтергәннәрдер, аннары асканнардыр...

— Күргәнмени?

— Санитарларның бер-бер артлы бәдрәфтән чыкканнарын күргән.

— Ул санитарлар кайда соң?

— Нигә алар сиңа? Алар шул көннәрдә үк расчёт алып юкка чыктылар.

— Ә сакчы? Ул исәнме?

Ризәләдән какшамас битарафлык аңкый иде.

— Исән, — диде ул, кәгазь пакеттан стаканга су салып.

Миндә кичекмәстән шул Җәлил исемле сакчыны табу теләге туды.

— Кайда ул хәзер? — дидем мин, Ризәләнең әкрен генә сок эчкәнен түземсезлек белән көтеп.

— Синең аны күрәсең киләме? — дип халат җиңе белән авыз кырыен сөртеп куйды ул.

— Әйе... Мөмкин булса.

Ризәлә бераз шомраеп калды:

— Нигә ул сиңа? Бу эшне кузгатмакчы буласыңмы әллә?

— Юк, минем бернинди эш кузгатырга теләгем юк, — дидем мин һәм Ризаләне куркытмас өчен урыныма утырдым. — Ул да моннан качтымы әллә?

— Кем?

— Теге вахтадагы сакчы.

— Юк, Җәлил шушы шәһәрдә яши.

— Аның үзенең милициягә барып сөйләргә теләге булмады микән?

— Юктыр. Милициягә мөрәҗәгать итсә, аның үзен, син дә катнашкансың ул җинаятьтә дип, хөкемгә тартырлар иде. Бу эшне каезлауда, яңадан куптаруда мәгънә юк. Бу гаепне берничек тә юып булмый инде хәзер. Туктар белән Рашатны да бу дөньяга кайтарып булмый. Мин дә беркемгә сөйләмим, сакчы да сөйләмәсен, сез дә башкаларга сөйләмәгез.

— Шулай да, теге Җәлил дигән сакчыны күрергә иде, — дидем мин, үзем өчен инде эчемдә бу карарны кабул итеп.

Ризалә, ниятемне аңларга тырышып, мине җентекләп күзәтергә тотынды.

— Аны күрү сиңа нигә? — диде ул, төссез караш белән йөземә текәлеп.

— Минем анардан дөресен ишетәсем килә, — дидем мин, озаккарак сузылган әңгәмәдән туя башлап.

— Ә дөреслек ник кирәк сиңа? — дип бәйләнүен дәвам итте ул.

Мин китәргә дип кузгалдым. Ризалә дә, капылт кына торып, каршыма басты һәм тагын чыраема нидер эзләгәндәй карап торды.

— Белгәннәремне кайсыдыр инстанциягә барып сөйләргә җыенмыйм, — дидем мин, Ризаләне тынычландырырлык тон белән. — Мин — язучы. Миңа Рашат бу вакыйга турында кайчан да булса әсәр язарга кушты. Курыкма, исемнәр үзгәртеләчәк, шәһәр исемнәрен башкача атармын, вакыйганың кайда барганын, кемнәр катнашканын аңламаслар.

— Җәлил диспансердан киткәннән бирле культура йортының вахтасында утыра, — диде Ризалә, тагын стаканга сок салып.

— Бергә бармыйбызмы янына? — дидем мин, Ризаләне үзем белән алып барырга теләгәннән түгел, ә җаны тыныч булсын һәм миңа ышансын өчен.

— Юк, бармыйм. Үзегез генә барыгыз.

— Ярар, — дидем мин, аның миңа иярмәвенә эчтән генә куанып. — Мин табам аны. Сез әйтте димәм.

— Әйтсәң дә ярый. Миңа барыбер. Сөйләшкәндә шомлануларым куркудан түгел, болай гына, галәт буенча гына. Куркудан узган инде мин. Яшисе килмәгәч, беркемнән дә, бернәрсәдән дә курыкмый башлыйсың икән ул.

## 26

Культура йортының өске өлешендәге «Чулпан» дигән язуны мин әллә каян ук күреп алдым. Керү ишеге янында исә «Район культура сарае» дип язылган иде. Дежур торучы базык гәүдәле олы яшьтәге агай мине танып алды һәм тавышы гыж-кыж килеп торса да, кычкырып, культура йортын дер селкетте.

— Зөлфәт әфәнде, хуш киддегез! Какими судьбами? Фирая! Сәбилә! Карагыз әле кем килгән! Зөлфәт Хәким килгән!

Шул арада вахта янында унбишләп кеше җыелды, мондагы хезмәткәрләр, күрәсең — араларында берничә ир кеше дә бар иде. Һәрберсе кул биреп күрешкәч, озын гәүдәле ханым директорының каядыр киңәшмәгә киткәнен әйтте.

— Сез концерт белән килергә җыенасызмы әллә? — дип кызыксынды ул.

— Юк, — диюем булды, халаты, бите, куллары буяу белән тапланып беткән яшь егет (мөгаен, рәссамдыр):

— Спектаклегез киләме әллә? — диде.

Җавабым аларны гаҗәпкә калдырды:

— Миңа монда вахтёр булып эшләүче Җәлил исемле кеше кирәк иде, — дидем мин.

Культура хезмәткәрләре, бер-берсенә карап, ни уйларга да белми торганда, мине каршы алган вахтёр Җәлилнең сменасы иртәгә икәнне әйтте. Вахтёр белән кызыксынуымның сәбәбен беркем дә сорарга базмады. Озын гәүдәле ханым үз бүлмәсенә чәй эчәргә чакырган иде, мин, рәхмәт әйтеп баш тарттым, күрәсең, ул аулакта вахтёрга минем ни йомышым төшкәнне белергә теләгәндер.

Җәлилнең өенә шалтыратып: «Казаннан Зөлфәт Хәким килде, синең белән очрашырга тели», — диделәр.

Кырык минут чамасы вакыт үтте микән, Җәлил — урта буйлы, урта тазалыктагы ир-егет тиргә батып, еш-еш сулап килеп тә житте. Житмәсә, бер аякка аксый икән, җәяү йөрүнең авырлыгы кыяфәтенә чыккан иде.

Минем яшьтәге кеше иде ул. Җәйге фуражкасын салып, битендәге тирне сөрткәч, миңа шактый вакыт елмаеп карап торды.

— Яшь чакта озын чәчле идегез сез, муеныгызга гитара асып, телевизордан җырлаганыгызны хәтерлим, — диде ул.

Җәлил хәзер дә минем концертларым буенча берәр эш кушарга чакырганнардыр дип уйлаган икән — аппаратура ташыргамы, аларны урнаштырыргамы, кыскасы, шуныңише йомыш буенча.

Концерт белән түгел, шәхсән аның янына килүемне белгәч, ул сагаеп калды. Ә инде мәдәният йорты каршындагы эскәмиягә утырып, мин психодиспансердагы вакыйганы искә төшергәч, ул бөтенләй куркуга калды. Мин аңа барысын да кыскача аңлаттым һәм аның әйткән бер сүзе дә миннән ары беркая, беркемгә китмәячәгенә ышандырдым.

Берәр кайчан әсәр язылса да, анда аның исеме башка булачагын, вакыйганың бөтенләй чит тарафта барачагын әйттем.

— Мин заводта эшләгән чакта, плитә астында калып, бер аягымны югалттым, бер аяк протез минем, инвалид мин, — дип башлады ул сүзен. — Шуңа күрә мин күп еллар инде йә сакчы, йә каравылчы, йә вахтёр булып эшлим. Ул көнне мин дежурствоны кабул иттем, андый-мондый хәвеф-хәтәр билгесе юк иде, диспансерда тынычлык, тәртип хөкем сөрә иде, — дип дәвам итте ул. — Төнге унберләр тирәсендә өченче катта бик каты кычкырган тавыш ишетелде. Гадәттә, анда уколлардан соң кабер тынлыгы урнаша, пациентларны кайвакыт уята да алмассың. Анда төнгә, гадәттә, ике санитар кала торган иде — таза беләкле егетләр. Минем пост аста, керә торган төп ишек катында гына булса да, өченче катка менеп, санитарлардан нинди тавыш булды икән ул дип сорарга булдым. Коридорга менү белән, медперсоналга гына керергә ярый торган бер урынлы бәдрәфтән санитарның чыкканын күрдем. Ул миңа таба атлады. «Монда бик каты кычкырдылар шикелле», — дидем мин аңа. «Кем кычкырсын, — диде ул. — Барысына да көчле уколлар кадалган, кычкыру түгел, ыңгырашучы да юк. Барысы да йоклыйлар». Мин санитарның күзләрендә курку шәйләдем, кулларының калтыранганын сиздем. «Синең зажигалкаң бармы?» — ди бу миңа. «Бар», — мәйтәм. «Әйдә, тәмәке тартабыз, — дип, ул мине коридордан чыга торган ишеккә таба этеп диярлек алып китте. — Монда сакчылар менәргә тиеш түгел... Син аста гына торырга тиеш». «Бик каты кычкырдылар», — дип кабатладым мин. Чөнки монда нидер булганын күңелем сизде. «Урамда кычкырганнардыр...» — ди бу миңа. «Ә икенче санитар кайда?» — дип сорадым. «Санитарлар бүлмәсендә», — дип җавап бирде ул. Шул вакытны мин бәдрәфтә су агызганнарын ишеттем. Минем белән сөйләшеп торучы санитар бит әле генә шуннан чыкты. Аннан соң анда беркемнең кергәнен күрмәдем. Санитар мине баскыч мәйданчыгына алып

чыгып житешалмады, бәдрәфтән икенче санитар да килеп чыкты. Мин аптырап киттем — болар икәүләшеп бәдрәфтә булдылар микәнни? Икенче санитар бер мәлгә безнең якка карап торды да, кызу-кызу атлап, коридорның теге башына китте. Аның да үзен тотышы бик сәер тоелды миңа. Ярар, боларның берсе унитазда утырганда, икенчесе умывальникта кул югандыр дип уйлап, зажигалкам белән санитарның сигаретын кабыздым да аска төшеп киттем. Иртәнге якта шау-шу купты — служебный туалетта пациент асылынган!

Мин төнлә тавыш ишетүем турында, өченче катка менүем турында милиция-мазар килгәнче үк баш врачның үзенә генә сөйләгән идем, ул мине кабинетында бикләп калдырып, каядыр чыгып керде, аннары Кафил Әхәтович янына керергә кушты. Ул исә миңа тукырга тотынды: «Туктар служебный туалетка кереп асылынган. Аны санитарлар күрми калганнар. Санитарларның служебный бәдрәфтән чыгулары табигый. Ул вакытта әле Туктар палатасында йоклап яткан. Син үзеннең өченче катка менгәнеңне беркемгә дә әйтә күрмә. Сиңа шик төшәчәк — чөнки син өченче катка менәргә тиеш түгел, синең постың — беренче катта, ишек төбендә. Югыйсә син өченче катка ник менгәнеңне исбатлый алмаячаксың. Мәетне сиңа «элеп» куюлары ихтимал». Минем ул вакыттагы халәтемне аңлыйсыздыр инде, — дип тәмамлады бәянын Җәлил һәм күкрәк тутырып тирән сулап куйды.

— Нишләп служебный туалетта асылынган, уртак бәдрәфтә түгел диган сорау калыкмады микәнни? — дидем мин, Җәлил бераз хәл алганнан соң.

— Нишләп калыкмасын, — диде ул, нәкъ шул сорауны көткән сыман. — Аны болай аңлаткан булдылар инде: имештер, уртак бәдрәфтә асылынып үләргә мөмкин түгел, анда бау эләктерергә дә, каеш эләргә дә бернинди урын юк, шуңа күрә медперсонал бәдрәфенең өстәге смывной бачогына простынясын бау иттереп бөтереп эләктергән дә асылынган, имеш. Мин үзем күрмәдем. «Ник бикләп йөрмисез служебный туалетны?» — дигән сорауга: «Кайвакыт онытыла инде», — дигән булдылар. Шул ук атнада теге санитарлар юкка чыкты. Увольняться иттеләр дә каядыр олактылар. Миңа да эштән китәргә боердылар. Мин боермасалар да киткән булыр идем, пәрәме шул ук көнне.

— Җәлил, ихластан әйт әле, — дидем мин, кулымны аның иңенә куеп. — Син соң нинди фикердә — Туктар үзе асылынып үлгәнме?

— Юк, аны теге ике санитар буып үтерделәр, шигем юк! — диде ул, һич кенә дә курыкмыйча.

— Ни өчен икәнне белмисеңме?

— «Мине монда гомерем ахырына кадәр яткырырга акча түләгәннәр!» дип скандал куптарган булган ул. Шуңа аны юк итәргә булганнар дип уйлыйм.

— Синең Туктар хакында Ризәлә белән сөйләшкәнең булгандыр? — дидем мин, ләкин бу сорауны ник биргәнемне үзем аңламадым.

Җәлил, кинәт миңа борылып:

— Әйе, сөйләшкәнем бар, — диде. — Ышанычлы кеше ул.

— Ышанычлы кеше юк бу дөньяда, Җәлил, — дидем мин, китәргә җыенып.

Минем бу сүзләрем аны шүрләтте булса кирәк, ул каршыма басып шактый вакыт миңа текәлеп карап торды.

— Сез мин сөйләгәннәрне беркемгә дә житкермәгез инде... — диде ул, күзләремә карап. — Мин сезне бик хөрмәт итәм.

— Юк, юк, борчылма, — дидем мин. — Рәхмәт сиңа ихластан сөйләвең өчен. Ә шулай да барыбер ышанычлы кеше булалмый бу дөньяда. Бер-берсен аңларга тырышучылар гына була ала. Аның анысы да бик кыйммәт.

...Казанга кайтып китәр алдыннан, мин тагын Ризәлә янына кереп чыктым.

— Рашат Туктарның үзенә кул салмаганын белмичә китеп барды... — диде Ризәлә, уйга калып.

— Белгән сурәттә дә Рашат үзендә гаеп тояр иде. Туктарның күзләрен ачмаган булса, баш күтәрергә этәрмәгән булса, бәлки ул вакыйга үлем белән тәмамланмас иде.

— Язмагыз бу турыда, — дип пышылдады Ризәлә, күзләрен йомып.

Бу хатын соңгы вакытта бик күп елаган ахрысы, аның күз яшьләре дә калмаган иде бугай инде. Ләкин картаеп барган көнендә ирсез яшәүче, наркоман малаен төрмәдән көтүче бу шәлперәйгән хатынга миндә (ни гаҗәп!) бернинди кызгану хисе уянмады.

— Теге Эдик монда яшиме һаман?

— Ул Мәскәүдә хәзер. Кем әйтмешли, «Большому кораблю — большое плавание». Анда зур бизнес белән шөгыльләнә, диләр.

Безнең бүтән сөйләшер сүзебез юк иде. Җан газабыннан котыла алмыйча иза чигүче бу хатынга кем нәрсә белән ярдәм итә ала? — дип уйлап куйдым мин шул мәлдә. Ул үзенең гаебен таный, шуңа күрә газапны да табигый итеп кабул кыла шикелле иде.

...Казанга кадәр ике сәгатьлек юлны мин ашыкмыйча гына үтәргә уйладым. Нәрсәгә ашыгырга? Кая ашыгырга? Гомумән, бу дөньяда ашыгу кирәкме икән? Синең ашыгуыңнан файда бармы? Ашыгуыңның кадерен беләләрме?

Хәзер Казанда Универсиада бара. Кемдер ярыша, кемдер тамаша кыла, кемдер күңел ача, ял итә. Кафилләр дә бар анда, Кларалар да. Безнең Казан әллә кемнәрне үзенә сыйдыра ул, әллә кемнәрне үз кочагына ала — кеше үтерүчеләрне дә, ришвәтчеләрне дә, уйнашчыларны да... Бәлки Кафил белән Клара очрашырлар да әле Универсиада трибунасында...

...Рашатның вафатыннан соң ел ярым вакыт узды, әмма ул минем уемнан чыкмый. Ул сөйләгән вакыйга миндә гомерем кояшы баеганчыга кадәр яшәр. «D» каласының психо-неврология диспансерында газап элмәгеннән ычкына алмыйча харап булган Туктар да гел исемдә. Аның газабы Рашатка күчкән, шуна озакка чыдамады ул олы җанлы кеше.

Алар бу дөньядан киттеләр.

Аларның язмышлары хәтеремнең тирән бер бураэнасына кереп ятты да мине торымнан торымга тынгысызлап тора.

Алар бу дөньядан киттеләр.

Газаплары миңа күчеп калды.

Газап беркая да китмәде.

Газап миндә хәзер.

*2014 ел, 25 август — 29 октябрь.*



Гөлнур
Айзат

# ТОРМЫШ БИТ УЛ – МИЗГЕЛ ГЕНӘ

## Мин әтиле идем

Мин әтиле идем! Әти — минле!
Нинди матур, рәхәт бергәлек!
Тормыш дигән олы болынлыкның
Кай жирендә генә йөрмәдек!
Һәрбер кошның тавыш-моңын тынлап,
Һәр агачка карап тукталып,
Урманында яз-жәй вәйран калып,
Йөрдек әти белән сокланып.
Чикләвеген жыйдык көз житкәчтен,
Капчык-капчык — нинди бай урман!
Мин әтиле идем! Истәлекләр
Күңелемә битләп язылган...
Һәрбер көннең үз шатлыгы белән
Үз борчуы калган язмада.
Кыен икән әти китеп баргач,
Ямь юк хәтта ямьле язда да!
Йөрәгемдә туган хисләремне
Әти өчен салдым жырларга.
Бүген шуна күңел канатлана,
Әти турындагы жыр барга!

## Синле күзләр

Күзләремә сәлам язып салдым,
Киткән кошлар белән кайтыр ул...
Синле күзләр миңа шундый якын,
Синле күзләр шундый матур ул!

Сары яфраклардан сары келәм,
Син киләсең шуннан нур чәчеп.
Кулларыма сары чәчкә суздың,
Узучылар калды көнләшеп.

Гөлнур АЙЗАТ — *шагыйрә; «Күз яше ачы була», «Өч мизгел», «Әманәт» исемле китаплар, күпсанлы жырлар авторы. Буа шәһәрендә яши.*

Сары күзләр бигрәк ямьле быел —
Син булганга микән янымда.
Күңелемдә һаман кояш балкый,
Синең нурдан күзләр чагыла.

Күзләр миңа сагыш китермәде,
Мәхәббәтле итте йөрәкне.
Бәхетләрдән күккә ашар өчен,
Күзләр дә соң әллә кирәкме?

## Китеп барам

Китеп барам... Синнән бөтенләйгә...
Эзләремне күмә тузаннар.
Бу юллардан синең белән бергә
Ничә тапкыр икәү узган бар!

Китеп барам. Әллә җиңелме соң
Мәхәббәттән китү яратып?!
Онытырмын, «вакыт — дәва», диләр,
Синсез дә кич җитәр, таң атар!

Китеп барам. Соңгы мәхәббәтем!
Ялгыз гына, дәшми... тын гына...
Безнең сердәш пар наратлар гына
Кушылалар күңел моңыма...

## Мизгелләр

Тормыш бит ул — мизгел генә,
Гел истә тотсын кеше!
Нинди көчле күренсә дә,
Тузан бөртеге төсле!
Әле генә бәхетле ул —
Елмая, уйный, көлә...
Бер минуттан ни булырын
Бер Ходай гына белә!
Сәяхәткә чыккан була,
Иң газизләрен алып,
Белми ләкин югаласын,
Күкләрдә ялгыз калып...
Белми: кайда көтә аны
Һәлакәт дигән афәт,
Белми ничек үләсен дә,
Байлык эчендә яшәп...
Бер мизгел җитә гомергә
Селтәнергә язмышың.
Киткәннәр китә калдырып
Якыннарга сагышын.
Корыч кошлар һаман саен
Гомерләрне кискәли...
Сабыйларның үлемнәре —
Йөрәкне иң кискәне!

Кайтмас башка өйләренә
Йөзләгәннәр — юк бүтән.
Ишетелә кыр казыдай
Тавышлары тик күктән.
Кайтавазлар, кайтавазлар
Күкләрдә калганнарның...
Ниләр генә төзәтер соң
Көткәннәр яраларын?!

## Сагыш

Гомерең буе мин дип янгансың да
Еллар буе җавап көткәнсең.
Вакыт арабызга дивар корган,
Сонладым мин, ташлап киткәнсең...

Куеныңда йөрткән сурәтемне
Учларыңа кысып тоткансың.
Соңгы сулышыңда исемемне
Бер тамчы су белән йоткансың...

Ә мин җүләр, моны белмәдем дә,
Сизмәдем дә, инде сонардым...
Мина бүген үпкәләрең житте,
Мине көтеп узган елларың...

Хәбәр китерделәр сонга калып,
Үзгәртәлмәм, хәер, кирәкме?!
Соңгы сәламенне — сурәтемне,
Учка кыстым тоеп йөрәкне...

## Тормыш

Үткәннәрне уйлап елар чакмы?
Күз яшендә бармы юату?
Тормыш — көткәненне эзләп табу,
Тормыш — тапканыңны югалту!

Дус дигәнең дошман булып чыга,
Дусның агуыннан баш яна!
Яратканнар — очрашудан курка,
Онытулар шуннан башлана...

Дога сыман гел кабатлап әйтәм:
Булма куркак, булма мескен дә!
Курыкканнар өчен юк дәрәҗә,
Юк ихтирам җирдә мескенгә!

# *«Казан утлары» архивыннан*



*Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»н төрмәдә исән-сау саклап калган фидакяр шәхес — бельгияле Андре Тиммермансның Казанга килгәч, университетта очрашу мизгелләренең берсе. Уңнан сулга: А.Тиммерманс, М.Нужин (университет ректоры), Тиммермансның хатыны һәм галим Х.Госман. 1966 ел.*



*Репрессия елларының ачысын үз җилкәсендә татыган язучы, фронтовик Гурий Тавлин (1925-1998).*



*Төрле елларда унбиш елга якын «Казан утлары» журналында хезмәт куйган күренекле тәнкыйтьче, тәрҗемәче Фәрваз Миңнуллин (1934-1994).*



*Галим-фольклорчы, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ленар Җамалетдинов. Быел аңа 80 яшь тулды.*




*Быел шулай ук үзенең юбилеен үткәрүче мөхәррир, публицист Эльмира Закирова (ул вакытта «Ялкын» журналының баш мөхәррире) Муса Җәлилнең туруны Таня һәм оныкчыгы Миша Малышевлар белән. 2006 ел.*



*«Казан утлары»ның 1000 нче саны чыгу уңаеннан Г.Камал театрында үткәрелгән тантанада катнашкан бер төркем язучылар һәм галимнәр. Сулдан уңга: Зәки Зәйнуллин, Мөдәррис Әгъламов, Зиннур Хөснияр, Ркаил Зәйдулла, Марат Закиров, Искәндәр Гыйләҗев. 2006 ел. 10 апрель.*

# ИКЕ ДАҺИ ДУСЛЫГЫ

ХӘСӘН ТУФАННЫҢ ТУУЫНА 115 ЕЛ



*Бөекләр бер-берсен яратмый, ул гына да түгел, күрәлми... Талантлар бер-берсеннән көнләшеп, үҗәтләшеп иҗат итә... Һәм бу көнчеллек бәйгесе еш кына фаҗигагә дә илтергә мөмкин... Моцарт белән Сальери язмышы — моңа ачык мисал...*

*Шушы фикер «сары» матбугат битләреннән, телевидение-радио тапшыруларыннан бертуктаусыз агылып, гади кешенең миенә сеңдерелә, үрмәкүч авы кебек аның күңелен уратып ала. Нәтиҗәдә, рух илчесе булган сәнгать кешесенең, зыялының абруе төшә, әдәбият-мәдәniяткә игътибар талантларның үзара низагларына, шәхси тормышына кайтып калып, гаилә-түшәк яссылыгына кучә... Халык исә, үзе дә сизмәстән, акны карадан аермас сарык көтүенә әверелә бара...*

*Әйе, зыялылар, милләтнең йөзек кашлары арасында бер-берсенең талантыннан көнләшү аркасында килеп чыккан үзара низаг-ызгышлар булмаган түгел — булган. Һәм алар әле дә бар. Хәтта якын туганнар арасында да очрый андый хәлләр. Ләкин бу — типик, кагыйдәгә әверелгән күренеш түгел. Чын талант иясе исә, һәр чорда да иҗатташының уңышларына сөенеп, аны үзенә үрнәк итеп куеп яшәгән һәм яши. Эчкерсезлек, гадилек — бөеклек күрсәткече ул. Татар һәм башкорт шигърияте күгендә мәңгелеккә балкыган йолдызлар Хәсән Туфан һәм Мостай Кәрим дуслыгы шушы ихлас мөнәсәбәтләрнең ачык бер мисалы булып тора.*

Мостай Кәрим Хәсән Туфан шәхесе һәм иҗаты белән узган гасырның утызынчы еллар башында ук, Чишмә районы Келәш авыл мәктәбендә укып йөргәндә, татар әдәбияты дәресләрендә таныша. «Беренче күргәндә, мин аны килештереп житмәдем. Кырыс йөзе, бигрәк тә иңбашына төшеп торган тузгак чәче (Пушкинныкы кебек бөдрә булса, бер хәл әле) күңелгә ятмады. Күрше Боголюбовка авылындагы чиркәү кагучы Семённың башы әнә шундый. Әтиемнең знакумы ул. Сүз, әлбәттә, Хәсән Туфаның дәреслек битендә басылган сурәте турында бара», — дип яза ул әдиптән беренче тәэссоратлары турында. Туфанның төс-кыяфәте матурлардан булмаса да, анын шигърияте яшь Мостафа күнелендә җуелмас эз калдыра. «Андагы фикерләр һәм образлар яфрак өстендә әллә кайдан күренеп яткан вак кызыл җиләк түгел иде, ә яфрак астына посып, сыгылып-сыгылып төшкән сутлы эре җимеш иде. Моны табу һәм күрү өчен миңа байтак ел кирәк булды. Берзаман шулчаклы мавыктым, анын эзеннән ияреп китәсем килде. «Күршемнең теләге» дигән бер шигыремне «нәкъ Туфанча» китереп чыгарырга тырыштым. Ләкин килеп чыкмады. Туфанча язу өчен Туфан, тик Туфан гына булырга кирәклекне тиз аңладым. Әйткәндәй, әлеге иярчен шигырь теге елларда Хәсән аганын күзенә чалынган бердәнбер шигырем булган. Азактан үзе әйтте: «Шуны укыгач, бу малайда шаукым булмагае», — дип уйлаган идем.

Озын уналты ел буе: «Онытыгыз. Ул юк инде», — дип тылкыдылар. Аның барын-югын ачык кына белмәсәк тә, күңел онытмады, ялган әмергә буйсынмады», — дип билгеле Мостай Кәрим үзенең 1988 ел башында язылган «Хәтере калып китмәде» дип аталган истәлекләрендә.

Әйе, уналты ел буена татар әдәбияты Туфансыз яши... Муса Җәлил, Фатих Кәрим кебек шагыйрьләр иҗатын искә алмаганда, лозунг-шигарьләрне хәтерләткән буш, шалтыравык шигырьләр хакимлек иткән заман бу. Сталин репрессияләре, Бөек Ватан сугышы китергән югалтулардан милли әдәбиятыбыз әле дә арынып бетә алмады бугай... Һәм менә, ниһаять, 1956 елның июнендә Казанга сөргеннән Туфан кайтып төшә. Тимер юл вокзалында аны каршы алучы азсанлы әдипләр арасында Башкортстанның бердәнбер вәкиле — Мостай Кәрим дә була. Моның көлкеле-мәрәкәле үз тарихы бар. Кыскача гына әйткәндә, «Бер яманның бер яхшысы бар» дигән мәгълүм мәкальгә туры килә ул. Хәер, сүзне Мостай аганың үзенә бирик.

«...Миңа 1956 елның июнендә Казанда аны (Хәсән Туфанны. — *И.Ф.*) каршы алучылар төркемендә булу шатлыгы эләкте. Эләкмәскә дә мөмкин иде. Бик мөмкин иде. Уфа — Мәскәү — Уфа теплоходының капитаны ярдәм кулы сузды миңа. Ул болай булды. Мәскәүгә барып әйләнергә, дөнья күрергә, әз-мәз языштырырга ният итеп, теплоходка утырдым. Каютама керсәм, анда бер әби урнашып алган. Мин капитанга бардым. Ул балалар уенчыгы «Ванька-встанька»га охшаган бер кеше булып чыкты. «Борчылма, — диде капитан, — бүтәнне табарбыз». Тар гына караңгы бер каютага мактый-мактый илтеп кертте.

— Әйбәтме? Каютаны әйтәм.

— Әллә инде. Ару бугай.

— Шәп бит! Үзеннекеннән дә шәбрәк. Янәшәңдә генә ресторан.

— Алай әйбәт булгач, әйдә, котлыйк. Ресторан эшлиме?

— Эшли. Хәзер әйтәм.

Ул чыгып, официантканы ияртеп үк керде.

Һәм башланды котлашу... Кают-компанияне дә, капитан мостигын да, радиорубканы да котладык. Котламаган җир калмады. Томанлы бер иртәдә комга утырып та тордык. Шөкер, тиз ычкындык алай. Өченче көнне, таң яктырганда, Казанга килеп җиттек. Минем Идел агышына каршы ары йөзәрлек хәл дә, капитал да калмады. Казанда төшәргә ниятләдем. «Ванька-встанька» елардай булып боегып калды. Гомер буе рәхмәт укыйм капитанга. Әгәр минем каютама теге әбине урнаштырып, миңа «аннан да әйбәтрәген» бирмәсә, Казанга кул болгап кына уза торган кеше идем мин, югыйсә.

Татарстан Язучылар союзында «иртәгә фәлән сәгатьтә фәлән поезд белән Туфан кайта» дигән хәбәр таралды. Иртәнге мәлдә яңгыр сибәләп торды. Вокзалга күмәкләшеп төшмәдек бугай, һәркем үз юлы белән килде. Халык күп түгел иде. Сибгат Хәкимнең, Габдрахман Минскийның, Гали Хуҗиның, Баян Гыйззәтнең, Мостафа Ногманның барлыгын хәтерлим. Бүтәннәре истә калмаган. Кешенең аз булуы мине бераз сәерсендерде. Соныннан төшендем: имеш, Туфан әле бөтенләй акланып кайтмаган икән. Белмәссең дөнья хәлләрен... Артыннан этәрмәгәндә, нигә тагылып барырга?


Вагоннан нәкъ үзебез көткән Хәсән Туфан сикереп төште. Әмма ул һәркемгә колач җәергә ашыкмады, сабырлык күрсәтте. Бәлки, ятсыну да, тартыну да, ниндидер кимсенү дә булгандыр. Яу җинеп кайтмаган бит. Ачылган кочакка ихлас омтылды.

Вокзал мәйданына чыктык. Яңгыр тагы сибәли башлады. Баксаң, көтеп алган кешебезне өенә илтергә машина юк икән. Нигә алдан уйланмагандыр инде. Ул чакта машинага кытлык әлләни түгел иде инде... Сәбәбе бүтәндә булыр. Үкенеп кенә түгел, әрнеп әйтәм монысын: янәсе, Туфанны каршылау рәсми вакыйгага әйләнергә тиеш түгел. Җәяүледән җавап аз.

Яшь чагында Баян Гыйззәт бик чос, житез була торган иде. Якындагы яшел «Москвич»ның ишегең җәһәт кенә ачты да шоферга кычкырды:

— Туфан кайтты бит!

— Кем? Кем?



— Туфан!!!

— Нинди Туфан? Кайтса ни...

Мондый ангыралыкка исе киткән Баян ишеккә башын бөтенләй тыкты. Кызу аңлашу китте. Тиз арада яшел «Москвич» тырылдый да башлады. Туфан, Минский, тагын кемдер икәү машинага утырып китте, калганнарыбыз үз җаебыз белән Туфанның өенә юнәлдек. Анда безне пилмән пешереп көтәләр иде.

Бу мәҗлестә сөйләнгән сүзләрне мин язып та, телдән дә хәтергә төшерәләдем. Әмма Хәсән Туфанның ничәмә еллар аерылышудан соң үз өендә әйткән иң мөкатдәс сүзләрен кат-кат искә алам. Без аның «тегендәге» хәл-әхвәлләрен сорашып, аңа кызгану, юату тойгылары белдерә башлагач, ул кырт кисте:

— Монысын куегыз әле, егетләр. Әйдәгез, үзебезнең әнкәбез Әдәбият, һәрберебезнең сөйгән яры Поэзия турында сөйләшик. Тансыклар канганчы сөйләшик.

Авыр сәгатьләрдә, кыен елларда күңел төшенкелегеннән, өметсезлектән мине нәрсә коткарып калган икән аны — әнкәбез Әдәбият, сөйгән ярыбыз Поэзия...»

Күрәсең, бу очрашу Туфан күңелендә дә суынмас эз калдыргандыр. Чөнки, еллар үтеп, яшь башкорт шагыйре инде данлыклы Мостайга әверелгәч, Хәсән Туфан үзен сөргеннән каршылау мизгелләрен күз алдыннан кабат-кабат үткәреп, истәлек караламаларында болай дип яза:

«Синең дөньяда бармы-юкмы икәнеңне белмәгән хәлдә, вагоннарга, каршылаучыларга карыйм. Әнә анда... кем ул? — «Бер яшь шагыйрь. Ул — Уфадан». Аннары без өйдә. Өлкән шкаф... Уналты ел үткән... һаман пичәтле. Шушы өйдән — шушы очрашудан кереп киттек бүтән гомергә без! Киләчәктәгесенә, минә хәзергесенә... <...>

..................................................................

*Тукайчылык белән Мостайлыкның*
*Интегралы булган осталык.*
*Мин Такташны күрдем һәм инандым,*
*Алданмадым,*
*Күргән кебек шигъри Алламны.*
*Синең белән дә мин, көтмәгәндә,*
*Ахыргача мәңгелеккә гүя ялгандым.*

*Истәлек ул бу көн синең, Мостай,*
*Аһәңең үк синең классик, бүтәнчә,*
*Асылда бит бу чор — Бабичларны*
*Инкарь иткән кырыс власть бит».*

Аңлашылуынча, шагыйрь күңелләре уртак дулкыннарда тибрәлеп, бер-берсенә аваздашлык, аһәңдәшлек тапкан була инде. Тимер юл вокзалындагы танышу, еллар сынавын үтеп, граниттан да ныграк дуслыкка әверелә. Туфан белән Мостай бер-берсе белән даими очрашып тора, хатлар алыша, телефоннан сөйләшә. Болар барысы да Хәсән ага Туфанның 2010 елда дөнья күргән биштомлыгында тәү тапкыр басылган көндәлекләрендә һәм хатларында ачык чагыла. Мәсәлән, «Көндәлек»ләрдән күренгәнчә, 1963 елның 10-16 гыйнвар көннәрендә Туфан Уфада була. Башкортстан Язучылар берлегенең чираттагы съездында катнаша; Башкорт дәүләт университетында студентлар каршында чыгыш ясый; каләмдәш-дуслары Кадыйр Даян, Баязит Бикбай, Сәйфи Кудаш, Гыйлемдар Рамазанов, Ибраһим Абдуллин, Рәми Гарипов, Муса Гали, Нажар Нәжми, Фәрит Исәнголов, Әхтәм Мансур, Рафаэль Сафин, күренекле сәхнә осталары Арыслан Мөбарәков, Фәридә

Кудашева һ.б.ларда кунак була. Кая гына бармасын, өлкән әдипне Мостай Кәрим озатып йөри. Ул аны тәүге көнне Уфа вокзалында каршылап, соңгы көнне шуннан ук Казанга озата. Шул ук елның 7-11 февраль көннәрендә инде Башкортстан делегациясе составында Мостай Кәрим Казанга, Татарстан Язучылар берлеге съездына килә һәм, кунакханәгә урнашып тормыйча, Хәсән Туфанның йортында яши.

Күрәсең, ике әдипнең дуслык мөнәсәбәтләре бик тыгыз булгандыр, чөнки Туфан көндәлекләре шактый киселеп, күп кенә шәхси әйберләр басмага кермәгән. Мәсәлән, 7 февраль көне түбәндәге бер җөмлә белән генә чикләнә:

*7/II «... Язган хатны яктым, Хәсән абый: андый нәҗесне Казанга китерәсем килмәде», — ди Мостай».*

Нинди хат бу? Туфан өстеннән югары даирәләргә (бу очракта: Башкортстан язучыларына) язылган шикаять-доносмы, әллә, киресенчә, Мостайның шундыйларга җавабымы? Мостай Кәримнең үзен тиргәп-сүгеп, Казаннан җибәрелгән хат булуы да бик ихтимал. Кыскасы, фаразларга гына кала. Тик шунысы төгәл мәгълүм: Фатих Мөсәгыйть кебек «тәнкыйтьче»ләрнең Хәсән Туфанны матбугат аша кыйнавы 1970 еллар ахырына кадәр дәвам итә. Яндырылган хат шуның шаукымы булырга да мөмкин.

Ике шагыйрьнең үзара язышкан хатлары да сакланган. Дөрес, әлегә Хәсән Туфанның Мостай Кәримгә язганнары гына дөнья күрде. Аларның да тик өчесе — 1960 елда язылганнары гына. Мостай Кәримнең Туфанга хатлары да вакыты җиткәч (башкорт шагыйренең 100 еллыгына булса, бигрәк тә яхшы!), басылып чыгар дип өметләнәм. Чөнки алар инде әлеге ике шагыйрь, ике шәхеснең генә түгел, ә, гомумән, ике халык, ике милләт — татар һәм башкортның уртак хәзинәсе. Рухи хәзинәсе...

Туфанның Мостайга язган хатлары каләмдәшенең шәхесенә тирән ихтирам, иҗатына саф сөю белән сугарылган. Шул ук вакытта үз шигърияте карата тыйнак мөнәсәбәт (хәтта артык тыйнак!) күзгә бәреп тора. Мәсәлән, 1960 елның 1 сентябрендә язылганында Хәсән Туфан болай ди:

*«Мин үзем өчен түгел, синең өчен шат: мин, әйтик, кайбер шигырьдә генә шагыйрь. Ә син шигырьдә генә түгел, мәкаләдә дә, мөгамәләдә дә; Казанда да, Кавказда да, Мәскәүдә дә; мәҗлестә дә — һәрнәрсәдә, һәркайда да тоташтан шагыйрь. Сагындыра да ала торган, үткән генә түгел, синдә иҗат, җанлы киләчәккә омтылыш булып тоелган сыйфат бар: киләчәкнең чиген тоя алу, ачык тоя алу көчле. Аның һәр сәгатеннән, һәр төне-көненнән матур яңалык табып булачагына ышанасың, билгеле. Синең шигырь, һәр яңа шигырь никадәр бәхет бирә: мин читатель бит. Һәм шактый азгын — һаман яхшыны гына эзләгән укучы».*

Бу сүзләргә бернинди өстәмә дә, аңлатма да кирәкми, минемчә. Барысы болай да аңлашыла. Шуны гына әйтик: Туфанның Мостай Кәримгә карата хәерхаһлы мөнәсәбәте аның Уфадагы каләмдәш-дусларына язган хатларында да ачык чагыла. Мәсәлән, 1978 елда Нажар Нәҗмигә 60 яшь тулу уңаеннан җибәрелгән котлау телеграммасы түбәндәге кереш сүз белән башлана: «Башкортстан һәм Татарстан әдәбиятында балкып яшәгән энеләрем һәм сеңелләрем бар. Алар — Бәшир (Гомәр Бәширов. — *И.Ф.*), Сибгат (Сибгат Хәким. — *И.Ф.*), Мостай һәм син, Нажар». Хәсән Туфанның иң якын дуслары исемлегенә керү — үзе үк тиңсез дәрәҗә инде ул, чөнки 1930 елларда бу мәсьәләдә авызы пешеп, күпләрнең хыянәтен кичергән шагыйрь дуслар сайлауга ифрат җитди карый, һәркемгә ышанып бармый.

Яшьлек дусты, «Галия» мәдрәсәсе буенча сабакташы Сәйфи Кудашка 1963 елның 22 апрелендә язган хатында Туфанның Мостай энесен зур акыл иясе, дипломатия осталыгына ия шәхес итеп санавы ачык күренә. Монда сүз Башкортстан китап нәшриятында татар телендә җыентыклар чыгара башлау турында бара. Хәсән ага Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудашка әлеге эшне Мостай Кәрим белән киңәшләшеп, берлектә башкарып чыгарга тәкъдим итә. «Бу мөһим мәсьәлә эшкә ашмаган изге ният кенә булып калмасын, кабул булмаган теләк кенә булып калмасын иде», — ди. Һәм, чынлап та, нәшриятта татар телендә китап бастыру эше җайга салына, 60нчы еллар уртасында берничә җыентык дөнья күреп тә өлгерә.

Әлбәттә, бу озакка бармый — республикада татар телендә китаплар 1990 елларда гына системалы рәвештә нәшер ителә башлый. Әмма Хәсән Туфанның шуңа омтылышы, Мостай Кәримне бу мәсьәләдә үзенә теләктәш итеп санавы — үзе үк зур мәртәбә, минемчә. Туфанның 1960 елда Башкортстан китап нәшриятында башкортча дөнья күргән «Күңел дәфтәреннән шигырьләр» җыентыгына кереш сүзне Мостай Кәрим язуы да шул өзелмәс дуслык хакында сөйли.

Әдипләрнең ел саен диярлек очрашып-күрешеп торуы турында алдарак билгеләп үткән идек инде. Алар иҗади сәфәрләргә дә бергә йөрешәләр. Мәсәлән, 1962 елда Казакъстанда узган Татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгында Туфан белән Мостай бергә йөреп кайталар. Кайту юлында, поездда Хәсән Туфан Мостай Кәримгә багышланган «Чарчадык шактый кунакта» исемле шигырен яза. 1972 елда Хәсән ага каләмдәшләре Сибгат Хәким, Нәҗар Нәҗми, Гыйлемдар Рамазановлар белән берлектә Урал таулары, Бөрҗән яклары буенча сәяхәт кыла. Сәфәрне оештыруда Мостай Кәримнең дә өлеше зур булуы хакында сөйләп тормасак та буладыр инде...

Ләкин Мостай Кәрим белән Хәсән Туфан очрашуларының иң истәлеклесе 1967 елның көзенә табан була. Монда башкорт шагыйре татар каләмдәшен үзенең туган ягы — Чишмә районы Келәш авылына алып кайта. Мостай аганың тормыш иптәше Рауза ханым белән Нәҗар Нәҗми дә аларны озатып йөри. Шагыйрьләр якындагы Кызлар тавына күтәрелә, Әүлия чишмәсенә барып, аның тешләрне камаштырырлык салкын суыннан авыз итә, шунда күмелгән дәрвиш каберенә баш ия. Хәсән Туфанның «Дәрвиш» кушаматы йөртүен исендә тотып, Мостай ага ана: «Дәрвиш белән дәрвиш күреште», — ди. Туфан, шаяруны кабул итеп, елмаеп куя.

«Шәйләми дә калдык, — дип дәвам итә Мостай Кәрим үзенең истәлекләрендә, — Бүләк арасы басуыннан бер төркем хатын-кыз чишмә янына төште. Алар башта зык кубып Раузаны сырып алды. Бу хатыннарның байтагы сугыш елларында Рауза апаларыннан дәрес өйрәнгән, бергәләп җәфалар кичергән. Тынычлана төшкәч, ят кунак белән тыйнак кына күрештеләр, шуннан Нәҗар белән миңа чират җитте.

— Сынабрак карагыз әле монавы агаегызга. Таныйсызмы? Йә? — диде Нәҗар.

— Әлләче...

— Таныш та кебек...

Авылда үткерләрдән, откырлардан саналган Гөлгайшә исемле кырыклар өстендәге хатын сөрәнләп үк җибәрде:

— Әстәгъфирулла! Танымаска тагы! Таныйбыз! Тома надан түгелбез дә! Үзебезнең Һади Такташ абыебыз ич бу! Рәхим ит! Хуш киләсез!

— Хәсән Туфан агайга охшатсам инде... — диде бер яшь килен.

— Дөрес охшатасың, — дип раслады Рауза, үзенең элекке укучысы Гөлгайшәнең хатасын төзәтүгә куанып.

Гөлгайшә дә тиз үк артка чигенмәде:

— Булсын! Булсын! Кайсы булса да әйбәт! Икесен дә яратып укыйбыз».

Менә шулай, келәшлеләрне зык кубарып, шигъриятькә, үзенә җаннарын әсир итеп, Туфан Казанга, Аккош күленә кайтып китә. Кайтыр алдындагы төндә, Келәш җирендә ул Мостай Кәримгә багышланган «Җил дә уйчан, каеннар да тынган...» дип башланган данлыклы шигырен яза...

Мостай ага билгеләвенчә, ике шагыйрьне «аралар да, вакытлар да аерып тормый». «Уфада да, Казанда да бер-беребезнең ишеген кагып та, какмый да кергәләп тордык, — ди әдип. — Хәсән Туфанга багышланган өемдәге беренче мәҗлестә кунак хөрмәтенә әйткән сүземне болай бетердем:

— Хәсән ага! Безнең өебезнең ишеге эчкә ачыла. Кулың буш булмаган чакларында аягың белән тибеп ач та рәхим ит! Һәрвакыт!

Хәсән ага сагаеп тыңлады. Бу мине шаяртмыймы дип, шым гына торып, тышкы ишекне ачып карады.

— Шулай икән дә ич!.. — дип куанды сабый табигатьле шагыйрь. — Минеке кайсы якка ачыла икән?

Без көлешергә керештек. Димәк, һәр квартираның тышкы ишеге эчкә ачылуга ул моңача игътибар итмәгән».



*Сулдан уңга: Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Мостай Кәрим.*

Әйе, шагыйрьләрнең фатир ишекләре дә, күңел ишекләре дә бер-берсе өчен ябылып тормый. Юл төшсә дә, төшмәсә дә, алар бер-берсе янына ашыга. 1968 елның бөркү июль көннәрендә Мостай Кәрим Горький шәһәреннән (хәзерге Түбән Новгород. — *И.Ф.*) машина куып кайтышлый, тезгенне (ягъни рульне) Аккош күленә тартып, Туфан йортының тупса төбенә килеп туктый. Кичкә кадәр икәүләп сөйләшеп утыргач, энгер-менгер төшкәч, алар татар әдипләре Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Абдулла Әхмәт, Риза Ишморат, тагын берничә язучы белән учак ягып, якындагы урманга бәрәңге тәгәрәтергә чыгалар. Иртәгесен иртән-иртүк Хәсән Туфан Мостай Кәримнең «лоцманы» булып, ана «Волга»сы белән кайтыр юлга чыгарга ярдәм итә.

«Ул мине нәкъ Уфа юлына чыгарып бастырды. Хушлашыр өчен без машинадан чыктык.

— Хәзер инде юлны белдем. Кире килгәндә адашмам. Әйдә, үзеңне Казанга илтеп куям, — дидем мин, — чынлап әйтәм!

— Оһо-һо! Шәбәйгән бу кучер егет.

— Алайса, әйдә, бергәләп Уфага китик.

— Моңысы ярап калыр иде дә...

— Әйдә машинага! Мөнҗиягә юлдан хәбәр бирербез.

Ул беравык икеләнеп торды.

— Юк инде. Шагыйрьләр булсак та, алдан уйланмаган эшне эшләр яшьтән узганбыз.

Ул юл читендә басып калды. Мин киттем. Азактан үкенде ул шул сәфәргә бергә чыкмаганына. Мин дә үкендем. Әле дә үкенәм...» — дип яза Мостай Кәрим 1988 елда.

Әлеге очрашуның үзенчәлекле җимеше булып, Хәсән Туфанның түбәндәге шигъри юллары кала:

*Менә шундый моңсу көннәремдә*
*Казаннарга килеп чыгасың да,*
*Аккош күлендәге ак каенга*
*Пегасыңны бәйләп куясың да,*
*Тик күршедән кергән кебек кенә,*
*Торагыма килеп керәсең...*
*Сагынуларым, димәк, сиңа, Мостай,*
*Барып җитә, җитә, күрәсең.*

Әйе, Хәсән Туфан гомер буе Мостай дустың, Уфадагы каләмдәшләрен сагынып яши. Мостай Кәрим билгеләвенчә, «шагыйрьләрне ул яшенә-картына, ыруына, затына аермады. Йә шагыйрь дип таныды, йә бөтенләй танымады. Сәйфи Кудаш, Сәгыйть Агиш, Баязит Бикбай, Кадыйр Даян, Нажар Нәҗми, Муса Гали, Гыйлемдар Рамазанов, Рәми Гарипов, Рафаэль Сафин, Әнгам Атнабаев һәм башка бәгъзеләр белән мәҗлес уртаклашты, дусларча әңгәмәләргә керде. Аның белән һәр очрашу дөнья ваклыкларын онытып торырга һәм тормышның, кешеләрнең, сәнгатьнең асылы турында уйланырга мәҗбүр итә торган иде».

Хәсән Туфанның Уфадагы дуслары янына соңгы килүе 1976 елның август аенда

була. Нәкый Исәнбәт белән бергә каләмдәшләрендә кунакта булып, яшьлегендә белем алган «Галия» мәдрәсәсенә, иҗатташы Рәшит Нигъмәти каберенә сәфәр кылгач, Нажар Нәжми аларны Агыйдел пристаненнан пароходка утыртып озатып кала. Ә инде Казанда Туфан йортыннан башкортстанлыларның эзе суынмый. Мостай Кәрим белән Хәсән Туфанның соңгы очрашуы 1980 елның ахырында, татар халкының бөек шагыйренә 80 яшь тулуга багышланган юбилей тантаналарында була. Биш көн буена әдипнең өеннән кеше өзелми. Сәйфи Кудаш, Мостай Кәрим, Нажар Нәжмиләр аның иң кадерле кунаклары була. Аларның берсе дә бу очрашу соңгысы булыр дип күз алдына да китерми. Ләкин язмышлардан узмыш юк шул... 1981 елның 10 июнендә Хәсән ага Туфанның йөрәге тибүдән туктый...

Бу урында Мостай Кәримнең Туфан дустының үлем тәэссоратларыннан туган юлларын китерү урынлы булыр. «Мин аның сырхау чагын да, кәрсез чагын да, өметсез чагын да күрмәдем, — ди ул. — Казан зиратында аның соңгы төяге янына килеп баскач та, монда Хәсән Туфан ята, дигән төшенчәне аңым кабул итмәде. Аяк очына кызыл чәчкә салдым. Чәчкә түгел, күкрәгемнән суырып алып, йөрәгемнең бер кисәген салдым».

Мостай ага Кәримгә Туфан рухын, Туфан шигърияте, дустының саф күңелен аның вафатыннан соң да якларга туры килә. «Үзгәртеп кору» чорлары житеп, татар җәмәгатьчелегенең билгеле бер өлешендә, аеруча яшь ислахчылар арасында, үткәннәрне кабаттан бәяләү, мәдәни мирасны ревизиягә тарттыру кебек омтылышлар барлыкка килгәч, Хәсән Туфанга каршы да уклар атыла башлый. Янәсе, совет җәмгыятенә каршы көрәшмичә, «гаделсез» система белән килешеп яшәгән икән ул. Димәк, нинди генә олы талант булмасын, милли әдәбият тарихында аңа урын юк. Һәм янә, сугыш елларындагы кебек, Мостай Кәрим Ватанын, яшьлек елларын, яу кырында ятып калган каләмдәшләрен, Туфан рухын яклап, төрле «иман саткан как башлар»га каршы күкрәге белән чыгып баса. Аның «Өч тулпар» (1991) шигыре Тукай, Такташ, Туфан рухларын шундыйлардан яклау өчен язылган. 2001 елда иҗат ителгән «Казан», «Сәфәр» шигырьләрендә дә бөек Туфанның күркәм образы гәүдәләнеш таба. Ә инде 1994 елга караган «Тәңребез төшемә керде» шигыренә эпиграф булып Хәсән Туфанның «Ходайны күрдем төшемдә» дигән мәгълүм юллары хезмәт итә.

Шагыйрь өлкән каләмдәше, остазы белән очрашу-күрешү, әңгәмәләшү мизгелләрен һәрчак күңелендә яңартып яши. Мәсәлән, аның гомер ахырында, 2001 елда иҗат ителгән «Таңгы сәгать иде» шигырендә Хәсән Туфан белән Аккош күле буенда очрашуы сурәтләнә. Туфанны югалту Мостай Кәрим өчен ярты җанын югалтуга тиң була дисәм дә, һич хаталанмамын, мөгаен. Соңгы елларында язылган шигырьләрендә мәшһүр Мостайның үткәннәрне, инде бакыйлыкка күчкән каләмдәшләрен сагынып яшәве ачык күренә...

Әйе, Мостай Кәрим белән Хәсән Туфан дуслыгын бөек затлар арасындагы эчкерсез, ихлас мөнәсәбәтләр мисалы буларак барыбызга да үрнәк итеп куярлык. Кыйблалар буталган, һәрнәрсә, шул исәптән дуслык та акча белән үлчәнгән бүгенге болгавыр заманда бигрәк тә...

**Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*Башкорт дәүләт университеты доценты,*
*«Тулпар» журналының җаваплы сәркатибе*

# КҮҢЕЛЕНДӘ ӘЛЕ НӘРСӘЛӘР БАР, — КОШЛАР ШУНЫ ҖЫРЛЫЙ НИБАРЫ...

***

*Хәсән Туфанга*

Сандугачка нигә буй-сын,
Нәрсәгә аңа бизәк?
Таңда бер сайрап җибәрсә,
Биш кат өзеләә үзәк.

Шагыйрьгә нигә чин кирәк,
Нәрсәгә аңа титул?
Патшалар ятлап алырлык
Шигырьләр яза бит ул.

*1968*

## Таңгы сәгать иде

*Сандугач баласы кебек*
*Шат яшәек дөньяда.*

Җырдан.

Берчак Туфан белән таң житкердек
Май башында «Аккош күле»ндә,
Кошлар сайрый, өзелеп сайрый кошлар —
Һәрберсе тик үз телендә.

Нәкъ Туфанча мөлдерәмә итеп,
Бокалларга коела ал шәраб.
Офык чите капылт чайкала да
Алсулыкка чума бар тараф.

Нурлар эчеп, отыры сайрый кошлар —
Газапмы бу? Бумы тантана?
Мин дустыма әйтәм: «Бөек шагыйрь,
Шуңа анык җавап тапсана».

«Миңа мәгълүм түгел аларның, — ди, —
Ни шатлыгы, җаным, ни зары.
Күңелендә әле нәрсәләр бар, —
Кошлар шуны җырлый нибары...»

Шушы булды җавап асылы —
Миңа гади бер сер ачылды.

*2001*

## Өч Тулпар

*Соңгы вакытта Казан матбугатында Тукай, Такташ, Туфанга карата кадерсез сүзләр күренгәли башлады.*

Татар Тукай, татар Такташ,
Татар Туфан. Тамаша!
Шушы затлар телемә килсә,
Җаным күкләргә аша.

Бу өч Тулпар тартып жилә
Татар рухы арбасын.
Сикереп төшмәс шул арбадан
Татар, кайда бармасын.
Пәйгамбәрен сатмас милләт
Әллә нинди хакларга.
...Әмма яман хәбәр-хәтәр
Килә безнең якларга:

Чүп ыргыталар Тукайга,
Таш аталар Такташка,
Хөкем итәләр Туфанны
Иман саткан как башлар.

Бу — халыкның тамырына
Балта чабу түгелме?!

Шундый хәлләргә шаккатып,
Рәнҗи башкорт күнеле.

Татар Тукай, татар Такташ,
Татар Туфан. Тамаша!
Шушы затлар телемә килсә,
Җаным күкләргә аша.

*1991*

Хәсән
Туфан

# САГЫНУЛАРЫМ, ДИМӘК, СИҢА, МОСТАЙ, БАРЫП ҖИТӘ, ҖИТӘ, КҮРӘСЕҢ...

***

Жил дә тынган, каеннар да уйчан, —
Тирән тынлык төнге Келәштә.
Тынлыктанмы, жире шундыйданмы,
Шигъри халәт туа йөрәктә.
Төн.
Келәш тын.
Кинәшәдер кебек
Жир белән күк
Нидер турында.
Йолдызларга гүя Кызлар тавы
Әйтеп куя гәпнең соңында:

«Күктән, читтән килгән нәрсә түгел,
Жирдә туган һәр жан — Жирнеке!
Бәс, күкнеке, Алланыкы түгел,
Мостайдагы кодрәт — минеке,
Жирнеке, илнеке!

*Келәш, 1967*

## И Мостай

Такташсыз да калган юлларымда,
Жәлилсез дә калган елларда,
Бик күңелсез булыр иде миңа
Син булмасаң әгәр жырларда,
Син булмасаң...

Есенин да түгел... һәм башка да,
Туфан гына бары — мин, Мостай.
Киңәшчесе әмма йөрәгемнең,
Фурмановы гүя син, дускай,
Син, Мостай!

Юлларыбыз бергә дә бит безнең,
Өйләребез аерым якларда...
«Яннарымда Мостай булса икән,
Сердәш булса...» — дигән чакларда.

Әйтерсең лә күңел дулкыннарым
Ирәмәлгә — башкорт Парнасына —
Син яшәгән якка китәләр.
Китәләр дә, барып житәләр дә
Хәлләремне гүя алар сиңа
Бәйнә-бәйнә баян итәләр.

Менә шундый моңсу көннәремдә
Казаннарга килеп чыгасың да,
Аккош күлендәге ак каенга
Пегасыңны бәйләп куясың да,
Тик күршедән кергән кебек кенә,
Торагыма килеп керәсең...
Сагынуларым, димәк, сиңа, Мостай,
Барып житә, житә, күрәсең.

«Карыйк әле, күрик, — дигән сыман, —
Мостафасын безнең Туфанның»,
Тәрәзәмә үрелә каеннарым,
Болдырыма килә урманым:
Килгән өчен рәхмәт әйтер өчен,
Сәлам бирер өчен, туганым! —
Тәрәзәгә йөгерә каеннарым,
Болдырыма килә урманым...

Күрәм, Мостай,
Яшәсәң дә һаман
Картаюны белмәс жан белән,
Иңнәреңдә авыр миссия шул,
Башкаена, энем,
Башкаена иртә чал кергән.

Нидер житмәс, бик күп житмәс иде,
Син булмасаң илдә, и дускай:
Бар булуың өчен рәхмәт сиңа,
Байлык булган өчен, и Мостай,
Байлык булган өчен.

*1969*

## Гамзат ич — безнең Рәсүл

*(Мостай Кәримнең илле яшьлек юбилеенда нәни шаяру)*

Кыямәт көндә әгәр дә
Якага ябышып Ходай:
«Син, — дисә, — җирдә чагында
Мостайда, теге табында,
Хәрәмне... ниттең бугай!» —

Әйтермен: «Хәзер
Җирдәге
Шәригать бүтәнчә шул:
Мөхәммәд түгел бит инде,
Гамзат тик безнең Рәсүл!

Ә безнең Рәсүл шәрабны
Хәрәмгә санамый бит;
Рәсүлең кушканны, Ходай,
Үтәми ярамый бит!»

Әйтермен: «Җирдә чагында
Салырга ярый иде, —
Ул эшне Бәшир агай да
Хәләлгә саный иде.

Кем салмый безнең табында,
Әйтегез колагына:
Безнең бу тостлар бары тик
Хәерле дога гына.

Дусларның теле төбендә
Иң изге сүзләр генә.
Кала алардан күңелдә
Шатлыклы эзләр генә.

Бәс, салыйк, сират күпердән
Чыгарлык итеп кенә;
Арыслан дигән киекне
Тотарлык итеп кенә!

Тостлар бит алар асылда
Хәерле дога гына;
Дудин да каршы түгелдер,
Мөгаен, моңа гына.

Замана шундый кичәгә
Даталар бирә торсын,
Бердәнбер кичә түгел бу,
Меңнән бер кичә булсын!

Гомернең, дусларым, мондый
Кадерле кичәләре.
Мең дә бер кичә икән ул —
Исләргә төшәр әле.

Дусларның шигъри табында
Үткәргән гомерләре
Җырга әйләнер.
Сагындырып
Төшкә дә керер әле...

*1969*

***

Чарчадык шактый, кунакта
Тостларны әйтә-әйтә,
Инде вәт кайтып киләбез
Ял итә-итә-итә.

«Хәлләрең ничек?» — дисәң син,
Сер итеп кенә сөйлим:
«Деньги есть! В мягком гуляем!»
Кәеф шәп, Мостай, минем.

Кәеф шәп, Мостай, минем,
Нипочём кайгы миңа:
«Автоном татар» гуляд бит
Казакъка — союзныйга.

Үтәбез, Мостай, бүген без
Азия — Урал чиген,
Янгырап китте ничектер
Хәтердә синең шигырь...

*1962*

# МИЛЛӘТ ГАМЕ БЕЛӘН ЯНЫП



Туксанынчы елларның җәй челләсе бара. Милли хәрәкәтнең бик нык куәт алган чоры. Мәдәни үзәкнең конференц-залында зур җыелыш. Төрле илләрдән килгән татар эшлеклеләренә олы хөрмәт һәм кайнар ихтирам күрсәтелә.

Нәүбәттәге кунакка сүз бирелә. Австралиядән килгән милләтпәрвәр Ләйлә Садри ханым мөнбәргә күтәрелә. Ана бер кочак матур чәчәк бәйләме тапшыралар. Ләйлә ханым, залга мөрәҗәгать итеп: «Мин бу чәчәкләрне Фәүзия Бәйрәмовага бирергә телим, ул – безнең Жанна д'Арк», – дип игълан итте. Зал гөр килеп кул чапты, һәм чәчәк бәйләме Фәүзия кулына күчте. Мине исә тетрәндергәне шул булды: «Жанна д'Арк» бит минем матбугатта чыккан сонетым исеме. Мин аны Фәүзия Бәйрәмовага багышлаган идем.

Милләтнең бу куркусыз ялкынлы кызы татар халкының азатлыгы һәм тигезлеге идеясен шаулап торган илле меңле мәйдан өстендә күп тапкырлар яңгыратты. Игълан иткән сәяси ачлыгы 14 көн дәвам итте. Моның кайтавазы Советлар иленең татарлар яши торган барлык өлкәләрендә яңгырады, Казанга теләктәшлек телеграммалары килеп торды.

Берзаман Фәүзиябез Дәүләт Советы депутаты булды. Милли мәгариф, мәркәз белән салымны бүлешү, халыкның тормыш хәлен яхшырту таләбе һәм тәкъдимнәре – аның ялкынлы чыгышларының эчтәлеген тәшкил итте.

Әмма Фәүзия эшчәнлегенең төп эчтәлеген татар халкын уртак милли тормышка туплау мәсьәләсе алып торды, хәзер дә аның бар тырышлыгы шушы өлкәгә карый. Моның нигезен үзләштерүгә ул тарихны тирән итеп өйрәнү аша килде. Русның намуслы һәм затлы тарихчысы Михаил Худяков мирасын җентекле өйрәнеп, ул профессиональ тарихчы булды, татар тарихын объектив яктырткан өчен репрессияләнгән шушы затның гөнаһсыз якты исемен фәнгә кайтарды һәм ана татар халкының рәхмәт хисен җиткерде.

Фәүзия ханым туктаусыз хәрәкәттә булып, татар халкы тупланган өлкәләргә сәяхәт кыла, милли активистлар белән очраша, музейларны өйрәнә, архивларда казына. Күпләп татар яшәгән төбәк музеенда милләттәшләребез хакында бер генә лаеклы экспонат та булмауга ачына һәм бу мәсьәләне төбәк җитәкчелеге алдында күтәрә.

Ул үзе җыйган мәгълүмат һәм материалларының таралып юкка чыгуына юл куймый. Аның һәр зур экспедициясе китап хәленә килә, басыла һәм бик кызыксынып укыла. Ләкин табигый рәвештә бер сорау туа: шул чаклы ерак юл сәяхәтләренә бу ханым кайдан акча таба икән? Әлеге сәяхәтләрнең бер өлешен Бөтендөнья татар конгрессы финанслый. Яки химаяче спонсорлар булыша. Боларның берсе дә булмаса, юлга күп итеп китап алып чыга һәм шуларны сатып, юл чыгымнарын каплый.

Ә Фәүзиянең китаплары бик кызыксынып укыла. Төбәк татарларының борынгы тарихлары, бүгенге тормышларында барлыкка килгән проблемалар һәр кеше өчен кызыклы һәм мөһим.

Сәяхәт адресатын Фәүзия үзе билгели. Ул күбесенчә татар тарихы аз яктыртылган урыннарга бара. Сәфәргә чыкканчы, кул астында булган материаллар һәм интернет аша барасы төбәген өйрәнә. Аның бер урынга унар тапкыр барган очраклары бар. Сәфәргә чыгуның бер генә форсатын да ычкындырмый ул. Язганнарының йотылып укыла торган китаплар һәм очерклар булуы гаҗәп түгел. Өйрәнгән төбәкләрен дә санап бетереп булмый. Менә аларның кайберләре. Себерне алсак, Тубыл, Төмән, Омск, Томск, Курган һәм Чиләбе өлкәләре; Пенза һәм Мордовияне ул тәфсилләп яктыртты.

Китапларын алсак, алар зур бер эпопея тәшкил итә. «Ачылмаган татар тарихы» дигән күләмле хезмәте 2011 елда чыккан. «Мишәр иле» дигән әтрафлы тарихи очерк шул китапка кергән. Аның тарихи очерклары күп. Шундыйларның берсе «Чәрдән ханлыгы»

дип атала. Егерме бер табак күләмендәге «Туран иле» китабы 2008 елда басылган. Укучылар хөкеменә тапшырылган «Алтын урда – алтын илем» китабы 2006 елда нәшер ителгән. «Дала Атлантидасы» дигән хезмәт ике телдә төсле фотолар белән басылган. «Сахалин утравы һәм татарлар» 2014 елда чыкты. Чиләбе өлкәсендәге атом катастрофасы турындагы китабы өч телдә: татар, рус һәм алман телләрендә дөнья күрде.

Фәүзия ханымның тынгысыз каләме татар халкының Батырша кебек каһарман тарихи затларын да калку итеп яктыртты.

Шушы талантлы каләм иясенең киң колачы халкыбыз яшәешенең бик күп тарафларын инләргә өлгерде. Ул үзенең әле генә күздән кичергән һәм телгә алынмый калган бихисап хезмәтләре белән татар халкының күз күремен киңәйтте, халыкның үз-үзен тулырак танып белүенә ярдәм итте. Аның актив иҗаты әле гөрләп дәвам итә.

Күпсанлы сәяхәтләре һәм кызыклы тикшеренүләре шушы фидакяр ханымга җәмәгатьчелегебез өчен фикер ориентиры булган концептуаль ике формуланы иҗат итү өчен нигез бирде. Аларның берсе – «Төбәк тарихы – милләт тарихы»; икенчесе – «Бөтен Русиягә сибелеп утырган татарлар һич тә диаспора түгел, алар һәр җирдә үзләренең борынгы ватаннарын дәвам итә».

**Нурмөхәммәт ХИСАМОВ,**
*профессор*

## Фәүзия Бәйрәмованың басылып чыккан китаплары

**Болын**. *Повестьлар*. Казан, 1986.

**Сәнгать дөньясына сәяхәт**. *Фәнни-популяр язмалар*. Казан, 1989.

**Моң**. *Повестьлар*. Казан, 1991.

**Мәйдан татарларны көтә**. *Публицистик язмалар*. Чаллы, 1993.

**Кара урман**. *Әдәби-документаль роман*. Чаллы, 1997.

**Безне онытмагыз.** *Пьесалар*. Казан, 1998.

**Дәверләр күчешендә**. *Публицистик язмалар һәм шигырьләр*. Әлмәт, 1998.

**Хаҗ көндәлеге**. *Дини-фәлсәфи язма*. Казан, 1999.

**Заман. Милләт. Кеше.** *Фәнни-фәлсәфи язмалар*. Казан, 2000.

**Күңел карлыгачларым**. *Повестьлар*. Казан, 2000.

**Соңгы намаз**. *Роман*. Казан, 2000.

**Мишәрнең бөек улы**. *Фәнни-публицистик язмалар һәм пьеса*. Казан, 2001.

**Алыплар илендә**. *Повесть*. Казан, 2002.

**Ахырзаман афәте**. *Публицистика*. Чаллы, 2002.

**Бәхет ачкычы**. *Фәнни-популяр язмалар*. Казан, 2002.

**Михаил Худяков и история татарского народа**. *Научно-популярное издание*. Казань, 2003.

**Таралып яткан татар иле**. *Фәнни-популяр язмалар*. Казан, 2003.

**Нух пәйгамбәр көймәсе**. *Роман*. Казан, 2004.

**Ислам – яшәү рәвеше**. *Дини-публицистик язмалар*. Чаллы, 2004.

**Туфаннан таралган татарлар**. *Фәнни-популяр язмалар һәм роман*. Казан, 2004.

**Батырша җитәкчелегендә милли-азатлык көрәше**. *Фәнни-тарихи язма*. Чаллы, 2005.

**Ядерный архипелаг или атомный геноцид против татар**. *Научно-популярное издание*. Казан, 2005.

**Кырык сырт**. *Романнар*. Казан, 2005.

**Алтын Урдам – алтын җирем**. *Фәнни-популяр язмалар*. Казан, 2006.

**Баһадиршаһ**. *Әдәби-документаль роман*. Казан, 2006.

**Der Nukleare Archipel oder der atomare Genozid an den Tataren**. *Научно-популярное издание*. Германия, 2006.

**Михаил Худяков и историко-культурное наследие народов Среднего Поволжья**. *Монография*. Казань, 2007.

**Тропою знаний к истине.** *Научно-популярное издание*. Москва, 2007.

**Татарская Караболка – 50 лет в объятиях смерти**. *Научно-популярное издание*. Казань, 2007.

**Күчем хан**. *Тарихи роман*. Казан, 2007.

**Туран Иле**. *Фәнни-популяр язмалар*. Казан, 2008.

**Милләт һәм дәүләт**. *Чыгышлар, докладлар, мәкаләләр һәм мөрәҗәгатьләр*. Казан, 2009.

**ГУЛАГ – яралы язмышлар**. *Публицистик язмалар*. Казан, 2010.

**Ачылмаган татар тарихы**. *Фәнни-популяр язмалар*. Казан, 2011.

**Күчем хан**. *Тарихи роман*. Казан, 2011.

**Батырша явы**. *Фәнни-тарихи язма*. Казан, 2012.

**Нераскрытая история татар**. *Научно-популярное издание*. Казань, 2013.

**Дала Атлантидасы**. *Фәнни-тарихи язма*. Казан, 2013.

**Милләтемә хезмәт иттем**. *Публицистик һәм фәнни-популяр язмалар*. Казан, 2013.

**Сахалин утравы һәм татарлар**. *Фәнни-тарихи язма*. Казан, 2014.

**Ана**. *Фәнни-тарихи язма*. Казан, 2015.

***Редакциядән:***

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# ПОЭМА БЕЛӘН ОЧРАШУ

Әдәбиятыбыз тарихына күз салсак, күрербез: татар әдәбиятыбыз поэма жанрын беркайчан үги итмәде.

Кол Галинең безнең көннәргә кадәр килеп житкән «Кыйссаи Йосыф» китабы хаклы рәвештә поэзиябезнең чишмә башы булып санала. Ә инде Сәйф Сараи, Котб, Мөхәммәдьяр, Акмулла, Габделҗаббар Кандалыйның гасыр кичкән поэмалары бүген дә рухи-мәдәни кыйммәтләрен югалтмаган. Аларны укып, ифрат зур фәлсәфи тәэссорат һәм эстетик ләззәт аласың.

Илдар Юзеев, Ренат Харис, Роберт Әхмәтҗанов, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалим, Флёра Гыйззәтуллина поэмаларыннан соң (гафу, барысын да санап чыгу мөмкин түгел) шигърияттә шактый вакыт тынлык, өзеклек урнашты шикелле. Юкса күңел яңа заманның яңа поэмаларына бик тә сусаган иде.

Ниһаять, әдәбият сөючеләргә күләмле яңа әсәр белән танышу мөмкин булды. Сүзем — Мөхәммәт Мирзаның «Казан утлары» журналында басылган *(№6, 2015 ел)* «Кысыр Гариф» поэмасы турында.

Автор аны укучыга поэма-кыйсса дип тәкъдим итә. Хәлбуки, күләмен һәм тормышыбызның сиксән ел чамасы сәхифәсен колачлауны күздә тотсак, жанры дөрес билгеләнгән. Әйе, әсәрнең шигъри тукымасында гаҗәеп зур һәм масштаблы панорама ачыла: колхоз тормышы, Бөек Ватан сугышы, ГУЛАГ һәм Совет армиясе хәлләре, аннары инде нефтьле көннәр, баласыз гаиләнең тормыш-көнкүреше һәм бүгенге көннәр вазгыяте...

Боларны конкрет каһарманнар, аларның ачы һәм сикәлтәле язмышы аша поэма тикле поэмага ничек итеп сыйдырмак кирәк! Кыскасы, әсәрдә мин романлык материал белән очраштым. Шунлыктан аның жанрын шигъри роман дип билгеләгәндә дә бернинди хилафлык булмас иде, мөгаен. Хәер, монысы авторның теләге вә ихтыярында. Чү! Бер урында «келт» итеп искә төште: бездә шигъри роман язуның кызыклы бер үрнәге бар иде ләбаса. Күренекле шагыйрь Салих Батталның «Чирмешән якларында» дигән күләмле әсәрен күпләр хәтерлидер әле. Халык җырларының форма үзенчәлекләреннән оста файдаланып язылган, драматик ситуацияләргә бай булган бу шигъри полотнода XX гасыр башындагы татар авылының катлаулы тормышы, халык массаларының азатлык өчен көрәше тирәнтен сурәтләнә.

Поэма кебек нәфис жанрда әсәр исеменең «кысыр» сүзе белән башлануы баштарак ничектер сискәндереп куйган иде (шигъри сүз түгел, янәсе). Әмма, поэманы ахырынача укып чыкканнан соң, әлеге сискәнү юкка чыга. Әсәрнең төп герое — сугыштан сонгы елларда «уйнаштан туган» Гариф. Аның яшәгән (әгәр шулай әйтергә яраса) дәвере салкын сугыш чорында үтә. Нәкъ шул сәбәпле ул гаилә корып та баласыз гомер кичерә. Бер кешенең фаҗигасе бу. Бер тамчы чыкта күкнең яртысы диярлек чагылган кебек, Гариф язмышында — күпләрнең, шул исәптән ил фаҗигасе дә ярылып ята түгелмени? Салкын сугыш, ашкынып кораллану ни-нәрсәгә китерде? Димәк, әсәрнең исеме аклана, ул эчтәлекне тулаем ачыклауга-йомгаклауга хезмәт итә, дигән фикергә киләсең.

Поэма башындагы кереш сүз укучыны әсәрнең фабуласына, вакыйгаларның нинди яссылыкта барачагына әзерли. Автор төп лейтмотивны белдерә һәм геройларның реаль кешеләр икәнлеген ассызыклый: «Салкын сугышның әлегәчә туктаганы юк. Аның корбаннарын тулаем әйтеп бирә алучы да булмас... Ул корбаннар арасында минем якташларым, якыннарым да бар...»

Әсәр буеннан-буена бишьюллыклар челтәренә корылган. Моның үрнәкләрен узган гасырның алтмышынчы елларында Хәсән Туфан, аннары Зөлфәт иҗатында күпмедер

очраткан бар иде. Күләмле поэмада бишьюллыклар дисбесен ахыргача «өстерәп» бару авторга җиңел бирелмәгәндер. Без бит шигърияттә дүртьюллыкларга тәмам ияләнгән кешеләр. (Музыка өлкәсенә якын бер кеше буларак әйтим, шигырьдәге бишьюллыклар миңа нота язмаларындагы биш сызыклы нота баскычларын хәтерләтә.) М.Мирза үзенең язганнарында, кайбер рифмада «аксап» китүләрне исәпкә алмаганда, бишьюллыклар лабиринтын уңышлы ерып чыккан. Бер җөмлә белән әйткәндә, әсәрнең эчтәлеге дә, геройлар да, теле-өслүбе дә халыкчан.

Бишьюллыклар димәктән, төрки әдәбиятта моның традициясе ерактан килә. (Мин әлеге темага тирән кереп тормыйм, галимнәр һәм әдәби тәнкыйтьчеләр тарафыннан бу хакта күп язылды.) Шунысын әйтә алам, Мирзаның бишьюллыклары һәм газәлләре яңача, заманча, сәнгатьчә фикерләве белән үзенә җәлеп итә. Әлеге яңа шигъри жанрларны үзләштерү һәм баетуның үрнәкләрен ул «Адәм баласы» (2009) һәм башка тупламаларында тәкъдим иткән иде инде. Шушы жанрга тугрылыгын раслап, яңа китапларының берсенә хәтта «Биш юлым — биш гөлем» дигән шигъри исем дә биргән. Бу мәҗмуганы дини-дөньяви лирик шигырьләр бәйләме дип тә атарга мөмкин. Ислам дине тәгълимате аша, Коръән Кәрим ярдәмендә авыр заманыбызның гаять четерекле, актуаль һәм кешелекле мотивларын шигъри телдә әйтеп-сурәтләп биргән. Китаптан бер үрнәк китерү белән чикләнәм:

*Бәхет — дәүләт милке,*
*Бәхет — Ходай ирке...*
*Адәм баласының*
*Дәүләтсезлеге нәкъ*
*Бәхетсезлек инде.*

Поэманың структурасы күләмле симфония кебек, ягъни эчке төзелеше өч бүлектән тора. Беренчесе — сугыштан исән кайткан фронтовик солдатлар һәм колхозның михнәтле тормышы. Икенчесе — гап-гади бер гражданин-солдатның армия хезмәте, анда төзәлмәс чиргә дучар булуы. Өченчесе... җан тетрәткеч финал.

Әлеге сәхифәләрнең барысы да яңача фикер йөртү, сәнгатьчә тел-сурәтләү, дәлилле һәм гыйбрәтле вакыйгалар, шигъри детальләр аша яктыртыла.

Поэманың башында ук диярлек «уйнаштан туган» дигән ачы гыйбарә... кинәт күзгә бәрелә. Бактың исә, бу — кыйссаның геройларына һәм эчтәлегенә тулаем кагыла торган лейтмотивларның берсе икән! Ягъни «дөньяга мәҗбүри килеп, ләгънәтле каргыш ашаган» буыннар турында... Тәгәри йомгак булып барачак әнә шушы мотивны автор бер строфага «дыңгычлап» тутырган да куйган:

*Толлар зарыгып көтсә дә,*
*Кайтмады көткәннәре,*
*Кайсылары, өмет өзеп,*
*Галәфиле Гайниләрне*
*Кунарга керткәләде.*

Укучы, уйнаштан туган Гариф атлы малай белән танышып өлгергәнче, иң әүвәле аның атасы образына юлыга.

Гайни солдат — ветсанитар, үз эшенең остасы, җиде авылны берләштергән колхозның ышанычлы тоткасы. Ул «касторка» маен (шәп деталь!) сөрткән саен, һәр авылда күп очракта малайлар үрчеп тора. Үсәләр, уфалла арбасына, колхоз тәртәсенә җигеләләр. «Тәртә сынса сына, сынмый Адәм баласы!» Ә син кара бу солдат Гайнине: үзе бар иткән малайларның хет бер тапкыр башыннан сыйпап узарга да вакыты юк аның! Ә колхоз дигәнең хәтәр бер нәрсә икән:

*Калхузлар — кумәк коллыкның*
*Кот чыгарлык үрнәге...*

Бу бәяләмәне шаккатып-гаҗәпләнеп укыйсын. Укыган саен, безгә көчләп тагылган, житмеш ел буе безнен — һәр шәхеснен, һәр милләтнен рухи мөстәкыйльлеген изгән коммунистик идеологиянен үзенен бер уйнашчы булуы, ул идеологиянен киләчәге өметсез «кысыр» булуына ишарә. Ишарә генә түгел, чын-чынлап раслау булып килеп баса. Элгәре бер дә колак ишетмәгән, ак кәгазьгә язылган сүзләр түгел бит бу. Элекме, элек булсамы?.. Монын өчен, һичшиксез, теләсә кемнен башы «себер» китәр иде. Үзгәртеп кору жилләре, ни әйтсән дә, сүз ирегә бирде безгә — моны танырга кирәк.

Әлеге «фетнә» фикер алга таба тагын да ныграк үстерелә. Кемнендер кайнар баштан әйтелгән сүзләренә игътибар итик:

*Хакыйкатьтә калхуз үзе*
*Тома ятим туган икән*
*Дәүләтнен уйнашыннан...*

Кем авызыннан әйтелсә дә, бу инде җәмгыятьнен хаталарын ачып салган яна сүз! Яшерен-батырын түгел ич, заманында колхозга керергә теләмәүчеләр яисә аны ачыктан-ачык тәнкыйтьләүчеләр өстә дә, халык катламында да булган ул елларда. Поэма дөреслекне яклау-хаклау эзеннән бара...

Икенче бүлектә тагын да гыйбрәтле хәлләр манзарасы ачыла.

Хезмәт көне — сынар «таяк». «Бригадир сызган таяк өч йөз алтмышка тулсын» дип, биш ел буе колхоз малларын көтә Гариф. Бәдәне ныгып, унтугызы тулгач, армиягә алалар аны. Күрше кызы Нәфисә, вагъдә төсе итеп, таслап төрелгән чиккән кульяулык биреп озата...

Сюжет спирале үз кучәренә һаман саен ныграк чорнала, урала бара. Әйе, сюжетка, вакыйгалар үсешенә корылган кыйсса бу. Хәтерлик әле, берзаман сюжетлы поэмалар язу ничектер модадан төшеп калган иде. Евгений Евтушенконын фәлсәфи уй-фикер сюжетына корылган поэмаларыннан сон бездә дә «кусоклап» язылган поэма үрнәкләре ижат螺 ителде. (Сүз унаеннан, мин үзем дә шундый характердагы ике поэма яздым.)

Кайтып төшик Совет армиясе хәлләренә... Безнен солдат Гарифжан күз күрмәгән, колак ишетмәгән ераак жирләргә барып эләгә. Ул утырган кораб ун көннән сон бозлы ярга килеп туктый. Автор, бу кыйтганын географик атамасын әйтеп тормый, «мәнгелек төн иле» дигән серле-саллы сүзләр рәвешендә тамгалау белән чикләнә. Хәлбуки, белеме вә мәгълүматы булган кеше монын Төньяк Себер ягына урнашкан Яна Жир утравы икәнен чамаларга тиештер...

Киноларда хәзер еш кына күрсәтелә торган аклы-каралы өшеткеч күренешкә тин юллар мондагы хәлләрнен хәтәрлеген бик ачык күз алдына китереп бастыра:

*Уран шахтасы авызы,*
*Төпсез кара чонгыл кебек,*
*Бөтереп ала үзенә, —*
*Кәйлә, көрәкләрен тотып,*
*Менләп мәхбүс китә кереп.*

Боларнын ГУЛАГ тоткыннары икәнлеген чамалау бер дә кыен түгел.

Кош та очмаган, үлән дә үсмәгән менә шушы кыргый-карангы кинлекләрдә үтәчәк инде Гарифжаннын да өч еллык гомере. Кем булып? Юк, тоткын түгел, киресенчә, винтовка тотып, рухи кыйналган мәхбүсләрне саклый ул. Конвойчылар сафында, ягъни.

*Урал, Себер — алтын базы,*
*Донбасс, Кузбасс — күмер базы...*

Ходай бу зу-ур илгә бай казылмаларын кызганмаган икән шул! Бушка хезмәт итүче куллар да житәрлек. Егерме елдан сон менә-менә, һичшиксез, килеп

житәчәк коммунизм — кул сузымында гына...

Болар — «медаль»нең бер ягы. Икенче ягында — кимсетелгән, физик һәм рухи яктан имгәтелгән кеше язмышлары...

Бик тә гыйбрәтле бер деталь безгә күп нәрсәне ачып бирә. Бактың исә, бирецә бозлы күкерт ташларын актаручы бер мең мәхбүсне (!) биш йөз солдат саклап, барлап тора икән... Шулай шул: ике кешене бер солдат саклап тормаса, бу зур илдә тәртип урнаштыру, империяне саклап калу «едва ли?..»

Ә уран шахталарында нурланыш үзенең кара эшен эшли: кешеләр дистәләп-дистәләп кырыла. Гариф солдат моргта санитар да, кочегар да була: крематорийда мәхбүсләрнең корып кипкән җәсәдләрен яндыруда да катнаша... Мәхбүсләр бер хәл, әмма уран зәхмәте конвойларны да аяп тормый икән шул: Гариф армия хезмәтеннән саулыгын, барыннан да бигрәк ирлеген югалтып кайта...

23 яшьлек Гарифҗан 50 яшьлек кыяфәттә кайтып төшә. Әнкәсе һәм килен Нәфисә аны бурсык мае, пеше солы белән көчкә үлемнән йолып калалар.

Гарифнын тагын да зуррак бәхетсезлеге — баласызлык, нәсел җебе өзелү. Нәфисәсе белән утыз ел яшәп тә, бәби табарга, сабыйларын назлап-үбеп үстерергә насыйп булмый аларга. Төн илендәге афәт нурынын яшәү тамырын көйдергәне әнә шулай гомер азагына кадәр дәвам итә, эзәрлекли, камчылый, изә, сыкрата аны.

Өченче бүлек — финал.

Ил кодрәте өчен кысыр Гарифлар да кирәк булган. Ә инде «кырык ел сер сакларга» дип имза салган Гарифҗанның гомере үлем йолдызлыгы белән тәгәлләнә...

Әлеге эпик әсәр аерым шәхесләрнең үзара каршылыклы мөнәсәбәтләрен, бигрәк тә шәхес һәм җәмгыять арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләрне бик тирәннән, психологик киеренкелек белән ачып күрсәтә. Мәңгелек тема булган гуманлылык һәм явызлык көрәше бер ятимнең яшәү өчен көрәше аша ачыла. Сугыш ятимнәре бөтен илләре белән кабат салкын сугыш кырына озатыла. Салкын сугыш — кораллану, коралың булса гына, кабат сугыш булмаячак дигән идеянең кысыр идея икәнлеген ачып күрсәтүе — авторның иң югары максаты, минемчә. Бу яна тема, яна идеяме? Түгел дә, әйе дә... Хиросима, Корея, Вьетнам сугышлары, Африка, Куба, Карип диңгезе каршылыклары салкын сугышта «ирешелгәннәрне» барлау булды. Бу хакта дөнья әдипләре чаң сукмады түгел... Инде «салкын сугыш чоры бетте» дигән ялган чор булды да, өр-яңадан салкын сугыш чоры башланды. Бу инде салкын гына булмас ахры... Кораллар космоска күчте. Ракеталарнын болытлар артыннан, йолдызлардан торып ора торганнары кулланылыр әлеге сугышта... Сугыш континентлар ара, галәмнәр ара булырга мөмкин. Бу — кешелеккә каршы иң явыз идея. Кешелекне кысыр итү, юк итү идеясе. Әлеге поэманы язып, Мөхәммәт Мирза яна гасырда беренчеләрдән булып кешелекне сак булырга чакыра.

Поэма гел киеренке төсләрдән тора икән дип расларга ашыкмыйк. Шагыйрь үз симфониясендә зур осталык белән лирик күренешләрне сурәтләүгә ирешкән: Агыйдел ярындагы яздан көзгә кадәрле җәйләү, табигатьнең матурлыгы, кешенең табигать баласы булуы, аның табигать белән гармониядә яшәү зарурлыгы... Табигатьтә — алгарыш, янарыш. Табигатьтә кысырлык булмый, була алмый.

Поэмадагы мәхәббәт өслүбе дә үзенчәлекле. Анда традицион «өчпочмак» юк та кебек. Гарифның әнисе белән сугышның беренче көнендә — Сабантуй көнендә вәгъдәләшкән, шул көндә үк фронтка китеп, хәбәрсез югалган егетнең фаҗигасен укучы тыныч кына кабул итмәгәндер. Гариф белән Нәфисәнен, ике сугыш соңы ятименен, үксезенең бер-берсенә саф-чиста хисләренә, вәгъдә-тугрылык көченә кабат-кабат сокланасың. Болар һич тә уйлап чыгарылган түгел, үзебез яшәгән чорның, үзебез белән янәшәдә гомер иткән меңнәрчә милләттәшләребезнең язмышлары бит.

Кимчелекләр юкмыни поэмада, дигән сорау туарга мөмкин. Мин аларны махсус эзләмәдем. Кабат-кабат укыганнан соң, кайбер теләкләрем, тәнкыйть фикерләрем дә оешты, билгеле. Аларны авторга җиткерү шулай ук мәслихәт эш дип саныйм.

Бу җәһәттән сүзнең башын кинәш-унаш рәвешендәге бер теләк белән башлыйсым килә. Өч бүлек, дидек. Менә калса, аларның һәркайсына исем кушылган булса, җәелеп аккан поэманың офыклары, эчтәлеге һәм сверхмаксаты җетерәк, тулырак

ачылыр иде шикелле.

Поэмада шундый бер сәерлек күрдем мин: Гариф солдат мәхбусләрнен мәетләрен яндыруда катнаша, дидек. Ай-һай, урманда утын кисү яисә исталекле учак ягу кебек гади бер эш түгел бит бу! Гомерләре сызып узганнарның көл-корымын үз күзләре белән күргән егетнен гаделсез үлемгә, өстәгеләр сәясәтенә, илдә барган фаҗигаи хәлләргә карата мөнәсәбәтен — ни нәфрәтен, ни протестын күрмәдек. Әйтерсен, ул — битараф, кушканны үтәүче бер робот шикеллерәк килеп чыга! Чү, мин ялгышмадым бугай. Чыннан да, казармадагы илдә яшәп, дөньяның күп нәрсәләреннән бихәбәр солдат нәкъ менә робот хәлендәге бер кеше (курчак) сыман күз алдына килеп баса. Солдатның теләсә кайсы фәрманга «Есть!» дип җавап бирү хокукы гына бар шул.

Ул — кушканны үтәүче роботтан бер дә ким түгел. Каршы килсән, сине әллә нинди әшәке ысуллар белән сындырачаклар, изәчәкләр... Минемчә, армия хәлләрен («дедовщина»ны да истә тотып), андагы гаделсез, тупас вазгыятьне тасвирлауда зур яңалык, табыш бу.

Менә шуларны уйлаганнан соң, «Гариф солдат нигә көрәшче түгел?» дигән сорауны куйсак, бу сөаль урынсыз кебек тоелыр иде, мөгаен.

Гарифны көрәшче сыйфатыннан тулаем мәхрүм итеп булмый. Ул — сугыш ятиме буларак, бала чагыннан алып (колхоз михнәте) һәм гомеренен соңгы елларына кадәр (төзәлмәс чир) «мин яшим» дип, «мин исән» дип тырыша-тырмаша, бөтен авырлыкларны күкрәге, җан көче белән ера-ера көрәште түгелме? Бу көрәштә һәр җәрәхәт тәннән җанга, бәгырьгә күчмәдеме? Ул «сынды», ди автор. Әмма ул көрәшеп сынды түгелме?

Һәр кешенен яшәү хокукы бар. Аны беркем дә чикләргә тиеш түгел. Гариф яшәү өчен көрәшә. Ул — аның Аллаһы биргән әҗере... Әлеге үтә мөһим мәсьәләдә автор берәүне дә ачыктан-ачык гаепләми һәм хөкем карары чыгармый кебек. Ләкин поэманың эчтәлегеннән, логик сөрешеннән җәмгыятьнен яшәеш кануннарына, буйсынучан халыкка, ялган демократия һәм эреле-ваклы диктаторларга зур «гаеп» ташлана: кешеләр, сез нишлисез, кая таба барасыз?!. Бу — набат! Ул кайтаваз булып тагын да яңгырар әле.. Яңгырарга тиеш...

Тагын нәрсә?

Поэманың азагы:

*Җавабым күпкә соңарды,*
*Укучысы булыр микән? —*

дигән икеюллык белән тәмамлана. Масштаблы зур илдә барган катлы-катлы вакыйгаларны үз эченә алган күләмле әсәрнең әнә шулай йомшак кына, гадәти генә тәмамлануы белән күнел килешми. Колачлы симфонияләрдәге кебек, бередә дә «аккорд»ның аягүрә бастырырлык сүзләр һәм аһәң белән тәмамлануы поэманың эчтәлегеннән үк сорала.

«Укучысы табылырмы?» дип тә хафаланасы юк. Поэманың темасы, актуальлеге, геройларның сикәлтәле язмышы, илкүләм фаҗигаләр, коллык кебек глобаль мәсьәләне күтәргән бу поэманы яшь буыннарга да кат-кат укырга кирәктер дип саныйм.

Күрми яисә укымый калганнар булса (интернет заманы!) — укыгыз, поэма сезне, һичшиксез, җәлеп итәчәк, фәлсәфи уйлануларга этәрәчәк.

**Рашат НИЗАМИ.**
*Сентябрь, 2015 ел*

# БЕР ЛЕГЕНДА ЭЗЕННӘН

Авылда элек зур табын җыйганда савыт-сабаны күршедән алып тору гадәте бар иде. Кире кайтарганда буталмасын өчен, һәр хуҗабикә үз савыт-сабасына тамга суга иде. Ул заманда кулланылган агачтан кырып ясалган бизәкле кашык, касә-коштабакларны әле дә музейда йә сувенир кибетләрендә күрергә була.

Аш үткәннән соң, әби кашыкларны аера: «Бер сызык — Гайфи хатынынынкы, куш сызык — Сәрбиләрнеке, япьле сәнәк үземнеке». Япьле сәнәк — Y — безнең бабайларның нәсел тамгасы. Элек авылда һәр кешенең нәсел тамгасы булып, ул тамга кашык-аякка гына түгел, чалгы-сәнәк, каеш-беләзек, ат дирбияләре, ызан баганалары, хәтта мал-туарга да салына торган булган. Ата-бабаларыбыз нәсел тамгасын изгеләштергәннәр. Аны бозу йә бутап кую гөнаһ саналган.

Нәсел тамгаларын өйрәнгән галимнәр безнең нәсел тамгаларының борынгы төрки язуга охшаш икәнлеген таныйлар. Шуңа алар фәндә борынгы язуның хәтер калдыгы булып саналалар.

Ләкин хәтер калдыгы дип кенә тамганың әһәмиятен киметергә кирәкми. Тамга үзе катлаулы күренеш. Ул, бердән, тамга куючының билгесезлектән, исемсезлектән аерылганын күрсәтсә, икенчедән, тамга — аралашкан кешеләр өчен таныш, кабул ителгән, мәгълүм билге булып тора. Ягъни, тамга безне ниндидер бер чик алдына куя. Әмма бу чик әле цивилизациягә аяк басу чиге түгел. Тамга — өнсезлектән, галәм бушлыгыннан аерылып, калкып чыгуга ясалган беренче адым гына. Тамгага мәгънә бирү, аны авазларга әйләндереп язу барлыкка китерү, телне язуга кушу-яраклаштыру, язуны һәм телне сакларлык итеп оешу — бу инде аерым бер халыкның цивилизация юлына кучкәнлек билгесе. Шул биеклеккә ирешкәннәргә генә хәтер тупларга, белем җыярга, тарих барлыкка китереп яшәргә юл ачыла.

«Өстә — күк Тәңре, аста — көрән җир кылынганда (барлыкка килгәндә) ике арада кеше углы барлыкка килде», — шушы сүзләр язылгач, тарих башлана.

Безнең нәсел тамгаларына охшаш тамгаларны Скандинавия илләрендә дә очратырга була. Куелышы да охшаш — йорт керәге, каеш-беләзек, таш ызан баганалары. Безнең эрага кадәр ике мең еллар элек Шан династиясе чорында Кытайда да, иероглифлар белән язуга күчкәнче, төрки тамгаларга охшаш тамгалар кулланганнар. Бүгенге көндә кытай археологлары мал сөягенә, ташбака кабыгына юрау өчен буларак (дип уйланыла) төшерелгән шундый тамгалы кыйпылчыкларны күпләп табалар. Фәнгә Фест дисбесе дип кергән, Крит утравында табылган түгәрәк дисктагы тамгаларның берничәсе шулай ук безнең нәсел тамгаларын хәтерләтә. Бу дискның язылу вакыты Шан династиясе чорына туры килә. Гомумиләштереп алганда, безнең эрага кадәр берничә мең еллар элек чордан башлап Аурупа һәм Азиянең төрле җирләрендә-илләрендә төрки тамгаларга охшаш тамгалар киң кулланышта булган.

Бабаларыбыз тормышында билгеле бер урын алып торган нәсел тамгаларының озын тарихи үткәне бар. Бик борын заманнарда язу булып хезмәт иткән алар. Фәндә борынгы төрки язуны «рун язуы» дип атау кабул ителгән.

Борынгы язуның безнең җирлектән фәнгә килеп керү тарихы болай башлана. Пётр Інең якыннарыннан берәү патшага улы туу хөрмәтенә алтыннан эшләнгән монарчы күрелмәгән ят әйбер бүләк итә. Пётр Іне бу бүләк бик кызыксындыра, ә аның Себер җиреннән табылган икәнен белгәч, шул якларда эзләнүләр үткәрергә кирәк дигән карар кабул итә патша.

Әлеге эзләнүләргә табигать белгече немец Даниил Готлиб Мессершмидтны

тәгаенлиләр. Ана ярдәмче итеп тоткын швед офицеры Ф.И.Таббергны билгелиләр. Алар 1720-1727 елларда, патша кушуы буенча, Себердә тикшеренүләр ясап сәяхәттә йөриләр: ул якларның табигатен, байлыкларын тасвирлыйлар, борынгы курганнардан алтын эшләнмәләр эзлиләр. Әмма курганнарның күбесе ул вакытта ук инде тулысынча актарылган, таланган булган. «Обь елгасына кадәр бер генә исән каберлек тә юк», — дип хәбәр итә тикшеренүчеләр. «Бугрование» дип аталган төшемле кәсепкә әйләнгән була инде курганнарны казу. Себер воеводалары курганнар алтынын үз кулларына төшереп, потлап эретеп туплаган булганнар. Шулай да патша исеменнән хәрәкәт итүче тикшеренүчеләргә кайбер әйберләр табып-сорап алып кайтырга насыйп була. Эрмитажда Пётр Інен Себер коллекциясендә саклана алар табып алып кайткан әйберләр. Игътибарлы тикшеренүчеләр юлларында очраган билгесез язулы ташларны да сурәткә төшереп алырга онытмыйлар.

Төрки язулы бу сурәтләр патшаларның сарай коллекциясендә бик озак кулланышсыз ята. Екатерина II илчеләренең берсе ташлардан күчерелгән язулы кәгазьләрне Ауропага алып чыга һәм алар фәнни җыентыкта бастырылып, белгечләр арасында кызыксыну уята. Ләкин язуларның серен чишәрлек, аларны укырлык кеше ул чорда табылмый.

Һаман билгесезлектә калган язуларны укуга XIX гасыр азагында данияле Вильгельм Людвиг Петер Томсен (1842-1927) алына. Ныклы әзерлекле олы галим, күп телләр белгән Томсен язуларны ачыклап кына калмый, борынгы төрки телнең 38 хәрефле алфавитын торгыза һәм әһәмиятле аңлатмалар белән ташъязуларның укылышын да бирә (1893 ел). Бүген дә даһи ачыш һәм фән юлында зур фидакарьлек үрнәге дип белгелиләр галимнең бу хезмәтен. Мең елдан артык билгесезлектә яткан Күлтәгин, Тоньюкук, Билге каган «телгә килеп», безгә үз тарихларын бәян итәләр бит. Телче галим буларак, Томсен 38 хәрефле борынгы язуның төрки телнең бөтен нечкәлекләренә җавап биргәнен дә тамгалый. Төркиләр соңыннан кабул иткән уйгыр язуында барлыгы 20 хәреф булып, уйгыр язуы төрки телнең аваз нечкәлекләрен бирә алмаганын дәлилләп күрсәтә.

Томсен белән бер үк вакытта бу язуларны укуга күренекле тюрколог В.В.Радлов та алынган була. Ике зур галим язуларның серен чишү юлында табылган уңышлары белән даими уртаклашып торалар. Соңыннан В.В.Радлов орхон-енисей истәлек ташъязмалары текстының беренче тәрҗемәсен бастыра.

Томсенның төрки язуының тарихи үткәне турындагы фикерләре хәзер дә әһәмиятен югалтмый. Галим язуның кайда, ничек барлыкка килүен төгәл ачыклау өчен үз заманы фәнендә җитәрлек дәлилләр юклыгын әйтә. Төрки язуның килеп чыгышына карата без ашыгып ясаган фаразлар хәрефләр охшашлыгына таянган оптик аллану булырга мөмкин, дип кисәтә Томсен.

Томсенның ачышларыннан соң йөз елдан артык вакыт үтсә дә, борынгы төрки язу үз серләрен саклый әле. Бүгенге көндә киңәйтелгән мәгълүмат челтәре (интернет) барлыкка килү, күп халыкларның миф һәм легендалары тупланып, тикшерелеп басылып чыгу, «Идегәй» дастанының әдәби җирлеккә кайтарылуы һәм башка шундый тарихи үткәнгә киң караш ташлау мөмкинлеге бирә торган материаллар табылу, төрки язуның тамырлары турында яңа фикерләргә юл ача кебек.

Галимнәр рун язуын икегә аерып тикшерә: Көнбатыш Ауропа руналары һәм төрки руналар. Көнбатыш Ауропа руналары ныклап өйрәнелгән һәм үз халыклары яшәешендә, алар тормышының тарихи яктыртылышында билгеле бер урын алып тора. Руналарга кагылышлы легендалар җыйналып бастырылган.

Борынгы скандинавлар руналарда бөек көч бар дип исәпләгәннәр. Руналар күрмәгәнне күрергә, ишетмәгәнне ишетергә ярдәм итүче серле язу булып саналган. «Руна» сүзе иске скандинав телендә «сер» яки «пышылдап әйтелгән сер» дигәнне аңлата. Руналарны, әйтелгәнчә, каеш, кылыч, йөзек, беләзек, амулет һәм башка шуның ише кеше үзе белән йөртә торган әйберләргә төшергәннәр. Алар белән йорт кирәк-ярагын тамгалаганнар, ташларга уеп язганнарга, истәлекле урыннарга куйганнар. Руналар архитектурада, тауар билгеләрендә дә кулланылган. Урта гасырларда христиан дин әһелләре руналарны мәҗүсилек калдыгы дип тыйганнар һәм бик күп истәлекләрне юк иткәннәр.

Руналар белән янадан кызыксыну XX гасыр башында кабына. 1908 елда немец Гвидо фон Лист «Руналар сере» дип исемләнгән китап бастыра. Бу китапны ул, бер ел сукыраеп торганда, үзенә күктән иңде дип игълан итә. Фон Лист кабат ачкан руналарның Скандинавия илләрендә таралган шигъри Эддаларда сурәтләнгән руналар белән охшаш икәнлеге ачыклану алар белән мавыгучыларның санын бермә-бер арттыра. Руналарга хәзер табигатьтәге күзгә күренми торган көчләр белән бәйләнешкә керергә мөмкинлек бирүче серле тамгалар дип карый башлыйлар. Мондый караш бигрәк тә Алманиядә көчле була. Руна җәмгыятьләре оешып, аларда руналар юрау, көч туплау, мәгълүмат кыры белән элемтәгә керү өчен арадашчы буларак кулланыла башлый. 1933 елда властька фашистлар килгәч, бу җәмгыятьләрнең эшчәнлеге тыела. Ни сәер тоелмасын, руналар үзләре нацистлар символикасында шактый урын алып тора. Каһәрләнгән свастика, гитлерюгенд билгесе, Эсэс эмблемасы — бераз гына үзгәртеп алынган руник тамгалар.

Руналарның барлыкка килүе турында скандинав легендасы менә нәрсәләр сөйли.


Бик борынгы заманнарда, безнең эра башында, бер кабилә Каспий диңгезе буйларыннан кубып күченеп киткән. Ул, хәзерге Россия, Украина, Польша, Алмания, Дания җирләре аша үтеп, Швециянең көньягына хәтле килеп җиткән. Кабилә ни өчен унайлы диңгез буйларын ташлап киткәндер, бу турыда легенда тәфсилләп сөйләми. Шуңа төрлечә юрарга була. Бәлки алар җирне тикшерүчеләр, белем таратучылар төркеме булгандыр. Төньяк халыклары легендаларын җентекләп укыганда, әлеге фикер ныгый төшә. Кабилә үз сәяхәтен төньякта яңа диңгез яры тапканчы дәвам иткәнгә охшый. Алар хәзерге Швеция җиренә килеп җиткәннәр һәм илнең көньягында бер сала нигезләгәннәр. Күченгән кабилә башлыгының исеме Сиг булып, шушы күчеш вакытында аңа Один алла рухы иңгән. Аны «Один» дип атап йөртә башлаганнар. Хәзерге вакытта Швециянең Упсала шәһәреннән ерак түгел борынгы Один храмы бар. Әлеге храм янындагы курганга Сиг-Один күмелгән, ди легенда. Руна мәктәбе шул урында барлыкка килгән.

Руналарның Одинга иңүе дә гади генә булмаган. Аның кабиләдәшләренә югалмаслык бер хезмәт калдырасы килгән. Ул руналарның барлыгын белгән. Әмма исенә төшерә алмаган. Исенә төшерү өчен (тотып алыр өчен, диелә), үзен агачка сөңгесе белән беркетеп, баш түбән асып куйган һәм шул хәлдә тугыз көн асылынып торган. Ашамаган, эчмәгән, торган да торган. Шулай асылынып торып, аның хәтта бер күзе чыккан. Әмма Күкләрнең мәрхәмәте белән ул руналарны тотып ала алган.

Төньяк халыклары миф һәм легендаларында Один исеме үзәк урынны алып тора. Ул бик күп сыйфатларга ия итеп бирелә. Легенда буенча Один һәм аның юлдашлары атларда (!) киләләр. Одинның аты (кушаматы — Слейпнир) шундый житез була ки, аның аягы да дүрт түгел, сигез булып күренгән. Одинны һәрвакыт Хугин һәм Мунин исемле ике козгын озатып йөргән. Җирдә казынучы, үләксә белән туенучы, күкне иңләүче озын гомерле бу кош күп миф һәм легендаларда телгә алына. Кара козгынның яшәү һәм үлем, яктылык һәм караңгылыкка бәйле булуы, галәм өнсезлегендә кинәт яңгыраган каты тавышы аны миф һәм легендаларда хәбәрче, дөньяның өч катында — Җир асты, Җир өсте һәм Күктә — арадашчы буларак билгели. Сугышчан рухлы Одинга ияреп очучы козгыннар — алар шулай ук хуҗасына хәбәр житкерүчеләр һәм хәбәрне җиһанга таратучылар булып торалар.

Один һәм аның кабиләдәшләре күп һөнәрләргә ия булган һәм җирле халыкны да үз һөнәрләренә өйрәткән. «Әмма бар серне дә ачып бетермәделәр», — дип тә искәртә легенда. Атта йөрү, металл эшкәртү кебек һөнәрләрдән тыш, Один кешеләрне матур итеп сөйләргә өйрәткән һәм руналар серен ачкан. Ул үзе шундый оста, матур сөйләгән, тыңлаучылар аның һәр сүзенә ышанганнар. Шигъри тел белән сөйләгән ул. Шуңа аны төньяк халыклары арасында шигърияткә нигез салучы дип тә саныйлар. Тагын ул үз кыяфәтен үзгәртеп, әллә нинди рәвешләргә керә белгән. Ә сугышта кыяфәте белән дошманын бастырган. Дошманнары сукыр һәм саңгырауга әйләнгән, шуңа ул аларны бик тиз җиңгән.

Бу сурәтләүләр икенче бер бөек легенда иясе Идегәйне хәтерләтә түгелме? Дастанда Идегәй турында «чичән икән», дип белдерә Субра җырау. Сугышта ул, нәкъ



*Патша таҗы. Ясалган вакыты билгесез. Скандинавия музейларының берсендә саклана.*

Один кебек, кыяфәте белән дошманнарын бастыра: *«Идегәй килә дигәндә / Аны белгән ни ир бар — / Урда бозып таралды», — диелә.* Икенче урында Идегәй үзе турында: *«Каргышым кара таштан үтәдер, / Аһым жирне-күкне тотадыр»*, — дип, тәэсир көченең чиксез икәнлеге турында әйтә.

Чагыштыруларны дәвам итеп, Один һәм Идегәйнең икесенең дә атка атланган Бөек дала ирләре булганын ассызыкларга кирәк. Ат ул заман ирләренә, җәяүле кеше белән чагыштырганда, чиксез хәрәкәт итү мөмкинлеге биргән. Жирне үзләштерүчеләр, берләштерүчеләр булган Один һәм аның юлдашлары. Алар Төньяк жирләренә дала рухын, дала белемен алып килгән. «Уйдырма», — дип әйтергә мөмкин тарихчы. Ләкин бу фикерне куәтләүче берничә дәлилгә тукталыйк. Ин әһәмиятлесе — безнең эраның беренче меңьеллыгында Аурупа халыкларының АТЛЫ булуы, атка атлануы тарихи факт. Ат ул чорларда бик сирәк, бик кыйммәт мал саналган. Шекспир героенын: «Полцарства за коня», — дигән сүзләре атның бәясен күрсәтә булыр. Атсызларны атка утыртучы, ат йөгәнләү өчен кирәкле дирбияләрне ясауны жирле кабиләләргә өйрәтүче булып, әлбәттә, дала кешеләре торган. Әкренләп беренче меңьеллыкта Аурупада да атлы сугышчылар пәйда була, рыцарьлар турында әсәрләр иҗат ителә башлый. Моңа аерым тукталып тормыйбыз, бу турыда махсус тарихи һәм әдәби әсәрләрдән укырга мөмкин. Шулай ук Бөек даланыкы булган сәнгать ысуллары да төньяк халыкларына үтеп керә. Корал, көнкүреш һәм бизәнү әйберләрен ясауда скиф-сармат (җәнлек) стиле үзләштерелә. Монын берничә үрнәген алга таба карап китәрбез.

Борынгы Төньяк җәмгыятенең рухи тормышында да зур үзгәрешләр күзәтелә. Төньяк халыкларының үз алласы саналган Тюрны Один культы кысрыклый. Халык авыз иҗатына Один ныклап кереп урнаша, ана багышланган бик күп мифлар иҗат ителә. Тагын бер күзәтү — телгә яна сүзләр керә. Борынгы Төньяк җәмгыятендә жрецларны «erilar» («эрилар» дип әдәбиятка кергән) дип йөрткәннәр. Бу сүз «Идегәй» дастанында телгә алынган «ерау» («җырау») сүзенә аваздаш бит. Один — ерау булганмы? Сурәтләүләр буенча бик мөмкин. Гомумән, Бөек далада ераулар — мәгълүмат һәм тылсым ияләре булган. Ә Один бер төркем кабиләдәшләре белән жир читенә барып житәргә, дингезнең читен табарга максат куйган шуларның берсе булуы бар.

Один нигез салган Упсала (Уппсала дип тә языла) шәһәре исеменә игътибар итсәк, «сала» кушымчасының «авыл», «торак урыны» дигән татар сүзенә тәңгәл икәнен күрәбез. Татарстанда Әлмәт янында Урсала дигән авыл да бар. Мәгънәсе — ур (нығытма) артындагы торак урыны, авыл. Әлмәт белән Урсала Зәй елгасының ике ярына урнашкан.

Хәзерге интернет заманында Бөек дала һәм борынгы Төньяк арасындагы бәйләнешләрне һәркем күрә ала бит. Алда искә алынган Пётр Інен Себер коллекциясендә алтыннан эшләнгән муенса бар *(Инв. №ГЭ Си 1727 1/67 «шейная гривна» дип бирелә)*, шуңа охшаш затлы экспонат «Королевский венец эпохи тёмных веков» исеме белән А.А.Хлевовның «Предвестники викингов» (274 бит) китабында сурәтләнә. Пётр Інен Себер коллекциясендәге кош сыннары шулай ук алда искә алынган китаптагы кошларга бик охшаш. Очраклымы бу? Әлбәттә, белгечләр бу сорауларга җавап тапмый калмас. Шулай ук китапта китерелгән кабер һәм истәлек ташлары да белгечләрнең чагыштырып тикшерүен көтә. Ташлардагы безнең яклардагыча куелган кояш билгесе, атларга мәдхия рәвешендә камил ясалган сурәтләр, ниһаять, Одинның төркиләрчә курганга күмелгән булуы — тарихның бер чорында дөньяның ике кыйтгасы арасындагы тыгыз һәм даими бәйләнешләр булуы турында сөйли. Тарихи бәйләнешләрнең ныклы җепләр булып дөньяның төрле кыйтгаларына сузылганын һәм сузылачагын ташка: «... дүрт ягындагы халыкны буйсындырганнар: башлының — башын идергәннәр, тезлене — тезләндергәннәр», — дип язып калдырганнар.



*Муенса. Б.э.к. V-IV гасырлар. Пётр Інең Себер коллекциясе. Эрмитаж. Санкт-Петербург.*

Сүз башыбыз руналар турында иде бит. Орхон-енисей язмалары, белгечләр фикеренчә, үзләренең камиллекләре белән аерылып тора. Ташъязудагы текстларның ике имла — кытай иероглифлары һәм төрки язуы белән бирелүе дә очраклы түгел. Дөнья һәрвакыт үзгәрештә. Кемнең, кайда, ничек үз тормышын дәвам итәчәге, илләрнең нинди фаҗига, зилзиләләргә дучар булачагы кемгә дә билгесез. Шуңа зирәк Тоньюкук истәлегенә куелган ташъязмада киңәш һәм кисәтү рәвешендә мондый сүзләр язылган: «Төрки халык өстенә коралланган гаскәр йөрттертмәдем, иярләнгән атлы гаскәр китертмәдем. ... Әгәр берәр җирдәге каганлы халыкның ахмак идарәчеләре булса, нинди борчуларга дучар булырлар иде». Бүген дә бик урынлы сүзләр! Ә инде истәлеккә куелган ташның ике язуда бирелүе аның киләчәк буыннарга барып житеп укылачагын бермә-бер арттыра. Тарихта моның мисалын Розетт ташы серләрен ачуда күрергә була: ташта өч төрле язулы текст булу борынгы мисыр язуын торгызырга ярдәм иткән һәм борынгы Мисыр язмалары «сөйләшә» башлаганнар.

Безнең бабаларыбыз булган борынгы төркиләр юл йөрүдән курыкмаган, тормышларын даими хәрәкәт-күчешкә көйләгән халык санала алар. Хәрәкәтнең көч-куәтен арттыруга төркиләрнең ат иярләүләре, тимер-чуен коя белүләре дә нык ярдәм иткән. Бөек дала — төркиләр бишеге. Атлы дала кешесе үткән һәр җирдә рун язулы истәлекләр сакланган.

Кытай белән чиктәш яшәгән борынгы төркиләр аларның мәдәни казанышларын, шул исәптән язуларын да яхшы белгәннәр. Шулай булмаса, ташларга үз язулары белән бергә кытай иероглифлары да төшерелмәс иде. Төркиләр — ат иярләгән йөремсәк халык, һәм алар иҗат иткән язу ысулы да яшәү рәвешләренә бик туры килгән. Язу-хәбәрне агач такталарга, таякларга, кул астындагы башка материалга җиңел генә төшереп булган, ташка чокып язганда, мәңгелек истәлек барлыкка килгән. Хәрефләр тиз хәтердә калган һәм сүзләр телдә ничек әйтелсә, шулай язылган.

Бик борынгыда, сөйләм теле барлыкка килгән ерак чорларда, аерым аваз үзе берничә мәгънәне белдергән сүз булгандыр. Безнең телебездә андый сүзләр әле дә кулланышта. «И», «у» — шундый сүзләрдән. Без аларны боерык фигыль буларак та, ярату, иркәләү, гаҗәпләнү, аптырау, кызгану, ачулану һәм башка бик күп хис-кичерешләрне белдерү яки көчәйтү өчен дә кулланабыз. Сөйләм теле тартыкларсыз үсми. Тартыкларда таш төшеп бәрелүе, җил сызгыруы, карга каркылдавы, үлән арасыннан елан шуышуы — гомумән, тирә-як табигать авазлары ишетелә. Сөйләмгә тартык кушылу — эш-гамәлнең, хәрәкәтнең катлаулану билгесе: «и — ти — кит», «у — бу — шу» һәм башкалар. Тартыктан гына торган сүзләр сөйләм телендә булгандырмы, ә менә кайбер телләр язуда сузыкларны бөтенләй төшереп калдыра. Борынгы мисыр язуы — моның үрнәге.

Рун язуында хәрефләрнең язылышына карап, аерым хәрефләрнең башлангычта сүз-тамга булуы мөмкин дип фаразларга була. Рун язуының кайбер үзлекләрен санап китик:

1. Тартыклар калын һәм нечкәгә аерылалар. Бу телебезнең әйтелешен бозмыйча язарга мөмкинлек бирә, ягъни сингармонизм законы саклана.

2. Хәрефләрнең язылышында табигать аваз-күренешләре, әйтелеш үзенчәлекләре чагылыш тапкан.

3. Сузыклар, тартыкка ияреп, бер үк язылышта калын йә нечкә булып укылалар.

4. Хәреф аерым сүз үзлегенә ия тамга булырга да мөмкин.

5. Язу уннан сулга башкарыла.

Әйткәннәрдән чыгып, аерым хәреф-тамгаларны табигать авазлары белән янәшә куеп карыйк.

(а-ә) Чиксезлек, тоткарлыксыз хәрәкәт, илаһилык, гажәпләнү, соклану, аңлау, тынычлану, ачулану, үч алу кебек хисләрне белдерә. Тамгасы — жир белән күкне тоташтыручы чиксезлек билгесе.

(б-бь) Чикләү, ябып кую, туктату, төпкә төшү, бату, калку, биеклек, биеклеккә омтылуны күрсәтә.

(г-гь) Агу, очу, үсү, гажәпләнү, соклану, хәтерләү. Тамак төбе белән әйтелә һәм язылышта тамак төбе авазы икәнлеге күренеп тора.

(д-дь) Яшәү вакыты, өзлексез хәрәкәт, әйләнеш, вакыт агышы, бүленү, дерелдәү, дулкынлану, давыл билгесе.

(з) Кояшлы көнне жиргә ятып күкне тыңласаң, һичшиксез, «з» авазын ишетәсең. Кояш, күк һәм мәңгелек билгесе.

(й-йь) Йомык йодрык кебек язылган бу аваз үз эчендә, үз өендә бикләнүне, жыелуны, йомыклыкны, үсәргә әзерлекне аңлата.

(к-кь) Жыелу, туктау, таралу, теләкнең кабул булуы, хәрәкәтнең тәмамлануы һәм янадан башлануы, көч, көчнең күктән иңүе һәм тамырларга таралуы, саклану, ышыклану, таяныч, ныклыкны күрсәтә.

(л-ль) Тамырлары жиргә күмелгән, яңа борын тәрткән үсемлекне хәтерләткән бу тамга жыюны, жыелуны, берләшүне, төпкә утыруны, мал, байлык, барлык, булганлыкны белдерә.

(м) Суда йөзгән балыкка охшаган, каршылыкны табигать биргән көч белән жиңеп, акылы белән дөньяны аңларга сәләтле «мин» билгесе. Жиңүгә, биеклеккә ирешүгә омтылучан икәнлеге тамгада күренә.

(н-нь) Билгесезлек, бушлык, дөньяны капшаучы һәм барлыкка китерүче «ни». Калын язылышы атка сугарга күтәрелгән камчыны хәтерләтә. Нечкә язылышы, билгесезлек тамгасы буларак, бик күп тамгаларның кыйпылчыкларыннан хасил була.

(ң) Иңү, чиксезлектән жыелу, билгесезлектән үсү тамгасы. Язылышында тамактан, эчтән әйтелгәне тоемлана.

(п) Сугу, кисү, бәреп чыгу, көч куллану, омтылуны аңлата.

(р-рь) Ирлек, житлеккәнлек, көч, максатка ирешү, ышаныч билгесе.

(с-сь) Күктән яуган тамчылар калдырган эзгә охшаган бу билге сулыш, агу, таралу, таркалу, сызгыру, чатнауны белдерә.

(т-ть) Туктату, тию, тыю, тау, таш, корал, көчне белдерә. Алхимиклар Марс планетасын каты «Т» тамгасы белән билгеләгәннәр.

(у) Яну, тәэсир итү, омтылу, атылу, жыелу, кисү, үтәли чыгу билгесе.

(ө-ү) Каршылык аша үткәндә үзгәрүне күрсәтә.

(ч-чь) Калын һәм нечкә язылышларында да «Чин» — дөньяда иң күп халыкка ия Кытай иленә ишарә бар. Хәтер, көч, ныклык, үрчем тамгасы.

(ш) Тукталыш, хәрәкәткә өстәмә көч кирәклеге, киртә, каршылык барлыгы күрсәтелгән.

(ы-и) Хәрәкәткә көч бирү, үсешкә әзер икәнне күрсәтеп тора.

(э-е) Күтәрелү, көч бирү, үсеп чыгу, егылу мөмкинлеге. Язылышы жил сыйпаган үләнне хәтерләтә.

Кешелек тарихында язу барлыкка китерү, авазларны билгеләү үтә әһәмиятле адым санала һәм борынгы бабаларыбыз тәжрибәсе моның гүзәл бер үрнәге булып тора. Рун язуы, борынгы төркиләр ижаты буларак, телнең бөтен нечкәлекләрен, тарихи үсешен үз эченә сыйдырган дип тә уйларга урын бар. Телебездә сүзләрнең ничек барлыкка килгәнен рун язуына таянып тикшерергә дә була. Берничә мисал карап китик.

Ат — фигыль һәм исемне белдерә, ике аваздан тора. [А] — чиксезлек авазы, [т] — тию, туктату, таш (корал) мәгънәсендә кулланылган. Ат — көч белән чиксезлеккә ыргытырга боерык. Дүрт аяклы ат дигән сөйкемле хайван да безнең бабаларыбызны дала чиксезлегенә ыргылдырган.

Су — агу аша таркалу һәм җыелу.

Ут — сүзнең язылышында [т] утны бәреп табу ысулын күрсәтә. [У] авазы үзе генә утны белдергән булырга да мөмкин.

Безнең милләтнең атамасы күп бәхәсләр тудырды һәм тудыра. Чит кеше, ят кеше, кыргый кеше, тәмуг кешесе — «татар» сүзенә галимнәр биргән аңлатмаларның кайберләре генә. Бу аңлатмаларның уйдырма икәнлеге күзгә бәрелеп торса да, алар хәтта мәктәп дәреслегенә дә кертелгән. Ә бит «татар» сүзе гасырдан-гасырга, телдән-телгә бик кадерләп тапшырылган сүз булган. Японнар корыч эретә торган мичләренә «татара», диләр. «Татар телен өйрәндем һәм татарча сөйләштем», — ди үзенең истәлекләрендә сәяхәтче Марко Поло, Көнчыгыш дөньясы өчен татар телен белүнең сулыш кебек кирәклеген ассызыклап. XX гасырның иң атаклы биючесе милләттәшебез Рудольф Нуриев турында язганда: «Атта чапкан татар каны аның биюендә», — дип сокланганнар. Ул үзе дә: «Атта чапкан татар бит мин», — дип әйтергә яраткан. «Татар» сүзенең һәр кулланышта да зур соклану, хөрмәт һәм кадер аша әйтелгәне күренә. Үз исемебезне рун язуында укып карыйк әле. Безнең борынгы язуыбызга таянып укыганда, «татар» сүзе өч сүздән тора: «т» — корал, «ат» һәм «ир» — кораллы атлы ир. Тарихи чынбарлыкка «татар» сүзенең нәкъ шушы укылышы туры килә дә инде.

Кайбер галимнәр төрки руналарны Себердә табылган ташларга төшерү өчен генә уйлап табылган очраклы язу дип тә баралар. Әйтерсең, Себердә фәннәр академиясе булып, тиз генә язу уйлап тапканнар да чокып язып та куйганнар. Бигрәк көлке фикер. Төрки руналар белән язылган «Ырк битик» (Юрау китабы) китабы табылу мондый беркатлы фикерләргә юл калдырмый югыйсә. (Китапның русча тәрҗемәсен интернеттан алып укырга була.) Кәгазьгә язылган төрле текстлы 20 фрагмент табылуын да билгеләп китәргә кирәк.

XIX гасырда (Себердән тыш) Истанбул шәһәрендә кәрван-сарай стенасына төрки руналар төшерелгән текст табалар. Бу текстның язылу вакыты төгәл билгеле — XVI гасыр. Димәк, төрки руналарны куллануны VIII гасыр белән генә чикләү дә сораулар тудыра.

Борынгы миф һәм легендалар, дастаннар дөнья яралу, тарих, андагы геройлар һәм үз заманында тупланган белемнәрне киләчәк буыннарга җиткерүче әһәмиятле мәгълүмат чыганагы булып тора. Археологлар шул легендалар, дастаннар эзе буенча барып, Троя шәһәрен казып чыгара, борынгы Мисырның күп тарихи урыннарын ача. Мифка нигезләнеп, галимнәр бүген дә Нух пәйгамбәр көймәсен эзләүләрен дәвам итә. Один турындагы легенда да төрле дип саналган рун язуының башлангычы Азия кыйтгасында булган уртак бер чыганакка барып тоташуын күрсәтә.

**Әдәбият**

1. Зәкиев М.З., Максимов Н.В. Татар теле. Дәреслек. — Казан: «Мәгариф», 1999.

2. Идегәй. Татар халык дастаны. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1994.

3. Из глубины столетий. — Казань: Татар.кн.изд-во, 2000.

4. История письма: Эволюция письменности от Древнего Египта до наших дней. — М.: «ЭКСМО»; TERRA FANTASTICA. — СПб., 2002.

5. История татар с древнейших времён в семи томах. Том I: Народы степной Евразии в древности. — Казань: «Рухият», 2002.

6. Кеннет Медоуз. Магия рун (тайные знания мудрецов). — М.: Издательско-торговый дом «Гранд», 1997.

7. Мифы народов мира. Энциклопедия. — М.: Издательство «Советская энциклопедия», 1982.

8. Хлевов А.А. Предвестники викингов. Северная Европа в I-VIII веках. — СПб.: Издательство «Евразия», 2002.

9. Языческие божества Западной Европы. Энциклопедия. — М.: «ЭКСМО»; СПб.: «МИДГРАД», 2005.

**Зәрия ХӘБИПОВА**

# ЧЫН ТУКАЙ ӨЧЕН КӨРӘШЕП...

Ибраһим ага идеягә бирелүчән, бер башына килгәнне һич чыгарып ташламый торган зат иде. Бу хакта аның бөтен тормыш юлы ачык сөйли. Озак еллар Тукайга багышлап роман иҗат итү хыялы белән янган И.Нуруллин башта аның хакында кече күләмле әсәрләр яза һәм аларда Тукайны төрле яклап ачарга, тәрҗемәи хәленең төрле баскычларына үтеп керергә тырыша. Шушы вакытта ул шагыйрьнең катлаулы тормышын, бай иҗатын фәнни яссылыкта тирәнтен өйрәнергә һәм матур әдәбиятта әлеге темага янадан әйләнеп кайтырга кирәклек фикеренә килә, дип уйлыйм. Галимнең «Тукайның әдәби пародияләре» исемле тәүге мәкаләсе 1948 елда дөнья күрә һәм шунда ук әдәби-фәнни җәмәгатьчелек игътибарын яулый. Шул вакыттан алып, Тукайның иҗаты, ул узган юл, аның татар әдәбиятында тоткан урыны хакында уйлану И.Нуруллинның гомере ахырынача дәвам итә.

Алда аталган язмада галим Беренче рус инкыйлабына мөнәсәбәтле формалаша башлаган яңа татар әдәбиятын теоретик нигезләү көрәшенә Тукайның рецензия-фельетоннар, мәкаләләр, шигырьләр, бигрәк тә юмористик-сатирик рухтагы әсәрләр белән катнашуын әйтә. Алар ярдәмендә шагыйрьнең реализм һәм халыкчанлык принципларына каршы торучыларны, әдәбиятта милләткә зарарлы идеяләр үткәрүчеләрне фаш итүен күрсәтә; бу юнәлештәге эшчәнлегендә ул татар халкының һәм рус әдәбиятының пародик әсәрләр иҗат итү тәҗрибәсенә таянды, иҗтимагый-сәяси мотивларга өстенлек бирде, ди И.Нуруллин. Тукайның юмор-сатирасын, нигездә, пародияләрен эчтәлек һәм форма ягыннан анализлый, аларның әдәби һәм иҗтимагый төрләренә хас үзенчәлекләрне билгели һәм, Тукай — реализм принцибына буйсындырылган тенденциозлыкны, ягъни идеялелекне, демократик идеялелекне яклаучы рәссам, дигән нәтиҗәгә килә.

«Тукай тәнкыйтендә реализм һәм типиклык мәсьәләләре»ндә (1953) И.Нуруллин, Тукай реализмны тормышны механик рәвештә генә күчереп алуда түгел, билгеле бер фикер, идея, дөньяга караш ачыклыгында чагылдыруда күрә, дип билгеләп һәм аның, әдәбиятта халык тормышы өчен әһәмиятле мәсьәләләр куелырга, ана хезмәт итүче идеяләр үткәрелергә тиеш, дигән фикерен яклый. Галим Тукайның типик образны абстракт фикер җыелмасы итеп караудан ерак торуын, типиклыкны гомумилек белән индивидуальлекнең органик берлеге итеп аңлавын күрсәтә. И.Нуруллин карашынча, реализмның үзәк проблемасы булган типиклык мәсьәләсен куюы, әсәрләрне шул ноктадан бәяләве – Тукайның әдәбиятта реализмны ныгыту юлындагы көрәшендә иң югары нокта.

1954 елда яшь галим «К вопросу о развитии идейно-эстетических и литературно-критических взглядов Габдуллы Тукая» исемле кандидатлык диссертациясе яклый. Анда Тукайның идея-эстетик карашлары тормыш һәм иҗат биографиясенә мөнәсәбәттә, үсеш-үзгәрештә күрсәтелә. И.Нуруллинның бу юнәлештәге эзләнүләре, шул эзләнүләрне чагылдырган язмалары соңрак «Тукай эстетикасы турында мәкаләләр» (1956) китабында да чагылыш таба. Галим фикеренчә, Тукай мирасы фикер ноктасыннан гаять бай һәм аның хакында соңгы сүз һаман да әйтелмәгән. Әлеге хезмәттә автор, шагыйрь иҗатына бәйле рәвештә, халыкчанлык, реализм, әдәбиятның иҗтимагый роле мәсьәләләрен күтәрә; әдәби тәнкыйть принциплары, форма һәм эчтәлек, әдәбият һәм халык иҗаты арасындагы бәйләнешләр, әдәбиятларның үзара тәэсире һ.б. турында сөйли, шагыйрь мирасына комплекслы якын килә, идея-эстетик карашларын бер система буларак ачарга омтыла.

И.Нуруллин Тукай каләме камилләшүдә XIX йөз әдәбиятындагы унай идея-эстетик традицияләрнең, татар халык иҗаты һәм рус классик әдәбиятының хәлиткеч роль уйнаганлыгын күрсәтә. Галим шулай ук шагыйрьнең әдәби тәнкыйть принциплары турында сүз йөртә, бу унайдан Тукай объективлыкны, демократик идеялелекне, чынбарлыкны яклаган дип билгели. Әлбәттә, галим хезмәтләрендә, шул исәптән монысында да чор идеологиясенә бәйле туган субъективрак карашлар да чагылыш таба. Әйтик, укучыга Тукай милләтнең алгарышына каршы хәрәкәт иткән

аерым бер динчеләргә, билгеле шәхесләргә генә түгел, дингә һәм дини-әхлакый, дини-суфичыл әдәбиятка каршы да кискен көрәш алып барган кебек аңлашыла. Үз карашларында да кайвакыт каршылыклы булуына карамастан, И.Нуруллин инде алтмышынчы еллар башында ук Тукай иҗатын, идеологик ноктадан бәяләүдән китеп, объектив яктырту кирәклеген әйтә.

Ибраһим ага хәтта диссертация яклауда да үзенчә булып кала, беркемне кабатламаган Тукай юлыннан китә: җитәкчелек, яклату киңәшмәсе өчен банкет уздырмый, ә табынны үз дусларына гына өендә кора. Бу кыланышының нәтиҗәсе озак көттерми, аны типкәләүләр башлана. Р.Нуруллинаның алда аталган истәлекләреннән күренгәнчә, аңа Якуб Агишев болай дип аңлата: «Галимнәр дөньясына яклау вакытында түгел, банкетта керәләр». Диссертацияләр аз якланган татар дөньясында бу ачы, әмма асылда күпмедер чынбарлыкны да чагылдырган һәм күпләр хакыйкать санаган күренешне Ибраһим ага асылда белми, һәм ул әле бик азларга гына билгеле була.

И.Нуруллинның шушы вакытка әдәби уңышлары да башлана кебек. Мәгариф министрлыгы уздырган конкурста аның балалар хикәясе беренче урынны ала. Сонрак галимне өнәмәүчеләр әдипнең бик отышлы язылган, сюжетлары тик үзе күргәннән һәм чынбарлыктан алынган балалар әсәрләрен дә актуаль проблемаларны чагылдырмый, эчтәлеге тормыштан ерак, дип гаепләп чыга. Студентларымның фәнни эзләнүләре Ибраһим аганың нәкъ менә балалар өчен хикәя жанрында каләм осталыгына иялеген, аларның хәзер дә мәктәп дәреслекләренә кертеп булырлык икәнлеген ачты. Ә бит дәреслекләр өчен бер уңышлы язылган хикәя юк заманда яшибез һәм бу төр конкурсларга да бик мохтаҗбыз. Аны укып-укып карыйм да Ибраһим ага чынлыкта яхшы хикәяче булган, дигән фикергә киләм. Их, язсыннар иде әле бүген андый әсәрләрне!

Ибраһим абый гыйльми эзләнүләрендәге, бигрәк тә Тукай фәнендәге уңышларын әдәбияттагылары белән кушар, артыкка китәр дигәндәй, әдәбият юлында тагын да зуррак киртәләр тудырыла. 1960 елда нәшриятка матбугатта чыккан хикәяләрен җыеп тапшырса да, иң көчле эчке рецензентлардан булган Ибраһим Гази һәм Гази Кашшафларның унай бәяләмәләрен алуына карамастан, китапны бастырмыйлар.

Студент чагында ук яшь каләмдәшләре белән үзара тәнкыйтьләшергә күнеккән, белемлелеге белән шаккатырган, Тукай һәм Сталин стипендияләрен алган, беренче курста укыганда ук фәнни эшләре конкурста җиңгән Ибраһим абыйны мөгаллимнәр җәмгыяте дә кочак җәеп каршы алмый. Житмәсә, ул студент чагында Хатип Госман белән фәнни бәхәсләргә кереп, анда үзен өнәмәү хисе уяткан була. Менә шушы чакта аңа борылырга да китәргә, үзен нәфис иҗатка багышларга, каләмен үстерергә һәм әдип буларак кына танылырга иде дә бит. Гаделсезрәк тә тәнкыйтьләргә дучар ителгән Ибраһим ага фән юлын сайларга карар кыла һәм тагын ялгыша да шикелле. Ә бәлки Ходай аны безгә Татар шагыйренең бөеклеген, талантын күрсәтер галим булачагын белгәнгә, олы фән юлына кертеп җибәргәндер? Кирәкмәгән ыгы-зыгылар мәйданын фәннеке белән чикләгәндер?..

Галимнең «Совет әдәбияты»нда 1961 елда дөнья күргән язмасы татар җәмәгатьчелеген айнытып җибәргәндәй итә. И.Нуруллин анда 1960 елда Тукай турында чыккан истәлекләрнең фальсификацияләнгәнлеге өчен, басманы чыгаручы һәм җаваплы мөхәррирләре Сәгыйть Исәнбай белән Гали Халитне үзе яраткан Тукайча көчле тәнкыйть утына ала. «Шагыйрьне өйрәнү юлында» (1966) язмасында галим: «Тукай кемнеңдер күтәрүенә, ясалма бизәкләргә мохтаҗ түгел, аның үз бөеклеген генә ачарга кирәк, ягъни фәннилектән тайпылмаска кирәк», — дип белдерә һәм үзе дә, заман мөмкинлекләреннән чыгып, шагыйрьне чагыштырмача объектив, иң мөһиме җанлы кеше сыйфатында яктыртуга ирешә.

«Тукай иҗаты (Беренче рус инкыйлабы чоры)» (1964) китабында И.Нуруллин Тукайның идея-эстетик карашларын Беренче рус инкыйлабы, иҗтимагый хәрәкәт, шагыйрьнең яшәү шартлары, тирәлеге, алган белеме, шул исәптән өйрәнгән әдәбиятлары белән тыгыз мөнәсәбәттә чагылдыра. Галим, Тукайның 1906-1907 еллар поэзиясендә халыкчанлык принциплары җинә, бу алга китеш барыннан да элек иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-эстетик карашларының үсешенә, әдәбиятның иҗтимагый ролен революцион-демократик рухта аңлый башлавына бәйләнгән; Тукай тәнкыйди реализм принципларын гамәли рәвештә тормышка ашыру белән

бергә, әлеге иҗат юнәлешенә карата кайбер фикерләр дә әйтә башлый, дип белдерә. Тәнкыйтьче, Тукайның мәхәббәт лирикасында, көнчыгышның шартлы-романтик стиленнән арына барып, әкренләп рус поэзиясе тәҗрибәсенә йөз тотуын билгели.

И.Нуруллин «Тукай эстетикасы һәм рус әдәбияты» мәкаләсендә шагыйрьнең Крылов, Кольцов, Пушкин, Лермонтов h.б. белән бәйләнешләрен тәгаен мисаллар ярдәмендә ача. Әйтик, Тукайның реализм турындагы фикерләренең формалашуында Гоголь иҗаты зур роль уйнавын әйтә; шагыйрьнең идея-эстетик позициясе революцион-демократик поэзиясенең башында торган Некрасовка аеруча якын, дип белдерә. И.Нуруллин Белинский, Чернышевский, Добролюбов һәм Писарев кебек тәнкыйтьчеләрнең дә Тукайга тәэсир ясавын билгели. Шул ук вакытта ул Пехтелев «Пушкин, Лермонтов, Тукай» исемле китабында Белинскийның Тукайга идея тәэсире булганлыгын ачыклап китүен игътибарга ала һәм, тәнкыйтьчеләрнең, бер-берсеннән алган фикерләргә нигезләнеп кенә, Тукайның Уральскида вакытта ук Белинский әсәрләрен укыган, дигән хупламавын әйтә.

Узган гасырның алтмышынчы-җитмешенче елларында И.Нуруллин, татар әдәбияты тарихы, әдәбият теориясе, әдәбият белеме буенча берничә китап яза, аларда ул еш кына Тукай иҗатына таянып фикер йөртә, карашларын раслый. И.Нуруллин хикәяләрен Тукай тормышына һәм иҗатына бәйле документлар, расланган фактлар нигезендә иҗат итә. Алар шагыйрь тормышының төрле чорларын, вакыйга-хәлләрен яктырта. Әдипкә башка темаларга язуга да Тукай иҗаты этәргеч биргәли. Әйтик, «Эш беткәч уйнарга ярый» (1952) әсәрендә автор балаларга кечкенә вакытта ук дөрес тәрбия бирү кирәклеген Алмаз исемле герое ярдәмендә аңлата. Ул Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый» шигырен укыгач, үз гамәлләре, ясаган хаталары турында уйлана һәм аларны төзәтү юлына баса.

1975 елда галимнең Тукай фәнендәге барлык уңышларын чагылдырырлык фәнни-әдәби «Габдулла Тукай» китабы дөнья күрә һәм 1982 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Алга таба галим Тукай тирәлеген, әйтик, җан дусты Ф.Әмирхан тормышын, иҗатын өйрәнү белән ныклап шөгыльләнә башлый, Тукай мирасын заман биеклегеннән торып бәяләү кирәклеген дә онытмый. И.Нуруллинның Тукайга кагылышлы булган шактый хезмәтләре, шул исәптән «Тукай» романы русча да дөнья күрде. 2000 елда «Тукай» романының үзгәртелгән, тулыландырылган басмасы — «Моңлы саз чыннары» чыга. Әлеге романда Тукайның тормыш һәм иҗат юлы җиде бүлеккә, ягъни тормышында әһәмиятле саналырлык этапларга бүленеп яктыртыла.

Алман галиме Михаэль Фридрихның «Габдулла Тукай – высокочтимый поэт на службе татарской нации и советского социализма» китабында И.Нуруллинның Тукай мирасын яктыртуга керткән өлеше темага мөнәсәбәттә чагылыш таба. Әлеге хезмәт һәм галимнең вакытлы матбугатта дөнья күргән язмалары Тукай шәхесенә, иҗатына бәйле бәхәсләрне объектив ачуы, шул исәптән бу бәхәсләрдә И.Нуруллин позициясен дөрес бәяләве белән әһәмиятле, һәм ул кинкатлам татар укучысына да ирештерелергә тиеш дип саныйм.

Ибраһим абыйны бездән дә яхшырак белгән Розалина Нуруллина, аны усал дип бәяләүчеләргә каршы, һәрдаим аның усал булмыйча, таләпчән икәнлеген яза. Мин дә шушы фикердә торам. Безнең татар кешеләре, бигрәк тә куркаклары, ялагайлары, үзләре дә тәнкыйтькә эләккәннәре еш кына төшенчәләрнең мәгънә эчтәлеген үзгәртеп куллана. Кешенең сүзе ныклы булдымы, үзен бернинди һөҗүмнәр ясап та куркыта алмадылармы, аның хакында усал дип фикер тарата. Мин Ибраһим абыйны усал гына түгел, хәтта бик йомшак иде дип раслыйм. Үземә мөнәсәбәтеннән чыгып, бары тик шундый бәяләмә бирә алам. Ул талантларга йомшак, булдыксызларга артыгы белән таләпчән иде. Һәм иң зур таләпчәнлекне ул үз-үзенә күрсәтте, шул таләпчәнлеге аркасында, безгә Тукай хакында күпсанлы кызыклы, мәгънәле, дәлилле, бай мәгълүматлы хезмәтләр язып калдырды.

**Рифә РАХМАН,**
*филология фәннәре кандидаты*



*Самия Тимербаева — Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында туып үскән. Белеме буенча филолог. Соңгы ун елда Италиядә яши. Шигырьләрендә туган якка, татар халкына, татар теленә мәхәббәт, сагыну хисләре, мәхәббәт лирикасы өстенлек итә.*

# КҮҢЕЛЕМНЕ САГЫШ БИЛӘДЕ

## Туган телем

Туган телдә сөйләштем мин бүген,
Күңелем китте гүя ачылып.
Күпме матур уйлар, әйтелмәгән сүзләр
Тел очымда торган басылып.

Туган телдә сөйләштем мин бүген,
Сүзләремне кат-кат барладым.
Үз телемнең нинди матурлыгын,
Тәмлелеген бүген аңладым.

Туган телдә сөйләштем мин бүген,
Күңелем тулы татлы сүз икән.
Туган җирдән читтә яшәгәчтен,
Сабыр гына булып түз икән.

## Татарым

Кайларга сибелгән татарым,
Калдырган ул газиз Ватанын.
Нужасын төягән иңенә,
Еракка юл алган иленнән.

Кайларга сибелгән татарым,
Өметен беркайчан өзмәгән.
Тырышкан, тырмашкан, җан аткан,
Бәхетен читләрдән эзләгән.

Кайт әле Казанга, татарым,
Бу — йорты бабаңның, атаңның.
Күңелдән уелмас, хәтердән җуелмас
Казаның — ул синең, бердәнбер Ватаның.

## Көз

Соңгы яфрак төште өзелеп —
Алтын көзнең соңгы бизәге.
Карадым да аңа, нигәдер,
Күңелемне сагыш биләде.

Көзләрне ник монсу, дибез без,
Көзләр дә бит матур, күрегез.
Гомеркәйләр көзгә үрмәли,
Көзләргә авыштык үзебез.

Сары төсне сагыш, дибез без,
Сары төс ул — кояш бизәге.
Ә шулай да карап көзләргә,
Күңелне бер сагыш биләде...

## Соңлаган сөю

Кем уйлаган, көзләр килү белән,
Сөю килер диеп яңадан.
Әйтерсең лә күңел яралары
Булмаган да, күптән ямалган.

Йөзләремә еллар эзен салган,
Чәчләремне кырау каплаган.
Тынгы белмәс ярсу йөрәк кенә
Яшьлек дәрманлыгын саклаган.

Саф йөрәгем гүя серле сандык,
Уй-хисләрем тирән бикләнгән.
Шул ачкычны тапшырырдай кеше
Синме икән, диеп шикләнәм.

*Италия, Сан-Марино*



*Рәмзия Әхмәтова – Актаныш районы Уразай авылында туып үсә. Минзәлә педучилищесын һәм Казан дәүләт университетының география факультетын тәмамлый. Шигырьләре лирик-самими, хис-кичерешләргә бай.*

## ҖАНЫМ — ШИГЫРЬ, КҮҢЕЛ — МОҢ

### Шигырь көче

Һәр күңелдә яшеренеп,
Бер шагыйрь ята.
Язгы кичләр, якты хисләр
Аны уята.

Гади генә сүзләрдән дә
Шигъри моң акса,
Уятып һәрбер күңелне,
Тәрәзен какса,

Йөрәктән чыккан хисләргә
Сүзләр табылса,
Таш бәгырьне дә елатып,
Җанга кагылса,

Туган телнең көче шунда —
Шигырьнең көче.
Җырлата да, елата да
Чын шагыйрь кеше.

Алтын бәһасенә торыр
Әйткән һәр сүзе,
Бер шагыйрьне җиңә алмас
Дошманның йөзе.

Шигырь тәмен тойган җаннар –
Рухи туганнар,
Алар күңелендә яши
Тукай, Туфаннар.

## Көзге җил

Сердәш яфраклары очты —
Җиргә инде сарылык.
Алашып йөри көзге җил,
Агачларга сарылып.
Әле тәрәзәгә чиртә...
Үтә җанга сугылып,
Эзләреннән тамчы-тамчы
Сагыш кала сыгылып.
Күшеккән җиргә сылана:
Ул да җылытыр түгел.
Җил сыеныр урын эзли,
Әйтерсен, ятим күнел.

## Җаным — шагыйрь

Күктән синсез җиргә индем:
Җаным — шигырь, күнел — моң...
Сызланып елаган сазның
Ник бер кылы түгел мин?!

Мәхәббәтем җырга сенеп
Түгелер иде саздан...
Адаштырдым сагышларны! —
Эзләрсең... тәүге яздан.

Өйрәндем синсез яшәргә,
Инде ялгыз түгелмен:
Уянды хистән мөлдерәп
Җаным — шагыйрь...
Түгел, моң!

## Минем күңел

Минем күнел сары көздәй...
Моңнар тулган яраларга.
Өзгәләнә, йолкына җил
Сагышлардан араларга.

Минем күнел салкын кыштай...
Керфекләрен ак бәс сарган.
Күзләрендә — туңган назлар...
Боздай салкын җанга тарган.

Минем күнел нурлы яздай...
Күкләрендә — киек казлар.
Катлаулы да, бик тә гади
Күнелемне аңлый азлар!

# ҖЫР ДӘВАМ ИТӘ

ОЧЕРК

*...Бөтен кешеләргә ишетелерлек итеп:*
*«Яшисе килә!» – дип кычкырырдай булам...*
Разил Вәлиев

Сизелер-сизелмәс кенә шадраланып торган кечкенә күл өстендә ялгыз аккош йөзә. Яр буенда ашыкмый гына ял итеп йөргән адәм балаларының аптыраулы йә кызыксынулы карашыннан качарга теләгәндәй, бер читтә боегып утырган таллар күләгәсенә дә килеп сыена ул, уйга чумган халәттә күл уртасында да оеп кала. Парын җуйган мәлендә яшәү ямен тәмам югалткан иде; ул чагында көн саен, сәгать саен ишетелгән тормыш җыры кыл калынлыгында гына булса да тотынып өметкә, якты бер нурга әверелде:

*Исеңдәме, иркәм,*
*Таныштык без икәү,*
*Җылы яктан кошлар кайтканда.*
*Көннәр аяз иде,*
*Күңелдә яз иде,*
*Яшьлегебез чәчәк атканда...*

Аларның моңлы тавыш белән парлап җырлавын ишеткән саен, аккошның яралы җанына беркадәр шифа ингәндәй була иде. Җыр кинәт өзелде. Вакытсыз өзелде, көтмәгәндә.

***

Аны һаман сагыналар, һаман яраталар һәм... битәрлиләр: «Нигә үзеңне сакламадың син?» Ташлап китүен кичерә алмагандай, һәркемнең телендә үпкәләүле бер аһән чагыла: «Барыбызны кайгырттың – тик үзең турында оныттың...»

Чикле генә гомер кишәрлеген сокланып туймас адымнар белән үткән гаярь кешеләр була. Фаяз Ибраһим улы Ибраһимов – шундыйларның берсе. Кем ул, ни өчен аның исемен гаҗәеп бер мәхәббәт, олылау һәм шаккату белән телгә алалар?.. Табиб. Житәкче. Менеджер. Җырчы. Рәссам. Төзүче. Дизайнер. Умартачы. Бакчачы. Гаҗәпләнмәгез, болар барысы да егерме ел буе «Бәкер» шифаханәсен җитәкләгән баш табибның – бер шәхеснең җан түренә сыенган һөнәрләр.

Мин кайчандыр, әле мәктәптә укыганда ук, көндәлек дәфтәремә Юлиус Фучикның «Кешеләр, мин сезне яраттым!» дигән сүзләрен күчереп куйган идем. Дөресен әйтим, асыл мәгънәсе турында әллә ни уйланып тормыйча гына... Фаяз Ибраһимов шәхесе белән аның вафатыннан соң гына танышырга туры килгән көннәрдә ни өчендер нәкъ менә шушы гыйбарә кылт итеп исемә төште. Күпләр «феномен» дип телгә алган табибның яшәеш сере әлеге сүзләргә сыеп беткән түгелме соң? Тормышны, хезмәтне, кешеләрне ярату һәм бар булмышын биләп алган җаваплылык хисе. Нибары шул. Нибары?..

— Әткәй, бу әрдәнәләрне әле беркөн генә теге урыннан монда күчергән идек, хәзер кире шунда ташырга дисен...

— Эш сөйгәнне ил сөяр, улым. Тик утырганчы, ике кулыңа бер эш булсын...

Юк, Арча районы Ташкичү авылын да, бакча артында ялгыз нарат үскән тыйнак



йортны да күргәнем булмады минем, тынгысыз жанлы Ибраһим агайның балаларына биргән сабагын да ишетергә туры килмәде. Сабырлык белән сугарылган Гафифә апаны да күрергә өлгермәдем. Шулай да бу гаиләдәге ата, ана һәм бала мәхәббәтенең ни дәрәжәдә югарылыгын тормыш үзе сөйли кебек. Унынчы сыйныфны бетергән Фаязның, авыру әнисен терелтү өчен табиб булам дип, үҗәтләнеп, медицина институтына омтылуы да моның бер мисалы бит. Беренче елны капкаларын киереп ачып тормаса да, иртәмесонмы аның барыбер үз дигәнен итәчәген Казан да аңлаган: фермада эшләп, китапларын шунда тәрәз төпләренә тезә-тезә имтиханга әзерләнгән егетне икенче килүендә борып җибәрергә ашыкмаган. Әллә соң Фаязның: «Фирдәлия белән бергә итәсен килсә, русча диктантны әйбәт язарга үзең булыш берүк», — дип Аллаһы Тәгаләдән ялварып сораулары ярдәм иткәнме... Шулай булмый ни: Ташкичүгә математика укытырга килгән кызны бер күрүдә ошатып өлгерде ләбаса. Күмәкләшеп концерт куйган кичләр, үзенең очына-очына матрос биюен башкарулары, Фирдәлиянең мари кызы булып тыпырдап биюләре ике йөрәктә очкын кабызырга житә калды. Кызның көзгә Казанга, пединститутның чит телләр факультетына жыенуын белгән Фаяз бу юлы имтиханнарны таш яуса да бирергә тиеш иде.

Сират күперен кичеп, «ниһаять, мин — медицина институты студенты» дип җиңел сулыш алгач, булачак укытучылар исемлеген карарга йөгерсә, ни күрсен: анда Фирдәлиянең фамилиясе юк бит! Тик ни хикмәт: тулай торак бүлмәсе ишегенә: «Фаяз, мин үттем, синең хәлләрең ничек?» дигән записка кыстырылган. Яшьлегем — гүзәллегем, яшьлегем — жүләрлегем димәсләр иде аны... Чая кыз кай арада уйниятләрен үзгәрткән дә, әйтми-нитми генә, университетның татар теле бүлегенә имтиханнар тапшырып яткан!

Һай, ул чаклар...

— Фаяз, мин синнән олырак бит. Үз группаңда яшьрәк кызлар бетмәс. Дуслар булып кына калыйк...

— Фирдәлия, мин бит синең паспортыңа карап килмәдем...

Тоткан жирендә өзә торган егетнең бу сүзләренә ни дисең? Ат яхшысы тездән билгеле, егет яхшысы сүздән билгеле. Әнә бит ул, күзләрендә — ихласлык, гамәлләрендә — ихтирам, адымында — ныклык. Тормышның һәр өлкәсеннән тәжрибә тупларга өлгергән аксакал дияр идең, егерме яшь кенә үзенә. Лечфак егетләре стройотряд белән Алабуга якларына төзелешкә киткәндә, аш пешерүче итеп Фирдәлияне дә алган иде, күр әле, үзе гомер буе повар булып эшләгәнмени, нәрсә ди:

— Син шулпаңны көндезгә күп итеп пешер дә яртысыннан кичкә яңа төрле аш әзерләрсең, алай җиңелрәк булыр...

Уку беткәнче ике тулай торак арасын бер итеп йөгерергә сабырлыгы житмәдеме, Фаязның:

— Әй, урамда вакыт әрәм итеп йөргәнче, тотыйк та өйләнешик инде, Фирдәлия, — дию дә уйнап түгел, уйлап әйтелгән сүз булып чыкты. Бербенсенә таяныр тал итеп карамасалар, мәхәббәтләрен пар балдак белән беркетергә ашыкмаслар иде анысы... Жан сөйгәнең белән алачыктагы тормыш та җәннәткә тиң, диләр бит. Яңа бистәдә берәүләрнең өйалды кебек бүлмәсендә фатирда торганда, алар бергә булулары белән бәхетле иде. Иртәнгә чүпрәк булып чүпрәк шыкраеп ката торган бүлмәне жылыту өчен, Фаяз ташландык йортлардан утын кисеп кайтуны да, вагон бушатырга йөрүләрне дә авырлыкка санамады. Беркадәр вакыттан соң, нарасый гына булган Маратларын биләүсәгә салган ике яшь белгечнең кулына Лениногорскига юллама тоттырганда, өч елга гына эшкә киләбез дип уйлаганда, бу төбәкнең гомерлеккә үзенә бәйләп

калдырасын, балалары, оныклары өчен туган туфракка әйләнәсен алар күз алдына да китермәгәндер, мөгаен...

Эшчеләр бистәсе булган Шөгер ягы дөя өркәчедәй тезелеп киткән Керкәле таулары, йолдыз күзе булып җәйрәп яткан күлләре, тау битеннән саркып чыккан чишмәләре белән балкып каршы алса да, эш урыннарына карап аһ итәрлек түгел икән шул: Фаяз Ибраһимович эшлисе больница – элекке төрмә урынындагы иске бер корылма; Фирдәлия укытырга тиешле мәктәп – өч чакрым җәяү йөрешле Иске Шөгер авылында. Ярый инде, теш табибына дип бирелгән йортына карап сөенерлек: дүрт фатирга исәпләнгән, ике катлы! Өйне «бизәргә» туйга салынган кашыклар бар да бүләк итеп бирелгән бала караваты бар. Туган якларны, әткәй-әнкәйләрне сагыну җанны телгәләсә дә, түзми кая барасың... Доньяларын түгәрәкләп, кызлары Гөлназ да тугач, үз ишегалдына ия аерым йортка күчеп, куяннар, мал-туар асрый башлагач, көнкүреш мәшәкатьләре дә бөтереп ала.

Бу чор да – гаиләнең пар канатлы мәле, балаларның әтиле балачагы. Дөрес, бик тиз арада тирә-якка даны таралырга өлгергән теш врачы эш сәгате дигәнне белми белүен: коридорда чират көтеп утырган соңгы авыруны озатып җибәрмичә, кабинетын бикләп кайтуны башына да китерми. Ял көннәрендә, төн уртасында өенә тиклем килгән кешене дә борып җибәрү юк: больницага бара, кабинетын ача, кирәкле ярдәмне күрсәтә. Шулай да буш вакыт тәтегәндә, Мараты белән Гөлназы утырган ике чананы бергә бәйләп, тартып йөрергә җай да чыга; яна ел якынлашканда, улын-горурлыгын ияртеп, чыршыга барырга да житешә. Әлбәттә, барган-барган, ике чыршы алып кайтыш: берсе – өйгә, икенчесе, зуррагы – больницага. Җәйләрен, берничә гаилә җыелып, табигатькә чыгулар, урманга бәлешкә тиклем пешереп алып барулар, ишегалдында учак тергезеп, пылау әзерләүләр – сагынып сөйләргә генә калган татлы мизгелләр.

— Безнең Ибраһим бабай балаларын эш белән үстергән, әти дә безне шул үрнәктә тәрбияләде. Каты булды, гадел булды, урамда буталып йөрүебезгә юл куймады. Мәктәптә укыганда, җәй саен мине эшкә кертә иде, кирпеч заводында да, мелиорациядә дә, битум заводында да эшләргә туры килде. Җәй көне бабай безгә килгәч, атналар буе урманда печән әзерләп ята идек. Чәй үләннәрен, мәтрүшкәне танырга шул чакларда өйрәндем. Мин үсә бардым, минем белән бергә чалгы да үсә торды... Ә болай балачагым әтинең эш кабинетында үтте минем, шунда уйнарга ярата идем. Мәктәпне әйбәт бетердем, дүртлеләрем бик аз иде. Документларны мединститутка да, КХТИга да тапшырдым, имтиханнарны яхшы биреп, икесенә дә үттем. Шул чагында әтинең әйткәне бүгенгедәй истә: «Нефть кайчан да булса бетә ул, улым, медицина бетми», — диде... Ул безнең «дөрес» кеше булуыбызны теләде. Яшьтәш малайлар мотоцикл ала башлагач, минем дә күз кызыккан иде, әти шулчакны абзарга дүрт үгез кайтарып бәйләде: «Мотоцикл аласың килсә, шуларны кара, тәрбиялә», — диде ул, артык үгет-нәсихәт биреп тормый гына. Әйтәм бит, ничек тә безне эш белән тәрбияләргә тырыша иде. – Бу сүзләрне Марат сонрак, үзе дә бала атасы, үзе дә табиб, үзе дә җитәкче булгач, кадерле кешесен эчке бер сагыш белән искә алган минутларда әйтәчәк. Ә ул чакта...

Фаяз Ибраһимовны инде Шөгер больницасына баш табиб итеп билгелиләр, тәүлек сәгатьләре тагын да кыскаргандай була: алны-ялны онытып, эш дип, больницаның яңа бинасы, гаражлары, ашханәсе дип, төн йокысын онытып чабулар башлана. Гаилә дә ишәя төшә: төпчекләре Алмаз туып, өй балаларның рәхәт шау-шуына күмелә.

— Юмарт булды инде Фаяз, кая барса, туган-тумачага, күрше-күләнгә дә житәрлек итеп, кочак-кочак күчтәнәч күтәреп кайта иде. Бервакыт бер баш умартабыз бар иде, шуннан бер чиләк бал алдык та бөтен күрше-тирәгә касә-касә бал өләшеп чыктык. Кеше хакына керү дигәнне белмәде ул. Исемдә әле: аралашып йөргән кешебез башкорт якларына ак майга барырга җыена. «Безгә дә бирәр кило ал әле», — дим мона. И аптырады инде: «Ник, Фаяз больницадан ала алмыймыни?» — ди исе китеп. Аннан ни дә булса алып кайту түгел, еш кына үзенең хезмәт хакы да больница кирәк-ярагына тотыла иде. Баш хисапчы: «Фаяз Ибраһимович, бу айда да

табельга кул гына куясыз бит инде», — дигәч, «Фирдәлиягә акчаны үгез тапшыргач бирермен әле», — ди икән Фаяз...

Фирдәлия апаның өстәл җәймәсен ипләп кенә сыпыра-сыпыра сөйләгән сүзләрендә үпкәләү дә, ачулану да түгел, иренен шушы сыйфаты белән горурлану чагыла. Югыйсә, ул чакларда, үзе дә мәктәптә татар теле, әдәбияты укытып, баш-аягы белән эшкә чумган мәлләрдә, балаларны тәрбияләү, өй учагын җылы итеп саклау, абзар тулы мал-туарны кайгыртып тору җинелләрдән булмагандыр. «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән исемгә ия булу өчен, мәктәптә дә тәгәрмәч эчендәге тиен урынына бөтерелергә; «Фаязның тылы нык анын», диючеләр алдында сынатмас өчен, сабырлыгын да, хатын-кыз акылын да, ныклыгын да бер учка төйнәргә туры килгәндер. Нинди генә кичәгә, бәйрәмгә бармасыннар, парлап җырлаган җырлары тормыш юлын яктыртучы маяк булгандыр.

1984 елдан 1994 елга кадәр больницада баш табиб булып эшләгән Фаяз Ибраһимовичны «Бәкер» шифаханәсенә күчергәч, анын: «Эх, монда бер генә атна булса да ял итеп караган булсам, килергә ризалык бирмәс идем», — дип сыкранып әйткәнен ин якыннары гына ишетеп алгандыр. 1933 елда ук ачылса да, тирә-юнендә әллә никадәр табигый байлыклар тулып ятса да, аягында чак басып торган шифаханә аны гына шомга салмаган, ул елларда бирегә эшкә билгеләнгән шактый табибларны килеп карауга ук борылып китәргә мәҗбүр иткән.

— Мединститутны мин үзем сиксән дүртенче елны бетергән идем. «Бәкер»гә невропатолог кирәк дип шушында эшкә билгеләгәч, килергә ризалаштым. Килсәм — зираттагы кебек чаган басып бетергән ниндидер бер «глушь», ташландык караңгы урын, агач бараклар... «Юк, мин әйтәм, шушында кан басымы үлчәп утырыр өчен алты ел буе укыдыммы», — дим. Шулкадәр тискәре фикер белән киттем, югыйсә, беренче августта эшкә чыгарга тиеш идем. Өйләнеп, башка җирдә эш белешеп йөргәндә, эзләп табып, барыбер шушында китерделәр китерүен. Фаяз Ибраһимович белән бик килешеп эшләдек, ул беркайчан беркемгә юк дип әйтә белмәде. Медицинанын кайсы өлкәсендә нинди яналык күрсә, шул хакта кайтып сөйли, уртаклаша иде. Категория буенча укыйм дигән табибларга бер проблема да булмады, Мәскәүгә дә барып укыдык, профессорларны шифаханәгә чакырып, монда да лекцияләр тынларга мөмкинлек бирде. Элек белән хәзергене чагыштырсаң, җир белән күк аермасы инде... — Шушы шифаханәдә озак еллар эшләүче, югары категорияле невролог Васил Вәгыйзович Әхмәтжановны тынлаганда, хәзер гөлбакчага әйләнгән бу урынны ул тасвирлаганча күз алдына китерү бик авыр шул.

Шифаханә яна баш табиб Ибраһимовны беренче көннәрендә үк сынау белән каршылый — иске «кәтүлни» шартлый, аны тиз арада аякка бастырырга кирәк. Ял итүчеләргә дигән корпуслар — тавык кетәклеге хәлендә. Дәвалау корпусы — бөтенләй юк. Эшкә килгән белгечләр кайда яшәргә тиеш — бу сорау һавада эленеп тора. Заманча җиһазлар турында хыялланасы да юк кебек. Шифаханәнен территориясе — кеше куркытырлык... Ә чоры соң нинди, чоры! Хезмәт хакын акчалата түгел, кыярлата, бәрәнгелата, хәтта аракылата түләгән заман. Менә шул чагында Фаяз Ибраһимович, туры мәгънәсендә инбашына биштәр асып, эзләнүләр юлына үзе чыга. Ерак Себер нефтьчеләре, Алтай, Урал, Кавказ яклары... Шул чорда бик популяр булган «взаимозачёт» дигән сүзнең асылына төшенү өчен, табиб кына булып калмыйча, менеджер, экономист, төзүче дигән һөнәрләрне дә «үзләштерергә» туры килә аңа. Путёвкалар бәрабәренә кайда мәрмәр таш, кайда металл, кайда агач, цемент юнәтеп, шифаханәгә исем яулау башлана.

Кичә белән бүген арасында төп-төгәл егерме ел. Бизмәнгә салып карасаң, бик аз кебек. Үлчәү тәлинкәсенен икенче ягына йокысыз төннәрне, үтелгән юлларны, эшләгән эшләрне, уйлаган уйларны, йөрәккә җыелып килгән хис-кичерешләрне куйсаң, чамасыз күп шикелле. Шифаханәдәге тышкы үзгәрешләрне барлап-күзәтеп чыгу өчен берничә сәгать җитәр иде: исемнәре үк күңелне кытыклап торган «Аккош», «Сандугач», «Тургай», «Карлыгач» корпуслары; табибларның барысын бер түбә астына җыйган аерым дәвалау корпусы; эшчеләр

өчен дип төзелгән фатирлар; кайчандыр куенына карга оялаган чаганнар үсеп утырган урында — брусчатка җәелгән, гөл-чәчәкләргә күмелгән аллеялар, чүплек урынында — пар аккош кайтарылган түгәрәк күл; ял итүчеләрнең күзен иркәләгән зоопарктагы кәттә кошлар һәм хайваннар; хуш исе борын канатларына килеп ягылган нарат урманында, ачык һавада төзелгән музей; кайбер район үзәкләре көнләшерлек мәдәният йорты; ирексездән елмаерга мәҗбүр иткән, берсеннән-берсе сөйкемле таш сыннар; иң көйсез кешенең дә зәвыгын канәгатьләндерерлек, чит ил отелендәгедән һич ким булмаган ашханә, затлы ризыклар, «швед» өстәле; табигый минераль суы белән сыйлаучы бювет; балалар мәйданчыгы... «Күзәтеп чыгарга берничә сәгать җитә», дип язганыма үзем үк каршы килермен шикелле, санап чыгу өчен генә дә никадәр вакыт таләп итәлә! Әле «дәваланучыларның өстәлендә үзебез житештергән табигый бал булачак» дигән максаттан төзелгән умарталык; карабодай басуы, ат фермалары, күкерт исе аңкып торган күлләр, тау чаңгысы трассасы, ял итүчеләр өчен эшләнгән пляж, шашлык пешерү, машина кую урыннары турында да әйтергә уйласаммы...

Бу эшләрнең барысын да башкарып чыгу өчен нинди куәтле команда таләп итәлә! Инженерлар, проектчылар, рәссамнар, дизайнерлар... Ни гаҗәп, коллективтагылар барысы да: «Проектын Фаяз Ибраһимович үзе сызды... Мебельләргә, стенадагы обойларга тиклем үзе сайлады... Кайда нинди чәчәк утыртырга кирәклеген ул уйлап чыгарды... Картинаны үзе тәкъдим итте... Аккошларны ул кайтартты... «Бәкер» тарихын чагылдырган музейны ул оештырды... Артистларны ул чакырды... Бәйрәмнәрне ул оештырды... Җиһазларны ул кайтартты...» — дип кабатлый. Моңа ышану кыен. Аның өчен дә тәүлектә егерме дүрт сәгать кенә булгандыр бит. Вагыннан эресенә кадәр бөтен мәсьәләне хәл итеп бетерү өчен кайдан нинди көч алмак кирәк?..

— Аның бөтен гомере «Бәкер»не кайгыртып үтте, иртә таңнан кара төнгә кадәр ул шушында булды. Сәгать иртәнге алтынчы яртыда инде Фаяз Ибраһимовичның безнең урамнан үтеп киткәнен күреп кала идем, без эшкә килүгә, ул бөтен территорияне карап, кайда нинди житмәгән җир бар — шуны күреп өлгергән була, — дип искә төшерә җәмәгатьчелек белән элемтә буенча баш белгеч Миләүшә Мортазина. — Безнең коллективта биш йөзгә якын кеше эшли, Фаяз Ибраһимович һәммәбезне исемләп белә иде! Аның гаҗәеп бер сыйфатына соклана идек без: үзеннән алда эшләп киткән баш табиблар белән гел күрешеп тора, аларны кайгыртырга да җай таба иде. Бервакыт Казаннан, инде өлкән яшьтәге Фәридә апа Янгуразова яныннан кайткач: «Чәйнеге искергән, оныттырмассың әле, киләсе барганда, яңа чәйнек алып барырга кирәк», — дигәне бүгенгедәй исемдә... Кайда нинди күргәзмә була, ул ничек тә башкаларны да ияртеп барырга тырыша иде, чит җирләрне күрсеннәр, карасыннар, ди торган иде.

Баш табибның барган бер җиреннән матурлык алып кайтуына күнегеп беткәннәр инде, әкияти хыялларны беркөн килеп барыбер тормышка ашырачагына да инанганнар. Башкортстанның Красноусольск шифаханәсендә брусчатка җәелгәнне күрүгә, кайтып әйткән сүзе — «Киләсе елда бездә дә шушындый брусчатка булачак!» Железноводскида бювет күреп, мыек очына чорнап куйган. «Швед» өстәле турында уй керүгә, үзе проект ясап, Мәскәүгә барып, заказ да биреп кайткан. Биредә дәваланучыларга уңайлы булсын өчен, һәр корпусны, сәламәтләндерү үзәген, ашханәне ябык коридорлар белән тоташтыру турында хыялланганда, моның мөмкин нәрсә түгеллеген төзүчеләр дә, инженерлар да исбатларга маташкан — тик баш табиб телендә «эшләп булмый» дигән төшенчә юк. Нәтиҗәдә — уңайлы, җылы, якты коридорлар бөтен шифаханәне бербөтенгә әверелдергән.

«Татарстанның атказанган табибы, Россиянең атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәре, күпсанлы бүләкләре булса да, Фаяз Ибраһимович — фәрештә түгел бит, гап-гади кеше, аның да кимчелекле яклары булмый калмагандыр», — дим, сүз куешкандай барысының беравыздан баш табиб турында яктыдан якты гына сүзләр сөйләвенә аптырап. Хәер, балта соравыма да ахыр чиктә шөшле тотып калам...

— Эш барышында төрле хәлләр очрый, дәваланучыларның берәрсе баш табиб янына зарланып керсә, безгә катырак әйткән мәлләре дә булгандыр. Тик ул шунда ук гафу үтенә белә иде: «Ныграк әйтеп куйдым бугай... Мин дә тере кеше бит, үпкәләмәгез инде», — дип шунда ук йомшарып куя иде. Гомере буе гел башкаларны кайгыртып яшәгән кеше турында монда сезгә беркем дә кыек сүз әйтә алмас дип уйлыйм... Фаяз Ибраһимовичның түш кесәсендә һәрчак кечкенә блокнот белән ручка йөри иде, берәрсе урамда туктатып, йомышын житкерсә дә, шунда ук теркәп куя, бер генә үтенечне дә, бер генә сүзне дә югалтмый иде. Кешеләргә гел елмаеп эндәшергә яратты. Безгә дә: «Америкада, кирәкме-кирәкмиме, гел елмаялар. Эчегездә ни кайнаса да, сез дә елмаегыз. Безгә бер килгән кеше сокланып, кабат-кабат килерлек, үзе белән тагын биш кешене алып килерлек булсын», — ди торган иде. — ТРның атказанган табибы, югары категорияле акушер-гинеколог Эльза Мөнәвировна Шәймәрданова сүзләрендә дә якты хатирәләр генә чагыла.

ТРның атказанган табибы, югары категорияле табиб-физиотерапевт Зәмил Вахитович Шәмсетдинов да шул ук фикерне кабатлый:

— Кимчелекле ягы? Үзен жәлләмәде ул, үзен сакламады, бөтен исәнлеген шушы шифаханәгә бирде. Аның кабинетында кичке уннарга кадәр ут сүнми иде. Гел кешегә әйбәт булсын дип яшәде, ял итүчеләрне дә, коллективны да, эшчеләрне дә кайгыртты. Германиядән заманча аппаратуралар кайтарту артыннан да үзе йөрде. Түбән Новгород заводыннан жиһазлар кайтарткач, шуннан ук профессорларны да чакырып, безгә лекцияләр укуны оештырды, сөлек белән дәвалауны, озонотерапияне, спа-процедураларны кертте. Ул чит илләргә барган вакытта татар ижтимагый үзәгендә булып, андагыларны шифаханәгә чакырып кайта иде. Шуна күрә безгә Татарстаннан, Рәсәйдән генә түгел, Германия, Австралия, Төркия, Франция кебек илләрдән дә киләләр. Фаяз Ибраһимовичның әле әллә нинди проектлары бар иде, ачык бассейн, теннис корты, футбол, волейбол кыры төзү турында уйлап йөри иде... Нишлисең, әйтәм бит, сакламады инде үзен, сакламады...

Кемдер аны кешеләргә яктылык өләшә-өләшә янып беткән шәм белән чагыштыра. Кемдер атылган йолдызга тинли, кемдер тоташ уттан гына торган янартауга охшата...

«Бәкер» шифаханәсенең данын ерак-еракка таратырга аның үзендә үк чыгучы ләм, зәңгәр балчык, югары дәрәҗәдә минеральләшкән «Мацеста» тибындагы күкертле су, «Нафтуся» формуласындагы Бәкер суы гына түгел, бирелә эшләүче табибларның, гомумән, хезмәткәрләрнең ихтирамлы карашы, жаваплылыгы, ачык йөзе ярдәм итә. Кем арбасына утырсаң, шуның жырын жырлыйсың, диләр бит – Фаяз Ибраһимович «мәктәбен» үткән коллектив үзе дә шифаханәгә галәти эш урыны дип кенә караудан күптән узган. Шулай булмаса, житәкчеләрен югалткан көннәрдә үк, «Бәкер»нең киләчәге өчен жан атып, аны жиде ятлар кулына тапшырырга теләмичә, тиз арада Марат Фаяз улы Ибраһимовны үзләренә баш табиб итеп чакырырга дәррәү кузгалмаслар иде. Менә дигән урында инде үз тормышын көйләп, жиң сызганып эшләп яткан ир-егеткә әлеге чакыру белән бергә мең борчылу, мең икеләнү, мең уйлану да килеп ирешкәндер...

— Булды, барысы да булды: икеләнү дә, борчылу да... Тик эш, кайда эшләсәң дә, эш инде ул. Чит кешедән калган урын түгел, таныш мохит – әтинең ничек эшләгәнен күреп тордым... Санаторий – аның тагын бер баласы кебек иде бит, егерме ел буе тәрбияләде, үстерде. Эш дип яңды әти, шулай дип китеп тә барды. Тик бездә бит кешенең барыбер кадере юк, бигрәк тә исән вакытта... Якты кеше иде әти, беркайчан да арыганын күрсәтмәде, позитив була белде. Казанда укыган чакта, безнең янга әти килсә, кояш килеп кергәндәй була иде. «Нәрсә, зачётка әзерләнәсезме? Бирәсез!» — дип шунда ук өметләндереп, көч биреп куя иде... Оныкларын бик яратты. Берсендә безгә килгәч, минем кызым Диләрәдән көндәлеген сорап алды да: «Билгеләрең әйбәт икән», — дип мактап, «гонорарын» да кыстырып куйды. Икенче килүенә инде Диләрә үзе үк: «Дәү әти, көндәлекне карыйбызмы?» — дип тора... Нәрсә дә булса уйладымы – әти аны барыбер эшли иде. Төзелеш эчендә дә гел үзе кайнады. Мин еш кына: «Әти, сина «атказанган табиб» дигән исем

генә житми, «атказанган төзүче» дигән исем дә бирергә кирәк», — дип көлә идем. Әтинен үзе исән чакта бер хыялы бар иде: «Улым, санаторийны ышанычлы кешегә калдырасы килә, син кайтырсын инде», — ди торган иде ул. Мин ризалашмадым: «Әти, үзен исән-сау гына эшлә әле», — дидем. Бераз үпкәләгәндер дә инде, шулай да ул хакта бүтән сүз кузгатмадык. Мин «Газпром»нын «Газовик» санаториенда баш табиб-директор булып эшли башлагач, бер-беребезгә шалтыратмый калган көн юк иде, гел кинәшләшеп эшли идек... Нишлисен, менә, әтинен вафатыннан соң кайтырга дигән тәкъдим булгач, кат-кат уйладым да ризалаштым.

...Коридорда, тәп-төгәл бер ел элек, баш табиб дигән исем астында Фаяз Ибраһимовичнын фотосурәте эленеп торган. Язмыш кушуы буенча дилбегә Марат Фаязович кулына калгач, әтисенен сурәтен каядыр читкә алып, инде анын сурәтен куярга җыенучыларга яна житәкче шунда ук үз «шарт»ын әйтә: «Нәрсә дә булса уйлап табыгыз, әтине моннан беркая алып ташлыйсы түгел!» Нәтиҗәдә шушы ук коридорда элекке баш табибка багышланган, коллективнын аңа булган хөрмәтен чагылдырган стенд барлыкка килә. Әлеге вакыйганы телгә алуым артык вак нәрсә булып тоелырга мөмкин. Ләкин бер сүз яки бер гамәл аша кешелеклелек төшенчәсе балкып торганда, әйтми каласы килми шул...

Аны барысы да сагыналар. «Бәкер»гә әллә ничәнче кат килүче авыруларга тиклем: «Фаяз Ибраһимович очраса, хәлләребезне сорашмыйча үтеп китми иде. «Барысын да бирделәрме, зарларыгыз юкмы?» ди торган иде. Юклыгына ышанасы килми, гел берәр җирдән килеп чыгар төсле», — дип телгә алалар. Табиблар да шул ук сүзне кабатлый: «Без инде анын бөтен җирдә булуына күнегеп беткән идек. Әле генә каршына очрап, сөйләшеп үтеп китә, бераздан бөтенләй икенче почмакта пәйда була, аны әле монда, әле тегендә очратасын. Бер кеше түгел, әллә ничәү диярсен...»

Биредә даими рәвештә үткәрелеп килгән бихисап матур бәйрәмнәрне дә, квартал саен чыгып килүче «Бәкер сулышы» газетасын да, хәләл туклануны да Фаяз Ибраһимов исеме белән бәйлиләр. Алтмыш яшендә хаж сәфәре кылган, Коръән тәфсирен укыган, Шөгердә мәчет төзүдә турыдан-туры катнашып йөргән, туган авылы Ташкичү мәчетенә дә ярдәм күрсәтеп торган, намазга өйрәнеп килгән баш табибнын шифаханә ашханәсенә хәләл ризыклар гына кертүенә, бер караганда, гаҗәпләнергә дә кирәкми. Икенче караганда, һаман бер үк сорау башны талкый: боларнын барысын күз унында тотарга, барысына өлгерергә кайлардан көч һәм сабырлык алып була соң? Йөрәк бит берәү генә, шагыйрь әйтмешли, «түгел бит әллә ничә...»

Заманнан калышырга яратмаган табибнын соңгы омтылышы (хәер, тәндә җан бар чагында омтылышларнын соңгысы буламы?) – өр-яңа веб-корпусны, «Карлыгач»ны аякка бастыру. Инде барысы да кырык иләктән иләнгән, затлылык һәм зәвыклылык ягыннан да кат-кат уйланылган, ничек тә Яңа елга тиклем өлгертәсе, ачасы, беренче кунакларга бүләк итәсе иде үзен! Шушы теләк күкрәгендә янар учак булып дөрли, аякларга җилләр житезлеге бирә, сыкрап-сыктап үзен сиздергән йөрәгенә сабыр итәргә, түзеп торырга кушып, әлегә көч-егәр өсти. Югыйсә, ул йөрәкне тикшергән табиблар: «Тиз арада операциягә!» — дип үз хөкемен чыгарды бит инде. «Карлыгач»ны гына ачып өлгертим, аннан соң үземне карармын, ял итәрмен...»

— Нигә шулкадәр бөтен вагына тиклем кайгыртасын, Фаяз? Син китсән, шунда ук списать итеп бетерәләр бит барысын...

— Утырткан агачларымны кисеп бетерә алмаслар әле, Фирдәлия...

Иренен, бар дөньясын онытып, яна корпус дип бәргәләнүен, сәер бер ашкыну белән ашкынуын күнеле сизде микән Фирдәлия апанын? Бәлки, сизгәндер дә... Карангы төндә анын эштән кайтыр сәгатен минутын минутка ялгап көткәндә, телефоннан ничә шалтыратып, жанга газиз тавышны ишетмәгәндә, бәгыре мен телемгә телгәләнүен үзе генә беләдер. Билгесезлектән бәргәләнгән минутларында хәтерендә Фаязы белән төн утырып сөйләшүләре, иренен: «Балаларга каты булдын, әйбәт итеп, тәрбияле итеп үстерден. Акыллы булдын, урам сүзенә карамадын», — дигән сүзләре яңарып алгандыр...

«Киттең... Үзенне сакламадын...» Бу сүзләр иреннәрдән түгел, жан түреннән

илереп ишетелә кебек. Аз гына, аз гына житешмәде. «Карлыгач»ка канат җәйрәп ишекләрен ачарга санаулы гына көннәр калган иде, дүртенче декабрьдән уникенче декабрьгә кадәр бер адым түгел, йөрәк күтәрә алмас кичерешләр сыйган икән... Фаяз Ибраһимовичның туган авылында аның җыр сүзләрен кайчандыр зур баннерга язып куйган булганнар: «Таш киссәк тә, тау кичсәк тә, кайтырбыз Ташкичүгә...» Кайтты. Мәңгелек моң, яктылык, кешелеклелек үрнәге булып, үз туфрагына кайтты.

Кеше китә — җыры кала. Җыр булып, Марат белән Эльвираның Диләрәсе, Динәсе, Данияры; Гөлназ белән Илдарның Дамиры, Мәдинәсе; Алмаз белән Лиянең Чыңгызы, Мәликәсе калгандыр. Тау битендә яфрак лепердәтеп утырган мәгърур агачлар, догалы чишмәләр калгандыр. Дүртенче «нарасые» булган, соңгы сулышы да шунда өзелгән «Бәкер»е калгандыр... Дөньялыкта чагында һәр нияте, һәр уе тормышка ашып килгән Фаяз Ибраһимовичның теләкләренә бакыйлыкта да киртәләр юк шикелле тоела. Җан-йөрәге белән корган матурлык һәм саулык илен улының ышанычлы кулларына тапшырып калдыру турында хыялланганы да, күрче, Аллаһы Тәгалә хозурына барып ирешкән.

***

...Күл читендә сагышланып утырган аккош күңелендә ниләр бар? Әле дә булса өзелгән җырны юксынып моңлануымы? Әллә, күккә ингән җаннар булып, «Яшисе килә!» дип эчке бер моң белән инрәп аваз салуымы?.. Чү, колагына ялгыш ишетелми бит, каяндыр, үзәкләрне өзәрдәй итеп, җыр агыла. Аккошның каерылган канатлары җәя сыман киерелә; ул гына түгел, күл буенда толымнарын юган таллар да, зекер әйтеп утырган агачлар да, күзгә сагыш белән сугарылган чатырлар да нидер көтеп тын кала:

*Горурланам, әти, синең белән,*
*Кечкенәдән сиңа сокланам.*
*Гомерем буе мин көч алып яшим*
*Синең биргән хәер-догаңнан.*

*Рәхмәт сиңа, әти, күңелемдә*
*Саклап йөртәм һәрбер сүзеңне.*
*Әгәр сайлап булса әтиләрне,*
*Сайлар идем барыбер сине...*

Марат, Гөлназ, Алмаз бу җырны әтиләренең алтмыш яше тулган көненә багышлап, өчәүләп җырлаганнар иде. Ялгыз аккошның яралы күңеленә беркадәр дәва булып, хәзер шул җыр ишетелә иде...

**Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА**

---

***Хата төзәтү***

*11 нче санның 145 нче битендәге 2 нче рәсем астын «Актай ролендә — Габдулла Шамуков», дип укырга.*

# СЕЗ ҺАМАН БЕРГӘ ИКӘН?!

Журналның 4нче санында «Әхмәт Гали, Гөлчәчәк Гали» дигән язмам чыккан иде. Шуна төзәтмә бирергә туры килә менә...

Гомер булмаганны, бик озак язган идем мин аны. Инде компьютерда җыелгач та һәм хәтта биткә салынгач та кат-кат өстәттердем, төзәттердем әле. Нәрсәдер төгәл үк әйтелми, нидер бөтенләй әйтелмичә кала кебек иде. Күптән аралашкан, күңелемә бик тә якын затлар иде шул бу... Менә бит, үзем дә сизмәстән Гөлчәчәк апа китапларыннан берсенең исемен кабатлап куйганмын: «Күңелемә якын затлар». (Апабыз мондый затлар арасына мине дә керткән иде — китаптагы мәкаләсе аша.)

Шулай итеп, редакция хезмәткәрләре Лилия белән Элеонораны да нык кына интектердем инде, ләкин сукранмадылар тагын, яратып эшләделәр. Тулаем «Казан утлары» өчен дә кадерле кешеләр иде бит алар. Инде менә журналны типографиягә дә төшереп җибәрдек. Язмам ярыйсы гына килеп чыкты шикелле. Ләкин шул төндә Элеонорабыз төш күргән. Төшендә аны... мәрхүм Әхмәт абый битәрләп алган! Гөлчәчәгеn үзеннән аерып калдырганы өчен.

Ул язмам ике бүлекле. Әхмәт абый турындагысы «Ул пәһлеван җитәкче иде» дип атала. Анда шушы образга мач килгәнрәк фоторәсем бирергә кирәк иде. Андый Әхмәт Галиевне Гөлчәчәк апа белән икәүләп төшкән фотоларының берсендә күрдем мин. (Фотосурәтләрне электрон почта аша Галиевләрнең оныгы Шамилә җибәрде, рәхмәт ана.) Һәм Элеонорага шул Әхмәт абыйны куярга куштым. Аны Гөлчәчәк апабыздан аерып алу бераз кәефне кырды кыруын, ләкин Гөлчәчәк апа исән булса, моңа һич борчылмас иде, Әхмәт абый хакына бит бу дигән уйдан юаныч тапкан идем. Инде менә Элеонорабызны юатасы булды. Синең печтик кенә дә гаебең юк, син кушканны гына эшләдең бит, дип. Фотосурәтне үзгәрткәндә, ул үзе дә борчылу-фәлән сизмәгән булган. Ягъни аның күңелендә мондый төш өчен «җим» юк. Төшкә ниләр кермәс, очраклы нәрсә генәдер бу дияр идең дә, тәп-тәгаен гамәлгә төбәлгән бит ул! Нигә мина, гаепле кешегә кермәгән соң дигән сорауга исә җавабым бар иде инде минем.

Шушы гаҗәеп затлар турында язганымны өйдә ялгызым гына тагын бер кат карап утырганда, кинәт балкон ишегенең пыяласы әкертен генә зенгелдәп куйды. Урта тирәсеннән. Миннән ярты метрда гына бу. Һәм башымда шундук менә мондый уй туды: Әхмәт абый белән Гөлчәчәк апа үзләре турында язганымны беләләр һәм шул рәвешле мона сөенүләрен сиздерәләр. Мин исә шундук болай дип әйттем: «Төшемә кермәгез, юкса эшләп бетерә алмам». Уйда гына түгел бу, кычкырып ук әйттем. Нигә алай дигәнемне белмим. Мине сискәндермәс өчен күңелемә сүзсез генә салынган сорауга җавап бирмәдем микән?

Бу «контакт»ны мантыйк (логика) бизмәненә салып карадым мин үзе. Әлбәттә инде, иң әүвәл башыма әлеге зенгелдәү очраклы бер нәрсә генә түгелме икән дигән уй килде. Ләкин бишенче каттагы ябык балкон тәрәзәсе аша үтеп балкон ишегенә кем орына ала иде соң? Һәм әле шундый матур, нәфис аваз чыгарып? Җил-фәлән дә кермәде, температура да тотрыклы һәм салкын да түгел иде. Минем үземә килсәк, ырым-шырым, сихер-михерләргә ышанмыймын. Психикам да әйбәт дип беләм. Һәрхәлдә, көпә-көндез түгел, хәтта төнлә йоклаганда да саташканым юк иде әле. Арыган хәлдә дә түгел идем, авырсынмыйча, яратып яздым мин бу әйберне.

Тагын шунысы да бар: аз гына да курку, шомлану галәмәте сизмәдем мин ул чакта. Һәм аннан соң да әле. Әйтерсең лә тап-табигый бер эш инде менә! Әхмәт абыйларның мина, мина гына түгел, бер генә җан иясенә дә аз гына да начарлык эшләмәячәкләренә ышану күңелгә тирән сеңгәнлектәндер инде бу. Адәм балаларындагы көчтән мең тапкыр зуррак көчкә ия булсалар да, курыкмас идем мин алардан. Болары гына түгел, гаҗәпләнү дигәне дә булмады әле хәтта. Шундый кешеләрнең бер-бер артлы дөньядан китеп баруы үзе гаҗәп тоелганлыктан микән инде бу? Әллә мондый шәхесләр белән бүтән беркайчан да аралаша алмаячагым белән килешергә теләмәүдәнме? Шул чакта җанга махсус тыныч халәт индерелде микән дип тә уйлап куйдым әле.

Менә шундый хәл, җәмәгать! Булганны төп-төгәл бәян иттем мин сезгә, хикмәтен

анлату исә көчемнән килми. Акыл анлап житкерми, күңел исә Әхмәт абыйлар белән контакт булганлыгына аз гына да шикләнми.



Теге төш исә берөзлексез борчып торды мине. Һәм, ниһаять, журналда фоторәсемнен чын, тулы вариантын һәм ошбу кичерешләремне чыгарырга кирәклекне анлап житкердем.

Гөлчәчәк апабызнын 80 яшьлек юбилеенда төшерелгән фото бу. Бәйрәм кичәсе 2008 елнын 5 апрелендә Милли-мәдәни үзәктә үтте. Әхмәт абыйны Гөлчәчәк ападан гына түгел, менә шушы бәйрәмнән дә аерган булып чыгам бит инде мин, димәк!

Табигый ки, бу хикмәтле хәлләрдән сон әлеге ике аләм баласынын тормышына тагын бер кат күз салмыйча кала алмый идем инде мин... Юк, тикмәгә генә килмәгәннәр алар дөньяга. Күпләр кебек жил унаена гына яшәп, эзсез-нисез китеп бармаганнар. Әйдәгез, кайбер тормыш мәлләрен бергәләп янә искә төшереп алыйк әле.

1991 елны Татарстандагы завод-фабрикаларнын нибары 2 проценты гына Татарстанныкы иде. Компрессор заводынын башлангычы аларны 92 процентка житкерергә мөмкинлек бирде! Арча районынын Сеже авылында Әхмәт атлы ир бала дөньяга килмәсә һәм бу заводнын директоры итеп куелмаса, бар да искечә калган булыр иде. Чөнки Татарстан хакимияте Әхмәт абый мона тагын ике заводны күндергәннән сон гына тотынды бу эшкә. Компрессорлары бөтен Рәсәйгә диярлек таралган заводка исә Мәскәү тарафыннан бик көчле икътисади басым ясала. Заказлар 38 процентка кими, 1570 кеше эшсез торып кала, алган компрессорларнын акчасы элек 4 көндә килеп житә торган булса, инде айлар буена килмичә тора. Мондый хәлдә бөтен башка директорлар да «Бирелә́м!» дип ике кулын күтәргән булыр иде. Өч орден иясе, техник фәннәр докторы, жете миле һәм куш йөрәкле Әхмәт Галиев түгел ләкин.

Эшсезләр янә эшле була, хезмәт хакы шәп кенә арта, өч меннән артык гаилә фатирга тиенә!. Ул житәкчелек иткән чорда заводнын эшләп чыгару куәте — 3,5 мәртәбә, хезмәт житештерүчәнлеге исә 2,2 мәртәбә арта, заводнын суыткыч машиналары алты Халыкара премия ала. Ул үзе исә АКШнын Библиография институты карары белән «1995 елнын Дөнья Кешесе» дип танылды.

Күп кенә татар түрәләреннән аермалы буларак, Әхмәт абый малай чагыннан алып вафатынача чын татар кешесе булып яшәде. «Ин шәп милли тәрбияне мина урыс малайлары бирде», — шулай дип сөйләгән иде ул. 5нче класста Яна Чүрилегә йөреп укый башлагач, сабакташлары аны бик тә Алексейга әйләндерергә теләләр, ана гел шулай дип дәшәләр. Болай гына үзгәртә алмагач, ике малай дәрестән сон ияреп китеп, «йодрык дәресе» бирмәкче була. «Үзләренә күбрәк эләкте», — диде Әхмәт абый.

Күпләрнен миллилеген эреткән түрә тормышы да «Алексей» ясый алмады анардан. Европа шәһәрләрендә халыкара конкурс бүләкләрен алганда да татарча гына сөйләгән ул. Чыгышы инглизчәгә тәржемә ителеп барган... Татар мәдәниятенә дә ярдәме күп булды анын... Жинелмәс заводны 1996 елны директорын эштән жибәреп кенә жинә алдылар!

Гөлчәчәк Кәрим кызы да — гажәеп зат. 19 яшендә үк авылларында драмтүгәрәк житәкчесе була ул. Казанда пионервожатый итеп билгеләнгәч, СССРнын ин шәп пионервожатые булып таныла! Һәм..., «кире рекорд»: әдәби ижатка житмешне узгач, ягъни язучыларнын күбесе инде ижаттан киткән яшьтә килә ул. Һәм жуелмас эз калдырып өлгерә. «Тулгак», «Өзелгән өмет» бәяннары, «Газзәбану» романы бу (өчесе дә безнен журналда басылды). «Тулгак» укылыш жәһәтеннән Милли китапханә үткәргән конкурста икенче урынны алды. «Тулгак» китабын бер сулышта укып чыкканымны мәнге онытасым юк. Иптәш кызымнын купега кереп урнашканнан сон: «Син бүген чәй эчәсенме?» — дигән сүзләрен колагыма да элмим. Елый-елый китапнын сонгы

битен япканнан соң да шактый гына уйланып яттым әле». Мәрхүмә каләмдәшебез Алсу Хәсәнова сүзләре бу. «Газзәбану»ның популярлыгы исә тагын да зуррак булды. Егылыплар укыды аны халык. Һәм эчтәлек ягыннан да саллы ул. Башкортстанның Яңа Кангышлы авылыннан Луиза Миңнеханова редакциябезгә менә болай дип язып җибәргән иде: «Авторның бу гүзәл әсәргә түккән һәм үз йөрәге аркылы үткәргән хезмәтләрен Раббым савапларыдан кабул итсә иде, аңа романындагы хәрефләре санынча шатлык илә уңышлар китерсә иде дип тели-тели укып чыктым. Шулкадәр яратып, аерыла алмыйча укыдым, күршемә, авылдашларыма да сөйләдем. Күпме хатын-кызларыбызга фәһем һәм тәрбия, әдәп-хәят алырлык искиткеч әсәр булган бу...» Монысы исә әдип Фирдәвес Хуҗин сүзе: «Хатын-кызларыбызның хисләргә бай эчке дөньясын болай тирән ача алган әсәр укыганым юк иде әле минем». «Үзеннән-үзе укыла торган матур тел белән язылган» — мондый фикерне төрле вариантларда ким дигәндә 12 әдип һәм укучы әйткән! Аларның берсе — Гөлчәчәк апага Язучылар берлегенә керү өчен тәкъдимнамә биргән Аяз Гыйләҗев: «Теле камил, саф татарча». «Тулгак» турында бу. Кызганыч ки, Аяз ага шунысын гына укып өлгерде шул!

Педагог, мәктәп директоры, язучы гына түгел, иң әүвәл чын шәхес иде Гөлчәчәк Галиева. Җиде ел элек язган шигыремдә болай дип әйткән идем мин аның турында:

*Хаксызлыкка йоны тырпаядыр,*
*Мәкерне ул күрә үтәли.*
*Теле нисез аның... каптырмасыз —*
*Дәшми калмас Гөлчәчәк Гали.*

Мондый Гөлчәчәкне бик тә ихтирам итәр иде Әхмәт абый. Ләкин яратып, гашыйк хәлдә яши алыр иде микән аның белән? Шөкер, менә мондый Гөлчәчәге дә бар иде шул аның:

*Төн йокламый чыга ала, җәлләп*
*Занзибарда үлгән атларны.*
*Колагыннан тартып үстермәкче*
*Күңеленә якын затларны.*

Сеженең Галиябануы белән Хәлиле булдылар алар әүвәл. Җир шарында аларга тиң пар булды микән? Авыр сынаулар үтеп тә 63 ел буена бер-берсенә гашыйк хәлдә яши алган ир белән хатын?!

Редакциягә килгәч, Гөлчәчәк апа кызларыбызга болай дип сөйләгән:

— Кер уганда көлмәгән битемә китереп, бу бит Әхмәтемнең көлмәге, бу бит Әхмәтемнең исе! — ди торган идем.

— Сөйдем, сөелдем, әле дә сөям! — бусы Әхмәт абыйның сүзе.

Үткән елның 11 маенда Әхмәт абыйны саташуга якын тетрәнү хәлендә күрдем мин! Хатыным Дания белән аларның Нагорныйдагы өенә, берни белмичә, Гөлчәчәк апа җан тәслим кылып ярты сәгать чамасы гына үткәч килеп кергәнбез бит без!..

Әхмәт абый Гөлчәчәк апасыз бары 258 көн генә яши алды... Сеже зиратында янәшә ята алар...

Менә бу дүрт шигырь юлы Әхмәт абыйныкы:

*Кулымдагы йөзегемнең*
*Исемнәре Гөлчәчәк.*
*Сиңа булган мәхәббәтем*
*Гүремә кадәр җитәчәк.*

Алай гына микән, Әхмәт абый?

Теге язмамда мондый җөмлә бар иде: «Болай дип әйтү ярамыйдыр да инде, ләкин Әхмәт Мөхетдин улы белән Гөлчәчәк Кәрим кызы оҗмах бакчаларында да бергә, җитәкләшеп йөрерләр кебек тоела миңа». Хәзер бигрәк тә шулай тоела бу...

**Рафикъ ЮНЫС**

## 2016 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр

МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1437-1438 ҺИЖРИ ЕЛЛАР

**8 апрель** — мөселман календарендa изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

**15 апрель** — Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич — Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**4 май** — Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә — Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**21 май** — Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310нчы һиҗри, 922нче милади ел).

**22 май** — Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**6 июнь** — изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә — Кадер кичәсе (1 июль).

**5, 6, 7 июль** — Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**11 сентябрь** — Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**12 сентябрь** — Гайдел-Әдъхә, Корбан бәйрәме. Мөселманнарның иң зур бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**13, 14, 15 сентябрь** — Ташрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**2 октябрь** — 1438 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**11 октябрь** — Гашура бәйрәме. Сөнниләр — Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар, Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнне мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

**1 ноябрь** – Сәфәр ае башланган көн.

**12 декабрь** – Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе — Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Әлеге изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

*Төзүче-мөхәррир —*
**Хаҗи Абдулла ДУБИН.**



Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу — безнең сәхифә!

*Ак җилкән*

## Кем казый?

БАЛАЧАК ХАТИРӘЛӘРЕ

Безнең әткәй мәктәптә утызынчы елларда белем алган. Нәкъ шул елларда татар «Яңалиф»кә[1] күчәргә омтылыш ясаган бит инде. Ул заманда мәктәпләрдә дүртәр-бишәр тел, өчәр графика өйрәнгәннәр. Кирилл, гарәп, латин графикасында әткәй иркен укый һәм аның телендә без аңламаган сүзләр дә бик күп була иде. Ни хикмәттер, сүзләр еш кына кискен бәхәс, көрәш-көрмәкләшү мәлләрендә әйтеләләр. Әткәй әйткән сүзне аңламый торып ни бәхәсне, ни көрәшне дәвам итеп булмый.

Әнә тагы дүрт ир-ат — әткәй үзенең өч улы белән идән тутырып көрмәкләшә. Аларның шахмат тактасындагы сугышлары шулай идән тактасына күчә дә китә шул. Кайсы кайчанрак елый башлар икән дигәндәй, әнкәй үзенең сынаулы карашын «сугыш кырына» төбәгән. Бәйләм бәйләгән булып утыра ул, ә чынлыкта бар нәрсәне ишетеп-күреп тора.

Эш елауга барып җиткәнче, әткәй кинәт сикереп торды да күтәренке тавыш белән: «Казыйны тыңла!» — дип аваз салды. Абый шунда сәерсенеп: «Кем казый? Нәрсәне казый тагы?» — дип аптырап калды.

Әткәй исә бертөрле мәгърур кыяфәткә кереп: «Мин — казый! Мин әйткәнчә булырга тиеш!» — дип кулын күтәрүе булды, Назыйм кинәт кенә сикереп, әткәй кулындагы фирзене эләктереп алды... Китте тагы көрәш-көрмәкләшү!..

Мине шул «казый» сүзе генә кызыксындыра бит инде. Чынлап та, нәрсә казый? Ә ник әткәй — казый? Көрәшчеләр мине ишетерлек хәлдә түгел. Аптырагач, әнкәй янына килеп, аның күзенә карыйм:

— Ни-нәрсә була икән соң ул «казый»? — дим.

Көтмәгәндә әнкәй җитез генә урыныннан торды.

— Хәзер казыйм мин аларны...

Әнкәй кып-кызыл булып кызган тимер кисәүне мичтән тартып кына алды да көрәшчеләр өстенә килеп туктады:

— Куегыз шахматны!

Бер караганда бик тыныч кына күренгән әнкәйнең дуамаллыгын барыбыз да беләбез.

Баш өсләрендәге кызыл кисәүне күргә, «батырлар» төрле якка сибелде. Әнкәй шахмат фигураларын иркенләп кенә тартмасына тутырды да дөрләп янган мичкә китереп тыкты. Котлары очкан малайларның шахматлары артыннан мичкә керердәй булып тартылып куюларын да, әткәйнең күзләрендә ялтырап киткән мут елмаю чаткысын да искәреп калдым мин.

— Мәсьәлә хәл ителде. Бу юлы әнкәгез үзе казый, үзе җәллад булды, — дип куйды әткәй. Ә мин исә тагы аның теленнән төшкән икенче таныш булмаган сүзгә аптырап калдым. «Җәллад»? Җәлләп түгелдер инде. Кая, җәлләдемени әнкәй?..

Көрәшчеләр кичке мал карау вакытын истән үк чыгарганнар икән. Әнкәй юкка гына кызмый инде ул. Беркемнең дә әйткәнен көтеп тормыйча, чыгып

[1] «Яңалиф» — латин графикасына нигезләнгән яңа әлифба.

шылдылар. Әткәй малларга дип мичкәдән ашлы су бушата башлауга, мин аның кулына үрелдем:

— Үзем, әткәй, түлке теге «казый» белән «җәллад»ны гына әйт тә...

Әткәй бишмәтен кия-кия генә әйтеп салды:

— Әнкәң хөкем итүчесе дә, җәза үтәүчесе дә булды.

— Ә ник соң шулай гына дип әйтмисең?

Әткәй бер мизгелдә икенче яссылыкка күчте. Монысын каян беләмме? Читтән карап торган кешегә ул әле генә киртәдән кычкырып төшкән әтәчнең канатларын җыеп куюын хәтерләтер иде. Бер мизгелдә күзләренең төсенә кадәр үзгәреп китте аның.

— Ни бит, кызым, — диде ул, инде мәктәп тактасы янында торган укытучыга охшап, — җанда кадимие тирәнрәк утыра. Аннары...

Минем сабырым сынып төште:

— Әткәй, син миңа үч итәсеңме соң? Аңламыйм мин ул «кадими»не, аңла-мыйм, — дип елап ук җибәрдем.

Әткәй кия торган бишмәтен салып ук куйды да:

— Тукта, шулкадәр үк булдымыни соң әле? — диде. — Кызып кителгән шул. Җиденче сыйныфка күчкән кыз шулай елап торамыни, — дип аркамнан сыйпамакчы булган иде дә, кулын этеп үк җибәрдем:

— Мин «сыйныфны» да белмим, «сыйнфый көрәш»не генә беләм...

Әткәйнең күзләре «Ачы күл» өсте кебегрәк шомланып китте һәм ул салкын акыл көче генә җитмәгәндә куллана торган коралына — шигырьгә мөрәҗәгать итте:

Син дә хаклы, мин дә хаклы —
Аерыйк кара-акны.
Җәдидие — якындарак,
Сагынам кадими чакны.

Шулай такмаклап алды әткәй. Җитдилектән качасы итсә дә, җитдилеккә кайтасы итсә дә, шулай шигырь белән сөйләшә ул. Миңа иң охшаганы да шул инде.

— Димәк, яшьлегеңне сагынасың, — дим, аңлавыма шатланып.

Әткәй тагы тынып торды да:

— Әйе, синең бу сүзләреңдә хаклык бар. — Безгә карата кадими — борынгы, элекке булса, кешелек җәмгыятенең яшьлеге генә әле ул. Җәдиди — хәзерге, яңарак була. Тик үткәнеңне, тамырыңны тоймасаң, бүгенгең бер мизгелдә җимерелеп төшәргә мөмкин. Үткәннәрен онытып, үз тамырларын үзләре кисүчеләр дә аз түгел...

Әткәй ул чакта бер кинофильмдагы геройларны (әллә «Долина красных тюльпанов» диде инде) мисалга китерде. Үз улын үзе танымыйча, хәнҗәр белән кадап үтергән этисе турында икән ул фильм, ә аның язмышына меңнәр язмышы бәйләнгән булган шул.

Малайлар малларга дигән ашлы суны да берәм-берәм кереп ала тордылар. Инде шахмат янган мичтә ипи дә пешеп чыкты. Өйгә ипи исе таралды. Искиткеч «тәртипле малайлар» — көрәшчеләр өйгә кереп, кулларын юдылар да өстәл янына килеп утырдылар. Яңа пешкән ипине әнкәй икегә генә ярып, өсләренә сары май салган. Әткәй табак белән селкенчәк китереп утыртты. Җиде кашык шәп-шәп йөреп алуга, табак та бушады. Бөтен ипиләрнең икесе дә юк булды.

Әткәй амин тотарга онытып утырган энекәшнең башын догага күтәрелгән кулы белән «ялгыш кына» өтеп алды, һәм барыбыз бергә аш кайтардык. Шуннан соң әткәй, бая урнашкан тынлыкны бозып, әйтеп куйды: «Эшкә! Иртәгә сәнәгати сәнгать белән шөгыльләнәсе булыр».

Юк икән, бу әткәйне мәңге төзәтеп булмас. Менә тагы әйтте дә куйды: сәнәгати сәнгать, имеш!

Ни белән шөгыльләнгәннәрен иртәгә генә күреп була инде. Әле сүз куертырга вакыт та юк, һәркем дәрес хәзерли.

## Сәнәгати сәнгать

Шахмат «һәлак булганнан» соң, икенче, өченче, аннан соңгы көннәрдә дә безнең малайлар майлаган каештай йөреп тордылар. Өй эшләре дә, өйгә эшләр (дәресләр) дә бернинди искәртеп торусыз, һичнинди ярдәмсез башкарылды. Әткәй дә әллә ниләр сызып-кисеп, үзенең «Зөләйха»сын көйли-көйли, шахмат командасыннан башка гына яшәде. Мич аслары, мич башлары, хәтта кирәгеннән артык итеп, утын белән тутырылды. Инде суны да чана белән малайлар алып кайта, ипине дә алар баса, хәтта сыерны да алар сава башлагач, әнкәй йомшарды һәм, дүрт сум җитмеш тиен акчасын кызганмыйча, кибеттән яңа шахмат алып чыгып бирде. Тик шуның белән шул икән дип уйлый күрмәгез тагы. Шахматчылар өстендә утлы кисәү ай саен уйнап торды һәм теге дүрт сум да җитмеш тиенне ай саен мич йота барды. Егетләр тәмам азды. Әнкәй дә инде мәңге йомшармаслык булып кырысланды. Ә җиңелүне кичерә алмый иде егетләр. Уйнар өчен ниндидер җай табарга тиеш иде алар һәм тапкан да булып чыктылар. Беркөнне, безне шаклар катырып, шахмат уйнарга утырмасыннармы! Каян алганнар?

Юк, беркаян да алмаганнар. Әткәй дә акча бирмәгән. Егетләр шахматны агачтан пычак белән юнып үзләре ясаган! Тактасы аңлашыла. Анысын сызасы да шакмаклыйсы, алар сыннарны да үз куллары белән ясаганнар. Менә бит, бөтенләй чын кебекләр. Атының ялына кадәр бар, билләһи!

— Менә, — диде әткәй, — минем авызымны ябалмыйча торуымны күреп, — шушы инде ул сәнәгати сәнгать...

— Ничек шушы,—дидем мин, аптырап — кайсысы сәнәгати?

Әткәй рәхәтләнеп көлеп җибәрде дә:

— Дүрт сум җитмеш тиен дә янга кала, янмый кала, — диде... — Агач сәнгатенә дә, ягъни агачтан матурлык ясарга да өйрәнәләр. Җәдиди итеп әйтсәк, «экономика искусствосы» була инде. Тик болар безнең үз сүзләребез түгел. Бурычка алганчы, борылып кара, кара сакалың артыңнан бара. .Үз сүзләребезне, тарихыбызны рәнҗетеп, нигә бурычка сүзләр алырга соң? — дип, моңсуланып калды ул.

Казанда 90нчы елларда күп татарлар яңа ишетәсе үз сүзләребезнең мәгънәләрен әткәй миңа 60нчы елларда ук шулай аңлаткан иде инде.

Шушы аңлашудан соң әткәй үзенең малайлары белән тимер кыргыч станда агачтан да, металлдан да әллә ничә тартма шахмат ясады. Агачлары шул ук мичтә һәлак була бардылар. Металлдан ясалганнары әнкәйнең теңкәсенә озак кына тиделәр әле.

Бер шахмат «командасы» күңелгә аеруча якын булып кереп калган — сатирик образлар итеп ясалганнар иде алар. Туркалар — корсаклы, офицерлар — чиләнкебек нечкә, король — бөкре, атлары — арбалы, солдатлары — ишәк. Әткәй монысын да бик нечкә, бик нәфис сәнгать дип атады. «Урынлы көлке үргә меңгерә, урынсыз көлке гүргә иңдерә», — дип моңсу гына елмаеп карап торды ул ошбу сыннарга.

Бу төр сәнгатьнең файдасы да бик тиде. Безнең гаиләдә урындык-өстәл, диван-карават ише җиһаз ясау гадәти нәрсә дип санала. Ә менә сервант кадәр сервантны да үз кулы белән ясады бит абый. Хәтта тактасыз-нисез өйне тышларга да алынды алар. Кибет янында ешрак йөри торган әнкәй башына килгән фикер барысына да ошады. Аракыдан бушаган агач тартмаларны сүтеп, шомартып, пар киртәләргә чыршысыман итеп тезделәр дә бастырып кактылар, тезделәр дә кактылар бүрәнә өйгә. Буяп та җибәргәч, өебез әкият өе кебек булды инде менә. Өйнең верандасын да үзләре корып, үзләре бизәде, карлыгачлы-күгәрченле, чәчәкле тәрәз йөзлекләрен дә үзләре ясады алар. Мунчасын да, абзар-курасын да... Кирпечен дә үзебез суктык, үзебез яндырып чыныктырдык. Шул кирпечләрдән чыгарган мичләр гомер буена хезмәт иттеләр

һәм... боларның барысы да безнең нәни «дәүләтебезнең» сәнәгати сәнгате булган икән!

Бүген таң калып уйланып утырам: шундый дәүләтчекләр, авыл-дәүләтләрне җимерү акылга сыя торган хәлме? Җаннардан төзелгән дәүләтләр ләбаса алар!Тиктормастай чабып йөргән тамырсыз кешеләргә, җимерелгән язмышларга карыйм да, авылсызлык, дәүләтсезлек фаҗигасе бу дигән нәтиҗәгә киләм.

**Нәҗибә САФИНА**

---

## ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

**Былтыргы бәйгегә 10нчы санда йомгак ясадык. Җиңүчеләрнең бер өлешенә бүләк (журналыбыз чыгарган, «Яңа базар» дигән сатирик китап) тапшырылды инде. Казаннан читтә яшәүчеләр үзләре яки туганнары-танышлары Казанга килгәч, редакциягә керсеннәр иде (Декабристлар ур., 2, 89297245954 телефоны аша алдан бәйләнешкә керә аласыз). Бу юлы алты җиңүче (бер — беренче, ике — икенче һәм өч өченче урыннар) билгеләнәчәк. Әҗере булыр. Күләм бер журнал битеннән артмасын иде.**

***

Бигрәк ваклана бу кеше дигәнең. Аңа акча кирәк, мал кирәк. Әйтерсең, дөнья шулардан гына тора. Әй, сез, Адәм балалары! Җир йөзендә мәхәббәт бар!

Берсендә шулай...

***

— Әни, мин күрше Сәлимәгә өйләнәм! — диде Дамир.

— Юк! Юк! Юк! — диде әнисе.

***

Үләм! Нәкъ шундый җете салават күпере! Аны күргәч, миңа ни дип әйткәнен хәтерли микән Илсур?

***

Ул дерт итеп уянып китте. «Онытканмын бит!»

***

Синме соң бу, Сания? Хәтерлисеңме, беренче, иң беренче тапкыр очрашуга барганда да, шушы көзге алдында озак кына басып торган идең бит...

***

Менә ничә көн инде Илсурның башында бер генә уй бөтерелә: калыргамы X сыйныфка, юкмы? Китсәң, БДИ бирүдән куркып киткән, диячәкләр. Калсаң...

***

Әлеге вакыйга инде онытыла да башлаган иде. Тик менә бүгенге хәл аны барсының да яңадан исенә төшерде.

***

Билгесезлек, мөгаен, иң авыр җәзадыр. Кайда ул? Ничек? Кем белән? Аны шушы сораулар гына борчыды.

***

Зәринә барсын да бер минут эчендә югалтты: сумкасын да, телефонын да, акчасын да... Һәм чит шәһәр уртасында япа-ялгызы басып калды.

***

— Әгәр дә әбиләр кебек яулык бөркәнеп, төренеп йөри башлыйсың икән — мин сине ташлыйм! — диде Азат каты гына итеп. — Әнә, дөньяда ниләр бара! Сиңа да берәр сылтау табып бәйләнсәләр? — Кыз икеләнеп, юк, икеләнеп түгел, уйланып калды.

***

«Син кайларда йөрисең икән?..» Бу җырны тыңлаганда, күзгә яшь килә... Яшь килә, ә син килмисең. Ике ел инде менә...

***

Арттагы партадан чәчемнән тарткан иде ул. Борылып, акаеплар караган идем үзенә... Чәч күптән кыскарды инде. Тик акыл гына кермәде шул һаман...

***

Чыгарылыш кичәсе безнең өчен кавышу кичәсе дә булды...

***

Кинәт кемдер күземне каплады. Шундый җылы, йомшак иде бу ике кул. Бик тә, бик тә тансык иде миңа мондый җылы игътибар. Тик кем соң бу?

***

Бу заман кызы түгелдер инде мин. Кульяулык чиктем әле менә. Тик ничекләр итеп кулына тоттырыйм икән моны?

***

«Фәһим Габделәхәтович, минем белән калып шөгыльләнсәгез иде!» — менә нинди язу тоттырган бит XI б дан Назлыкаева... Кирәк булыр инде, әйе, кинәт «икеле»ләр ала башлады бит кызый.

***

Төбендә серле утлар янган кавыштырма казаны! Хыялга чумып, һәр кичне егермешәр, утызар кат урап чыгам бит мин аны... Тукта, тукта, каршыга кем килә ул?

***

— И, зәңгәр күк! Утыз яшемә җитеп тә, үземә пар таба алмадым бит җирдә! Ай кызын булса да төшер инде, ә? — шулай дип әйтүе булды, нәрсәгәдер сөртенеп, мәтәлепләр китте Гафур!

— Хәлең ничек, абзый? «Скорый» чакырыймы? — Бик тә матур иде бу тавыш!

***

Кайчан кияүгә чыгасың дип теңкәгә тия башлагач, хәйләсен таптым бит: «Пенсиягә чыккач!» — дип җавап бирә башладым. Уйнап әйткәнем... утыз елдан соң чынга ашмасынмы!

***

«Привет! Сколько лет, сколько зим! Таныдыңмы?» Йокыдан уяныр-уянмас, күзләремне уа-уа, планшетымны табып алганда, әнә шундый хат килеп ирешкән иде. Юк, танымадым. Ашыга-кабалана хәбәр иясенең фотоларын барларга керештем. Булмас ла! Үзе микәнни? Үзгәргән...

***

«Элдеңме?!» — дип сүз башлады патрон. Аның исәнләшүе дә, таләбе дә, искәртүе дә, сөйләшүне дәвам итүнең төп шарты да — һәммәсе шул сүзгә сыеп беткән иде.

***

...Ир дигәне җай гына үз көненә яшәп, бернинди наз, ярату хисләрен тойдырмаганга илереп әйтте ул бу сүзләрне.


***

Бер елдан соң эзләп тапты ул Чыңгызын. Менә бергә булабыз, бәхетле тормыш корабыз дигәндә генә, язмыш аларны кабат аерды. Мәңгегә...

---

# «ТАНЫМЫШ» ДӘРЕСЕ

*Дәрес дәвам итә! Үткән «уку чирегендә» иң шәп җавапларны Зөлфия Әбүбәкерова, Саимә Ибраһимова, Наилә Вилданова һәм бигрәк тә Рушания Низамова җибәрделәр. Җавапларны эпиграмма рәвешендә бирү (Р.Низамова, З.Әбүбәкерова, З.Исламова) аеруча да куандырды.*




*Шаржларның авторы* — **Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

Туфан МИҢНУЛЛИН

## Их!

— Мин әле ул вакытта яшьрәк идем. Телевизор карап утырабыз. Арабызда җитмештән узган Заһри бабай да утыра. Телевизорда илаһым ла матур бер кыз җырлый. Син — үлсәң дә аның матурлыгын язып күрсәтә алмыйсың, Туфан, мин дә сөйләп бирә алмыйм. Җитмәсә тагын, күлмәгенең изү, түш турысы түгәрәкләп кисеп алынган. Шунда күз төшә бит, үтереш инде. Карадым да каттым инде телевизорга. Җырлап кына бетермәсә ярар иде дим. Төн буе, көн буе җырласын иде. Йокламый, эшкә бармый карап утырыр идем.

Заһри бабай да телевизорга кадалган. Дөньясын оныткан. Карап-карап тора да «Их!» дип куя. Арттырып әйтүем түгел, теге кыз җырлап бетергәнче, егерме-утыз тапкыр ихылдагандыр. Күләсене китерә, күләргә вакыт кына юк; күз, күңел — әлеге кызда.

Икенче җырчы чыккач, Заһри бабай бераз гына карап утырды да торып китте. Мина да кызык түгел монысы. Шунда күлүемне тыярга тырышып, Заһри бабайдан сорадым:

— Нишләп бик ихылдадың, Заһри бабай? — дидем.

— Ничек инде ихылдамыйсың, тешләрен күрмәдеңмени? — ди,— шунардагы тешләр миндә булса, ипи катысын җебетеп ашар идемме?.. — ди.

## Барыбер

Бер башкорт артистының малае рус мәктәбенең беренче классына укырга керә. Беренче көнне үк малай өенә җылап кайта.

— Нәмә булды? — дип сорый әтисе.

— Мине татарин дип үртиләр,— ди малай, мышкылдап.

— Ә һин иртәгә әйт уларга. Мин татарин түгел, башкир диген! — дип өйрәтеп җибәрә әтисе.

Икенче көнне тагын да ныграк җылап кайта малай.

— Нәмә булды инде тагын? — ди әтисе.

— Үртиләр, — ди малай.

— Мин өйрәткәнне әйттеңме һун?

— Әйттем... — ди малай. — Татарин, башкирин адин чурт дип көләләр!

Роберт МИҢНУЛЛИН

## Спектакльдән соң

Актаныш районының бер авылына Минзәлә театры килеп төшә. Артистлар Әхәт Гаффарның «Иртәгә улың булырмын» исемле әсәрен уйныйлар. Спектакльдән соң, ошап бетмәгән микән инде, бер апа сөйләнә-сөйләнә чыгып бара икән:

— Кичә бик начар төш күргән идем, шушы спектакльне карыйсыга булган икән...

### Язучы Камил Кәримовка

Камил Кәримне син инде
Әйбәт beләсең.

Концертта аны тыңласаң,
Көлеп үләсең.

Тик беркемнен дә үләсе
Килми, күрәсең.

Концертка килеп үләргә
Кем соң теләсен?

Шуна күрә беркем көлми,
Белеп үләсен!

### Шагыйрь Зиннур Мансуровка

Зиннур Мансур шигърияттә
Үсә зур тизлек белән.

Шигырьләрен яза Зиннур
Үзгә бер күзлек белән:

Хәтта аңларга да була...
Укысаң сүзлек белән.

### Шагыйрь Газинур Моратка

Евтушенкодан ким түгел
Сәхнәдә безнең Морат.
Евтуштай гына шагыйрьләр
Бездә дә бар ул, бырат!

**Госман ГОМӘР**

### Толстой кулы

Язучылар берлеге яшь авторларның семинарын оештырды. Анда мин дә чакырылдым. Шигырь-хикәясез генә. Тыңлап утырырсың, өйрәнә торырсың, диделәр.

Семинарда Нәкыя Гыймадиева (фамилиясе шулайрак истә калган) дигән авторның хикәяләрен бик мактадылар. Атилла Расих аларны «Лев Толстой кулы белән язылган» талантлы әсәрләр дип бәяләде.

Ниһаять, семинар тәмам. Коридорга чыктык. Яшь авторны әлерәк кенә Сталин лагерьларында булып кайткан элеккеге студент — Аяз Гыйләжев култыклап алды. Еллар узып, Аяз Гыйләжев — халык язучысы, Нәкыя ханым аның хәләл җефете булгач кына төшендем «Толстой кулы»ның кем кулы икәненә.

Юкәдә икән чикләвек!..

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

# 2015 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ**

2015 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №5

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Ибраһимов И. Рухыбыз сау безнең. №1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЯҢА ДӘҮЛӘТЧЕЛЕГЕНӘ — 25 ЕЛ**

«Республикабыз язмышы өчен үзебез җаваплы — мөстәкыйльлек менә шул инде ул» *(ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән Илфак Ибраһимов әңгәмәсе).* №8

Таһиров И. Автономиядән мөстәкыйльлеккә таба. №8

Чигенүме, җиңелүме? *(Р.Хәким, Р.Вәлиев, Ф.Сафиуллин, Д.Исхаков катнашында «түгәрәк өстәл»).* Р.Юныс әзерләде. №10

**ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ**

Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары, мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов белән Илфак Ибраһимов әңгәмәсе. №9

«Татар исән чакта аның язучылары да булачак» *(Зөлфәт Хәким белән Илфак Ибраһимов әңгәмәсе).* №1

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әхмәтгалиева А. Капка. *Хикәя.* №1

Габделхакова Р. Даладан килүче. Мөгез. Яңгырдан соң. *Хикәяләр.* №7

Зарипов Р. Үзгә юлда. *Хикәя.* №4

Имамов В. Сөләйман солтан. *Тарихи роман.* №№10-12

Камалов Х. Яңа шәһәрдә. *Бәян.* №1

Кәрами Р. Кая чабасың, гомер юртагы? *Роман.* №№8-10

Кәримов К. Тургайлы болытлар. *Роман-элегия.* №№ 2-3

Миңнуллин Т. Хат башы — яз каршы. *Бәян.* №8

Сәгъди Р. Мин дә бер татарыңдыр... *Документаль бәян.* №№1-2

Хәким З. Газап. *Бәян.* №12

Хәлим А. Паравыз кычкыртты. *Хикәя.* №2

Хәлим А. Ала-коладагы дүрт Иван. *Хикәя.* №9

Хәмзин А. Шамкай. *Бәян.* №11

Хәнифов Ш. Кеше булып калырга. *Әдәби-документаль бәян.* Тәрҗемәче һәм әдәби яктан эшкәртүче — Хуҗин Ф. №6-7

Хәсәнов Ә. Бәхет кайда оя кора. *Роман.* №6

Шәмси С. Ата белән ханбикә. *Тарихи хикәя.* №4

Юнысова А. Талисман. Курку. *Хикәяләр.* №10

**КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ**

Әдһәм Г. Меңнәрнең берсе. *Бәян.* №10

Әминов Н. Себер кунагы. *Бәян.* №4

Гарипова Х. Тозак. *Бәян.* №3

Даутов Г. Моңнар булып кайтырмын. *Документаль бәян.* №3

Зыялы С. Агулы теш. *Бәян.* №9

Мирһади Г. Төш. *Бәян.* №1

Хуҗин Ф. Без белмәгән сугыш. *Документаль бәян.* №5

Шәрифуллин Н. Ялгыз кеше язмалары. *Бәян.* №7

**ШИГЪРИЯТ**

Айзат Г. Тормыш бит ул — мизгел генә. *Шигырьләр.* №12

Аланлы Л. Тормыш — шундый... *Шигырьләр.* №7

Антым белән илне якладым *(А.Алиш, М.Җәлил, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, Х.Мөҗәй, Ш.Мөдәррис, З.Нури, С.Хәким шигырьләре).* №5

Әхмәдиев Н. Күпме тарих тузга язылган. *Шигырьләр.* №9

Әхмәтҗанова С. Арча сулары. *Лиро-эпик цикл.* №11

Әхтәмова Ж. Кешелекне ничек югалтмаска. *Шигырьләр.* №1

Бәшәр Р. Ачык күңел ишегем. *Шигырьләр.* №11

Булатова К. Җуелмаслык эзләр сакланыр. *Шигырьләр.* №3

Вәлиев Р. Җанны айкый сагыш бураны. *Шигырьләр.* №4

Галиев М. Су каргышы. *Шигырьләр.* №6

Гыйззәтуллина Ф. Илаһилык вә даһилык. *Шигъри дастан.* №12

Гыйләҗев И. Һәр милләтнең үз кыйбласы. *Шигырьләр.* №1

Гыйләҗев Ф. «Уян, милләт!» диеп көйли татар. *Шигырьләр.* №4

Дәрзаман Җ. Күңелләрдә булды яхшылык. *Шигырьләр.* №7

Җамал Р. Агымнарга ятып акмадым. *Шигырьләр.* №10

Җамалетдинова Ф. Һәм үзебез — тарих көзгесе. *Шигырьләр.* №3

Җиһангирова Ш. Түзә алмый җаным моңлыктан. *Шигырьләр.* №9

Зәйдулла Р. Дөньяда берни үзгәрми. *Шигырьләр.* №1

Зәйдулла Р. Хәтер көне. *Шигырь.* №10

Зыятдинов Ф. Әремнәрне мактап җырлармын. *Шигырьләр.* №10

Зыятдинова Ф. Тик яратып китик дөньядан. *Шигырьләр.* №10

Идиятуллин Р. Җир-туфрагым — җан бизәгем. *Шигырьләр.* №2

Исхаков Ә. Уйларым — йөрәк тибешем. *Шигырьләр.* №7

Мансуров З. Ямьнән аерылмый бер гамь дә. *Шигырьләр.* №4

Миңнуллин Т. Робагыйлар. *(М.Галиевнең кереш сүзе белән).* №8

Мирза М. Кысыр Гариф. *Поэма-кыйсса.* №6

Морат Г. Кош хокукы кирәк кешегә. *Шигырь.* №8

Мөхәммәтшин Г. Кояш чыга һәркөн саен иртән... *Робагыйлар.* №11

Мөхәммәтша Р. Җанга төшә авыр күләгәң. *Шигырьләр.* №12

Низами Р. «Әйе!» һәм «Юк!» *Публицистик цикл.* №11

Рәхим Г. Чал тарихны салган иненә. *Шигырьләр.* №7

Сафин Р. Вакыт көтә илдә таң атуын. *Шигырьләр.* №1

Сафин Ф. Тын суларга карап. *Сонет-такыя.* №4

Ситдыйкова Ә. Җырга-моңга тулы елларым. *Шигырьләр.* №4

Сөләйман Ж. Югалыр күк бу мизгел. *Шигырьләр.* №3

Суфиянов А. Чагылдырып чорның сурәтен. *Шигырьләр.* №10

Ул бит безнең күңел Туфаны *(Ш.Галиев, М.Әгъләмов, Г.Рәхим, Р.Миңнуллин, А.Юнысова, Ф.Тарханова, Л.Лерон, Р.Рахман, Л.Шәех, Ф.Гыйләҗев шигырьләре).* №8

Харис Р. Хәтерләтеп татар язмышын. *Шигырьләр.* №5

Шагыйрьҗан Л. Туган телең ул бит — могҗиза. *Шигырьләр.* №6

Шаһиева Р. Сукмагыңнан киттем — җыр булып. *Шигырьләр.* №9

Шәмсуаров Т. Куәт бирә Ватан җылысы. *Шигырьләр.* №7

Шәрипов Р. Үз бәясен алсын вакыйга. *Шигырьләр.* №2

Янсуар Л. Дөньяныкы үтәр — бездән дә... *Шигырьләр.* №3

Яши ул көн, яши һәм яшәр... *(Р.Вәлиев, Р.Мингалим, Р.Гаташ, М.Мирза, Г.Морат, Г.Әхтәмова, Ф.Тарханова, Л.Шәех, Л.Фәтхетдинова шигырьләре).* №5

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Миңнуллин Т. Әбрәкәй. *Комедия.* №8

Миңнуллин Т. Бетсен ирләр, яшәсен хатыннар. *Ике пәрдәле комедия.* №8

Миңнуллин Т. Го-о-о-ол! *Сатирик комедия.* №8

Салихов Д. Баязит. *Драма.* №4

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Вәлиев Р. Туфрактан яралган Тукай *(Т.Миңнуллинның гамәл дәфтәреннән кайбер сәхифәләр).* №8

Ибраһимов И. Мин белгән Туфан. №8

Сәгъди Р. Драматург-режиссёр. №8

«Шәймиев чоры татар тарихына кереп калачак» *(Туфан Миңнуллин белән Нурсөя Шәйдуллина әңгәмәсе).* №8

Шәфыйков Я. Рейхстагка җиңү байрагын беренче булып кем кадаган? №4

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Арсланов М. Туфан Миңнуллин драматургиясе. №8

Батулла Р. «Даладан килүче» хикәясе турында бер-ике сүз. №9

Батулла Р. Бер кәлимә, ике сүз. №11

Без тарихта эзлеме? *(Г.Арсланов, И.Заһидуллин, И.Ибраһимов, И.Рәмиева, Р.Ханнанов, З.Хәким, Ф.Хуҗин катнашында «түгәрәк өстәл»).* №11

Вәлиулла И. Шигъри мәйдан ни сөйли? *(2014 елда «Казан утлары»нда басылган шигъри әсәрләргә күзәту).* №5

Габделхакова Р. Батырша эзеннән. №7

Заман прозасында — чор сулышы *(Д.Заһидуллина, М.Вәли-Барҗылы, Г.Насыйбуллова, Л.Бәдертдинова, Г.Мансурова катнашында «түгәрәк өстәл»).* Р.Ханнанов әзерләде. №3

Низами Р. Поэма белән очрашу. №12

Хәбетдинова М. «Төш»тәге серләр *(Т.Миңнуллинның «Төш» спектакленнән соң уйланулар).* №8

Хәсәнова Ф. «Бар гаебең ихласлык булган, шагыйрь!» яки мулла мәхәббәте турында уйланулар. №11

Шәрәфиев Р. Бер китап тудырган күп уйлар. №11

Шәрипов Ә. Кешеләрең синең чын хәзинә. №7

Юсупова Н. Шигърият дөньясы: 2014 ел. №4

**ФӘН**

Бәширова И. Тукай төрек телендә язганмы?.. №4

Вәлиев Р. Еракка китеп карасаң... №7

Хәбетдинова М. «Алар бит безне ташлап киттеләр...» №5

Хәбипова З. Бер легенда эзеннән. №12

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. Сәхифәне Р. Мусабәкова әзерләде. №№2, 5

**ТАРИХ**

Гариф Н. Яр Чаллы түгел, Чаллы! №10

**СӘНГАТЬ**

Алмазова А. Фәрит Яруллин һәм аның даирәсе *(«Шүрәле» балеты куелуга 70 ел).* №3

Алмазова А. Татар музыкасын яңартучы *(Алмаз Монасыйповның тууына 90 ел).* №9

Арсланов М. Хуш, Хуҗа Насретдин! №4

Арслан Ф. Халкыбыз җәүһәрләре. №5

Зәйдулла Р. Директор *(Шамил Закировның тууына 70 ел).* №3

Гайнетдинова Д. Гамьле рәссам. №7

Насретдин хуҗа булган илдә *(Фәрит Бикчәнтәев белән Рабит Батулла әңгәмәсе).* №4

Рәхим Г. Ветераннар гимны ничек туды. №5

Сәгыйтова Г. Сәйдәш маршы, татар маршы... №1

Сәгыйтова Г. «Кара Пулат» серләре. №3

Югары сәнгатькә юл *(Казан дәүләт консерваториясе ректоры Рубин Абдуллин белән Илфак Ибраһимов әңгәмәсе).* №6

Яшәвенең гаме дә, яме дә — театр *(Наилә Гәрәева белән Гүзәл Сәгыйтова әңгәмәсе).* №11

**ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ**

Рахман Р. «Нинди дәрт бирлә каләм сызсам да...» №11

Рахман Р. Чын Тукай өчен көрәшеп... №№11-12

**ХӘТЕР**

Әхмәтгалиева А. Җыр дәвам итә. *Очерк.* №12

Мортазина М. Бар кадер Бәкердә. №7

Таһиров И. Гомеремнең чишмә башы — Шөгерем. №7

Фәйзуллин Р. Юксыну. №3

Хәйруллин И. Кабатланмас шәхес. №3

Хәмидуллин Л., Хәмидуллин Б. Җиңүләр җиңел бирелмәде. *Тарихи-публицистик язма.* №№6-7

Хәсән Ә. Безнең язмыш. *Истәлекләр.* №№4-5

Хуҗин Ф. Мәңгелек һәйкәл. №7

Шамова Ә. Сезнең язмыш сугыш уты белән уралгән. №№1-6

Юныс Р. «Әхмәт Гали, Гөлчәчәк Гали...» №4

Юныс Р. Сез һаман бергә икән?! №12

**100 НЧЕ БИТ**

Батулла Р. Тукай-Тукай, дибез... №4

Батулла Р. Халыклар арасында оятка калмыйк инде! №10

Бәдигый Х. Җәлил энциклопедиясен тәзик! №2

Борһанов Ә. Без тарихта эзлеме? №1

Имамов В. Яңа байларыбыз татармы? №11

Миңнуллин Т. Татарның әхлакый кодексы. №8

Морат Г. Музалар тын тормасын дисәк. №3

Морат Г. Балалар әдәбияты ник үги? №12

Рәхим Г. Беренчеләр. №7

Сафин Ф. Сугыш сөреме жанда утыра. №6

Сөләйман Ж. Кызыл Чишмә янә гөрли. №9

Юныс Р. Җинүнең көенечле катламнары. №5

### МӨГАЛЛИМ МӨНБӘРЕ

Гыйбадуллина З. Әхлак сагындагы шагыйрә. №10

Тимергалиева Э. Фоат Садриевның «Таң җиле» романында борынгы әдәбияттан килгән традицияләр. №1

### ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ

Лениногорск районы әдәби-иҗат берләшмәсе шагыйрьләре Гыйләҗев Н., Сәлманова Н., Бигҗанова Х., Әхмәтова Г. шигырьләре *(Р. Хәбибулланың кереш сүзе белән)*. №7

Сарман районы әдәби-иҗат берләшмәсе шагыйрьләре Әюпов Б., Гыйльфанова Р., Григорьева Ф., Големова Л., Ихсанова Э., Кәлимуллин Р., Минһаҗева Ә., Ногманова Ә., Әксәнова Г. шигырьләре *(Р.Кәлимуллинның кереш сүзе белән)*. №10

Удмуртия Язучылар берлегенең татар язучылары бүлеге әгъзалары Биектаулы И., Сафин Г., Баттал Р., Низамова Ә., Исхакова Г. шигырьләре *(Р.Батталовның кереш сүзе белән)*. №2

### КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Әхмәтов М. Тәсбих. №9

Ганиева Т. Моңаю бар күкнең үзендә дә. *Шигырьләр*. №9

Гөроглы. *Дастаннан өзек*. №9

Вәлиев М. Төркилектә төрле булсак та, бергә без... №9

Додуев Ә. Һәрбер кеше үз юлыннан бара. *Шигырьләр*. №9

Миңнегулов Х. Төрки сүз сәнгатенә бер караш. №9

Өмәруглы Я. Озату сые. Агылый белән Тагылый. Ике чынар. Ун доллар. *Хикәяләр*. №9

Солтанов О. Мизгелләр ага тиз сызып. *Шигырьләр*. №9

Сөләйман С. Берләшик Ватанда. *Шигырьләр*. №9

### ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Харис Р. «Җир шары рәисе» Велимир Хлебников *(тууына 130 ел тулу уңаеннан)*. №10

Хлебников В. *Шигырьләр*. №10

### ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Бикчурин Ш. Кайту. *Хикәя*. №7

Дәүли Н. Ату. *Хикәя*. №5

### БӨЕК ҖИҢҮГӘ — 70 ЕЛ

Әпсәләмов Г. «Совет әдәбияты» журналы турында солдат хатлары. №5

Биектаулы И. Милли каһарман генерал Хәсән Салихов. №5

Бөек Ватан сугышы. XXI гасырдан караш *(И.Ибраһимов, И.Гыйләҗев, А.Кәбирова, Ә.Галләмова, Ш.Мостафин, Р.Юныс, Х.Бәдигый катнашында «түгәрәк өстәл»)*. №5

Зарипов Р. Корпус командирлары. №5

Мостафин Ш. Әтием әманәте. №5

Мостафин Ш. Ядрәләрне эреткән йөрәк. №5

Шәфыйков Я. Йөрәк хәтере. №5

### ЮБИЛЕЙЛАР

#### РЕСПУБЛИКА МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНӘ 150 ЕЛ

Бәйрәмова Г. Милли китапханә: үткәне, бүгенгесе, киләчәге. №10

#### ХӘСӘН ТУФАННЫҢ ТУУЫНА 115 ЕЛ

Фазлетдинов И. Ике даһи дуслыгы. №12

Кәрим М. *Шигырьләр*. №12

Туфан Х. *Шигырьләр*. №12

#### «НУР» ГАЗЕТАСЫ ЧЫГА БАШЛАУГА 110 ЕЛ

Вәлиев М. Баязитов «Нур» гәзитен ничек язып өлгерткә? №10

#### ШӘЙХИ МАННУРНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Тулбай мончысы. №1

#### САЛИХ БАТТАЛНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Баттал Ф. «Күләгәдәге» Баттал. №11

#### ГАЛИ ХАЛИТНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Хатипов Ф. Галимнең әдәби-теоретик фикер дөньясы. №6

Сверигин Р. Остаз күрсәткән юлдан... №6

#### ГАРИФ АХУНОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Кәримов К. Арча кыры. №11

#### МӘГЪСУМ ХУҖИННЫҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ

Шәрәфиев Р. Остаз. №5

#### РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Вәлиев М. Каләм җиле. №4

Әхмәтҗанов Р. Шигырь иле. *Шигырьләр*. №4

ТУФАН МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Әюпов Р. Драматург-философ. №8

Бикчәнтәев Ф. «Үзен театр өчен жаваплы сизде...» №8

Галиев Р. Туфан күзлеге. №8

Зарипов Ә. Яшьнәп яшәгән яшьтәшем ядкаре. №8

Ибраһимов Ф. Театр дип яшәде... №8

Лоханов П. Якташыбызны яд итәбез. №8

Минаева Л. Әлмәт сәхнәсендә Туфан әсәрләре. №8

Миңнуллина-Юнысова Ә. Туфан кызы язмалары. №8

Мөслимова Ф. Энә түгел, китап! №8

Низами Р. Туфан дәвам итә. №8

Өмет хатлары *(Т.Миңнуллинның мәхбүсләр белән язышкан хатлары)*. №8

Ханнанов Р. Ничә Туфан бәхәсләшә аларда... №8

Ханов О. Сагындырасың, Туфан ага... №8

Шәймиев М. Туфан белән горурлану, ижатына соклану көчәя бара. №8

ЭДУАРД МОСТАФИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Морат Г. Күз калдырып китә кошлар... №1

Мостафин Э. Чит ярларда. *Шигырьләр*. №1

**БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ**

Абдулла Әхмәтнең тууына 110 ел. №3

Әдхәт Синугылның тууына 80 ел. №3

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

МАННУР САТТАРОВКА 95 ЯШЬ

Саттаров М. Ике бомба, теш һәм Изольда. №9

ИЛЬҺАМ ШАКИРОВКА 80 ЯШЬ

Бәйрәмова Г. Моң тажы. №2

Зәйдулла Р. Алпар. №2

Низамова Ф. Табыну. №2

Рәхим Г. Халкыбыз горурлыгы. №2

МӘДИНӘ МАЛИКОВАГА 80 ЯШЬ

Хисмәтова Л. Әсәрләрендә буыннар язмышы. №9

ВАКЫЙФ НУРУЛЛИНГА 80 ЯШЬ

Редакция котлавы. №6

ӘЗҺӘР ШАКИРОВКА 75 ЯШЬ

Зарипов Ә. Милләт жанлы артист. №2

Шакиров Ә. Әти. *Хикәя*. №2

МАНСУР ШИҺАПОВКА 75 ЯШЬ

Маликова М. Аның жырлары озын гомерле. №10

ЖӘУДӘТ ДӘРЗАМАНГА 70 ЯШЬ

Минһажева Л. Гашыйк күңел тибрәнеше... №10

ФӘУЗИЯ БӘЙРӘМОВАГА 65 ЯШЬ

Хисамов Н. Милләт гаме белән янып. №12.

ЖӘУДӘТ СӨЛӘЙМАНГА 60 ЯШЬ

Жамалетдинова Ф. Иңдә — жиһан. №3

ФИРҮЗӘ ЖАМАЛЕТДИНОВАГА 55 ЯШЬ

Габделхакова Р. Сафлыкка манылган әсәрләр. №3

ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕНӘ — 60 ЕЛ

Нурмөхәммәтов Р. Данлы үткәннәрдән — лаеклы киләчәккә! №7

Хөсәенов Р. Татарстан нефтенең туган жирендә. №7

**ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТЛАР**

Батулла Р. Укалы ижат. №4

Рахмани Р. Нәниләрнең үз шагыйре. №4

Шаһиев Р. Клара Булатованың «Күзге чор» ижатында фәлсәфи сыйфатлар. №4

**ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ**

Батулла. Мәгънә. №№1,3

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Гаташ Р. Бәшири «мырау»лап кына язганмы? Әдәбият елында мирасыбыз турында бер уйлану. №6

Мөслимова Ф. Сурәтләрдә — тарих... №6

Мөхәммәтжанова Л. Тарих булып дәшә Чура батыр. №9

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Васыйлова Г. Кем син, Хәмит абый? *Хикәя*. №5

Гайфуллина М. Йөрәгем яна. *Хикәя*. №10

**АК ЖИЛКӘН**

Абдрахманова А. Чана кайда? *Хикәя*. №6

Габдрахманова Р., Салахова А. *Шигырьләр*. №6

Гатауллин Р. Килмә якын. *Шигырьләр.* №2

Зарипов Х. Кеше батыр турында поэма. №5

Кутуй Г. Рөстәм мажаралары. *Бәян.* №№5, 6, 10

Нургатина А. Сынаулар. *Бәян.*

№1

Сафина Н. Кем казый? Сәнәгати сәнгать. *Балачак хатирәләре.*

№12

Сафина С. Төш. *Шигырь.* №1

Токранова Н. Яңа сулышым син. *Шигырь.* №1

Ханнанов Р. Тәүге карда ак эзләр... *Хикәя.* №3

Хикәя яза аласызмы? №№1-4, 6,10,12

**БУЛМЫШЛАР**

Вәлиев Р. Күктән төшкән бәхет. «Наполеон» коньягы. №1

**ИГЕЛЕК**

Баттал Ф. Яхшы гамәл заманы уздымы? №2

**ФИКЕР**

Шакиров Ә. Илдар Ханов. №1

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Әхмәтова Р. Җаным — шигырь, күңел — моң... *Шигырьләр.* №12

Вәлиев Р. Җанны айкый сагыш бураны. *Шигырьләр.* №4

Мөдәррисова З. *Хикәяләр.* №7

Тимербаева С. Күңелемне сагыш биләде. *Шигырьләр.* №12

**УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ**

Салихова З. Соңгы балкыш. *Хикәя.* №10

Фазлыева Н. Җимерек өмет. *Хикәя.* №1

**УКУЧЫ СҮЗЕ**

Кашапова Ә. «Казан утлары» яктысы. №6

**КАЙТАВАЗ**

Гәрәев Р. Киләчәккә төбәлгән әсәр. №1

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Уены-чыны бергә. *Сәхифәне М.Галиев әзерләде.* №№1-12

**МӘКАЛЬ ӨМӘСЕ**

*Сәхифәне Р.Юныс әзерләде.* №№1, 2, 4, 6, 11

2016 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. *А.Дубин әзерләде.* №12

«Танымыш» дәресе. №№2-6, 12

«Казан утлары» архивыннан. *Сәхифәне Р.Фәйзуллин әзерләде.* №№1-12

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1-12

Яңа китаплар. №№1, 2 , 10, 11

### МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ — КФУның ШӘРӘФЛЕ ДОКТОРЫ

Казан федераль университеты алдындагы казанышлары өчен Минтимер Шәймиевкә «КФУның шәрәфле докторы» дигән мактаулы исем бирелде. Бу хакта университет ректоры Илшат Гафуров халыкара фәнни совет утырышында игълан итте.

### МӘСКӘҮ КӨННӘРЕ

Татарстанда өч көн дәвамында Мәскәү көннәре барды. Казанга Мәскәү шәһәр Думасы рәисе Алексей Шапошников житәкчелегендәге рәсми делегация килгән иде. Башкала кунаклары арасында дәүләт эшлеклеләре, мәдәният һәм сәнгать әһелләре, хезмәтләре, иҗатлары белән танылган милләттәшләребез бар иде. Казанлылар хәтеренә бу көннәр Мәскәүнең рәсми делегацияләре һәм республика хөкүмәт вәкилләре катнашында үткәрелгән күп кенә мәдәни чаралар белән кереп калды.

Шуларның берсе — «Новый балет» Мәскәү дәүләт музыкаль театры В.Качалов исемендәге Казан академия Рус зур драма театры сәхнәсендә О.Уайльд әсәре буенча эшләнгән «Соловей и Роза» спектаклен куйды. «Хәзинә» Милли сәнгать галереясендә ачылган «Мастер и ученик» күргәзмәсе дә сәнгать сөючеләрдә кызыксыну уятты, анда Россия халык рәссамы Сергей Андрияка һәм аның шәкертләренең картиналарын күрергә мөмкин иде.

Программа кысаларында шулай ук Мәскәү янындагы сугышларда катнашкан ветераннар белән очрашулар, «түгәрәк өстәл» утырышлары, ирекле һәм грек-рим көрәше буенча иптәшләрчә көч сынашулар булып үтте.

Мәскәүлеләр Казаныбызга озак елларга истәлек булырлык, күңелгә бик тә ятышлы тагын бер бүләк калдырды. Ул — 2 нче Газовая урамындагы йортның олы юлга карап торган ягына татар халкының горурлыгы патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең зур итеп ясалган портреты һәм «Моабит дәфтәре»ннән татар һәм рус телләрендә язылган шигыре. Казанлылар граффити стилендә ясалган рәсемне, Универсиада проспектыннан узганда, көн саен күрә ала. Мәскәүнең мәдәният департаменты Татарстан башкаласындагы йортны бизәргә тиешле бу рәсемне күпсанлы граффити сурәтләр арасыннан сайлап алган. Рәсемнең авторлары — яшь рәссамнар Александр Емельянов белән Владислав Порвеев.

### КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

Казакъстанның Астана, Семипалатинск шәһәрләрендә — шагыйрь Абайның туына 170 ел тулуга, Хуҗа Әхмәд Ясәви исемендәге халыкара казакъ-төрек университетында (Төркестан каласы) төрки телләрне үстерүгә багышланган фәнни-гамәли конференцияләр булды. Соңгысы VI тюркологик конгресс кысаларында узды. Конференцияләрдә Казаннан КФУ профессоры Хатыйп Миңнегулов катнашты һәм докладлар белән чыгыш ясады.

***

Гаяз Исхакый истәлегенә багышланган «Төрки телле мәгълүмати мәйданда татар журналистикасының роле һәм урыны» дигән фәнни-гамәли конференция булды. Аны КФУның социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты һәм «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте үткәрделәр.

Конференциянең Тукай клубында узган пленар өлешен әлеге институтның гаммәви коммуникация бүлеге мөдире, профессор Васил Гарифуллин алып барды. Чыгыш ясадылар: филология һәм мәдәниятара бағланышлар институты профессоры Хатыйп Миңнегулов, Васил Гарифуллин үзе, Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре Фәния Гайнуллина, «Мәдәни җомга» газетасы баш мөхәррире Вахит Имамов. Төркиянең Анкарадагы Гази университеты доценты Фәрһат Тамирнең чыгышын телевизион күпер аша тыңладык. «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары Сөмбел Таишева да конференциядә фәнни темага чыгыш ясады («Татар журналларының формалашуында Гаяз Исхакыйның роле»). Пленар утырышка Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев йомгак ясады. Гаяз Исхакыйның тынгысыз милли рухы чыгышларда да, фикер алышуда да гел сизелеп торды.

Конференциянең секция өлеше Казан Федераль университетында үтте. Секция

утырышын Васил Гарифуллин һәм «Мәгариф» журналының баш мөхәррире Иллар Миргалимов алып бардылар.

### ЮБИЛЕЙЛАР

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында язучы-прозаик, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Сәҗидә Сөләйманова премиясе лауреаты Вакыйф Нуруллинга 80 яшь тулуга багышланган әдәби кичә булды. Кичәдә әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов сөйләде, бәйрәмдарның каләмдәшләре: әдәбият галиме, шагыйрь Нурмөхәммәт Хисамов, язучылар Марсель Галиев, Ркаил Зәйдулла һ.б. чыгыш ясады. В.Нуруллинны якташлары исеменнән Балык Бистәсе муниципаль районының мәгариф идарәсе җитәкчесе Илсур Садыйков, район газетасының баш мөхәррире, шагыйрь Вазыйх Фатыйхов котлады. Кичә дәвамында аның алып баручысы, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт юбиляр белән әңгәмә корды. Бу сөйләшү җыр-музыка, Вакыйф Нуруллин әсәрләреннән өзекләр уку белән үрелеп барды.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында Татарстанның халык язучысы, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гариф Ахуновның тууына 90 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе үткәрелде. Шушында ук Арчадагы «Казан арты» тарих-этнография, әдәбият һәм сәнгать музейлары тарафыннан әзерләнгән, Г.Ахуновның тормышын һәм иҗатын чагылдырган күргәзмәне карарга мөмкин иде. Кичәне Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт ачып җибәрде. РФ Дәүләт Думасы депутаты Фатыйх Сибагатуллин, язучылар Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Вахит Имамов, Лирон Хәмидуллин, Данил Салихов, Шәһинур Мостафин, Г.Ахуновның кызы, шагыйрә Наилә Ахунова һ.б. әдип турында истәлек-хатирәләрен уртаклаштылар. Кичәдә Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы буенча төшерелгән нәфис фильмнан, әсәрләре нигезендә куелган спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде, җырлар җырланды.

### «ИДЕЛЕМ АКЧАРЛАГЫ» БӘЙГЕСЕ

Республикада яшь язучыларның «Иделем акчарлагы» бәйгесе узды. Быел ул 15нче тапкыр үткәрелде. Аңа 100дән артык эш кабул ителде. Аларга Газинур Морат (жюри рәисе), Ләбиб Лерон, Илсөяр Иксанова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов бәя бирде. Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы Казандагы Г.Тукай музеенда булды. Быел шигърияттә Гран-прига лаеклы кеше табылмады. Прозада бу бүләкне Казандагы 7нче лицейның татар теле һәм әдәбияты укытучысы Алмаз Мансуров алды. Яшь шагыйрьләр арасында беренче урынны КФУ студенты Ләйлә Хәбибуллина, прозаиклардан шушы ук уку йортыннан Гөлүсә Шиһапова яулады.

### ТАТАР КИТАБЫ — КОНКУРСТА ҖИҢҮЧЕ

«Университетская книга — 2015» дип аталган Бөтенроссия конкурсына йомгак ясалды. Бу бәйгедә югары уку йортлары өчен чыгарылган 1000нән артык басма тәкъдим ителде. КФУ профессоры Хатыйп Миннегуловның 2014 елда рус һәм татар телләрендә чыккан «Восточная классика и татарская литература» дип аталган укуукыту әсбабы (Казан, «Яз» нәшрияты) 25 иң яхшы хезмәт исемлегенә кертелде. «Высокая культура издания учебных книг» номинациясендә җиңүче дип табылды һәм махсус диплом белән бүләкләнде.

### ОЧРАШУЛАР

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирза), аның урынбасары Рамил Ханнанов, бүлек мөхәррирләре Камил Кәримов, Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, Чаллы шәһәренең 29нчы гимназиясендә каланың 60лап мәктәп-гимназияләреннән җыелган татар теле, әдәбияты укытучылары, яшь иҗатчылар белән очраштылар, мастер-класслар үткәрделәр. Әдәби очрашу Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институтында да булды.

***

Арча районы Өчиле авылы мәдәният йортында «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе Вакыйф Нуриев белән очрашу булды. Җирле үзидарә җитәкчеләре, китапханә һәм мәдәният йорты хезмәткәрләре тарафыннан оештырылган бу чарада сүз журнал, анда басылган һәм басылачак әсәрләр, язмалар турында да барды.

2015 елның 18 ноябрендә 77нче яшендә озак еллар «Казан утлары» журналы редакциясенең баш хисапчысы булып эшләгән **Рәхимова Асия Гомәр кызы** вафат булды.

2015 елның 23 ноябрендә 84нче яшендә Татарстан Республикасының халык артисты **Бәһманов Ирек Вәли улы** вафат булды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: исторический роман В.ИМАМОВА «Сулейман султан»; повесть З.ХАКИМА «Боль»; дастан Ф.Гиззатуллиной; стихи Р.МУХАМЕТШИНА, Г.АЙЗАТА;
«100-я страница»: Г.МУРАТ. «Не осиротела ли детская литература?»
«Наши юбиляры»: статья И.ФАЗЛУТДИНОВА «Дружба двух гениев», стихи М.КАРИМА, Х.ТУФАНА; статья Н.ХИСАМОВА «Горюя за судьбу нации».
«Литературная критика»: Р.НИЗАМИ. «Встреча» с поэмой».
«Наука»: З.ХАБИПОВА. «По следам одной легенды».
«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.РАХМАН.
«Новые имена»: стихи С.ТИМЕРБАЕВОЙ, Р.АХМЕТОВОЙ.
«Память»: очерк А.АХМЕТГАЛИЕВОЙ «Жизнь продолжается...»;
Р.ЮНУС. «Вы всё вдвоём?!».
«Белый парус»: Воспоминания детства Н.САФИНОЙ.
«Узнавайка».
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
Из фотоархива журнала.
Библиографический список произведений, опубликованных в 2015 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Зимний пейзаж. *Работа Айрата Гайфуллина*;
парк перед Дворцом земледельцев в Казани.

# IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: historical novel by V.IMAMOV «Suleiman Sultan»; novel by Z.KHAKIM «Pain»; dastan by F.GIZZATULLINA, poems by R.MUHAMETSHIN, G.AYZAT;
«100th page»: G.MURAT. «Is not orphaned children's literature?»
«Our heroes of the day»: article by I.FASLUTDINOV «Friendship of two geniuses», poems by M.KARIM, H.TUFAN; article by N.HISAMOV «Grieving for the fate of the nation».
«Literary Criticism»: R.NIZAMI. «Meeting» with the poem».
«Science»: Z.HABIPOVA. «On the trail of a legend».
«Tukay and Tatar literature»: section is led by R.RAHMAN.
«New names»: poems by S.TIMERBAEVA, R.AHMETOVA.
«Memory»: A.AHMETGALIEVA. «Life goes on...»; R.YUNUS. «Are you still together?!».
«White Sail»: Childhood memories by N.SAFINA.
«Find it out».
«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.
From photo archives of the magazine.
Bibliographic list of works published in 2015.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Winter landscape. Work by Ayrat Gaifullin;
the Square at the Farmers's Palace in Kazan.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Кышкы пейзаж. *Рәссам Айрат Гайфуллин эше.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Казандагы Игенчеләр сарае каршындагы парк.

# Газета-журналга язылган өчен iPad!

**1 Языл**
30.12.2015 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

**2 Җибәр**
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

**3 От**
Айпад, фотоаппарат һ.б. бүләкләр отарга ашык!







Акцияне үткәрү вакыты: 01.11.2015 — 10.03.2016

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 өстәмә номер - 1261

16+
Реклама

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2015
Парклар һәм
Скверлар елы



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)